www.kazanutlary.ru

# КАЗАН УТЛАРЫ

*ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ*

*1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА*

Бу санда

БАШ МӨХӘРРИР СҮЗЕ

Илфак ИБРАҺИМОВ. Яңа елның яңа әдәби бизәкләре. ....4

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Разил ВӘЛИЕВ. Яңа елның яңа таңы ата... *Шигырь*. ....3

Рабит БАТУЛЛА. Илбашы. *Татарстан Республикасының Беренче Президенты, татар халкының олуг шәхесе Минтимер Шәймиев турында хикәяләр*. ....10

Айдар ХӘЛИМ. Син милләтне иттең Тукайлы. *Шигырьләр*. ....66

Марсель ГАЛИЕВ. Тимә, яшәсен! *Роман-новелла.* ....72

Рафис КОРБАН. Килә җырлар язып калдырасы. *Шигырьләр*. ....127

Хисаметдин ИСМӘГЫЙЛЕВ. Исәр. *Хикәя*. ....131

Рүзәл МӨХӘММӘТША. Догада кузгалырбыз... *Шигырьләр*. ....146

*100нче бит:* Газинур МОРАТ. Миңкәйдән — Бабайгача. ....100

ЯҢА ИСЕМНӘР

Ландыш ГАБДРАХМАНОВА. Өметтән нәзек җеп эрләдем. *Шигырьләр*. ....152

ЮБИЛЕЙЛАР

Факил САФИН. Зөлфәтлек *(Зөлфәтнең туууына 70 ел)*. ....155

ЗӨЛФӘТ. Томырылдым тирән үткелгә мин... *Шигырьләр*. ....161

Рифат СВЕРИГИН. Кыйблага кайту *(Айдар Хәлимгә 75 яшь)*. ....164

Ләйсән ГАЛИЕВА. Уртак хаклык *(Разил Вәлиевкә 70 яшь)*. ....170

ГАМЬЛЕ ӘҢГӘМӘ

Тарих һәм заман *(тарих фәннәре докторы Дамир ИСХАКОВ белән Рәфикъ ЮНЫС әңгәмәсе)*. ....174

ТУКАЙ ҺӘМ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ

Рифә РАХМАН. Ачы тәҗрибә авазы: Мөхәммәт Мәһдиев. ....180

ЮБИЛЕЙГА БАРЫШЛЫЙ

Мирсәй ӘМИР. Игътибар җитми! ....183

Хикәя яза аласызмы? ....185

ПЕЧӘН БАЗАРЫ

Рәниф ШӘРИПОВ. Сары йортка әтәч килә. *Хикәя*. ....188

«Казан утлары» архивыннан. ....150

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ....190

Гамәлгә куючы –
«Татмедиа»
акционерлык
җәмгыяте

*БАШ МӨХӘРРИР –*

**Илфак Мирза улы**
**ИБРАҺИМОВ**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Рәдиф Җамалетдинов**
**Айрат Зарипов**
**Дания Заһидуллина**
**Дамир Исхаков**
**Зиннур Мансуров**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Вакыйф Нуриев**
*(җаваплы сәркатип)*
**Данил Салихов**
**Айрат Сибагатуллин**
**Энгель Фәттахов**
**Равил Фәйзуллин**
**Рамил Ханнанов**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Рәфикъ Юныс**

---

*Мөхәррирләр:* **Айгөл Әхмәтгалиева, Гөлзадә Бәйрәмова, Фәнил Гыйләҗев, Камил Кәримов, Рәфикъ Юныс.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Рәзилә Хәйретдинова, Наил Кадыйров.**

*Исәп-хисап бүлеге:* **Эльвира Камалова** (баш бухгалтер).

---

✉✉: Редакция һәм нәшер адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Баш мөхәррир – 222-05-50 (өст. 1618).*
*Баш мөхәррир урынбасары – 222-09-83 (өст.1612).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге – 222-09-83 (өст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге – 222-09-80 (өст.1268).*
: **Факс** – (843) *222-09-83 (өст.1612).*

: **E-mail:** kazanutlari@yandex.ru

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

---

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 29.12.2016, график буенча 29.12.2016.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108$^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ М-3393. Тираж 5250.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2011 елның 23 мартында теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-44362.
Индекслар: 73210, П2365 (физик затлар өчен), 16262, П2368 (юридик затлар өчен). Бәясе иркле.

---

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2017 ел

Разил
Вәлиев

# ЯҢА ЕЛНЫҢ ЯҢА ТАҢЫ АТА...

Уза еллар аккан сулар кебек,
Алдагысы – гүя яңа елга...
Ә елгалар бүген боз астында,
Ташып агар язын Яңа елда.

Яңа елда ак бураннар дулар,
Кар астыннан калкыр умырзая.
Яңа елда җанда сорау туа:
«Үтмәгәнме гомер, – диеп, – зая?»

Язмыш елгасына башын салып,
Ага еллар, ага дәрьяларга.
Яңа елда хыяллана кеше, –
Яши башлар сыман өр-яңадан.

Яңа елда, могҗизалар көтеп,
Оран салам сезгә, карабайлар! –
Яңа елда, бәлки, берәрегез
Милләт зарын илдә бер абайлар...

Яңа елның яңа таңы ата, –
Йоклаганнар кайчан уянырлар?
Кайчан узар салкын урыс кышы?
Милли булыр кайчан милли-онерлар?

Киләсе ел – гүя, өмет тулып,
Ага торган шаулы яңа елга.
Шул елгада коенырга язсын
Һәммәбезгә Яңа килгән елда!

# ЯҢА ЕЛНЫҢ ЯҢА ӘДӘБИ БИЗӘКЛӘРЕ



Яңа елның беренче көненнән, кырда-урамда кар яуса да, яки буран дуласа да, аязып, кырлачның зәмһәрире зәңгәр пәрдәсен элеп торса да, күңелләребез табигатьнең өр-яңадан тууына, яңарышына йөз тотканын сиземли булыр. Елның беренче атнасында якты көн бер минутка, аннан киләсе атналарда бишәр минутка озая. Икенче ае урталарында, кырлач чигенүгә, бөреләр керфегенә шәмәхә төс куна башлый. Тагын ике-өч атнадан көн белән төн тәгаен тигезләшә. Аннары тәүге тамчылар... Аннары карга, сыерчык бураннары... Инешләре, иделләрендә бозлар актарылып ташый да, оҗмах яшеллегенә төренгән болынкырлар – сандугачлар, ак болытлы аяз күк тургайлар хөкемендә кала... Аннары Сабантуйларына кадәрге вакытны саный башлыйбыз... Ел да шулай кабатлана.

Ел фасылларының көн белән төн озынлыгына бәйле үзгәрешләре табигатьнең үзе булып кабул ителә... Һәр тереклек, һәр үсемлек шул табигыйлеккә яраклашып үзенең яшәү дөньясын булдыра... Туа, үсә, өлкәнәя... тагын туа, тагын өлкәнәя... тагын... тагын...

Инеш, иделләрдә бозлар актарылып ташыганда, ярларында эзләре кала. Узып киткән елның да вакыт ярларында эзләре язылып калды. Татар халкы өчен пәйгамбәр шагыйрь Габдулла Тукайның тууына 130 ел тулу белән аеруча истәлекле ул... «Уртак Ватанда хакыбыз шактый ук», – дип язган шагыйребезнең бу юллары бүген: «Уртак йортыбыз Җир шарында безнең дә Хак Тәгалә билгеләгән урыныбыз, үзебез булып яшәргә хакыбыз бар!» – дип тә яңгырый.

Узган елда тарихи Болгар шәһәрендә нигез ташлары салынган Рәсәй Ислам академиясе бинасы быел төзелеп сафка басачак, булачак руханиларыбызга ишекләрен ачачак... Ул югары дини мәгариф үзәге Хак динебезнең сафлыгын, хилафсызлыгын саклауда дөньякүләм әһәмияткә ия булыр... «Саклангынны саклармын», дигән Бөек Иҗатчыбыз кешелек алдына куйган иң җаваплы сынауларны үтү вакытларын кичерә бүгенге дөнья... Кешелек үзе яратылган, Хак динебез иңдерелгән җирләрдә җаһиллекнең коточкыч гарасаты купты. Дөньялыкта ганимәт малы бәрабәренә көн итүне яшәү мәгънәсе иткән кавемнәр, дәүләтләр, иблис ихтыярына бирелеп, бөтен хокукый һәм әхлакый чикләрне җимереп, кешелеккә куәтле яу ачтылар... Бу даулы яуларны бөек Рух – Иман гына, мәгърифәтле инану гына чигендерә алачак та...

Узып киткән ел республикабызда сулыкларны саклау елы булып та язылды үзенең елъязмасына. Глобаль дөньяның глобаль проблемалары бихисап... Алар арасында иң әһәмиятлесе, санаулы еллар үтүгә, бөтен кешелек алдына килеп баса торганы – эчәр су проблемасы булачак дип кисәтә экологлар... Җир шары климатының нибары бер градуска гына җылынуы да табигый су чыганакларын

киптерәчәк икән. Котып бозлары эреп, дөнья океаннары җәелеп, дистәләрчә мең чакрымнарда коры җирне тозлы су басып китүе, мәңгелек туң җирләренең эреп сазлыкка әверелүе җирнең географик картасын да, экологияне дә танымаслык итеп үзгәртәчәк икән... Бүгенге глобаль дөньяда углеводород энергетика чыганаклары өчен даулы яулар алып барыла, алдагы унъеллыкларда, бер Аллаһы үзе саклый күрсен, бер йотым эчәр су өчен кан коюлар башланмагае, дип кисәтә безне сәясәтчеләр, галимнәр һәм көрәшчеләр.

Узган ел Россия күләмендә иң мул иген уңышы җыеп алынган ел булып та тарихка кереп калды әле. Игенчелек өчен табигый шартларның бик уңайлы төбәктә булмавына карамастан, менә дистә елга якын татарстанлылар Кубань, Ростов өлкәләрендәгедәй мул иген үстерергә омтыла. Шунысы игътибарга лаек: урып-җыю эшләре югалтуларсыз, зур оешканлык белән башкарыла бездә. Ил халкының яшәү сыйфатын эзлекле яхшыртуга йөз тотканда, боларның барысы да хәлиткеч әһәмияткә ия, әлбәттә.

Уртак Ватанда эзле булу, хакыйкый хокуклы булу һәрдаим практик гамәлләр белән нигезләнеп, ныгытып торуны таләп итә. Бу яктан караганда, Татарстанның ил икътисадын ныгытуга керткән өлеше һәркем танырлык саллы булуын дәвам итә. Бу республикабыздагы барлык сәнәгать төрләренең тотрыклы эшчәнлегендә чагыла. Татарстан инвестицияләр кертү, дөньякүләм интеграцияләр җәһәтеннән гел алдан бара. Фән казанышларын кулланышка кертүдә, барлык өлкәләрдә инновация проектлары тәкъдим итүдә аерылып тора. Менә шундый глобаль мәсьәләләрне хәл иткәндә, милли республика буларак, үз этник мәдәнияте, мәгарифен үстерү мәсьәләләре дә читкә этәрмичә алып барыла бездә...

Милли мәсьәлә, милләтләр мәнфәгате... Кайчандыр бу мәсьәлә тугандаш, дус халыклар гаиләсе СССРда тулысынча хәл ителгән, дип белдерелгән иде. Чыннан да, милли республикаларда милли мәктәпләр проблема буларак күтәрелми дә кебек иде. Мәктәптә үз ана телендә белем алу табигыйдән табигыйрәк хәл кебек иде. Баксаң, ул чор-дәвердә дә бу проблемалар шактый кискен булган икән бит. Алар милли мәгариф проблемасы буларак түгел, ә авыл белән шәһәр проблемасы буларак каралган, күрәсең... Шәһәр – димәк, бу, барлык яшәү-көн итү, белем алу, аралашуда милли компонентлар тәмам фәкыйрьләнеп беткән дигән сүз.

Инде СССР дәүләте таркалды. Ә милләт проблемалары куерганнан-куера гына бара. Элекке бердәм, куәтле илдә бер гаиләдә көн иткән халыклар арасында каршылыклар килеп чыга. Гәрчә, халыклар арасында каршылыклар чыкмый, ул каршылыкларны китереп чыгаралар дисәләр дә, гасырлардан гасырларга: «Иң бөек максатыбыз – хөр мәмләкәт», – дип яшәгән халыкларның омтылышын да инкарь итеп булмый шул.

Татар халкының үз дәүләтчелеген – хөр мәмләкәтен булдыру юлында соңгы чирек гасыр дәвамында алып барган бердәм омтылышы, көрәше нәтиҗәсендә дөнья җәмәгатьчелеге тарафыннан «Татарстан феномены» дип бәяләнгән дәүләт бердәмлеге барлыкка килде.

«Татарстан феномены» бәяләмәсенең күп билгеләре бардыр. Әмма иң мөһиме, дөнья җәмәгатьчелеген җәлеп иткәне ул – Татарстан Республикасында милли мәсьәләләрне көйләп торуның үрнәк нәтиҗәләренә ирешүедер.

Бүген куәтле, байлыкка баткан ил-дәүләтләрдә дә милләтләр, конфессияләр арасында хәлләр киеренкелеге үзен гел сиздереп тора. Татарстандагы тотрыклы татулыкның асылы нидә соң? Бу сорауга татар халкының мәкаль-әйтемнәрендә төпле җаваплар бар... «Күрше хакы – Тәңре хакы!» дигәненә игътибар итик... Адәм баласы кайда гына туып, кайда гына яшәмәсен, аның янәшәсендә һәрчакта

кемдер яшәячәк, гомер итәчәк. Ул «кемдер» дә Аллаһының колы, аңа да җанны Аллаһы иңдергән. Җан биргәнгә җүнен биреп, бу дөньяда яшәргә хокук биргән. Ул инсанның да бу җирдә яшәргә тулы хокукы бар, хакы бар! Аллаһы бүләк иткән хакы! Күршелек, янәшәлек – ул Хак ихтыяры, Адәм балалары шуңар дучар ителгән. Милли мәсьәләләрдә табигый гаделлекнең төп асылы шулдыр ласа!

Күп милләтле ил-дәүләтләрдә «күрше хакын хаклау» максатында Федератив дәүләт төзелешен булдыру – кешелекнең иң олы казанышыдыр, мөгаен! Татарстан Республикасының яңа тарихы үсешенә караган чирек гасырда аның зирәк җитәкчеләре Федератив дәүләт төзелешен алга сөрделәр. Ул татар халкының олуг максаты – мөстәкыйль хөр мәмләкәтен кору өчен дә, үзе белән янәшәдәге күп халык-милләтләрнең хөрлеге өчен дә, шул милләтләр-халыкларны бер түбә астына туплаган Рәсәй дәүләтенең хөрлеге өчен дә бердәнбер кулай юл бит! Татарстан үз мәмләкәтендә барлык милләт вәкилләре өчен үз этник мәдәниятен, гореф-гадәтләрен, иң мөһиме – Ана телләрен саклау, үстерү өчен реаль алшартлар булдыра алуы белән һәркемгә үрнәк, феноменаль күренеш булып бәяләнде. Шунысы игътибарга лаек: Татарстандагы милләтара, конфессияләр арасындагы тотрыклылыкка татар халкының, аның зыялылары – галимнәре, иҗатчыларының көндәлек тырышлыгы, иҗтиһат итүе белән дә ирешелә... Бу изге эштә быел үзенең 95 еллыгын билгеләп үтәчәк «Казан утлары» журналы, аның дистәләрчә авторлары, күпсанлы укучыларының да лаеклы өлеше бар... Соңгы елларда журналыбызда халкыбызның дәүләтчелеге тарихы, милли каһарманнарыбызга багышланган эпик әсәрләр белән бергә бүгенге яшәешебезне, замандашларыбызның әдәби образларын чагылдыручы әсәрләр дә күпләп күренә башлады. Әдәбиятчыларыбыз үзләренең төп миссиясе – мәгърифәтле, әдәпле әдәбият аша халкыбызның рухын күтәрү, аны киләчәккә ышанычлы өметтә яшәүгә туплау миссиясен үтәүгә чын-чынлап алындылар... Журналыбызның ике ел рәттән Бөтенроссия күләмендә оештырылган «Многоликая Россия» конкурсында җиңүче булып танылуы моңа бер мисал.

Бу җөмләдән республикабыздагы әдәби басмаларның турыдан-туры әдәби процессны оештыру эшчәнлеген дә аерып күрсәтү зарур. Бер елда гына да халык шагыйре Зиннур Мансуров тарафыннан «Тукайча татар кодексы» дип исемләнгән фәнни, әйтергә кирәк, монографик эчтәлеккә һәм тәэсирле көчкә ия, бөтен татар халкы өчен манифест булырдай әсәр язылып дөньяга таралды... Дөньяга бөек Тукайны тудырган шагыйрь әнкәсе – Бибимәмдүдәнең катлаулы язмышына багышлап, язучы Марат Әмирханов тарафыннан югары кимәлдәге әдәби әсәр язылып, журналыбызда нәшер ителде. Күренекле әдипләребез Фоат Садриев, Марсель Галиев, Вахит Имамов, Данил Салихов өр-яңа романнарын «Казан утлары» аша үз укучыларына җиткерделәр. Чиләбедә яшәп, рус телендә иҗат итүче милләттәшебез Рөстәм Вәлиевнең «Дөнья гаме» (Г.Тукайның тормыш юлына багышланган) романын яшь галим һәм прозаик Рөстәм Галиуллин тәрҗемәсендә журналыбызда бастырып чыгардык...

Милләтпәрвәр язучыбыз, тарихчы-галимә Фәүзия Бәйрәмова миллият темасын милли каһарманнарыбызга багышланган роман-бәяннары аша эзлекле төстә яктыртып килә. Аның Һади Атласиның тормышы һәм сәяси эшчәнлегенә багышланган «Соңгы туранчы» исемле документаль әсәре иң югары бәяләмәләргә лаеклы хезмәт!

Кереш сүз кысаларында бөтен әдәби процесска бәя биреп бетереп булмый. Санап үткән мисалларда милли әдәбиятыбызның бүгенге үсеше процессын иң олы роман жанры аша күрсәттек. Тукайлы әдәбият елы шагыйрьләребезнең

актив иҗаты белән узды. Журналыбыз битләрендә Р.Фәйзуллин, Р.Харис, Р.Гаташ, Г.Рәхим, К.Булатова, Ф.Гыйззәтуллина, Р.Вәлиев, Р.Миңнуллин, А.Хәлим, Р.Зәйдулла, М.Мирза, Г.Морат, Җ.Сөләйман, Р.Бәшәр, Л.Лерон, Ф.Сафин, Ф.Мөслимова, И.Ихсанова, Л.Шәех – барысы 100дән артык шагыйрьләребезнең өр-яңа поэма-шигырьләре басылып чыкты.

Рәсәйнең төрле төбәкләрендә яшәп иҗат итүчеләрнең активлыгы, журналыбыз белән бәйләнышлары ныгый бара. Иң мөһиме – яшь иҗатчыларыбызның әдәби өлгергәнлек чалымнарын күрү өметләр уята.

Әйткәнебезчә, әдәби процесс агышы журналыбызның алдагы саннарында жанрлары буенча галимнәр тарафыннан тирәнтен анализланып сезгә җиткерелер, хөрмәтле укучыларыбыз. Бу уңайдан барыгызны да әлеге процесста катнашырга чакырып калабыз. Фикерләрегезне әйтеп, хатларыгызны электрон почта аша безгә юллагыз.

Инде сезне басылачак өр-яңа әсәрләр – яңа елның яңа әдәби бизәкләре белән дә таныштырып, кызыктырып алыйк...

Укучыларыбызга Ф.Садриев, В.Имамов, А.Хәлим, Н.Гыйматдинова, З.Хәким, Ф.Бәйрәмова, М.Әмирханов, Р.Рахман, К.Кәримов, В.Нуриев, Р.Сәгъди, Н.Хәсәнов, А.Хәсәнов, Ф.Сафин, А.Әхмәтгалиева, Х.Ибраһимов һ.б. әдипләребезнең дистәләрчә өр-яңа бәян-хикәяләре, шагыйрьләребезнең өр-яңа поэмалары, шигырьләре тәкъдим ителәчәк.

Яңа елның иң беренче саны халык язучысы Рабит Батулланың «Илбашы» дип исемләнгән әсәре белән башланып китә. Әсәрнең исеме үк җисеменең эчтәлеген җиткерә булыр. Ул – халкыбызның асыл улы, Татар халкының дәүләтчелеге үсеше тарихында җуелмас эз калдырган, Татарстан Республикасының чирек гасыр дәвамында берөзлексез җитәкчесе булып хезмәт иткән, бөтен татар иленең милли әйдәре – Илбашы булып танылган Минтимер Шәрип улы Шәймиевнең тормыш юлы һәм иҗтимагый-сәяси эшчәнлегенә багышланган беренче әдәби әсәр.

Әйе, милли әдәбиятыбызда Татарстан Республикасының Беренче Президенты Минтимер Шәрип улы Шәймиевнең әдәби образын тудыру – бүген өлгергән мәсьәлә. Илбашына багышлап моңарчы язылган очерклар, шигъри әсәрләр, җырлар аның әдәби образын тудыруда билгеле этаплар булып тора. Бигрәк тә очеркларда аның шәхесенә генә хас сыйфатларны анык күрсәтү, аның психологик портретын шәрехләү, кешелеклелек сыйфатларын чагылдыру җәһәтеннән дистәләрчә уңышлы язмалар дөньяга чыкты. Ил күләмендә һәм Татарстанда булып үткән кантарлы вакыйгаларга бәйләп, Илбашының эчке кичерешләре, хезмәттәшләренә, гомумән, кешеләргә карата булган мөнәсәбәтләре шактый тулы яктыртылды.

Илбашы турында эпик әдәби әсәр язарга халык язучысы Рабит Батулланың барысыннан да өлгеррәк булып алынуы аңлашыла да. Беренчедән, Батулла – Илбашының замандашы, ул татар иле-көнендә барган бөтен вакыйгаларны күзәтүче әдип кенә түгел, ә шул вакыйгалар эчендә үзе үк турыдан-туры катнашкан милләтпәрвәр көрәшчебез дә бит әле. Ул – мәйданнарда ялкынлы чыгышлары белән милләттәшләрнең аң-зиһенен уяткан оратор, радио, телевидение, матбугат аша дистәләрчә, йөзләрчә кат чыгыш ясаган мәгърифәтче. Икенчедән, Рабит Батулла – үзенең иҗат гомерендә тарихи шәхесләргә багышланган «Сөембикә», «Кылдан нечкә, кылычтан үткен», «Кәбир Бәкер», «Аксак Тимер», «Тукай-Апуш», «Бию җене кагылган егет» романнарын, дистәләрчә киносценарийлар, сәхнә әсәрләре язган тәҗрибәле, киң колачлы язучы. Р.Батулланың «Урыннары җәннәттә булсын» дигән, милли каһарманнарыбызга багышланган очерклары,

хикәятләре тупланмасы үзе дүрт томлы. Бер сүз белән әйткәндә, зур иҗат тәҗрибәсенә ия була торып, «Илбашы» романын язарга нәкъ менә Рабит Батулла алынмаса, гаҗәп тоелыр иде.

«Илбашы» әсәренең ике үзенчәлеген билгеләп үтү зарур. Автор әдәби каһарманы образының никадәр олы булуын һәм аңа мөнәсәбәтле вакыйгаларны тулысынча колачлау мөмкин түгеллеген анык белә. Шуңа да карамастан, ул үз каһарманының дөньяга килүеннән алып бүгенге көнгәчә тормыш юлын эзлекле рәвештә хикәяләп барудан чигенми. Менә шул хикәяләү ысулы, стиле аңа документаль-нәфис жанрдагы эпик әсәрне иҗат итәргә ярдәм итә дә. Шундый 74 хикәя тупланмасындагы әсәр бердәм сюжет аша бербөтенлеккә ия роман булып кабул ителә, эпик жанр таләпләре югарылыгындагы, ил-көндә тулы бер гасыр дәвамында барган вакыйгаларны колачлый алар. Әдәби каһарманнарның нәсел-нәсәпләрен, язмышларына бәйле фактларны җентекләп, тирәнтен өйрәнгән автор. Илбашының һәм булачак гомер юлдашы Сәкинә ханымның ерак бабалары, нәсел-тамырларын барлаганда, һәр ике нәселнең төрле дәрәҗәдә репрессиягә эләгүләрен, тормыш университетларын бик яшьли үтүләрен, шул катлаулы чорны бөтен дөреслеге белән тасвирлый ул. Әсәрдә милли татар гаиләсе традицияләре, йолалары, өлкәннәр-балалар, ир-хатын мөнәсәбәтләре үрнәкләре хикәятләр булып та, аерым вакыйгаларда каһарманнарның үзара гамәлләрендә дә чагылыш таба.

Әсәрдә тупланган хикәятләрнең бер өлеше әдәби каһарманыбызның ил-көндә яшәү өчен көрәшүче, социаль җитлегү юлын үтүче үсмер, ир-егет, гаилә башлыгы буларак тормыш юлына багышланса, бер өлеше аның ил-көндә берсеннән-берсе җаваплырак дәүләти вазифалар башкаручы ир-атның тарихи шәхес буларак үсеш эволюциясе кебек кабул ителә. Бу хикәятләрдә тормышның һәр коллизиясенә ирләрчә җаваплы, аек акыл белән карарга өйрәнгән мөстәкыйль фикер йөртүче сәясәтче, Илбашы образы гәүдәләнә.

Илбашындагы гаделлек күпбалалы гаиләдәге тәрбиядән килә. Автор әйткәнчә, ишле гаиләдә «син тәртипле бул, син намуслы бул», дип вәгазьләүдән бигрәк, «менә сиңа шундый эш, син шуны башкарып чык», дип вазифа куеп җаваплылыкка өйрәтәләр. Ишле гаиләдә олыны – олы, кечене кече итү, туганлыкның иң изге әманәт булуы канга сеңдерелә. Табында өлешнең тигез салынуы, күмәк хезмәт күнекмәләре һәм шәхси үрнәк – болар барысы да дәүләтнең бер «күзәнәге» булган гаиләнең өстенлекле тәрбиясе. Гаиләдә тугызынчы бала булып туган Минтимер гаилә мәнфәгате – дәүләт мәнфәгатен сабый чагыннан ук тоемлаган ласа. Ана сөте белән, Ата үрнәге белән алган ул бу сыйфатларны...

...Минтимер Шәрип улының Актанышта икмәк кабул итү элеваторын үзе төзетүен ишеткәнем бар иде. Бер очрашуыбызда үзе тагы да ачылып сөйләп алды бу хакта.

Мелиорация һәм су хуҗалыгы министры булып эшләгән бер елны игеннәр аеруча нык уңа. Тик җәй, көз бик яңгырлы килеп, урып-җыю эшләре соңара. Колхозларда ашлыкны киптерү җайланмалары җитешми. Чаллы элеваторы ерак. Минтимер ага күрше республика җитәкчеләренә – аларның Актанышка терәлеп корылган элеваторына – Актаныш ашлыгын салып киптерү үтенече белән мөрәҗәгать итә. Ут-күршеләр исә төрле сылтаулар табып ризалашмыйлар... «Шул чакта үзем өчен дә, алар өчен дә гарьләндем», – дип искә алган иде Минтимер Шәрипович.

Шул көнне үк ул Чаллыга килә. Үзара яхшы мөнәсәбәттәге «Камгэсэнергострой» төзелеш берләшмәсе җитәкчесе Е.Н.Батенчук янына кереп хәлне сөйләп

бирә. Кичекмәстән Актанышта күршеләрнекеннән ким булмаган элеватор төзергә килешә бу ике тәвәккәл ир-ат. Нидән башларга – бер проект та юк... Ярый ла «КамГЭС» ил күләмендә куәтле оешма. Үзләрендә геодезистлар да, проектчылар да бар. Минтимер Шәрипович нинди ышандырырлык сүзләр тапкандыр да илнең удар төзелешендәге оешманы «чит, планда каралмаган» төзелеш эшенә ничек җәлеп иткәндер? Фәкать мәскәүләрдән рөхсәт алынып, финансланып кына төзелә торган стратегик корылманы бер ел дигәндә төзеп бетереп, куллануга бирәләр алар. Бу хикәят әсәрдә юк. Әмма аңа охшашлары җитәрлек. Мондый мөстәкыйльлек, тәвәккәллек сыйфатлары аңа Илбашы булып сайлангач, әсәрдә урын алган тагы да катлаулырак сәяси проблемаларны хәл иткәндә, Татарстан Республикасы, татар милләте мәнфәгатьләрен яклап, корыч калкан булып басарга ярдәм итәчәк әле.

Республикабыз халкын тузган торак хәрабәләреннән чыгару, илдә иң беренчеләрдән булып газлаштыруны хәл итү үзе бер эпопея... Актаныш, Мөслим, Минзәлә районнарындагы авылларны газлаштыруның шаһиты үзем ләбаса...

...Әлмәт – Пермь нефть үткәргечендәге торбаларны алыштыру вакыты җитә… Бу эшләр Федераль үзәк планы буенча үзәктән финанслана бит инде. Нефть үткәргечләре өр-яңа трассага салына, янәшәдәге элекке трассада исә ремонт үткәрелеп, ул алда саналган районнарга газ үткәрү магистраленә әверелә... Һәр районга, авылларга магистральләрне сузуны республика җитәкчесе әнә шундый төрле ысуллар, тәвәккәл адымнар белән хәл итә... Беренче елда ук мәктәп, балалар бакчасы, больницалар мөстәкыйль рәвештә газ белән җылытуга күчә, тагын өч-дүрт елдан бөтен авыл йортларына газ керә...

Шушы ике хикәят авыр сугыш елларында эвакуацияләнеп килгән заводларны тиз арада япа-ялан кырда корып сафка бастыру белән бердәй күз алдына килә... Бу эшнең башында булдыклы, тәвәккәл җитәкче һәм ул сайлап алган кадрлар тора бит... Илбашының кадрлар сәясәте, үзенең шәкертләрен тәрбияләп үстерү таланты әсәрдә аерым хикәятләр булып та бирелә...


Илбашының үз вазифасын шәкертләренә тапшырып, Республиканың Дәүләт Киңәшчесе булып эшли башлавына да җиде ел узып китте. Бу чор – хатирәләрне яңартып, мемуарлар язып ятар өчен кебек югыйсә... Юк шул, милләтеңнең, Тукай әйткәнчә, дөнья йөге арбасыннан төшеп калмавы өчен көн дә ни дә булса эшләргә кирәк шул. Тукайның «Хакъкыбыз уртак ватанда шактый ук» дигән шигъри юлы Минтимер аганың төп тормыш девизыдыр, мөгаен. Шулай булмаса, Болгар, Зөя тарихи тыюлыгының колач җитмәс эшләрен колачларга алыныр идемени ул?! 1100 еллар элек Ислам динен дәүләт дине буларак кабул иткән Болгар бүген бөтен Евразия киңлекләрендә хак динебезнең мәркәзе булып танылды! Тарихи әһәмияте гасырларга җитәчәк бу эшнең башында Дәүләт Киңәшчесенең торуы беркемдә дә шик калдырмыйдыр. Дин өчен, милләт өчен, гомумән, бөтен кешелек өчен җан атып яшәүнең, иҗтиһат итүнең иң даһи үрнәге бу!

Хөрмәтле укучыларыбыз! Сезгә тәкъдим ителгән әлеге әсәр Яңа елның 20 гыйнварында үзенең 80 яшьлек гомер бәйрәмен билгеләп үтәчәк, Татарстан Республикасының Беренче Президенты, Бөтендөнья татар иленең Илбашы, безнең әдәби каһарманыбыз Минтимер Шәрип улы Шәймиевкә барлык татар халкының ихтирамы, рәхмәтләре булып та, тәбрикләүләребез, иң изге теләкләребез булып та барып ирешсен!

Яңа еллар мөбарәк булсын!

Бергә булыйк, бердәм булыйк!

**Илфак ИБРАҺИМОВ**



Рабит
Батулла

# ИЛБАШЫ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ БЕРЕНЧЕ ПРЕЗИДЕНТЫ, ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ ОЛУГ ШӘХЕСЕ МИНТИМЕР ШӘЙМИЕВ ТУРЫНДА ХИКӘЯЛӘР

Хезмәт кенәгәсе

Тулы исеме – Минтимер Шаһишәрип улы Шәймиев.

1937 елның 20 гыйнварында Татарстанның Актаныш төбәге Әнәк авылында урта хәлле игенче гаиләсендә туа.

1954 елда урта мәктәпне тәмамлый, Казан дәүләт авыл хуҗалыгы институтының механика бүлегенә укырга керә.

1959 елда – Мөслим төбәгендә инженер, баш инженер.

1959 елдан – Минзәләдәге «Сельхозтехника» төбәкара берләшмәсе җитәкчесе.

1967-1969 елларда – КПСС өлкә комитеты инструкторы, бүлек мөдире ярдәмчесе.

1969 елдан – Татарстан мелиорация һәм су хуҗалыгы министры.

1983 елда – ТАССР Министрлар Советы Рәисе урынбасары.

1983 елдан – КПСС өлкә комитеты секретаре.

1985 елдан – ТАССР Министрлар Советы Рәисе.

1989-1990 елларда – КПСС өлкә комитетының беренче секретаре.

1990-1991 елларда – ТАССР Югары Советы Рәисе.

1991-2010 елларда – Татарстан Республикасы Президенты.

2010 елдан – Татарстан Республикасының Дәүләт Киңәшчесе.

### Йола

*Йоласыз халык – юлсыз халык.*
Татар халык әйтеме

Күп балалы ата-ана, әби-баба үз балаларын, оныкларын тәрбия кылам дип башына да китермәгәндер. Алар, хәтта «педагогика» сүзенең ни-нәрсә аңлатканын, Макаренко, Сухомлинскийның кем икәнен дә белмәгән килеш, тулы канлы, сәламәт зиһенле балалар үстергән. Эш арасында, табын-тәгам

Рабит БАТУЛЛА (1938) – *Татарстанның халык язучысы; иллегә якын китап авторы, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Казанда яши.*

янында үзара сөйләшүләр, кайсы капкадан чыккан баланың начарлык кылганы, кайсы капкадан чыккан баланың кешеләргә игелек кылуы турындагы әңгәмәләр – шул була торгандыр инде ул йола, гадәт, шәригать тәрбиясе.

Ат җигеп урманга бару, ничек агач аудару, ничек аны турыйсы, ничек төйисе, камыт бавын ничек кыскартасы, атның сыртын ыңгырчак яки камыт суктырмас өчен ни кылырга кирәк – бала, атасы кылганнарны күреп, икенче вакыт, атасына охшатырга тырышып, шушы гамәлләрне кыла – шул түгелме инде ул хезмәт белән тәрбия бирү?!

Капкадан чыкканда, әбисенең, анасының, атасының, апа-абыйларының: «Нәселебезнең йөзенә кызыллык китермә, апаем!» – дип, көн саен озатып калуларыдыр инде ул олы тәрбия.

«Апаем» – Актаныш, Сарман якларында кыз балаларга, сабый оланнарга, үзеңнән кечеләргә әйтелә торган иркәләү сүзе.

Басу капкасыннан читкә чыгып киткәндә, авылдашларыңның: «Апаем, зинһар, авылыбызның йөзенә оят китермә!» – дип, сине озатып калуларыдыр инде ул «педагогика» дигән нәрсә.

Казаннан, Татарстаннан чит җирләргә, илләргә чыгып киткәндә, бөтен халкыңның: «Татар милләтенең йөзенә кызыллык китерә күрмә, апаем! Синең белән танышкач, менә татарлар нинди уңган, менә татар милләте нинди итагатьле, зиһенле олан үстергән дип сокланып калсыннар», – дип, үгет-нәсихәт биреп калуыдыр инде ул тәрбия.

Актаныш төбәгенең Әнәк авылы оланы Миңкәй шушы гадәт-йолаларны зиһененә сеңдереп үсте.

«Миңкәй» – Минтимернең сабый чактагы кыскартылган исеме.

Адәм баласының холкын, гамәлләрен, фикер юнәлешен борынгы ата-бабалардан калган әнә шушы йолалар билгели.

Ана теле, йола, гаиләнең игелекле гамәлләре баланың рухына мәгънәви нигез булып ята. Гаилә йоласы нык булса, тышкы мохит, урам, яман төркем берни дә эшли алмый. Чөнки булачак шәхеснең баш очында ата-бабаның кылыч кебек үткер кисәтү йоласы эленеп тора.

Шул чагында милләтең таза, нык, чит-ятлар йогынтысына, яманнарның котырыгына бирешмәс булыр. Балалары, оныклары яшәүгә теше-тырнагы белән ябышып ятса гына, халык башкалар алдында абруй казаныр. Ана телен, үз халкының йолаларын белмәгән кеше мескенлеккә-кимсенүгә дучар була, читләр йогынтысына тиз бирешә. Ул милләт әкренләп «халык»ка әйләнәчәк, тора-бара маңкортлар өеренә әвереләчәк. Йоласыз, тәрбиясез өердән Аллам сакласын! Милләтен, йолаларын җуйган өер үз халкы өчен генә түгел, башка халыклар өчен дә куркыныч була башлый.

Табын янындагы сиздермәс тәрбия генә түгел, укытучы остазлар, әдәбият, халык сәнгате, аулак өйләр, Сабан туйлары, бәйрәмнәр, риваять-әкиятләр дә кешенең рухын ныгыта, аны үз милләтеннән читкә җибәрми, милләт мәркәзенә ныграк тарта һәм беркайчан да аны үзеннән ычкындырмый. Милләтнең үзәккә тарту гайрәте дә шундадыр.

## Кушамат

Бу сүз ике өлештән тора. Кушым – «өстәмә, кушылган», ат «исем, ат» мәгънәсендә килә. Кушылган исем, тагылган исем, Кытайда (Шәркый Төркестанда) яшәүче татарлар телендә «такма ат» дип тә әйтәләр.

Шәймиләр токымының кушаматы – «Чаптын».

Минтимернең бабасы Шаһимөхәммәт (Шәймөхәммәт, кыска исеме – Шәйми) авылның хәлле кешесе булган, аны хәтта «авыл бае» дип тә атарга мөмкиндер. Аның каралты-курасы нык, мал-туары күп, яхшы атлары Сабан туйларында гел беренче урынны ала килә. Өстендә төлке тун, башында камчат бүрек.

Сандугач сайрыйдыр кайларда,
Төлке тун, камчат бүрек байларда...

Минзәлә өязендә уза торган Сабан туйларында Шәйми чабышкыларына чыккан ат булмаган, диләр. Нәсел кушаматы «Чаптын» әнә шуннан килә. Шәймөхәммәтнең Чаптын айгырын тарантасына җигеп, чигүле чикмән киеп, башына каракүл бүрек элеп урамнан узганда, тузан бураннары уйнап кала торган була. Ә инде ул төлке толыбын киеп, башына камчат бүреген батырып, арка терәүле чанасы – кошёвкасына утырып урамнан узганда, авыл кар өермәсенә уралып калган, диләр.

## Яучы

Чаптын Шәймөхәммәте, йола сагында торучы шәхес-гаилә тәртипләрен ныклы кулында тотучы буларак, улын үзе сайлаган кызга, Нәгыймәгә өйләндергән.

Хәер, «Шәймөхәммәт бай улы Шаһишәрипне Нәгыймәгә өйләндергән» дигән сүз бигүк дөрес тә түгелдер. Ул вакытта төрки халыкларда, шул исәптән татарларда да яучылар мәктәбе эшләгән. Яучы соралмаганда, ягъни ике гаилә озак еллар якыннан аралашып яшәгәндә, «колак тешләтү» йоласы булган. Бер гаиләдә кыз бала туган, икенчесендә ир олан дөньяга килгән. Ике ата болай килешкән (бу йола Чыңгыз хан заманасыннан ук калган): бишектәге ике баланы бергә якын китереп, колакларын тешләткән, ир олан кызның колагын авырттырганчы тешләргә, кыз еларга тиеш булган. Сабый кыз елаганда, кодалар да куанычларыннан елашкан, аннан соң шатланышкан, кул бирешеп, калым-мәһәр алмашкан. Балигъ булганчы ике бала үзара аралашып, бер-берсенә күнегеп яшәгән. Соңра балигъләк вакытлары җиткәч, аларны никахлаганнар. Гадәттә, бу никах бик нык булган, алар күптин-күп, чуктин-чук балалар үрчеткән. Бу йола, кызганыч, онытылган инде.

Яучы ярдәмендә кавыштыру исә шактый катлаулы гамәл булган. Яучы һөнәре нәселдән нәселгә күчеп килгән. Яучы психолог та, күзәтүчән очлы күз дә булырга тиеш. Чын яучы якын-тирәдәге авыл-шәһәр кешеләренең нәсел-нәсәбе, нәбрә-токымы турында мәгълүмат туплаган. Кайсы нәселдә нинди чир бар, кайсы гаиләнең балалары кызыш, чорсыз, пырдымсыз – барысы да яучының башында, яшерен дәфтәрендә сакланган.

Шәймөхәммәт, әлбәттә, яучы яллаган булырга тиеш.

Әйтик, менә шушындыйрак сөйләшү булгандыр яучы белән бай арасында.

Яучы хатын килеп керә. Аның кыз яучылап килгәнен хуҗабай күрсенгә, ул читек балтырыннан бер балагын чыгарган, озын итәген бераз ача төшкән. Хуҗабай шуннан аңлый: әһә, бу яучы хатын минем улыма кыз димләргә килгән, дип уйлый.

Хуҗа ишарәсе белән яучыга табын әзерлиләр. Яучы, озак кына дога укыганнан соң, сүз башлый:

– Кем, Шаһимөхәммәт, җиткән җегетең бар, ие, кем...

– Бар-бар, Аллага шөкер, кем, Хәсилә бикә...

– Өйләндерергә кирәк, кем, Шаһимөхәммәт...

– Бик кирәк, кем, бик кирәк...

– Үзеңнең берәр теләгән кешеңнең кызын алдырасың килмиме соң, Шаһимөхәммәт?

– Әнә теге, кем, Тауасты Гыйззәтулланың...

– Айа-һу, кем, Шаһимөхәммәт, аларның нәселендә җыгыла торган чирлеләр бар бит... Озак яшәмиләр алар, кем...

– Таптым! – дип кычкыра Шаһимөхәммәт. – Күрше Усы авылындагы Сафиулланың төпчек кызы Нәгыймә!

– Нәкъ өстенә бастың! – ди яучы. – Тамырлары нык, кем, Шаһимөхәммәт! Үзе чибәр, үзе уңган, үзе китап укый. Ерак чишмәдән су алып кайтуларына гына кара син аның. Гәүдәсе тал чыбыгыдай сыгылмалы, шөпшә билле, ул атлаулары, аккош йөзәмени...

Кыз сайлана, яучыга мул итеп әҗер бирелә, чәйләр эчелә, бетте-китте вәссәлам!

Шаһимөхәммәт туйны шәпләп уздыра.

Карт хаклы булып чыга бит, Нәгыймә йорт җанлы, бала җанлы килен була. Ул Шаһишәрипкә никахлап кияүгә чыккач, Нәгыймә Шәймиевага әйләнә. Минтимернең нәсел исеме бабасы Шәймөхәммәттән килә.

Совет хакимияте урнашкач, Шәймөхәммәт кара кулаклар исемлегенә кертелә. Ләкин Себергә сөрелми кала. Әле ул чагында кулакларны Себергә сөрү кампаниясе тизләнеш алмаган була. 1929 елда, 60 яшендә Шәймөхәммәт бакыйлыкка күчә. Ул Себер, Колыма, каторга, ГУЛАГ җәһәннәменнән вафаты аркасында гына котылып кала. Бәхетле кеше дими ни диярсең, валлаһи!

Шаһимөхәммәтнең улы, Минтимернең атасы Шаһишәрип, көр каралтыга хуҗа булып кала. 29 яшьлек акыллы мужик Шаһишәрип дөньяның кай тарафка барганын сизеп ала, чорсыз кыланмый, сабыр гына, тыныч кына колхозга керә. Шаһишәрифнең кыска исеме – Шәрип, җирле сөйләмдә халык «ф» урынына «п» авазы куеп сөйләшә, әйтик, Фатима – Патима, Фәхри – Пәкъри...

Нәгыймә килен ун бала китерә. Тугызынчысы – әсәребезнең каһарманы – Минтимер Шәймиев булыр! Ул, гаилә куанычы булып, 1937 елның 20 гыйнварында дөньяга килә.

Минтимер дөньяга аваз салганчы, бу токымга байтак җәфалар кичерергә туры килә әле. Минтимернең бабасы Чаптын Шаһимөхәммәте ихатасына бәлаләр ишелеп төшә, көр каралты-кураны, хәләл көч белән тупланган бөтен малны тартып алып, гаиләне урамда калдыралар. Ләкин кулаклар исемлегенә кертелсә дә, Шаһимөхәммәтне ни өчендер Себергә сөрмиләр, әмма ул үзен-үзе туган авылыннан сөрә.

Шаһимөхәммәтнең улы Шаһишәрип партиягә кереп ала, коммунист буларак, аны күмәк хуҗалык җитәкчесе итеп куялар, ул кулаклардан талап алынган маллар белән идарә итәргә керешә.

Бу гамәл Шаһимөхәммәтне яшен суккандай итә. Ничек инде аның сөекле улы коммунистларга – халыкны кычкыртып талаучыларга хезмәт куя?

– Ризалыгым ю-ук! – дип кычкыра токым башы.

Шаһишәрип ярсыган атасына аңлатып карый.

– Әткәй! – ди ул сабыр гына. – Тышта, урамда, калада ниләр булганын аңламыйсыңмыни син?

– Адәмнәр алдында хурлыкка калдырдың син нәселне! Мәңге бәхил түгел! Кире кайт, балам, бу уеңнан! Минем улым дәһриләр ягында, ул алласызлыкка язылган! Тфү, әстәгъфируллаһ! Тәүбә ит, улым!

– Мин алласызлыкка язылмадым, эткәй.

– Камунистлар Алласыз, кара дәһри алар!

– Син бит Коръәнне дә, хәдисләрне дә яхшы беләсең, эткәй! – дип, һаман сабыр гына аңлатырга тырыша Шәрип атасына. – Сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салаллаһу галәйһи вә сәлам заманасында була бу вакыйга. Каты җәзаларга чыдый алмыйча, кайбер мөселманнар, балаларын, якыннарын шул җәзалардан коткарыр өчен, кяферләр алдында Аллаһны инкяр итеп, эчтән генә шаһәдәт догаларын кабатлаган һәм аларны Аллаһ ярлыкаган, чөнки алар күңелләре белән Аллага ышанган. Мин дә күңелемдәге Аллаһы Тәгаләне инкяр итмим, халкымны, нәселемне саклап калыр өчен, аларның сүзен кабатлаган булам, Алла шаһит, мин кяфер түгел, эткәй!

Ләкин Шаһишәрип үзсүзле картны җиңә алмый. Шаһимөхәммәт, туган авылы Әнәкне ташлап, Уразмәт авылына, олы кызы йортына күченеп китә. Һәм калган гомерен шул йортта, кызы тәрбиясендә яшәп, гүр иясе була. Авыр туфрагы җиңел булсын! Шаһимөхәммәт мәрхүмнең урынын җәннәттән әйләсен! Амин!

## Гармун

Үзен белә башлаганнан бирле Минтимернең беренче ачык хатирәләре Бөек Ватан сугышы белән бәйле булды. Сугыш башланган чакта аңа нибары дүрт яшь иде.

Атасы... Кырыс йөзле атасы сабыйның хәтерендә яхшы саклана. Каушаганмы, аптыраганмы, сөекле хатыны, балалары ятим кала ич... Әллә кайта, әллә юк, бу хатын өй тутырык балалар белән нишләр соң...

Анасы... яулык почмагын тешләп, башкаларга күрсәтмәскә тырышып кына сыктый. Апалары бер кырга – аталары янына, бүредән куркып чулаган мал кебек бергә өелгән, сабый Минтимер-Миңкәй дә шунда... нарасый әле, ни булганын, ни булачагын аңлап та бетерми...

Гармун тавышы... Җиз телле тальян авазы сагышлы моң булып зиһен түрендә калган. Атасына, анасына, апаларына ияреп, Миңкәй дә урамга чыкты, анда шау-шу, кычкырыш, елаш, җырлаш, гармун тавышы...

Йә кайтырбыз, йә кайтмабыз,
Сау булыгыз, туганнар...

Чиный, өзелеп-өздереп чиный гармунның уң як урта теле. Хәтерли әле Минтимер, ул тавыш, гармун тавышы, бигрәк тә әнә шул чиный торган тавышы агайлар ерак-еракларга киткәч тә озак ишетелеп торды...

Сабан туйларында, гармун бәйрәмнәрендә тальян гармун тавышы ишетелгән саен, Минтимер Шәймиев һәрвакыт атасы белән бик күп ир-егетләрне сугышка озатканнарын хәтерендә яңартыр. Күпләрне, бик күпләрне гармун сугышка озатты, бик күпләрне кире алып кайтмады. Авыр туфраклары җиңел булсын! Мәрхүмнәрнең урыннарын җәннәттән әйләсен! Кайтканнарының да күбесе аксак-туксак, кулсыз-чулак, саңгырау-чукрак иде бахыркайларның.

## Кәҗә сөте

Ачлыкка чыдый алмый башлагач, кемдер шешенә, кемдер артык нык ябыга, кемдер, һични сорамыйча, битараф йөз белән, сәкегә сузылып, түшәм санап ята. Шәймиләр курасында да рәт юк, җиде җан ачыга.

Авылда колхозлашу чорыннан калган келәтләр бар. Аларны амбар дип тә атыйлар. Анда ашлык саклыйлар. Ашлык астан җилләп торсын дип, язын кар сулары, җәйге яңгыр сулары кермәсен өчен, аларның барысын да субайлар өстенә утыртканнар. Җәйге кызу көннәрдә кәҗәләр, гадәттә, көпә-көндез көтүдән качып авылга кайта. Күләгә урын эзләп, шул келәтләр астына керәләр.

Дус малайлар киңәш итте.

– Әйдәгез, кәҗә савып сөт эчәбез! – диде кемдер.

Малайларның кайсысы өеннән атасы фронттан алып кайткан котелок, кемдер алюмин мискә алып, ә Миңкәй токтасыз кружканы күлмәк астына яшереп, келәтләр янына төштеләр. Кәҗәләр, кызудан качып, күләгәдә рәхәт чигә, барысы да күши. Бер кәҗәнең сөте жилененнән үк тамып тора.

– Миңкәй, – диде Җылгыр, – анау теге кәҗәнең сөте артык, киметергә кирәк!

Ике үсмер кәҗәне тотып алды. Берсе, ике мөгезеннән тотып, кәҗәне җибәрми тора, Миңкәй, күлмәк эченнән токтасыз кружкасын чыгарып, кәҗәне сава башлады. Кружка яртылаш булгач, эчеп тә куйды. Кәҗәнең сөте җып-җылы, куп-куе иде. Миңкәй торды, савылган сөтне Җылгырга биреп, үзе кәҗәнең ике мөгезен Җылгыр кулыннан алды. Җылгыр кәҗә сава башлады, аңа савуы җайсыз иде бугай, ул, кружканы бер читкә куеп, чалкан ятып, кәҗә җиленендәге сөтне имә башлады. Яңак сеңерләре арыгач кына туктады, Миңкәй кәҗәне ычкындырды. Кәҗә, җиңеләеп киткәндәй, ятып тагын күшәргә тотынды.

– Рәхмәт, кәҗәкәй! – дип, малайлар келәт астыннан чыкты.

Шул көнне Җылгырның эче китте. Эт карынына сары май килешми инде ул! Шуннан соң аңа Кәҗә Җылгыр кушаматы тагылып калды.

Кемдер үсмерләрнең бу гамәлләрен күргән бит тәки. Шулай итеп, авыл малайлары, ай буе кәҗә савып, сөтен эчеп, ачлык хисен баса төшә. Ә кәҗә хуҗалары көтүчегә килеп зарлана ук башлаган:

– Ай буе кәҗәләребезнең җилене буш кайта. Әллә үзең савып аласыңмы? – дип шелтә белдергән.

Җитмәсә, малайларның нindидер савытлар тотып келәт янына йөгергәннәрен дә күреп алганнар...

Самавыр янында тагын сорау алу башланды.

– Шул дөресме? – диде кырыс ана.

Минтимер дәшмәде.

– Димәк, дөрес! – дип, тавышын күтәрә төште әнкәсе. – Атагыз гына исән-сау кайтсын! Үтерер атаң бу эшең өчен! Хат язам атагызга. Атагыз ни күзе белән карар халык йөзенә, аның баласы Минтимер ятим гаиләнең карап торган бердәнбер кәҗәсенең сөтен сава. Аларда берсеннән-берсе бәләкәй ике сабый бала, кәҗәнең сөт җыеп алып кайтканын көтеп, ач утыра. Син аларның өлешен имгәнсең, җүнсез бала.

Әнкәсенең иң олы ачулану сүзе «җүнсез бала» яки «тәрбиясез бала» иде. Шул сүзне әйтсә, җир тишегенә кер дә кит, билләһи.

Язмый әнкәй, нишләп инде әнкәй тикле әнкәй фронтта сугышып йөрүче атасына малаең Минтимер кеше кәҗәсен яткызып имгән дип хат язсын ди, юк, болай гына куркыта ул.

– Әнә атагызның камчысы! – дип, Нәгыймә апа матчада эленеп торган камчыга төртеп күрсәтте.

Белә лә Минтимер матчада атасының камчысы эленеп торганын, ләкин аның ул камчыны матчадан алганы булмады. Камчыны анасы еш ала иде, җилпенеп дулгана-дулгана да сукмыйча кире үз урынына элеп куя. Бетте! Камчының тәрбияви вазифасы шуның белән тәмамлана.

Үскәч, Минтимер аңлар: анасы балалары каршысында иренең абруен күтәрер өчен шулай куркыткан, аталарыннан шүрләп торсыннар, янәсе. Шул рәвешле, аталары сугышта булса да, әнкәләре балаларын тәрбияләүдә актив катнаша булып чыга. Машалла! Яшәсен халык тәрбиясе!

Сагышлы гармун сугышта яраланган Шәрип абзыйны авылга, туган нигезгә алып кайтты, шөкер.

Зур сөенеч иде атаның кайтып төшүе, алты бала белән калган солдатка-ана бик куанды. Яралы булса да, тере бит, дип елый иде Нәгыймә. Ул тавыш чыгармыйча гына, тыйлыгып кына елый. Аннары елмая.

Үсә төшкәч, Минтимер аңлар: аның атасы, җәрәхәтле булса да, исән кайткан әле, шөкер, ул куаныч булып ана йөзендә балкый, ә башкаларның ирләре, яшь киленнәрнең яшь-яшь кияүләре мәңгегә кайтмас, Нәгыймә ана кайгылы аналарның, хәсрәтле толларның кайгысын уртаклашып шулай сыктаган икән. Бу да – кеше өчен кайгыра белү – Минтимер өчен олы бер сабак иде.

Шатлыгым бар дип, хәсрәтле кеше алдында күрсәтеп, артыгын сикеренмә. Хафага төшкәннәрнең хәсрәтен, кайгысын уртаклаш. Аларга ярдәмче бул. Бу гамәл кешене басынкылыкка чакыра, сабыр булырга өнди. Минтимер Шәймиев гомере буе шатлыгыннан сикереп шатланмады, кайгысын башкаларга күрсәтеп кайгырмады. Бу аның гадәте, холкы, фигыле иде.

## Аш белән ат

Бервакыт Миңкәй мәктәпкә бара торган җиреннән кире борылып кайтты. Аның аякчуы, өс-башы чыланган иде.

– Ай Аллам, ни булды, балакаем? – дип каршы алды аны Нәгыймә апа.

Атасы эндәшмәде. Ул кырыс кына тамак кырды да камыт бавын рәтләвен дәвам итте.

– Анау теге җүнсез мин барасы юлга ялган чокыры ясап куйган, – диде Минтимер күңелсез генә.

– Ә кем күргән аның чокыр ясаганын? – диде атасы, эшеннән аерылмый гына. – Бәлки, ул ясамагандыр.

– Әйттеләр! Малайлар күргән! – диде Минтимер.

– Кеше сүзе кеше үтерер! – диде анасы. – Ул ясамаган булса?

Ана улының букчасын иңеннән алды, букча да манма суга баткан, итеген мич авызына кибәргә куйды. Чыланганнарын салдырып, баласы өстенә коры, җылы киемнәр кигезде. Аннары карыш-карыш калтырап утыручы улына мәтрүшкәле кайнар чәй ясап бирде.

– Кар суыннан томау төшмәсен, мәтрүшкәле чәйне күбрәк эч! – диде Нәгыймә апа, аннан соң өстәп куйды: – Ни кызык табалардыр инде бу балалар бер-берсен суга батырып.

Ялган чокырын ясаган җүнсез малай Минтимердән көнләшә иде. Аның алдынгы укучы булганына да, пимасы өстеннән кызыл эчле галошлар киеп йөргәненә дә кызыга. Шуңа күрә ул ялган чокырын кичә үк ясап куйган. Көрәк

белән чокыр ясагач, анда күп итеп кар суы тула, аннан соң, көрәк белән тагын юеш кар салып, чокырның авызын каплыйлар да көрәкне сак кына тартып алалар, чокырны каплап торган юка кар шулай тотылып кала. Аннары чокырны күрмәсеннәр өчен аның өстенә саламдыр, тирестер сибеп чыгалар. Ашыгып эшкә яки мәктәпкә барганда, кеше юка кар каплавычына баса да аягы белән чокыр тулы салкын суга бата. Йөгереп барганда шул чокырга төшеп аякларын каймыктырган, хәтта сындырган кешеләр дә булгалый. Бу – куркыныч уен.

– Мин аның үзенә дә ялган чокыры ясап куям әле! – диде Минтимер.

Атасы эшеннән аерылмыйча гына әйтеп куйды:

– Үч алу егет кешегә килешми! Таш белән атканга аш белән ат! – диде.

Шушы бер җөмләгә татар халкының зиһнияте, тарихы, холкы, сабырлыгы, йоласы сыйган. Кем сиңа чокыр казыган икән, син аннан үч алма. Кемдер синең бакчаңа таш ыргытса, ыргыткан кешенең кем икәнен белгән очракта да син аннан үч алма, аңа яхшылык эшлә. Бәлки, ул сине аңлар, бәлки, ул синең дустың булып китәр. Дус булмаган очракта да син аңардан үч кайтарма. Син ул түбән кешедән өстен булып кал. Җаның тыныч булыр. Һич югында, сиңа кабахәтлек кылган кеше яңадан сиңа яманлык эшләмәс.

Ишле гаилә табын янына җыелып утырганда, бәләкәй Миңкәй бу мәкальне бик еш ишетә торган иде.

Таш белән атканга аш белән ат!

Үч кайтарма!

*Җәза бирсәгез, үзегезгә бирелгән җәза микъдарында гына җәзалагыз. Ләкин үч алмыйча, сабыр итсәгез, һичшиксез, сезнең файдага булыр.* (Коръән, 16: 126)

## Абый

*Агай-эне, ак мыек,*
*Бер-беребезне какмыек,*
*Бер-беребезне каккан чакта,*
*Бер-беребезне яклыек.*

Халык җыры

Апаларга бай булды Минтимер, ике апасы, бер сеңлесе бар. Абыйсы берәү генә. Апалары Минтимерне сөя, юата, тәрбияли, ә менә абыйсы Хантимер – башка. Ул абый гына да түгел. Ул яклаучы да, аның эшен башкаручы да. Умырып эшли, машина-комбайн җене кагылган кеше ул абый. Бәләкәйдән үк Хантимер энесен машинаны танып белергә өйрәтте. Бәләкәйдән үк алар бергәләп мал карады, су ташыды, кар көрәде, хайваннарга курмы салды. Минтимер укырга һәвәс, атлыгып тора, күп вакыт өйгә бирелгән эшләрен дә әзерләргә өлгерми, абыйсы дәшмичә генә Минтимер башкарырга тиешле эшне эшли. Укысын энем, һәвәсе булгач. Нәгыймә апа да читтән генә ике улының нинди мөнәсәбәттә икәнен күзәтә. Хантимернең Минтимер башкарасы эшләрне дә майтарып ташлаганын да күрә, ләкин эндәшми. Ике ир туганның дус-тату булганына ана кеше нык сөенә иде. Алар бер-берсе өчен җан ата, бер-берсе өчен үләрдәй булып тора.

Бер алманы бишкә бүләек,
Беребез өчен беребез үләек.

Әйтерсең лә шушы матур җырны бары тик Минтимер белән Хантимер өчен генә чыгарганнар. Һәрвакыт ике туган арасында бары – бергә, югы уртак була килде.

Олыны – олы, кечене кече итү шул буладыр инде ул.

## Мәргән

Малайларның һәрберсе үз маясында булган шәпиләрен (кузналарын) су буена алып төшәргә тиеш иде. Кемдер сигез кузна алып (хәлле гаилә баласы), кайсыдыр – дүрт кузна (урта хәлле гаилә баласы), кайсыдыр бер шәпи алып (үлле-мәлле гаиләдә яшәүче), кемдер буш кул белән су буена төшә, монысы җир идәнле, ярым ач, ярым ялангач йортта яшәүченең бичара баласы иде. Ул кузна уенын карарга, кем өчендер җан атарга килгән.

Уен башланыр алдыннан һәр малай үз маясыннан берәр кузнаны күчкә куя. Ике яки бер кузнасы булганнар өемгә өлеш чыгармый. Җиде бала өемгә берәр кузна куйды.

Кайсыдыр, Гитлерга охшатып, тактадан карачкы ясап, яр буена утыртып куйган. Малайлар барысы да чуерташ җыйды. Карачкыдан унбиш адым ара калдырып, сызык сыздылар.

– Хәзер төз ату ярышлары булачак, – дип кычкырды Җылгыр. – Һәркем бишәр таш кына атарга хокуклы. Кем дә кем шушы арадан Адольф Гитлерга таш атып тигезә ала, карачкыга иң күп тигезгән малайга өемдәге җиде шәпи була!

– У-у... – дигән аваз яр буйлап китте.

– Чиратка басабыз! Санап барабыз!

Ташлар карачкыга атылып бетте. Иң төз атучы Миңкәй булып чыкты, аның биш ташы да Гитлерга тигән иде. Шулай итеп, аңа үзенең дүрт кузнасы өстенә җиде шәпи мәргәнлеге өчен бирелде, унбер кузналы Минтимер горур иде.

Яр башын тигезләп, такыр ясадылар, һәр бала теземгә берәр шәпи куярга тиеш. Һәр бала тимерлектә тимерче абыйлар коеп биргән тимер аткый тоткан. Һәр катнашучы шул тимер аткый белән шәпи тезмәсенә төбәп атарга тиеш, аткый ничә кузнаны аударса, ауган кузналар атучыга була.

Уенның кызган чагында гына Миңкәй карт тал янында мышык-мышык елап торучы шәписез малайны күреп алды. Бу малайның кузна уенында бик тә катнашасы килә иде, ләкин аларның курасында бозау, сарык түгел, кәҗә дә юк, ул каян алсын кузнаны. Бу җир идәнле фәкыйрь баласы Самат иде.

Минтимер, үзе откан кузналардан аерып, аңа өч кузна бирде.

– Мә, апаем, бу шәпиләрне ал, син дә уйна! – диде.

Уен кыза бара, малайлар шунда бәргәләшеп тә ала. Уенның кызган чагында гына Минтимер әйтте:

– Иптәш уенчылар! Уенда Самат та катнашачак! Куй, Самат, шәпиеңне! – диде.

Самат кыюсыз гына, ләкин эчке бер куаныч белән бер кузнасын тезмәгә куйды. Менә аңа да атарга чират җитте. Бала каушаган, аның тимер аткые юк иде. Минтимер аңа үз аткыен сузды. Самат рәхмәт әйтергә дә онытты, аның игътибары кузналар тезмәсендә иде, ни өчендер ул ике учын төкерекләде дә аткыен, уң кулына тотып, уң күзенә якын китереп, озак кына төзәп торды, киерелеп кизәнде дә тимерне кузна тезмәсенә таба атты. Аткый, тезмә яныннан гына узып, читкә очты.

– Һәй, кыек кул! –дип кычкырды малайлар.

Тагын чират көтәргә туры килде. Уенчыларның аткан бере кузна аудара. Самат тезмәдә миңа шәпи калмас инде дип кайгыра. Ниһаять, аңа тагын чират җитте. Бу юлы аткый беренче кузнага тияр-тимәс кенә узды.

Малайлар ыржаеп көлеште.

– Чулак! – дип кычкырды.

Самат аның саен каушый барды.

– Сабыр, сабыр бул! – дип пышылдады Минтимер.

Самат тезмәгә соңгы шәпиен куйды. Бу юлы аның аткые тезмәдәге бөтен шәпиләрне себереп алып китте.

Малайлар шаккатты, бигрәк тә Минтимер сөенде. Самат чәчелгән шәпиләрне кабалана-кабалана итәгенә җыйды.

Малайлар соңгы шәпиләрен теземгә куеп чыкты, Минтимернең дә соңгы кузнасы иде. Откан кеше буларак, Самат тулы теземгә беренче атарга тиеш иде. Һәм атты да бар шәпине себереп тә алып китте.

– Хәрәмләште, ул сызыкка басып атты! – дип кычкырып караганнар иде дә, булмады, Минтимер кырт кисте:

– Сызыкка басып атканын күргәч, нигә туктатмадыгыз? – диде.

Шулчак Самат кузналары белән мәш килеп кыптырдый башлады, шәпиләре арасыннан өчесен, иң олыларын, ата шәпиләрне сайлап алып, Минтимергә сузды:

– Минем сиңа бурычым бар иде, Миңкәй, ал! – диде.

Минтимер кузналарны алып, өчесен дә тезмәгә куйды, Самат та нәкъ шулай эшләде.

Җылгыр әйтте:

– Дуслар, туаришлар! Ике арада уен яңадан башлана! Кем беренче ата?

– Откан кеше! – диештеләр.

– Юк! – диде Җылгыр. – Бу – яңа уен! Шобага салабыз! Кемдә бакыр акча бар?

Минтимер кесәсеннән Әби патша акчасы чыгарды, Җылгыр акчаны алды да әйтте:

– Мин акчаны чөям, күн ягы, ягъни ике башлы кош ягы төшсә – Миңкәйгә, иләк ягы, ягъни сан ягы төшсә – Саматка.

Акча зыңгылдап һавага очты, такырга килеп төште, барысы да акчага иелде.

– Күн як! – дип шаулашты малайлар.

– Иң беренче булып Миңкәй ата! – дип кычкырды уенбаш.

Минтимер кулына аткыен алды. Бик озак төзәгән булып торды да атып җибәрде, әмма аткый тезмә өстеннән очып китте.

– Җүри генә атты! – дип кычкырдылар. – Җүри тидермәде!

– Җүриме-түгелме, атарга тиеш кеше атты! Кыштырдамагыз! – дип боерды Җылгыр.

Хәзер Самат чираты иде. Бу юлы ул төзәмичә генә атты – алты кузна берьюлы тезмәдән чыгып та очты.

Шәпи уены тәмам булды. Бу көнне Самат батыр калды.

Малайлар таралды. Саматның чалбар кесәләре, күлмәк итәге, түбәтәе кузна белән тулы иде.

Алар, Минтимер белән Самат, юлда бергә кайтты.

– Миңкәй! Син бит иң төз атучы! Син җурамал гына тигезмәдең бит, иеме, Миңкәй? – диде Самат. – Шәпиләр миңа булсын дип...

Минтимер иң өсләрен сикертте, ләкин бер сүз дә әйтмәде.

Самат бәхетле иде.

– Беләсеңме, Миңкәй... мин бу шәпиләремне сатам!

– Нигә, ни өчен? – дип, гаҗәпләнеп сорап куйды Минтимер. – Алга таба да уйнарсың бит әле, уйнарбыз...

– Мәктәпкә йөрергә минем букчам юк, – диде Самат. – Калганына бирәр

аяк киеме юнәтәсе булыр. Анысына көзен чикләвек җыярмын, Алла боерса. Егерме биш стакан чикләвек сатсаң, яхшы киндер букча алып була икән...

Бу мәлдә Самат бик тә бәхетле иде, ә Минтимер бөтен кузналарын оттырып бетергәненә күрә бәхетле иде...

## Тургай

*Сабан тургайлары сайрый,*
*Мактап Сабан туйларын...*
Халык җыры

Язын җир кабаргач, туфрак пешкәч, бакча эшләре башлана, бәрәңге утыртырга кирәк. Әмма иң беренче теләк – ачлыкны басу. Казылган җирдән чыккан черек бәрәңгене, крахмалга әйләнгән, бөрешеп беткән кәлҗемәне лар төбендәге көрпә белән бутап, кычыткан җыеп, кысыр аш пешерер әнкәсе.

Лар – он, икмәк саклау өчен калын тактадан эшләнгән зур тартма, икмәк сандыгы; ларёк – вак-төяк сата торган кечкенә кибет; ларец – бизәнү әйберләре салып куяр өчен тартмачык.

Кечкенә Миңкәй, болынга чыгып, кузгалак җыеп кайтыр. Катык булмаганда, кузгалак кысыр ашка гаҗәеп әчкелтем тәм өсти. Кысыр аш ул – итсез, майсыз, үләннәр салып пешерелгән сыек шулпа.

Кузгалак җыярга барганда, Минтимер тургай тавышын ишетеп туктап калды.

Болын җәйрәп ята, каерылып печән үскән, быел болынны ике тапкыр чабып алырлар, Алла боерса. Каерып-каерылып агай-апалар печән чабар. Их, егетләр, печән чапкандагы чалгы тавышын тыңласаң, дөньяңны онытасың, билләһи. Чжиңк-чжиңк – үткен чалгы печән чаба, чалгы узган җирдә озын үлән сабаклары авып кала, икенче селтәнгәндә киселгән печәнне чалгы сул якка алып китеп тезмәгә сала. Байтак вакыт чапканнан соң, чалгычы туктый, билбавыннан янавычын чыгарып, чалгысын үткенли, оешкан комнан ясалган кайрак кебек янавыч корыч чалгы буйлый йөри башлый, чалгы гаҗәеп матур тавыш чыгара, әйтерсең лә скрипка уйный, чалгы үзе скрипка, аның сыза торган кылы – янавыч, үткенләнгәч, тагын чжиңк-чжиңк башлана. Йөз ел тыңлар иде Миңкәй шушы музыканы.

Батыр егет печән чаба, дисәнә,
Үтми аның чалгысы, дисәнә;
Үтәр иде чалгысы, дисәнә,
Анда кызлар кайгысы, дисәнә.

Йөгрә-йөгрә җиләк җыя, дисәнә,
Зәңгәр күлмәк кигәне, дисәнә;
Җыймас иде җиләген, дисәнә,
Кайтыр тиздән сөйгәне, дисәнә.

Ай, миленький, кызларның душасы,
Яучыларга кемнәрне кушасы?

Агай-егетләр авыр эш эшләми дә кебек, алар уйный гына сыман, шулкадәр җиңел селтәнәләр. Агайларга шатлык: мул печән өлгергән, печән ул – сөт, ит, май, бәлеш, гөбәдия. Шуңа күрә бу эшне эшләве аларга авыр, җәфа түгел, арыганлык та ләззәт бирә агайларга. Беренче тапкыр мул печән чабып, аны

киптереп, эскерт, кибән, чүмәләләргә өеп куйгач, бераздан болында курпы өлгерә. Курпы ул уҗым сыман кыска була, әйтерсең лә көрәшчеләрнең кыска чәче кебек. Курпысын чабарга агайлар чалгыга кечкенә тырмачык беркетә, чөнки курпыны чалгы җыеп бетерә алмый.

Каерылып үскән, чабылмаган печән арасында ат кузгалаклары күп була, күгәрчен күзе, сары, зәңгәр чәчәкләр күкрәп үсә.

Күктә тургайлар сайрый, аларның тавышлары гына ишетелә, үзләре күренми. Бары тик күктән серле тавыш иңә. Игътибар беләнрәк карасаң, зәп-зәңгәр күктә бер нокта шәйләргә була. Шул нокта сайрый да инде. Бер урында талпына, үзе сайрый, тургайның телен аңлап була аның, сүзләр әйтеп сайрый сабан тургайлары. Өздерә генә тургайлар, гүя үзара ярыш оештырганнар.

Миңкәй, болынга ни өчен килгәнлеген дә онытып, тургай сайравын тыңлый:

Киррам-киррам төеп,
Тиррам-тиррам чөеп,
Фистивай-фистивай,
Кире тай, кире тай...
Тю-тю-тю-тю-тю-тю...
Бит-бит-бит-бит-бити.
Фит-фит-фит-фит-фити,
Чурт-чурый, чурт-чурый,
Чеп-чеби, чеп-чеби.
Физдики-миздики, киздики, чирт.
Чика-чиру, чика-чиру,
Чика-чиру-чикиюр,
Тирриур, тирриур-пәк.
Физулики-мизули титиррр...

Аяк астындагы печән арасында чикерткәләр кайнаша, аһ, аларның сайравы үзенә күрә бер могҗиза, үзенә күрә бер оркестр, музыка. Көн эссе булганда, чикерткә тавышы аеруча зыңлап тора.

– Бик каты сайрый чикерткәләр, челлә эссесе яндыра, кичкә яңгыр яумагае, – дип, үзалдына сөйләнеп алды Миңкәй бабайлар сыман.

Малай, ике кулын артка куеп, алга таба китте. Бу мәлдә ул сабый оланга түгел, гомер кичергән зиһенле картка охшый иде.

Зурлар кебек, кулны артка куеп,
Йөри идек таптап болынны...

Ул сазлык ягына борылган гына иде, әллә каян тәкәрлек килеп чыкты, аңа башка тәкәрлекләр кушылды да, кызганыч тавыш белән чиелдый-чиелдый, Миңкәйнең баш очында әйләнә башлады.

– Һәй, – диде Минтимер. – Курыкмагызсана! Тәкәрлек, курыкма, мин синең ояңны туздырырга килмим. Мин синең йомыркаларыңны ватарга килмим, мин синең балаларыңны урларга килмим. Тимим мин сиңа.

Тәкәрлекләр, баланың игътибарын үзләренә тартып, оялары яныннан читкә алып китәргә тырыша иде.

– Бар, юлыңда бул, кеше, син безнең ояларыбызга якын килмә, әнә теге якка, безнең ојлардан икенче якка кит, – дип чиелдый иде тәкәрлекләр.

– Әй, аптыраттыгыз инде! – диде Миңкәй. – Киттем-киттем, миңа сезнең балаларыгыз кирәкми, миңа кузгалак кирәк.

Шулай сөйләнә-сөйләнә, Миңкәй болын түренә китте.

Ул күп итеп кузгалак җыйды да, ялан тәпиләрен ялтыратып, авылга элдерде. Сазлык яныннан узганда, аның каршысына тагын тәкрарлек өере күтәрелде. Алар тагын сабыйны ояларыннан читкә алып китәргә маташа иде.

Чыннан да, ул юраганча, кичкә таба, челләдән кызган һаваны яңгыр болытлары каплап алып, шәп итеп яңгыр явып китте.

– И-и, балам, – дип каршы алды аны әнкәсе. – Сыерыбыз ташланган иде, катык урынына кузгалак салырмын, иншалла. Рәхмәт, балам, кулыңнан куан!

## Абага чәчәге

*Абага чәчәген тел астына салган*
*кеше күренмәс була.*

Халык әкияте

Мал асларын тазарту, мал-туарга салам-печән ташлау, җыелган тиресне чуманга (талдан үрелгән зур кәрзин) тутырып, лапас артына ташу – оланның вазифасы. Яшьли тырыш, эшчән, ару белмәс булып үсте Минтимер. Арыган чакта да ул анасына, апаларына, абыйсына арыганлыгын сиздермәскә тырыша иде.

– Җегет кеше арыганын башкаларга әйтеп тормый инде ул! – ди олылар.

Әткәсе кайткач, тормышлар бераз рәтләнде. Шәрип абзыйны күмәк хуҗалык җитәкчесе итеп тә куйдылар.

Кичләрен җыелышып сәкедә утырганда, ниләр генә сөйләнми, халыкара хәлләр турында да, күрше-коланнарның тормыш-көнкүреше хакында да, борынгы риваятьләр, нәсел тарихы турында да дәресләр иде ул кич утырулар.

Гадәттә, ата кеше сүз башлар иде.

– Минем чын исемем – Шаһишәриф, – дияр иде ул. – Ул «шаһ» белән «шәриф» сүзләреннән ясалган. «Шаһ» – падишаһ, патша дигән сүз. «Шәриф» исә абруйлы, данлы, Мөхәммәд пәйгамбәрнең яраннарына карата әйтелә торган дәрәҗә булган.

«Димәк, безнең әткәйнең исеме «дәрәҗәле патша» дигәнне аңлата», – дип уйлады Миңкәй.

Сабый ата-бабасының риваятьләрен тыңлап үсте. Булачак шәхесне риваятьләр генә түгел, мал-туар да сиздерми генә тәрбия кыла. Ул апаларының, абыйсының, әнкәсенең малларга карата иркә сүзле, миһербанлы булуларын еш күрә иде.

– Сыерга, кәҗәгә ягымлы, иркә сүзләр әйтсәң, сөтне тагын да күбрәк бирә! – ди апалары.

Дөрестер дә!

Бәлки, кешеләр дә назлы сүзгә мохтаҗдыр?

Минтимер гомере буе йомшак тавышлы, назлы сүзле, әмма кирәк чакта кырыс та, гадел дә була белде.

Табын янына җыелгач, хатирәләр башлана. Ни өчен әти-әнисе Хантимер, Минтимер исемнәре кушкан балаларына? Баксаң, аларның кыз балалары күп булып, ир оланнары туган бере үлә барган икән. Андый очракларда тагын йола ярдәмгә килә: Үлмәс, Тансыкбай, Яшәр кебек исемнәр пәйда була. Тимер кебек чыдам, нык, сәламәт булсын дигән өмет белән ата-ана оланнарына Хантимер, Минтимер исемнәре куйдырган. Чыннан да, Хантимер дә, Минтимер дә саутаза булды, шөкер.

Минтимер басынкы, уйчан булып үсте. Ул да сабый чакта хыялыйрак иде. Әкиятләр, ата-бабасы сөйләгән риваятьләр аның хыялый күңелен уята торган иде. Ул кара бураннарда, туктаусыз яңгыр яуган чакларда избачка чаба. Элек

китапханәне «избач», ягъни «изба-читальня» дип атыйлар иде. Әнә шул избачтагы китапларны Миңкәй күп укыды. Ә менә абага чәчәге турындагы риваять аның күңеленә ныклап кереп утырды. Абага чәчәгенең могҗизасы турында аның олылар авызыннан да күп тапкырлар ишеткәне бар иде инде.

Имеш, абага җәй уртасында, ай тулган төннең уртасында чәчәк ата икән. Шул чәчәкне өзеп тел астыңа салсаң, син күренми торган кешегә әйләнәсең, ди. Миңкәйнең кулына Гадел Кутуйның «Рөстәм маҗаралары» исемле китабы да килеп керде, шуны кулдан-кулга йөртеп укый-укый туздырып бетерде балалар. Китапта Рөстәм исемле бер малай абага чәчәген өзеп авызына каба да, күренмәс кешегә әверелеп, фронтка китә. Һәй, немецларне кырып кына сала, малай, мин сиңа әйтим. Фашистларның штабларына кереп, карталарын-документларын алып, совет командирларына тапшыра, корал саклана торган складларын шартлатып йөри, ә үзенә берни дә булмый.

Чыннан да, абага бик тә серле үсемлек бит. Ул елга бер генә, җәй уртасында, ай тулган төнне, сәгать уникедә генә чәчәк ата. Ә төн уртасында карурманга ничек барасың, урман тулы сугыштан качып килгән бүре чирүе. Уникешәр тавыш белән улый башласалар, куркуыңнан котың ботыңа җитәр. Шулай да кызыксыну куркуны җиңде. Йөрәкле малайлар карурманга абага чәчәк атканны карарга китте. Абага чәчәген өзеп, тел астына салып, күренмәс кешегә әверелеп йөрсәң, иллә дә кызык булыр иде бит.

Урман белән авыл арасында Шүрәле чокыры бар. Ниләр генә сөйләмиләр ул Шүрәле чокыры турында, имеш, соңга калган юлчыларны, чокырыннан чыгып, Шүрәле кытыклап үтерә икән, имеш, Шүрәле кытыклаган кеше исән калса, гел көлеп йөри торган җүләргә әйләнә икән. Төн уртасында малайлар Шүрәле чокырын урап йөгерде. Шөкер, Шүрәле чыкмады. Кайтканда да Шүрәле чокырын әйләнеп уздылар. Алай да котлары ботларына җиткән иде.

Ләкин батыр йөрәкле малайлар, әллә ничә тапкыр куркыныч Шүрәле чокырыннан узып, урманга барса да, абаганың чәчәк атканын күрмәде. Алар күренмәс кешеләргә әверелә алмады.

Соңыннан Минтимер белде: абага ул чәчәк атмый, споралар, хлорофиллар һәм тамыр бүленүе белән үрчи икән. Минтимернең өмете киселде, күңеле төште. Матур әкият, маҗаралар вәгъдә итә торган гүзәл риваять җимерелде. Малай олыгаеп киткәндәй булды, ул тагын да җитдиләнде һәм шуннан соң беркайчан да тормышка ашмас хыяллар белән мавыкланмады. Аның вөҗүденә, бәдәненә, зиһененә прагматиклык, аек акыл белән фикер йөртү рәвеше салынган иде инде.

## Кече ураза

Әбиләр җәйге чиллә вакытында да, урак урганда да, печән чапканда да ураза тотуларын өзмәде. Бичаракайлар утызар сутый арыш урганда да, никадәр кибеккән, сусаган булсалар да, авызларына бер тамчы су капмыйча, бер бөртек арыш-бодай ашамыйча, кайберләре һуштан язып егылгаласа да, уразаларын бозмады. Савап өчен, Аллага инанган өчен, оҗмахка керер өчен, алар шушы җәзаларны кичкән, күрәсең.

Малайларның да ураза тотканы бар.

Шулай бервакыт, Шүрәле чокырын узып, алар урманга җиләккә китте. Миңкәй җиләкчеләр арасында иң чосы, иң остасы иде. Аның савыты иң алдан тула. Моның сере бар. Җиләк исе бөтен аланны тутырган, савытка салганы

тагын да ислерәк, малайларның түземсезләре иң башта җиләкне савытка түгел, үз авызына сала. Беттең! Син инде савытыңны тутыра алмаячаксың. Хуш исле тәмле җиләкнең өзеп алган берсе синең авызга кереп барачак. Берне кабам, икене чиләккә салам дип җыйсаң да булмый. Нәфес үзенекен итә, җиләк үзеннән-үзе авызга кереп китә.

Ачыккан балага бу үзенә күрә ураза, тыйлыгу, нәфесеңә юл куймау сынавы була килде. Нәфесеңне тыя белү сине күп бәлаләрдән коткарачак, ул синең холкыңны ныгытачак. Нәфес – шайтан ул, һаман котырта, берне генә кап, тагын берне генә аша, ди.

Шуңа күрә кагыйдә бик кырыс: савытыңны тутырмыйча торып, бер генә җиләкне дә авызыңа аткарма! Юкса җыйган җиләгең савытыңның төбен дә күммәячәк. Савытыңны мөлдерәмә, түбәләмә итеп тутыргач, күзең күргән җиләк синеке, рәхәтләнеп аша.

Җиләк белән тулган чиләгеңнең өстен мәтрүшкә учмасы белән каплап куясың. Җиләк түгелмәсен өчен дә, кояш эссесеннән саклау өчен дә. Түбәләмә тулган чиләк белән өйгә кайтып керүгә үк өйдәгеләр:

– Һай, Минтимеребез җиләкне күп җыйган! – дип, аны мактап каршы ала.

Сабыйга шуннан да зур сөенеч бармы икән! Кылган эшеңне күреп, мактау сүзе әйтсәләр, бигрәк тә рәхәт булып китә.

Тулы савыт белән мәтрүшкә учмасын күргәч, әнкәсе:

– Менә хәзер җиләк белән мәтрүшкәле чәй эчәрбез! – диде.

## Хәдичә апа

Минтимер шахмат белән мавыга башлады. Шахмат бик кыйбат тора. Мәктәптә дә ул берәү генә. Чиратыңны озак көтәргә туры килә. Шуңа күрә Минтимер аны үзе ясарга булды. Шахматның шакмаклы тактасын әтмәлләү әллә ни кыен булмады. Юка фанер тактаны кул пычкысы белән кисте дә акка кара шакмаклар ясады. Ә менә фигураларны ясавы шактый катлаулы булып чыкты, дөрес, пешкаларны, филләрне, тураларны ясау да авыр түгел иде, тик атларны ясау озакка сузылды. Агачтан кисеп алынган түмәрчекне атка әверелдерергә кирәк иде. Минтимернең кулы алтын бит аның. Атларны ясап бетергәч, кара, ак буяуга буяп, кояшта киптерде. Шәп килеп чыкты. Буш вакытларында, бигрәк тә коеп яңгыр яуган чакларда, малайлар, эшне дә, ашауны да онытып, печәнлектә, җылы мунчада шахмат ярышлары уздыра иде. Шахмат уены аның тормышының нигезе булып ятты. Шахмат алдын-артын уйлап эш йөртергә өйрәтә, ордым-бәрдем кеше шахматчы була алмый.

Минтимер бер яктан икенче тарафка сугылмас шәхес булып өлгереп килә иде инде.

Малайның бу басынкылыгын укытучысы Хәдичә апа бик тиз күреп алды, һәм аны сыйныфның старостасы итеп сайладылар. Мәктәпне тәмамлаганчыга чаклы ул алыштыргысыз лидер була килде. Аның язмышына «син – лидер» дип язылган иде инде.

Гадәттә, лидерлар шау-шулы, җитәкче булырга атлыгып торучы, үзен лидер буларак күрсәтәсе килүләре белән аерылып тора. Андыйлар күзгә керә, гаугалы дан яуларга тырыша. Минтимер калай әтәчләрне яратмый иде. Калай әтәчләр алар күп сөйли, аз эшли, эшләгәндә дә кеше күрсенгә генә эшләгән булып кылана. Дөресе шул: андыйлар эшләгәнгә салыша, эшләгән булып маташа. Ю-ук, әтәчлекне сөймәде ул. Миңкәй – җитди олан, төпле олан. Шушы кечкенә

генә татар авылында туып үскән малайга андый тактика, стратегия, итагать, эчке культура каян килгән?

Ул беркайчан да атасының күмәк хуҗалык җитәкчесе булуын купайтмады, атасы белән мактанмады, персидәтел малае дип, колхоз эшләреннән йөз чөермәде, башкалар кебек, ни кушсалар, шуны эшләде. Үзенә ташламалар таләп итмәде. Шуңа күрә дә аны сыйныфташлары да, укытучылар да хөрмәт итә, аңа ышана, аңа таяна иде.

Яшерен-батырын түгел, укытучылар, гадәттә, авыл җитәкчеләренең балаларына үзгәрәк мөнәсәбәттә тора. Авыл Советы яки колхоз җитәкчесенең баласына билгене арттырып кую дисеңме, дәресен белмәсә дә, аны яклау дисеңме. Гади колхозчы баласын битәрләгәндә, башлык баласының башыннан сыйпау дисеңме – барысы да булды инде. Минтимер бу яклауларга, бу ташламаларга мохтаҗ түгел иде, чөнки ул бөтен фәннәрдән дә алда бара. Җитәкче баласы булганы өчен түгел, тырышлыгы, үз зиһене белән лидерлыкка чыккан үсмер иде ул.

Шулай да дәрес әзерләргә өлгермәгән очраклары да булгалый. Каралты-курада да, колхоз эшләрендә дә бөтерелә торгач, өйгә бирелгән эшне эшләү арткарак күчә. Бәс, дип уйлый укытучы Хәдичә апа, димәк, балаларга бирелгән теманы дәрестә ныграк, тирәнрәк аңлатырга кирәк. Хәдичә апа балаларның ерак урманнан чәнәшкәгә салып утын алып кайтканнарын да, «уфалла» арбасы белән ерак болыннан печән ташыганнарын да белә, ашлама өчен көл җыйганнарын да, черемә ташыганнарын да күзәтеп тора, шуңа күрә ул укучыларының сабакны дәресханәдә үзләштерүләрен тели һәм кайбер очракларда кыен хәлдә калган укучыларга ташламалар да ясый торган иде.

Башка яшьтәшләре кебек үк Минтимер дә каралты-кура тирәсендә бөтерелә, колхоз өмәләрендә дә катнаша, персидәтел малае буларак, аңа артта калырга, эштән качарга ярамый, ул үрнәк булырга тиеш. Шушы гадәтенә күрә укытучы Хәдичә апа Минтимерне хөрмәт итә.

Атасы гелән әйтә иде:

– Балалар, бүтәннәр авыр эшкә алынмаганда да сез баш тартырга, хәйләләргә тиеш түгел. Чөнки сез – персидәтел балалары, сез Алланың кашка тәкәләре түгел! – дия торган иде.

Зиһенле бала үсеп килә.

Бу – ата-ана тәрбиясе. Хәйләләп, авыруга сабышып, авыр эштән калу юк. Бу – авыл йоласы һәм, ниһаять, милләт йоласы!

Мөгаллимә Хәдичә апа балаларның авыр заманада, сугыштан соңгы ачлы-туклы елларда яшәгәннәрен ачык күрә, аларны эчтән генә кызгана да иде. Ләкин кызганганын балаларга күрсәтми. Кызгансаң, бала гел кызганганыңны өмет итеп яши, кызгану, яклашу баланың үҗәтлеген киметә, тырышлыгын азайта, ул кызганганны-яклаганны көтеп ялкаулана. Бу бала мәктәпне тәмамлаганнан соң еш кына югалып кала, үзе өчен көрәшми, кемнеңдер ярдәмен көтеп яши башлый. Гадәттә, көткән ярдәм аңа килми, кеше төшенкелеккә бирелә, бар кеше дә аңа дошман булып күренә, ул эше уңмас адәмгә әйләнә, аңа бер генә юл кала: хәмер эчү яки үч алу. Аның күңелендә уңыш казанганнарга кызыгу, аларның дәрәҗәсеннән көнләшү хисе уяна. Кызыгу хисе көнләшүгә әверелә, көнләшү үч алуга илтә. Чибәр кызның йөзенә көндәшенең агу сибүе, матур биючене биемәслек итеп кыйнап, аякларын имгәтеп ташлау, үзенекеннән яхшы тормышлы кешенең йортына ут төртү – барысы да көнләшү вә үчлектән килә. Үчле кешенең йокысы тыныч булмый, ул гел ничек итеп дошманыннан

үч кайтару турында гына уйлап ята, аның ашказанында ялкынсыну барлыкка килә, ялкынсыну җәрәхәткә әверелә, ә инде җәрәхәтнең олы авыруга әйләнүен көт тә тор. Андый кеше үзенең булдыксызлыгын, уңышсызлыгын башкалардан күрәчәк, бәс, башкалар гаепле икән, ул алардан үч алырга тиеш булып чыга. Аһ, нинди читен тормыш, үзенә дә читен, аның юлында очраган бүтәннәргә дә читен тормыш әзерли ул көнчел бәндә.

Шушыларны аңлау каян килә? Әлбәттә, гаилә тәрбиясеннән, йолалардан килә, әмма тулы канлы шәхесне алар гына да тәрбияли алмас иде, әгәр дә саф канлы шәҗәрәң, каннан килә торган нәселдәнлек булмаса...

Авылда башлангыч сыйныфларны укытучы Хәдичә апага каян килгән бу сиземләү, бу зиһният?

Минтимер Шәрип углы Шәймиев гомере буе беренче укытучысы Хәдичә апа Әхмәдуллина турында уйланыр, аңа сокланыр, аңа чиксез рәхмәтләр укыр.

«Хәдичә Әхмәдуллина» дип өстәге җитәкчеләр генә әйтә торган иде укытучыга, бөтен балалар өчен ул бары тик «апа» булды. Бу мөгамәлә укытучы өчен иң олы дәрәҗә иде. Ни өчендер хәзер балаларга «Хәдичә Ибраһимовна», «Габделхәй Гатиятуллович» дип эндәшергә кушалар. Бу гадәт татар халкының йоласында юк иде бит, хәтта олуг ханнарга, падишаһларга да «син» дип, олыларга «абый», «ага», «абзый», «әфәнде», «туташ», «ханым» дип эндәшә торганнар иде. Олуг шәхесләребез Нәкый Сиражетдинович Исәнбәткә дә, Бакый Идрисович Урманчега да без «Нәкый ага», «Бакый абый» дип олылап эндәшә идек. Бу бер дә әдәпсезлек саналмый, киресенчә, шәхесләрне зурлау булып аңлашыла торган иде. Ә нигә укытучыңа, остазыңа олылап «Хәдичә ханым», «Минтимер әфәнде», «Шәриф ага», «Мансур абый» дип эндәшмәскә?! Бу – йоладан килгән бөек культурабызның чагылышы бит, бер дә культурасызлык түгел!

Киләчәктә боларның барысы да Минтимергә ярдәм итәчәк, һичшиксез ярдәм итәчәк.

## Ганимәт кашыгы

*Бервакыт өстәл янына бөтенебез ашарга җыелып утырдык. Өстәл уртасында тары боткасы салынган зур табак тора. Тәлинкәләр юк инде ул чакта, барыбыз да шушы табактан ашыйбыз. Ботканың кыл уртасына май салынган. Ботканы кашыкка аласың да майга манып кабып җибәрәсең. Мин, бәләкәй булгач, чамалап бетермичә, боткага бабайдан алдарак сузылганмын, күрәсең, бабай үзенең кашыгы белән шалт итеп кулыма сукты.*

Минтимер Шәймиев

Укытучы Хәдичә апа үз эшенең остасы, балаларның остазы иде. Һәм ул бик бәхетле иде, ничәмә-ничә буын баласы аның дәресханәсендә укып, белем алып чыкты. Башлангыч сыйныфта төпле белем алса, бала җиденче сыйныфта югалып калмый. Җиденче сыйныфны яхшы тәмамласа, сигезенчегә барып кергәч, каушап калмый, урта мәктәптә төпле белем алса, алга таба инде ул ныклы адымнар белән бара. Хәдичә апага үз сыйныфында укып чыккан йөзләгән шәхесләр чиксез рәхмәт укый. Аның иң төп сыйфаты шул иде: ул, балаларның ата-анасы кем булуына карамастан, аларга тигез бакты. Начар укыганнарга яхшы укучыларны ярдәмче итеп куйды, фәннәр җиңел бирелгәннәргә исә мавыгулар уйлап таба торган иде.

Сыйныфта Минтимер алда бара, аңа уку җиңел бирелә, шуңа күрә ул агачтан үзе ясаган шахмат уены белән мавыга, электр техникасы, машина техникасы белән әвәрә килә, аңа ат җене кагылган. Җитешмәгән җире юк.

Оештыру сәләте дә бар малайның, кычкырмас, ләкин тыңлатыр, әйтерсең лә ул аларның яшьтәше түгел, әйтерсең лә ул – укытучы.

Мәктәптә әбәт ашау оештырырга кушылган иде. Табын өчен, ризык китертү өчен Минтимер җаваплы.

Сыйныфта болагай бер укучы бар иде, үзе кыланчык, пәрвайсыз, әнкәсе әйткәндәй, «җүнсез-җүнтек» бер малай инде шунда. Кылана торгач, бу шаталак башка бер кешенең ашын түктерде. Минтимер түзмәде, атасының сугыштан алып кайткан саллы кашыгы белән малайның шәрә маңгаена кундырды. Катырак сукты бугай. Малай кычкырып куйды, аннан ике учы белән кашык төшкән урынны каплады, елый ук башлады, аның маңгае күбеп чыккан иде. Минтимер сукты сугуын, әмма үзе малайны кызгана иде. Малай озак еламады елавын, шуннан соң аның тәртибе майлаган кебек булды. Ләкин Минтимер һаман тынычлана алмады, катырак сукты, гаделсезлек кылды бугай ул...

## Чукмар

*Бүре, никадәр куәтле һәм акыллы булса да, барыбер бүрек була.*

Аталар сүзе

Шәрип абзый, туры айгырына атланып, уң кулына чукмар (кистән) тотып, бүре ауларга китте. Мылтык белән бүрегә теләсә кем бара аны, ә менә син мылтыксыз, чукмар белән генә барып кара. Анысын бик сирәк аучылар гына булдыра ала. Шәрип Шәймиев әнә шул сирәк аучыларның берсе иде. Тәвәккәл, гаярь ир.

Бүреләр күрше авылларның ферма түбәсендәге саламны актарып тишек ясаган да, абзарга кереп, әллә ничә сарыкның башына җиткән. Әнәк авылының фермасына гына бүре төшмәгән. Димәк, көт тә тор, Әнәк сарыкларына да ач бүреләр тарафыннан һөҗүм булачак.

Байтак йөрде аучы урман тарафында һәм эзләгәненә юлыкты да. Бүреләр, гадәттә, бишәр, җидешәр булып ауга чыга. Менә урманнан биш бүре тезелешеп чыкты. Яланга чыксыннар, урманга кереп кача алмаслар, дип уйлады Шәрип абзый. Ат шомлы итеп акрын гына кешнәде дә колакларын шомрайтты.

– Сабыр... – дип пышылдады аучы. – Сабыр...

Бүреләр абайлаганчы һөҗүмгә атылырга кирәк. Бүре чирүе юл такырына чыгып, урманнан байтак ара киткәч, Шәрип әче итеп сызгырды да атының янбашына типте. Турайгырның бүре авына беренче генә чыгуы түгел, ул бүре өстенә барырга өйрәтелгән иде.

Бүреләр көтелмәгән бу сызгырудан, өсләренә ажгырып килүче айгырны күреп, төрлесе төрле якка сибелде. Шәрип-аучы чирү башына төбәп чаба иде. Калган бүреләрне ян-якта калдырып, ул чирүбаш артыннан элдерә. Тәҗрибәле, азау ярган бүре иде ул. Кар салган якка, урман ягына каерырга маташа, белә ул, ат тирән көрттә чаба алмый, карга баткан айгырга бүре үзе ташланырга мөмкин. Шәрип-аучы аты белән аның урманга юлын кисте, азау ярган бүрене такыр басудан чабарга мәҗбүр итте. Бүре бөтен көченә ыргый, ат та тиресеннән чыгардай булып чаба. Шәрип-аучы бүрене куып җитеп узып китте дә, каршысына төшеп, аны Шүрәле чокырына таба чабарга мәҗбүр итте. Үзе атын тыя төште, чапсын бүре, хәле бетсен, ат хәл алсын. Бераз хәл алгач:

– Әйдә, малкай, – дип, ул тезгенне җибәрде, турайгыр белән бүре арасы якынайганнан-якыная бара, алар инде янәшә чаба, бүрене бастырып куганда, Шәрип, өзәңгегә аягүрә басып, киерелеп, кирәмәйләп, бүренең ике колагы арасына чукмар белән орды. Бүре тәкмәрләп артта калды. Шәриф атын борды, бүре кар туздырып ауный иде, аучы җәһәт кенә атыннан сикереп төште дә итек кунычыннан артыш таягын чыгарып, ыржайган бүренең теш арасына тыкты, алдан әзерләнгән сүс катнаш нечкә каеш белән үрелгән киндерәне аның танавына урап та куйды. Берни эшли алмый җанвар шулай иткәч. Тәвәккәл Шәрип бүренең аякларын бәйләде, атын чакырды. Чиру башы кырык килолап булгандыр, аучы аны, көчкә күтәреп, атының сыртына аркылы салды.

Шәрипнең беренче тапкыр гына тере бүре алып кайтуы түгел иде бу, шулай да колхоз идарәсе янына кеше күп җыелды, бигрәк тә бала-чага. Минтимер дә шунда иде. Хәзер атасы бүрене тире җыючыга алып китәчәк, карап калырга кирәк. Балалар да, олылар да бүренең алагаем олы булуына шаккатты.

Минтимер бүре янына килде. Аның карашы бүре күзләре белән очрашты. О-о, ул караш! Тыныч ятса да, буйсындырылган булса да, әгәр аны ирекккә җибәрсәң, бугазыңны чәйнәр.

Минтимер бүрене кызганып куйды. Бичара! Балаларың синең аудан бәрән алып кайтканыңны зарыгып көтәдер, ә син юк, бәрән дә юк, ирек тә юк – чирүбашы тоткын. Хәзер аны, төбәк мәркәзенә – Пучыга алып китеп, тире җыючыларга тапшырырлар. Бүре тоткан аучыга байтак кына акчалата бүләк тә бирәләр бугай.

Бүре сабыйның үзен кызганганын аңлады кебек, ул тагын Минтимергә бакты.

Акыллы бүре үз хәлен бик яхшы аңлый иде, ахрысы. Аның карашы сабыр. Шулай, кайчандыр син чирүбаш, кешеләрнең йөрәгенә курку салган батыр бүре булгансың, хәзер синең тиреңнән йә бүрек тектереп киярләр, яки, тагын берничә тире кушып, толып тектерерләр.

Бала-чага шау-шу килә, олылар да, бүрегә карап, Шәрип-аучының батырлыгына соклана. Минтимер генә сөенми.

Йокларга яткач та, бүре карашы аның күз алдыннан китмәде.

Бичара җанвар! Синең хәлдә калырга язмасын!

## Бер уч арыш

*Тамак тәмугка кертә.*

Аталар сүзе

Сугыш елларында да, сугыштан соң да халык ачыкты. Дөресен генә әйткәндә, халыкның тамагы ипигә 1965 елларда гына туя башлады. Бичара игенче үзе иккән игеннән бер уч ашлык алса, әгәр дә аны тотсалар, башы бетте – ун елга утырталар иде. Икмәкне бүлгәндә дә, бер хезмәт көненә, уңышына карап, 100-200 грамм арыш тия торган иде. Шуңа ничек мал асрыйсың, шуңа ничек өс-баш карыйсың? 365не 100гә тапкырласаң, 36,5 кило арыш тия, ягъни ел буе эшләгәнеңә ике пот икмәк чыга. Авыл кешесенә ал юк, ял юк, ул елның 365 көнен дә колхозда эшләргә мәҗбүр ителгән. Колхозчы «курорт, шифаханә» сүзләрен ишетеп тә белми.

1861 елда түгел, әле 1961 елда да Россиядәге авыллар өчен крепостное право бетерелмәгән иде.

Сугыштан яраланып кайткан Шаһишәрипне колхоз рәисе итеп куюлары Әнәк халкында өмет-ышаныч уятты. Күрше хуҗалыкларда сугыштан соңгы

чорларда күпме кешене, икмәк урлауда гаепләп, зинданнарга ташладылар. Нинди урлау ди тагын, бер кесә, бер уч бодай өчен утырталар иде. Булыр-булмас бөтен малын тартып алып, шәрә калдырдылар.

Чирек гасыр персидәтел булып эшләү дәверендә Шаһимөхәммәт улы Шаһишәрип Шәймиев бер генә кешене дә төрмәгә утыртмады.

– Бар, улым! – дия иде Шәрип абзый. – Ындырда эшләүчеләргә, арыш уручыларга әйт, бер бөртек тә итәк асларына алмасыннар. Иртәгә тентү килә.

Минтимер йөгерә-йөгерә барысын да кисәтеп чыга торган иде.

Иртәгесе көнне кичкырын, көтү кайтыр алдыннан, уракчылар да кайта башлады. Шулвакыт авылга тентү килеп төште. Тентүчеләрнең бигрәк тә кәттәләре иде бу юлы. Жуков «газигы»на төялешеп килгәннәр: алда утырганы – прокурор Кашапов, арттагылар – башкарма комитет вәкиле, участок милиционеры. Соңгысы берәрсен кулга аласы булса дип килгәндер инде. Болар, кемне дә булса икмәк белән тотып, бүген үк алып китәргә ниятли иде, ахрысы. Чакырылмаган кунаклар чәйләгәндә, Шәрип абзый, тарантасына утырып, алардан алдарак юлга кузгалды, уракчылар инде басудан олы юлга чыгып килә иде.

– Алмадыгызмы? – дип сорады Шәрип абзый.

Хатыннар дәррәү җавап кайтарды:

– Жу-ук, Шәрип абзый! – диеште.

Ләкин Шәрип аганың очлы күзе иң артта посып кына торган бер хатынны күреп алды, ул тарантасыннан төште дә хатын янына килде.

– Тиз бул! Юл кырына түк арышыңны! Тегеләр килеп җиткәнче түк тә туфрак белән капла!

Персидәтелнең тавышы каты булды, ахрысы, хатын елый башлады:

– Шәрип абый, ике балам ач утыра, өйдә бер кабарлык бөртек юк!

Башкалар да, яшь хатынны кызганып:

– Бигрәкләр дә кызганыч балалары! – дип, кыюсыз гына аны яклады.

– Таш капчыкка утыртсалар, ике балаң кемгә калыр? – диде Шәрип абзый. Уракчыларның бичара хатынга теләктәшлеге аның күңелен йомшартты бугай, ул хатынны җилтерәтеп читкә алып китте. – Бар, тиз бул, анау теге уйсулыкка кереп ят! – дип, Шәрип абзый хатынны чокыр сымак җиргә таба төртте. – Тикшерүчеләр киткәнче тыныңны да чыгарма!

Хатыннар да, персидәтел дә бу урыннан тизрәк китәргә ашыкты. Ул арада калкулыкта тентүчеләрне төягән машина күренде.

Хатыннар машинага юл сапты, машина туктады. Аннан тентүчеләр коелды.

– Нинди җыелыш монда? – диде Кашапов.

– Яхшы урганнар хатыннар, малатсы! – диде Шәрип абзый. – Ике норманы тутырып кайтып киләләр, арыганнар.

– Карап караек! – дип, Кашапов кулы белән ишарә ясады. Милиционер хатыннарны тенти башлады.

– Күрмисезмени? – диде Шәрип абзый. – Аларның кесәләре буш, бер җирләре дә калкып тормый.

– Калкып тора! Менә бит! – дип, милиционер әдәпсез рәвештә олы күкрәкле хатынны капшый башлады.

Барысы да айгылдап көлде. Бары тик бер кеше генә көлмәде, прокурор Кашапов кына. Персидәтел Шәймиев хатыннарның арыш белән тотылмаганнарына сөенеп көлде, прокурор исә хатыннарны тота алмаганына көенеп кара коелды.

Тикшерүчеләр буш кул белән кире борылды.

Бичара яшь ана караңгы төшкәнче чокырда ятты, аны күршесе килеп алды:

– Киттеләр теге яэҗүҗ-мәэҗүҗләр! Чык! – дип кычкырды ул.

Бервакыт Шәрип абзый эштән арып-талып кайткач, соң гына йокларга яткан иде, каты итеп тәрәзә кага башладылар.

– Ай Алла-Ходаем! – дип, Нәгыймә апа сикереп торды.

Аннан соң Шәрип абзый тамак кырды:

– Кайсы йөри төн уртасында! – дип киенә башлады.

Ирле-хатынлы күршеләр иде бу, аларның өч баласы ачлыктан хәлсезләнеп ята. Баксаң, болар, кешеләр йоклап беткәнне көтеп, колхоз амбарына ачкыч ясатып, дүрт-биш кило арыш урлаган икән.

– Урлавын урладык та, – дип сүз башлады хатын, – Әбүбәкер әйтә, сизенсәләр, Шәрип күзенә ничек карарбыз, кешеләр ни әйтер, диде дә менә урланган арышны монда китердек, кире йөрсәң, кеше күрер, дидек. Зинһар, кичер, Шәрип абзый.

Шәрип, ир белән хатынны ияртеп, кире амбарга алып китте, арышларын кире салдырып, амбарны бикләп кайтты.

– Атасы, – диде Нәгыймә ана, – балалары ач бит, бер-ике уч калдырырга иде, ичмаса.

Шәрип, ишетелер-ишетелмәс кенә:

– Калдырдым инде... – дип, янә йокларга ятты.

## Моң

Үсмер Минтимер авылда «көнчелек», «көнләү» сүзләрен күп ишетте. Көнләшүчеләрне дә, көнләүчеләрне дә күп күрде. Икесе дә яман хис, начар гамәлдер.

Нәрсә соң ул көнчелек, ә нәрсә ул көнләү, көнләшү?

Көнчелек ул – кызыгу, башкаларның байлыгына астыртын кызыгу, башкаларның хатынына әхлаксыз рәвештә кызыгу, сәләтлеләрнең сәләтенә усал кызыгу. Кызыгу ул үзе гөнаһлы гамәл түгел. Мин бик яхшы биючегә, мәшһүр җырчыга кызыгам, ләкин миндә аларга карата көнчелек хисе барлыкка килми. Мин Илһам Шакировка, Рудольф Нуриевка кызыгам. Мин алардан көнләшмим, чөнки, аларга зыян эшләсәм дә, аяк чалсам да, алар урынын яулап ала алмаячакмын. Мин аларның сәнгатенә кызыгам, аларның сәнгатеннән ләззәт алам, мин аларны хуплыйм, хөрмәт итәм. Әгәр дә кызыгуның төбендә мәкер ятса, ул көнчелеккә әверелә.

Ә көнләү нәрсә? Ир хатынын көнли. Сәбәпсез көнли. Хатынының гаебе дә юк, ләкин ире билгесез кешедән хатынын көнли. Бу – ирнең үзенә ышанмавы, хатыным миннән яхшырак егетләр белән чуалмыймы дип уйлавы, ягъни ул – үзен башкалардан кимрәк дип, кимсенү, мескенлек чире йоктырган бичара.

Көнләшү дә көнләүгә бик якын. Бусы конкретрак шәхескә карата кулланыла бугай. Ул *хатынын дустыннан* ***көнли.***

*Ул бәк* ***көнчел*** *кеше,* бу очракта кеше байлыгына кызыгу да, хатынын башкадан ***көнләү*** мәгънәләре дә хәрәкәт итә.

*Ул Габдулланы хатыныннан* ***көнли.*** *Ул Габдулладан* ***көнләшә.***

Дөньяда, кешелек җәмгыятендә көнчелек кебек нәҗес хиснең булганы юк һәм булмас та.

Кызыгудан башланган һәм көнчелек, көнләү, көнләшү дәрәҗәсенә җиткән

бу нәҗеснең үрнәген фани дөньяга Адәм галәйһиссәламнең баш углы Кабил күрсәтә.

Адәм угыллары Кабил белән Һабил Әкълимә исемле бер кызны сөя. Әкълимә Һабилгә чыгарга тели, Кабил аларга комачаулый, тарткалаш китә. Адәм әйтә:

– Икегез дә Аллаһка корбан чалыгыз! Аллаһ кайсыгызның корбанын кабул итә, Әкълимә шуңарга кияүгә чыга! – ди.

Икесе дә корбан чала, Аллаһ Һабилнең корбанын кабул итә. Чөнки Һабил ихластан корбан чала. Кабил исә мәҗбүр булганга гына корбан китерә. Һәм, үч итеп, Кабил Һабилне үтерә.

Җиһанга беренче үтерешне дә әнә шул көнчел кызыгу алып килә.

Багыгыз сез дөньяга! Сугышларның, үтерешләрнең, хыянәтләрнең, талауларның барысы да кеше малына, кеше хатынына, җиргә, нефтькә, алмазга, алтынга мәкерле кызыгудан башланган. Бүген гарәп илләрендә бара торган кан коешларга да төрле сылтау табалар, ә төп сәбәбе – нефть ятмалары...

«Бер генә кешегә кызыктым – гармунчыга, бер генә кешедән көнләштем – гармунчыдан!» дип әйтер Минтимер, Илбашы булгач.

Чыннан да, аның сабый чагында гармун уйнарга бик тә өйрәнәсе килә иде. Өйләрендә гармун да бар югыйсә, ләкин, күпме генә шыңгырдатса да, көй чыкмый. Гармун уйный белү – егетлек галәмәте, гармунчысыз уен юк, туй юк, озату юк, каршы алу юк, гармун ул – татарның җаны.

Аларның курасыннан ерак түгел оста гармунчы яши, аның улы Зөфәр дә гармунчы. Зөфәр болай гына кергәнме аларга, әллә атасы чакыртканмы аны Минтимер янына, Зөфәрдән гармун уйнарга өйрәнсен дип, шайтан белсен. Бераз сөйләшеп утырганнан соң, Зөфәр кулына гармунны алды, аның шунда гармуны әллә нишләде, тавышы үзгәрде, Зөфәр, башын бер янга кыегайтып, көй эченә кереп китте, бу «Озату» көе иде. Зөфәрнең бармаклары телләргә тияр-тимәс кенә кагылып уза. Бас ягындагы урта тел кызганыч тавыш белән чинап-чинап ала.

Йә кайтырбыз, йә кайтмабыз,
Сау булыгыз, туганнар.

Бу – Минтимернең атасын, бик күп абыйларны сугышка озаткан көй. Минтимер дә, атасы да, башкалар да көй тәэсирендә иде. Анасы Нәгыймә апа, күз яшьләрен башкаларга күрсәтмәс өчен, яны белән борылды да яулык очы белән битен каплады, нәкъ 1941 елның 22 июнь көнне кебек. Үзәк өзгеч көй иде бу.

Басу капкасын чыккач та
Күтәрелде тузаннар;
Йә кайтырбыз, йә кайтмабыз,
Сау булыгыз, туганнар.

Көй туктады.

– Әйбәт гармун! – диде Зөфәр.

Миңкәй могҗизаның шаһиты булды һәм аның башыннан бер фикер-теләк сызылып узды: ничек булса да, мин дә шулай уйнарга өйрәнәчәкмен дип, күңеленә беркетеп куйды.

Ул мунчада да, лапас кыегына менеп тә гармун уйнарга маташып карады,

тик гармун Миңкәйгә буйсынырга теләмәде, бармаклары аны тыңламады. Күпме генә тырышса да, ул гармуннан көй чыгара алмады.

Узар вакытлар. Күп эшләр майтарыр Әнәк сабые Миңкәй, олы дәрәҗәләр яулар, Минтимер Шәймиев булып, дөньякүләм дан казаныр. Җиңә-җиңә алга, югарыга күтәрелеп, бик бәхетле булыр ул.

Илбашы буларак туган көнен уздырганда, аңа бик кыйммәтле, затлы бүләкләр тапшырырлар. Ләкин иң кыйбатлы бүләк әле тапшырылмаган булып чыгар.

Туган көн туе гөрләп барганда, сәхнәчеккә Минтимер Шәймиевнең хәләл җефете Сәкинә ханым, ике углы – Айрат белән Радик чыгар һәм алар бәйрәмдар хөрмәтенә аның иң яраткан җырын җырлый башлар. Зал да, бәйрәмдар да тынып калыр... Салмак кына моң агыла, Минтимер шатланган да, каушаган да. Гаиләсенең бергәләп җырлаганын аның беркайчан да ишеткәне булмады. Гаиләсе аңа сюрприз әзерләгән иде. Монда бер ачыш, бер могҗиза барлыкка килде. Сәкинәнең җыр сөйгәнен, үзе дә җырлаганын ул яхшы белә, ә менә балалары – инде ир-егетләр булып өлгергән улларының җырлаганын беренче тапкыр ишетә. Ул, кунакларга сиздермичә генә, куаныч яшьләрен сөртеп алды. Җыр тәмам булды, Минтимер Шәрип улы күңеле тулганын күрсәтмәс өчен уңайсыз гына елмайды.

– Сез үзегезнең иң бәхетле кеше икәнегезне кайчан белдегез? – дип сорады бер журналист бәйрәмдардан.

Минтимер Шәймиев бу сорауны көтмәгән иде, каушабрак калды һәм уңайсыз елмаеп әйтте:

– Менә шушы мизгел минем бәхетем! Хатыным, балаларым халык моңы белән мине тәбрикли! – диде. – Сезгә тагын бер серне ачыйм инде: шушы туган көнемә килеп җиткәндә, мин гомерем хыялына ирештем. Гармунда яраткан көйләремне чыгара башладым. Менә сиңа мә, Ходай, күрәсең, шулай кушкан, – бәхет өстенә бәхет!

## Мунча

*Тәңгә – мунча, җанга юк!*
Габдулла Тукай

Кичләрен капка төбендә картлар утыра, яшьләр, сабыйлар олылар янына елыша. Агайлар анда сугышта күргәннәре, әсирлектә булганнары турында сөйли. Сабыйлар йотлыгып тыңлый. Сугыш маҗараларыннан соң өлкәннәр тормыш-көнкүреш, колхоз эшләре, гореф-гадәтләр турында сүз башлый. Шулчак ерактан:

– Зөфә-әр! Мунча өлгерде-е, ка-айт! – дигән тавыш ишетелде.

– Бар, әнкәң мунчага чакыра! – диде кемдер.

– Кайта-а-м! – дип, Зөфәр өйләренә таба йөгереп китте.

Сөйләүче агай Зөфәрнең ялан аякларыннан бөтерелеп калган тузанга карап торды да әйтте:

– Һәй, почык борыннар! – диде. – Сез мунчаның ни икәнен беләсезме соң?..

Җавап та көтеп тормаенча, ул сөйләп тә китте:

– Мунча ул – фәйләсүфиә, дускайларым! Мунча бик борынгы заманнарда татарларда барлыкка килгән... Әүвәл-әүвәлләрдә халык мунчаның ни икәнен белмәгән. Су коенган, суда юынган да вәссәлам. Билгуар ханның өч углы булган. Баш ханзадәнең исеме – Ташкын, уртанчысыныкы – Чапкын, төпчекнеке Качкын икән. Берзаманны Билгуар хан баш угланы Ташкын ханзадәне өйләндерергә ниятләгән. Төрле илләрдән бик күп гүзәлләр килгән.

Ханзадә иң гүзәл кызга өйләнгән. Шәпләп туй ясаган болар. Туй узуга, ханзадәне билгесез чир баскан. Табибларны да, өшкерүче-төкерүчеләрне дә, сихерчеләрне дә, тылсымчыларны да чакырганнар – берсе дә ханзадәгә ярдәм итә алмаган. Ханзадә үлгән. Йола буенча икенче ханзадә Чапкын тол калган җиңгәсенә өйләнергә тиеш булган. Туйлап алганнар. Шул ук хәл кабатланган. Ханзадә Чапкынны да чир баскан, ул да озакламый вафат булган. Олуг хан Билгуар уйга калган: бу тол киленгә өйләндерсәм, соңгы углымны да әрәм итәрмен, ни киңәш бирәсез, дип, ул яраннарын җыйган. Яраннар әйткән: бу киленең синең юха елан булырга тиеш, дигән. Аның юха икәнен белер өчен син мунча ясат, уртасына чуерташлар өеп, мич чыгарт, каты итеп мунчаны кыздыр. Вә әйт киленеңә, без яңа йола-гадәт башлыйбыз, никахтан соң кәләш белән кияү мунчага барырга, чишенергә, бер-берсен юындырырга тиеш, диген. Юха еланнан туган хатынның кендеге булмый. Чөнки еланнар күкәйдән чыга. Чебешләрнең, бәбкәләрнең, еланнарның кендеге юк. Имезүче җан ияләреннән туганнар кендекле була, чөнки алар ана карынында ярала.

Шулай итәләр дә, никахтан соң кияү белән кәләш мунчага китә, хатынның күлмәген салуы була, кияү аның бүксәсенә бага, ә бүксә шоп-шома, анда кендек юк икән. Ханзадә Качкын тиз генә мунчадан чыга да ишекне терәтеп бикләп куя. Хатын никадәр ялварса да, ханзадә ишекне ачмый. Бераздан тавышлар тына, ишекне ачып керсәләр, ни күзләре белән күрсеннәр, теле белән ишек тоткасына уралган елан үлеп ята, ди. Никахтан соң бергәләп мунчага керү йоласы әле дә булса саклана. Матри, почык борыннар, чибәр кызга өйләнәм дип, юха еланга юлыга күрмәгез!

## Ахириләр

Ат көтүен сакларга алар өч малай чыкты.

Иртән бер ярка кабыклы бәрәңге ашап, бер чокыр шикәрсез кабакчәй эчкән, икенчесе көрпә катыштырылган бер телем алабута ипие ашап, өченчесе арыш боламыгы йотып чыккан малайлар төш вакытында бик каты ачыкты. Алар чишмәгә ятып су да эчеп карады, печәнне чабып алганнан соң тырпаеп калган ат кузгалагының каты көпшәсен дә чәйнәп бакты, ачлык барыбер үзенекен итте. Эчтә бүреләр улый иде.

– Булмый болай! – диде Зөфәр. – Кузакка барырга кирәк.

Карар нык иде. Ат көтүче өч малай болай план корды:

– Берәү балаган янында каравылчының игътибарын басудан читкә тартып, сөйләндереп тора, калган икәвебез коры яр эченнән борчак басуына үрмәләп, күпме булдыра ала, күлмәк эченә кузак тутыра. Соңыннан каравылчыны сөйләндергәнгә дә тигез итеп бүлеп чыгабыз!

– Килештек! – диде үсмерләр.

– Ә кем каравылчыны сөйләндерә?

– Миңкәй сөйләндерә! – диде Фәрит.

– Персидәтел малае... – дип каршы төште өченче көтүче.

– Бигрәк яхшы, аны урлаша дип уйламас.

Үз араларына ышанычлы иптәш итеп алганнарына Минтимер эчтән генә куанды, димәк, алар аны чит итми, аңа ышана.

– Киттек! – диде Фәрит.

Минтимер атына атланды да каравыл чатыры ягына чаптырып китте, калганнары җәяү коры яр юлы буйлап атлады. Коры ярга җитәрәк, малайлар

үлән арасыннан үрмәләп барды, аннан соң шуышуга күчте, ул арада Минтимер, атын чаптырып, каравылчы куышы янына килеп җиткән иде инде. Ул бабайга сәлам бирде, тамак кыра-кыра, каравылчы чатырыннан чыкты.

– Ә-ә, синмени әле бу, Миңкәй улым! Арумы?

– Аруын ару, кем, бабай.

– Ни йомыш, олан?

– Йомыш шул, бабай: мәктәптә җәйге каникулларга өйгә эш биргәннәр ие...

– Соң?

– Соң... Менә син сугышта күргәннәреңне сөйләсәң, мин аны эстинә гәҗитәсендә чыгарам, кызык булыр иде...

– Һәй, кем, улым Миңкәй, хәтер бетте...

– Хәтереңдә калганнарын булса да сөйлә...

– Әйдә кер минем куышка, торма анда кояшта, атыңны агачка бәйлә, – дип, бабай чатырына кереп китте, атын бәйләгәч, Минтимер дә эчкә узды.

Куышта караңгы, салкынча иде. Каравылчы бабай, сырмасына кырын ятып, тамагын кырыштыргалап, сүз башлады.

– Кыхым, Жуковны күрдем мин фронтта... Ай-яй гаярь кеше ие ул... Ну исемсез калкулыкны алганда тутырды инде халыкны пүләмүт астына...

Солдат бабай озак сөйләде, аның белән бергә Минтимер Берлинга хәтле үк барып җитте.

Берлинны алгач, малай куыштан чыкты, атына атланып, коры яр тарафына элдерде. Ул барып җиткәндә, күлмәкләрен шыплап тутырган «юан корсаклар» коры ярдан чыгып килә иде. Шулчак Минтимер ат өстеннән атасының урта юл буйлап, нindидер бер кешене тарантасына утыртып, бирегә таба килгәнен күреп алды. Малайлар уйсулыкта, аларны күрми. Борчак караклары туп-туры тарантас каршына килеп чыгачак! Һәм тотылачак!

«Әгәр районнан килгән палномочный булса, бетте баш, әткәйне дә, мине дә, малайларны да апкитәчәкләр!» дигән уй сызып узды малайның башыннан.

Ул атының корсагына типте, бераз чапкач, яр астына карап сызгырды. Малайлар башларын күтәреп аңа бакты, Минтимернең кул хәрәкәтләреннән, аның хафалы чыраеннан алар хәтәр килгәнен аңлап алды. Минтимер аларга кире борылырга, ярга кереп посып ятарга кушты. Озакламый тарантас тавышы, персидәтел айгырының пошкырганы ишетелде. Минтимер атын аскы якка, олы юл тарафына куды. Тау астыннан атлы тарантас күренде, Минтимер атасы каршысына китте. Шәрип абзый атын тыя төште, аның янында, чыннан да, район вәкиле утыра иде.

– Улым, син нишләп йөрисең монда? Нишләп син көтүдә түгел? – дип сорады атасы.

– Әткәй, – диде Минтимер, – анда малайлар калды, мин каравылчы бабайдан фронт хәлләрен язып алдым.

– Алайса, ярый, – дип, атасы атына чөңгерде, айгыр тарантасны ындырга таба алып китте.

Тарантас узып киткәч, Минтимер сызгырды, яр чокыры борылмасыннан малайлар чыкты. Алар, өчесе бер атка атланып, болын ягына чапты. Минтимер, малайларны төшереп, басуга кереп бара торган атларны җыярга китте. Малайлар кузакны өлешкә тигез итеп бүлеп чыкты. Минтимер әйләнеп кайтканчы алар кузакка кагылмаган, бергә җыелгач, дәррәү кузакка ябырылдылар.

Шушы вакыйгадан соң малайлар – Минтимерне, Минтимер малайларны «ахирәт дус» дип йөртә башлады.

## Мунча пәриләре

Татарда «Ахирәткә чаклы дус булырга» дип ант итү йоласы бар. Малайлар, егетләр бил каешларын, пәкеләрен алмаша һәм аулак урында бер касәдән икесенең каны тамызылган кымыз яки сөт эчә, бер-берсенә ахирәткәчә дус булырга сүз белән ант итә. Шуннан соң егетләр бер-берсенә «ахири» яисә «ахир» дип эндәшә башлый...

Ахириләр тагын киңәшкә җыелды.

– Избачка Таҗи Гыйззәтнең пьесалар китабы кайткан! – диде Минтимер.

– Кайда укыйбыз? – диеште ахириләр.

– Зөфәрләр мунчасында!

– Ие, безнекеләр бүген мунча яккан иде, башта кунаклар керер, аннан әткәй-әнкәй керер, аннан бала-чага, мунча сәгать сигезләрдә бушар... – диде Зөфәр.

Узганында Фәритләр мунчасында Шәриф Камалның хикәяләрен укыганнар иде, «Сәмруг кош» хикәясен укыганда, ләүкәгә дә, идәнгә дә ятып, тәгәрәп, эчләре катканчы көлделәр.

...Менә күктә оча торган машиналар уйлап табучыларның ярышы уза, Германиянең дә очкычы ялтырап тора, Россиянеке дә ким түгел, французлар да яңа очкычлары белән мактана. Ә инде татар очучысының агачтан эшләнгән машинасын күреп, бөтен дөнья халкы көлә башлый. Менә Айга очып китәргә старт бирелә, немец машинасы корымга батып ватылып төшә, Россиянеке дә, Айга барып җиталмыйча, керәчине бетеп, кире борыла, французның очкычы бөтенләй Ай кырында күренми, ә Гайнетдин исемле татарның агач очкычы Ай тирәли очып йөри дә, тегесе үзенең кәләпүшен Айга кадаклап төшә.

Татар галәме шаулаша:

– Әйтергә кирәк Гайнетдингә, кәләпүшен ике-өч көн алмыйча торсын! Әһле дөнья белсен татарларның кем икәнен!.. – ди.

Бу юлы ахириләр, Таҗи Гыйззәтнең пьесаларын укып, бичара Гөлчирәне кызганып елады.

Мунчада сукыр лампа яктысында китап укып, малайларның бите-башы сөремгә буялып кайта, шуңа күрә аларга «мунча пәриләре» дип кушамат тактылар.

Шулай итеп, кемнең мунчасы җылы, малайлар шунда күчә-күчә китап укый. Виктор Гюгоның «Хокуксызлар»ын, Гарриет Бичер-Стоуның «Гәрчич оҗмахы балалары»н, Марк Твенның «Том Сойер маҗаралары»н, Кави Нәҗминең «Язгы җилләр»ен, Мирсәй Әмирнең «Агыйдел»ен күмәкләп укый-укый туздырып бетерделәр.

– Иң яхшы китап – кулдан-кулга йөреп тузган китап, – дия иде китапханәче апа.

## Медаль

Минтимергә уку бик җиңел бирелә иде. Аның алтын медальле аттестат алачагына бөтен мөмкинлекләр дә бар. Барча имтиханнарын да ул «бишле»гә генә бирде. Җәмәгать эшләрендә дә актив катнаша, тәртибе дә «бишле». Алтын медаль алырга өмет тә, ышаныч та бар иде. Әмма Минтимергә алтын медаль эләкмәде, көмеше дә тәтемәде. Күрәсең, әллә кайдагы татар малаена алтыннары җитмәгәндер инде.

Кыскасы, Мәгариф министрлыгында утыручы чиновниклар ни өчен

Минтимер Шәймиевкә алтын медаль бирелмәгәнлеккә сылтавын да тапканнар. Имеш, ул математика мәсьәләсен чишкәндә «тригонометрик функцияләрне» кыскартуда иң кыска юл белән китмәгән.

Кызганыч ки, югарыда утыручы «педагоглар» әллә кайдагы, Актаныш ягындагы Әнәк авылы баласын рәнҗеттек дип уйламагандыр да. Ихтимал, ул алтын медальне кемгә дә булса барыбер биргәннәрдер.

Әлбәттә, бу гаделсезлек Минтимернең кәефенә китереп сукты. Күрәсең, аны алда катлаулы, кайчакларда аңлашылмый торган тормыш көтә булыр. Мәктәп диварларын калдырып, олы дөньяга аяк басканда, ул бу турыда нык уйланыр.

Шуңа күрә Минтимер «алтын медаль» вакыйгасын тиз онытты. Гаилә йолалары, Әнәк авылы гадәтләре, Пучы мәктәбе укытучылары Минтимер Шәймиевне олы юлга сыйфатлы итеп, тәвәккәл итеп, максатчан итеп әзерләгән иде инде.

Һәм Минтимер Шәймиевне мактаулы тормыш юлында күп тапкырлар орденнар, медальләр белән бүләкләрләр, аның күкрәге никадәр киң булса да, ул бу орден-медальләрне сыйдыра алмас иде.

Ленин ордены – 1966
Хезмәт Кызыл Байрагы ордены – 1976
Халыклар дуслыгы ордены – 1987
II дәрәҗә «Ватан каршындагы хезмәтләре өчен» ордены – 1997
I дәрәҗә «Ватан каршындагы хезмәтләре өчен» ордены – 2007
III дәрәҗә «Ватан каршындагы хезмәтләре өчен» ордены – 2010
IV дәрәҗә «Ватан каршындагы хезмәтләре өчен» ордены – 2014
Дуслык ордены – 2015
Батырлык һәм намус ордены – 2004
«Әбүгалисина» исемендәге көмеш медаль – 2011
Ахьдз-апша ордены – 2004
«Россия-ЮНЕСКО»ның истәлекле медале – 2005
Әл-Фәхр ордены – 2005
Изге Сергий Радонежский ордены – 2005
Минин-Пожарский ордены – 2005
Олимпия ордены – 2008
«Татарстан Республикасы каршындагы казанышлары өчен» ордены – 2010

Бу орден-медальләр Минтимернең хәләл көче белән яулаган алтын медален бирмәгәннәренә язмыш тарафыннан түләү, бурыч кайтару иде.

## Ике капчык тары

1949 елда, атасы Шаһишәрип хуҗалык җитәкчесе чагында булды бу хәл.

Сугыш тәмамланган булуына карамастан, халык әле һаман ачыга, кешеләр ачтан шешенә, шешенә-шешенә ябыга башлый, аннан шыр сөяккә калып үлә иде. Халык язга чыкты. Үләнгә ябырылды. Җир сөрергә, булган орлыкны чәчәргә кешеләрнең хәле юк иде. Атларга, сыерларга өй түбәсеннән төшкән, күгәреп беткән салам черееге ашаталар. Сабан тарту түгел, үз аягында көчкә басып тора бичара хайваннар.

Хуҗалык рәисе коммунист Шәрип Мөхәммәт углы төннәрен йоклый алмый иде. Аның башында бер генә уй: «Ничек халыкны ачлыктан коткарырга, ничек итеп соңгы ашлыкны туфрак куенына тапшырырга? Чәчми калсак, ни ашарлар, тагын ачлык булачак...»

Ә райкомнан чәчүне башлагыз дигән хәбәр юк, имеш, туфрак өлгермәгән. Өлгергән, туфрак пешеп беткән, чәчәргә вакыт!

Әйе, йокыдан калды Шәрип абзый. Күпме фаҗига, күпме үлемнәрне күреп, сугышта да агармаган чәченә чал төште. Инде төзәлеп беткән, онытыла язган җәрәхәтләре сызлый башлады. Нишләргә? Малларны ничек аякка бастырырга, кешеләрне ничек сакларга?

Аның инде ничә төн ут йотып ятканын хатыны Нәгыймә генә аңлый иде шикелле.

Ул сак кына иренә эндәште:

– Син, атасы, ике ут арасында шулай яначаксың, – диде.

Шәрип абзыйның бугазыннан ут булып «у-уф» бөркелеп чыкты.

– Нишлим соң, карчыгым? – диде чарасыз Шәрип.

– Күрәләтә хайваннарны да, кешеләрне дә үтереп булмый бит инде, атасы! Әткәй ничек кылган булса, син дә шулай кыл!

Шаһимөхәммәт ачлык елларда арыш биреп авыл халкын үтермичә калган!

Шәрип абзый юрганын атып бәрде дә, сикереп торып:

– Карчык, куй җиз самавырыңны! – дип кычкырды.

Тавышка балалар уянды. Ут кабыздылар. Нәгыймә апа самавыр шалтырата башлады, балалар да сикерешеп торды, олы якка керделәр, әмма аталарының елмайган йөзен күргәч, ни әйтергә белми аптырап калдылар.

– Яхшыга гына булсын! – дип теләделәр.

Таң алды иде бу. Чәй янында бәйрәм кебек иде.

Чәйләп алгач, кыска тунын, күн белән тышланган каракүл бүреген киеп, Шәрип абзый идәнгә каты басып чыгып китте.

Силсәвиттә кизү торучы хатынга язу тоттырып, ул амбар башлыгына җибәрде. Кәгазьдә: «Маяда торган ике капчык тарыны ашлык җилгәрә торган урынга китерт. Калганын аңлатырмын! Маһирәне аш пешерүче хатыннарны уятырга җибәр, таң атуга, чәчүгә төшәбез, олы казанны ындыр табагына китерт. Ботка пешерер өчен суга җибәр. Калган чәчүлекне, минем атка төяп, ерак басуга ташыт», – дип язылган иде.

Ул икенче кизүчегә дә язу биреп, каядыр юллады. Бу кәгазь бригадирга аталган иде: «Аягында басып торган ат белән үгезгә башак бирдерт, яхшылап эчерт. Аннан аларны сабанга җигегез, сөрә барырбыз, чәчә барырбыз».

– Бетте-китте! Вәссәлам! – дип кычкырды Шәрип абзый.

Бу мәлдә ул ярым шашкан кыяфәттә иде. Юк, бу аның шашканлыгы түгел, шатлыгы иде. Ниһаять, хәл ителде, бер кабаладан котылды. Бу аның шәхси карары иде! Бу аның авыл халкын коткаруы иде!

Ашасыннар, тамаклары туйсын! Яхшырак эшләрләр. Ләкин туфракны кысыр калдырмабыз, орлыкны амбарда күгәртмәбез! Беләм, бер уч икмәк өчен ун елга утырталар. Беләм, бер сәнәк салам урлаган өчен катыр сөрәләр. Сөрсеннәр, ичмасам, минем вөҗданымда тап булмас!

Бу көнне авыл халкы кабердән терелеп чыккан өрәкләр кебек иде. Чәчүчеләргә генә дип пешерелгән ботка аеруча нык ачykканнарның балаларына да бераз эләкте. Персидәтелнең бу тәвәккәллеген бәһаләп бетергесез иде.

Чәчү тәмамлангач, Шәрип абзый тагын кычкырды:

– Машалла! Хәзер орлыкны казып ала алмаслар!

Ләкин Нәгыймә бикә генә тыныч түгел иде.

– И Ходаем, ниләр генә булыр инде, утыртмасалар гына ярар иде, мин бер итәк бала белән тагын ни кылырмын?! – дип, эчтән яна иде бичара.

Бер кабаладан котылды, икенче кабалага килеп капты Шәрип абзый.

«Яхшы» кешеләр әләкне төбәк мәркәзенә түкми-чәчми ирештергәннәр.

Куркыныч комиссия, Шәймиевләр капкасын киереп ачып, курага керде. Барысы да артык җитди, бар агентлар да кысыр көн портфель тоткан. Прокурор Кашапов, итек кунычына чат-чот чыбык белән суккалап:

– Саботаж! – дип кычкырды. – Контра!

Бу сүзләрдән Нәгыймә бикәнең дә, балаларының да җаннары табан астына төшеп китте шикелле.

– Кем рөхсәт итте сиңа башбаштаклык кылырга?! – дип ысылдады Кашапов. – Дәүләт малын әрәм-шәрәм итәргә партячейка карар чыгардымы? Партия куштымы? Райком куштымы?

– Беркем дә кушмады, – диде Шәрип абзый. – Башкаларны монда бутамагыз, зинһар! Алар гаепле түгел.

– Алайса, кем кушты? – дип кычкырды прокурор. – Контра капиталистлармы?

– Вөҗданым, намусым кушты! – диде Шәрип абзый.

– Күрсәтәм әле мин сиңа вөҗданыңны!.. Ничә пот тары чәчтегез? Бәлки, син кем беләндер чәчүлеккә дип калдырган тарының яртысын урлагансыңдыр?

– Мин бер бөртек тә үземә алмадым, барысын да халыкка бирдем! Ә күпме тарының ач колхозчыга ашарга бирелүе, күпмесенең чәчелүе турындагы кәгазьләр кладаушикта, бригадирда!

– Тентегез! – дип кычкырды Кашапов.

Ике милиционер, ике пүнәтәй йортка, амбарга, лапасларга кереп актарына башлады, ләкин берни дә таба алмады.

– Ни өчен райком белән киңәшмәдең? – диде Кашапов.

– Калганы турында мин адвокат каршында гына сөйли алам! – диде Шәрип абзый һәм тоткынны алып китәргә әзерләнгән арбага үз теләге белән менеп утырды. – Борчылмагыз, – диде ул хатынына, балаларына. – Минем гаебем юк. Озакламый кайтырмын, Алла боерса!

Халык үз җитәкчесен басу капкасына чаклы елый-елый озата барды.

## Мин гадел хөкемдар булачакмын!

Район үзәге Пучы урта мәктәбендә укыганда, Минтимер хокук фәне белән кызыксына башлады. Ул вакытта төбәк мәркәзендә Исрафилов фамилияле мәшһүр бер адвокат эшли, ул Минтимер укыган мәктәптә мантыйк фәне буенча керә иде. Укучылар аны бик ярата, хөрмәт итә. Халык арасында аның гаделлек сагында торуы, гаепсезләрне яклау нотыкларын оста-матур сөйләве һәм еш кына гаепләнгәннәрне аклап-яклап калуы турында сүзләр күп йөрде. Бер төркем үсмерләр төбәк мәхкәмәсенә шул адвокатның чыгышларын тыңларга бара башлады. Гаҗәеп кызыклы өлкә икән ул «хокукчылык» дигән нәмәстә. Гаепләүчесе дә хаклы кебек, аңа да ышанып утырасың, яклаучысы да хаклы кебек, аңа да ышанасың. Ә хөкемдар бөтенләй башка бер хөкем карары чыгарып куя.

Минтимер күңелендә хокукчы булу теләге борынлады. Ул, бөтен яклап тикшереп, гаепсезне аклар, бары тик гадел хөкем генә чыгарыр иде. Ул мохтаҗларны, кимсетелгәннәрне, мескенлеккә төшкәннәрне, бичараларны яклар иде.

Бу теләк атасы белән булган, чак кына фаҗигагә китермәгән вакыйгадан соң тагын да көчәйде.

Күп еллар җигелеп халык файдасына эшләгән колхоз җитәкчесен, Ватан азатлыгы өчен сугышта яраланган солдатны, намуслы коммунист Шаһишәрип Шаһимөхәммәт улы Шәймиевне гаепләп, прокурор Кашапов эш кузгатты. Халык пошаманга калды. Кашапов бик тә канәгать иде: Джеймс Бонд исемле америка шпионын тотканмыни, Рейхстагка Җиңү байрагын кадаганмыни!

Шәрип абзыйны гаепләр өчен прокурор ниләр генә кыланмады, аның курасында кабат тентү ясатты. Ләкин актарынучылар һични таба алмады. Казан-табак төбендә бер генә бөртек тары тапсалар да, Шәрип абзыйны күп елларга зинданга аткарачаклар иде. Халык яклады, дуслары яклады, иң зур дәлил үстергән уңыш булды, чөнки чәчүне үз вакытында оештыра алмау сәбәпле, районның күп хуҗалыкларында иген уңмады. Адвокат яклады, дәлилләр булмау сәбәпле, хөкем эше туктатылды. Партия райкомының әмереннән башка үзбаш эш кылганы өчен Шәймиев Шәрипкә каты шелтә биреп чыгардылар. Анысына гына түзәр батыр Шәрип.

Минтимер хөкем барышын башыннан ахырына кадәр тыңлап, карап утырды. Ул атасының аклануына чиксез шат иде, адвокатның гаепсез кешене ничек яклавына аның исе китте. Һәм ул эчтән генә:

– Мин адвокат булачакмын! Гаепсезләрне, гаделлекне яклаячакмын! – диде.

## Чибәркәй

Азагы яхшы тәмамланган шушы шомлы вакыйгалардан соң Минтимер янә укуга ябышты. Укуда аның эшләре һәрвакыт ал да гөл була килде. Хәтере шәп, тирә-якны, табигатьне, кешеләрне күзәтүе аның холкын ныгыта, мантыйкка өйрәтә. Минтимерне бигрәк тә кешеләрнең үзара мөнәсәбәте, мөгамәләсе кызыксындыра. Ул кемнең кайда нәрсә әйткәнен яхшы хәтерли һәм, вакытлар узгач, әгәр дә бу кеше әүвәл исбатларга тырышканына каршы сөйләсә, кирәк чакта ул аның нәрсә әйткәнен исенә төшерә. Шуңа күрә, үсмернең олыларча җитди фикер йөртүенә карап, аннан бераз шүрлиләр иде. Чыннан да, Минтимер үзен бик җитди тота иде. Шул сәбәпле, башка җилбәзәк егетләр кебек, ул бер кыздан икенчесенә күчми. Әйттем исә кайттым, Минтимернең моңарчы кызлар белән ныклап танышканы да булмады әле.

Ләкин аның күз тоткан кызы бар иде. Ул аны сиздермәстән генә күзәтә: кыз ничек көлә, ничек атлый, ничек киенә?

Кыскасы, ошый аңа бу чибәркәй. Ул вакытта татар авылында бай киенүче кызлар юк иде. Әмма чибәркәйнең итәге, күлмәге, яулыгы, хәтта олтанлы итеге дә, чытлыкыйлыгы да үзенә килешеп тора. Минтимернең басынкылыгы, кычкырып көлмәве, бары тик тыйнак кына елмаюы, ордым-бәрдем эш йөртмәве чибәркәйгә дә ошый. Аларның карашлары бик еш очраша. Тансы-мансыларда алар гел бергә бии. Читтән күзәтеп торганнарга алар менә дигән пар булып күренә. Бәлки, ул шулай булгандыр да әле, бер уйласаң. Ләкин язмыш дигәннәре кешеләрне һәрдаим сынап бага, кайсысын рәхимсез шартларга куеп сыный, кайсысын җиңелчә генә, фаҗигасез генә тикшерә.

Минтимер Казан авыл хуҗалыгы институтына укырга кереп, беренче курсны тәмамлап кайткач белде: аның чибәркәе башка егет белән йөри башлаган икән.

Хәер, Минтимер, бу хәбәрне ишеткәч, аның чыннан да дөрес икәненә ышангач бәргәләнмәде, кичерешләрен читләргә сиздермәде. Аналитиклар,

гадәттә, сабыр була, холериклар кебек, пычак тотып, кызын яки көндәшен суярга чыгып йөгерми.

Баш беткәнмени? Башка чибәрләр юкмыни? Китсен! Бәлки, икесе өчен дә шулай һәйбәтрәк булыр. Әгәр дә ул башкага тиз генә күчә алган икән, димәк, аның хисләре нык булмаган, какшау хисле кызның ниемә кирәге бар? Ул, бәлки, шул кеше белән бәхетле булыр. Нигә аларның бәхетенә комачау итәргә?

Минтимернең чибәркәй янына барасы да, аны күрәсе дә килмәде. Ул аңа битараф иде.

Бу уйлардан егеткә җиңел булып китте. Аның кәефе күтәрелде. Ул якты язмышына таба җиңел атлады.

## Син Кәтиев булырсың!

– Улым! – дип эндәшер аңа атасы Шәрип абзый. – Син МТС башлыгы Кәтиев кебек бул... Аның кулында халыкның өмете, аның кулында техника, аның кулында икмәкнең уңышы. Яхшы каралты-кура җиткезеп, абзар тулы мал-туар асрап, ныклы нигез корып яшә. Үз нигезең нык булсын, башкаларның нигезе дә нык булсын өчен, син авыл хуҗалыгы техникасына баш бул! Илне ашатучы кеше үзе ашаткан кешеләрдән фәкыйрьрәк яшәргә тиеш түгел! Икмәк булса, бар да була. Җыр булса, икмәк тә була, дип тә әйтәләр. Шулкадәр мул икмәк җитештергән кеше башкалардан хәерче булырга тиеш түгел!

Икмәксез җыр ул бары тик кайгылы җыр гына булырга мөмкин. Чыннан да, татар халкы мең ярым елдан арткан гомеренең соңгы 400 елын ачлы-туклы, кайгылы тормышта уздырды. Ләкин җыр чыгарудан, шигырь язудан, дастаннар иҗат итүдән, Коръәнне күпләп бастырып таратудан, мәчет, мәдрәсә корудан туктамады. Димәк, «икмәк булса, җыр да була» дигән гыйбарә яртылаш кына дөреслеккә туры килә. «Икмәк булса, җыр да була» әйтемен заманча таркатып баксак та, мантыйк аксый кебек. Шәймиев Илбашы булып утырганда, Татарстан икмәксез калмады. Аның шәкерте Рөстәм Миңнеханов Илбашы булганда да Татарстан икмәксез калмас. Икмәк булса, ит тә, сөт тә, кием дә, икътисад та – барысы да була. Бүген дә татар халкы авыл хуҗалыгы мәхсулаты* белән үз-үзен тәэмин итә. Мохтаҗларга да өлеш чыгарып тора әле, шөкер. Икмәк күп, ләкин халыкта бәетләр чыгару, дастаннар иҗат итү юк. Әдәбиятыбыз саекты. Композиторлар мәктәбендә шәхесләр азайды. Эстрадабызны бер күзәнәкле, гел кабатлана торган, бер-берсенә тач охшаш көйләр басты. Җырчылар азайды, җырлаучылар күбәйде. Әллә дөнья төшенчәләре үзгәрә, әллә табигать, йолалар үзгәрә, әллә халык мәкальләре, халык әйтемнәре искерә бара – белгән юк.

Минтимер атасына «мин адвокат булам» дип әйтергә базмады. Ул аның сүзләрендәге хакыйкатьне аңлады, әлбәттә. Егет техниканы, математиканы ярата. Чыннан да, ә нигә әле җир кешесе булмаска?

Киләчәктә ул әйтер: мин сәясәтче булмасам, җир кешесе булыр идем, дияр.

Минтимер «ә» димәде, «җә» димәде, документларын туп-туры авыл хуҗалыгы институтының механика факультетына илтеп тапшырды һәм ялгышмады. Ул атасының киңәшен тотканына беркайчан да үкенмәде. Адвокат булып киткән очракта да ул шөһрәт казаныр иде, ләкин тар даирәдә генә. Ә аның узган юлы, тар даирәләрне үтеп, киңәя, тирәнәя барып, бөтен халыкның казанышына әверелде. Шул түгелме бәхет?!

* Мәхсулат – эшләп чыгарылган мал, бу очракта – ит, май, сөт, икмәк.

Озак еллар Илбашы булып эшләгәндә, бик күп катлаулы мәсьәләләрне чишкәндә, Минтимер Шәймиев, чыннан да, адвокат сыйфатында иде. Казан Кирмәнен, Болгар каласын ЮНЕСКО исемлегенә керттерүдә аның адвокатлык эшчәнлеге бәһаләп бетергесез булды. Тарих әле Шәймиевнең бу өлкәдәге эшчәнлегенә яңадан әйләнеп кайтачак.

## Сабак

Минтимернең тәкъдирендә шулай язылгандыр инде, күрәсең, аны беренче курстан ук рәһбәр (староста, җитәкче) итеп куйдылар. Институтта укый башлаганчы ук, сентябрь аенда, аларны авылга бәрәңге алырга юлладылар.

Студентлар авылга бәрәңге алырга килгәч, кызыклар була иде инде ул.

Балачакта ук Минтимер үзе өчен эчке тәртип кагыйдәләрен булдырган иде, ул үз-үзен кулда тотарга өйрәтте. Кемнеңдер үз эшенә җавапсыз караганын, эштер-өштер эшләгәнен күрсә, күңеле әллә нишләп китә. Институтта укыганда да ул шушы, үзе төзегән кагыйдәләрне тотарга тырыша иде.

Курсның рәһбәренә эчке тәртип кагыйдәләреннән читкә чыккан студентны шелтәләргә, клубта кичә вакытында хәттин ашса, тиз генә җыелыш җыеп, студентның тәртибен тикшерергә, колхоз эшеннән кыяклаганнарга кисәтү ясарга хокук бирелгән. Ә бит андыйлар да табыла, алар үзләрен башкалардан өстен куя, башкаларны кимсетә торган гамәлләр кыла.

Толя Марамыгин атлы бер студент бар иде аның курсында. Үзе укуын да рәтләп укымый, колхоз эшеннән дә гел кыяклау ягын карый, иң алдан ялга утыра, иң арттан кузгала. Бәрәңгенең сабагын гына йолкый, бәрәңгесен туфракта калдыра. Минтимер, бу эшне сизеп, Толяны читкәрәк алып китеп кисәтү ясады:

– Кешеләр бу бәрәңгене халык өчен үстергән, көч түккән, ә син аны туфракта черергә калдырып китәсең! – дип битәрли башлаган иде, Марамыгин аның сүзен тыңлап бетермичә китеп барды да, аннан, борылып:

– Чаплашка! – дип кычкырды. – Какое твоё дело!

«Чаплашка» дигәненә Минтимернең исе дә китмәс иде, түбәтәй киеп йөргәч, «чаплашка» инде, әмма Анатолий бу сүзне шундый нәфрәтле, шундый мыскыллы итеп әйтте ки, Минтимер ни сабыр булырга тырышса да түзмәде, кулындагы зур гына бәрәңгене Толяга томырды. Бәрәңге тегенең уң чигәсенә килеп тиде. Ул, ике кулы белән бәрәңге тигән җирен каплап, җиргә чүгәләде. Минтимер каушап калды, шундук Толя янына атылды. Бичараның күз төбе күгәреп-кабарып чыккан иде.

Бу хәлне башка студентлар да күреп торды, алар Минтимер яклы иде. Шулай да ул, мине институттан куарлар инде дип, хафага калды.

– Курыкма! – диде сыйныфташы һәм авылдашы Гайнулла Гыйздуллин пошаманга калган Минтимергә. – Чакырсалар, без – шаһитлар да барырбыз. Чакырсалар, чатнатып әйт: СССРның Төп Законы ни? Дөрес! Конституция, диген. Конституциядә ничек язылган, диген. Конституциядә «СССРда халыкларның, милләтләрнең хокукы тигез!» диеп язылган, диген. Бәс, милли низаг чыгарырга маташканы, ягъни сине түбәтәй киеп йөргәнең өчен «чаплашка» дип мыскыллаган Анатолий Марамыгинның үзен комсомолдан чыгарып, институттан куарга була!

Авылдашы, шәриге Гайнулла Гыйздуллин, институтны тәмамлагач, Бөгелмәдәге һөнәр училищесы директоры булып китәчәк.

Чыннан да, эшне зурга җибәрмәделәр. Анатолий да бәлаләп йөрмәде. Ләкин ул үзенең тар маңгаена зур бәрәңге генә түгел, зур сабак та алган иде.

Сабак алды ябалак!

– Этнең койрыгын кем киссә, шуңар җизнәй дип әйтә! – диде ул Гайнулла дустына.

## Күңел күзе

*Күңел күзең күрмәсә, маңгай күзе – ботак тишеге.*

Халык әйтеме

Адәм баласына тумышыннан ук үзенә тиң пар әзерләп куелган, диләр. Акылы белән уйламастан, кеше үзенең парын эзли. Ир кеше ялгызы – ярты кеше, хатын-кыз ялгызы – ярты кеше. Бер-берләрен табышып, йола кушканча кушылгач кына алар done бербөтенгә әверелә, ди.

Ләкин егерме-утыз яшенә чаклы сөйгән ярын эзләп тә, адәми зат үз тиңен таба алмаска мөмкин.

Шулай итеп, бик күпләр үз парын табалмыйча үлеп тә китә.

Әллә ничә хатынга өйләнеп тә яхшы гаилә кора алмыйча – үзенең сөйгән ярын табалмыйча дөнья куйганнар бар.

Бөек бәхет ул – эзләгәнеңне табу.

Аллаһы Тәгалә адәм баласына күңел сиземләве биргән, шул күңел сиземләве аша ул, бу кыз синең ишең түгел, бу егет синең парың түгел, дип хәбәр ирештерә торадыр.

Ләкин кемдер шушы хәбәрне ишетми, кемдер аңа игътибар итми һәм нык ялгыша.

Адәм баласының маңгай күзе булган кебек, күңел күзе дә була.

Кешеләрнең күпчелеге дөньяны, вакыйгаларны, әйберләрне маңгай күзе белән генә күрә. Азчылык маңгай күзе белән дә, күңел күзе белән дә күрә. Алар күңел күзе белән вакыйгалар сөрешен, кешенең рухын, чуалчык вакыйгаларның серен күрә ала.

Күңел күзе сукыр кеше вакыйгаларны, процессларны маңгай күзе белән генә күрә, шуңа күрә ул, кешеләргә яхшылык кылам дип, яманлык кыла. Революцияләрнең барысы да кешелеккә яхшылык эшлим дип кылынган җинаятьләр. «Бөтен җир крестьяннарга!» дип, бай җир биләүчеләрнең җирен талап алып, крестьянга биргән булып, крестьянны да, алпавытны да хәерче иттеләр. Халыкка игелек кылам дип махсус оештырылган продразвёрстка талаулары булды. Яки болар – чынлап торып халыкка игелек кылабыз дип инанган талаучылар. Һәр ике очракта да бу – җинаять!

Күңел күзең күрмәсә, син хата артыннан хата ясарсың һәм бәхеткә ирешә алмассың. Башкаларны да бәхетсез итәрсең.

Минтимернең күңел күзе ачык иде.

Күңел күзе ул – навигатор, күңел күзе ул – компас!

Күңел күзе күрмәсә, маңгай күзе – ботак тишеге.

Аның юлында да яхшы кешеләр дә, яманнары да очрады. Күңел күзе ачык Минтимерне күңел сиземләве коткара килде, шөкер!

Ләкин аның булачак яры кайда, кайларда йөри торгандыр, билгесез.

Билгесез, ләкин Минтимернең күңеле сизенә, бу дөньяда бар аның пары, бар! Ул аны һичшиксез эзләп табар, алар барыбер кавышыр, иншалла!

## Сәкинә

*Бер мәхәббәт табар өчен*
*Бер яшьлегем җитәрме?..*
Разил Вәлиев

Сәкинә ул сөйкемле кызның исеме, Сәкинә Ахунова. Сак, сабыр, тыныч мәгънәсен белдерә ул «Сәкинә» исеме. Кешенең исеме аның холкын билгели, диләр, дөрестер дә. Алга таба күрербез!

Сәкинә белән Минтимернең нәсел тарихы да бераз охшаш. Сәкинәнең бабасы да таза гаиләле, көр тормышлы булган, димәк, мал таба белгәннәр, бәрәкәт саклый белгәннәр.

Сәкинәнең ата-бабасы, әби-анасы Казан артындагы Күн авылы кешеләре.

Һо-о, Күн авылының тарихына кереп китсәң, чыга алмассың, билләһи.

1552 елда Казанны җимергәч, ханлыкны юкка чыгаргач, Явыз Иван буе арба чәкүшкәсеннән узган һәр татар оланының башын чаптырырга әмер бирә.

– Татарларны Казаннан куып, авылларыннан сөреп чыгарырга! Аларның йортларына рус воеводаларын урнаштырырга! Татарлар Казан каласына кырык чакрымнан да якын утырмаска, йорт салмаска тиеш! Татарларны Казанга якын җибәрмәс өчен, юлларга сак, каравыл гаскәрләре куярга!

Тикшереп карагыз сез: Казаннан кырык чакрымнан якын авылларның исемнәре татарныкы булса да (Тылмачи, Майдан, Карагуза), анда татарлар түгел, руслар яшәп ята. Кырык чакрым ераклыктагы Шәле, Күн, Әлдермеш, Чыршы авылларында татарлар яши. Борынгы йола дәвам итә. Рус белән чиктәш булып яшәргә курыкмаган батыр халык яши ул авылларда. Усал халык.

Күн, Шәле авыллары Явыз Иван заманасында ук булган. Каһарманнар яши ул авылларда. Һәр авылның үз һөнәре булган. Шәлеләр шәл бәйләгән, Күннәр күн иләгән, баш бирмәгән, бай булган. Көр тормышлы халыкның каны уйнаган, Сабан туйлары атналарга сузылган, кыз урлау йолалары әле һаман да яшәп килә. Хәтта Совет хакимияте дәверендә дә Күн белән Шәле үзләренең мәчетләрен җимерттермәгән, манараларын кистертмәгән.

«Күн» атамасының тарихы болай. Авыл борын заманда Казанга бик якын утырган булган. Җиңүчеләр бу халыкны Казаннан кырык чакрымга күченеп китүен таләп иткән. Халык буйсынмаган. Сугыш башланган. Мәскәүгә буйсынган әнчек татарлар халыкны үгетли башлаган.

– Күчеп утырырга күн инде! – дип, алар авыл башлыгына ялварган. – Күнмәсәгез, Иван, тагын да зур гаскәр белән килеп, барыгызны да кырып бетерәчәк!

Шуннан соң гына халык күченеп, шушы урынга килеп урнашкан һәм бу авылга «Күн» дип исем кушканнар.

Халык телендә икенче бер риваять тә йөри.

Имеш, Күн авылы иң кирәкле һөнәр – тире иләп, күн эшләү белән дан тоткан, иләгән тире каймак кебек йомшак, каеш кебек чыдам булган.

...Менә 1931 ел килеп җитә. Көр тормышлы хуҗаларны кулак дип гаеплиләр. Революция булгач, җыен галах, кәҗә дә асрый алмаган хөрәсән ялкаулары коммунистларга куштанлыкка язылa. Күн авылының бер куштаны Шакирҗанның кайсы малы кайда ятканлыгын әләкләп, аны зинданга яптырырга уйлый. Шакирҗан Ахунов хатыны Гөлсем белән, бөтен малларын талаучыларга калдырып, эш коралларын гына алып, Казанга күченеп китә.

Волков урамындагы бер ташландык йортның подвалын сипләштергәләп, алар шунда яши башлый. Шакирҗанның кулы тире иләргә дә, балта эшенә дә оста була. Аларның тормышы рәтләнә. Менә шушы Волков урамындагы 22 нче йортның 9 нчы фатирында 1939 елның 23 августында Минтимернең булачак сөеклесе Сәкинә дөньяга килә...

Шәһәрдә туса да, Сәкинә җәен авылда – йә Күндә, йә Шәледә туганнарында үсте.

Күн, Шәле авылларының йолалары бик тирәнгә китә. Йолаларның берсе – ирләр җәмгыятендә тыйнак, басынкы кыз эштә ут өертергә тиеш, палас сугарга, малын карарга, чишмәдән су ташырга, мунча ягарга, энеләре, сеңелләренә күз-колак булырга, олыларга, ата-анага хөрмәт тәрбияләргә тиеш.

Сәкинә дә нәкъ шушы тәрбиядә үсте. Ул инде буй җиткән кыз, кооперация техникумында укый башлады. Техникумда бәйрәмнәр-танцылар еш була иде. Бервакыт ул дус кызы белән танцыга китте. Бер татар егете аны биергә чакырды. Бер чакырды, ике чакырды – алар азакка чаклы бергә биеде, егет озата кайтырга да рөхсәт сорады. Карап торышка үзе бер дә начар түгел, кыз риза булды. Менә шуннан китте аларның танышуы, байтак кына бергә йөргәннән соң, Сәкинә егетне өенә, гаиләсе белән таныштырырга чакырды.

Чәй эчеп утырганда, әнисе Гөлсем егеттән сорап куйды:

– Син кайсы якныкы буласың?

Егет кыю гына сөйләп китте:

– Минем әти-әни Питрәч районы Күн авылыннан! – диде.

– Кем баласы буласың?

Егет атасының исемен әйтте. Шунда Гөлсем апаның кулыннан тәлинкәсе төшеп китте.

– Әни, ни булды? – дип, Сәкинә әнисе янына килде.

Гөлсем апа итәгенә түгелгән чәйне тастымал белән сөртте. Бераз тынычлана төшкәч, аягүрә басты һәм:

– Кызым, синең бу егетең – безнең малларны талап алган, безне катыр сөрергә уйлаган кешенең баласы! – диде.

Егет белән Сәкинә тораташ кебек катып калды, Гөлсем апа берни булмагандай ишек катына барып басты. Бу хәрәкәт «егет, чыгып кит!» дигәнне аңлата иде.

Сәкинә бер егеткә, бер анасына карап алды.

– Әни, дөресме шул?

Әнисе сабыр гына:

– Дөрес, кызым, – диде. – Алар безнең бөтен малны туздырып, ашап бетерде!

Егет бер сүз дә әйтмичә китәргә җыенды.

– Бу егетнең безнең өйдә кабат эзе дә булмасын! – диде хуҗабикә. – Үзем исән чакта кызымның шундый кеше баласы белән йөрүенә юл куймам!

Егет сүзсез генә чыгып китте. Ишек ябылуга, Гөлсем апа калтыранып елый башлады. Алар кочаклашып, икәүләшеп елый иде.

Кызга – егет, егеткә кыз ошый иде. Нишләтәсең, шулай язгандыр. Алар мәхәббәт бөреләнгәнче үк аерылышты.

Ләкин әле бу эш моның белән генә төгәлләнмәде. Егет солдат хезмәтенә китә икән. Егетнең анасы ялынып килде:

– Зинһар, безне гафу ит! – дип башлады хатын сүзен. – Без гаепле түгел, аңа куштылар бит...

Гөлсем бер сүз дә әйтмәде.

– Улым әрмиягә китә, Сәкинәнең озата төшүен бик тели... Гөлсем, минем улым Сәкинәңне бик ярата, зинһар, аны солдатка озата төшәргә җибәр.

Гөлсем апа, мәрхүм иренең диварда эленеп торган фоторәсеменә якын килеп, хатынга әйтте:

– Кара! Сез менә шушы изге кешене хатыны, күкрәк баласы белән өеннән кудыгыз! Малларын талап, балаларын хәерчелеккә сөрдегез! Кара, туры кара Шакирҗанымның йөзенә. Без эт тә яшәмәс подвалларда яшәдек. Шакирҗаным аркасында без янә аякка бастык, ә сез һаман хәерче. Юк! Җибәрмим мин алмаз кебек кызымны! Чыгып кит, зинһар!

Хатын чыгып китте. Ана белән кыз тагын бер-берсенең кочагына ташланып үкси башлады.

Сәкинәнең, бәлки, егетне озатырга төшәсе дә килгәндер, ләкин ул анасын өзелеп сөя, ул аның ихтыярына каршы баралмый иде.

Сәкинәнең дә күңел күзе ачык, аның да күңеле сизгер иде. Әгәр дә бу егет белән кушыла калса, очрашкан саен ике як пычакка пычак килер иде. Юк, бу егет Сәкинәнеке түгел.

## Шәле кичләре

Күн авылында туган нигез калмагач, әнисе Сәкинәне вә башка балаларын җәйгелеккә Шәле авылына кайтарып куя торган иде. Сәкинәне эш вакытында авыл кызларыннан аерып булмый. Суын ташый, урагын ура, утынын яра, мунча яга, сыерын сава – менә дигән уңган килен. Сәкинә дус кызлары белән кичләрен клубка чыга башлады. Бу чагында ул инде шәһәр кызына әйләнгән, ләкин шулай да яулыгын Шәлечә бәйли иде. Шәле кызлары чигешен маңгайга туры китереп, калфак кебек почмаклап бәйли яулыкны. Балитәкле ситсы күлмәк, шәлеләр чиккән алъяпкыч, ак йон оекбаш, ялтыравыклы кызыл эчле галош – гаҗәеп килешә иде бу кием кызга. Шулар өстенә тез астына җиткән ике озын кап-кара толым. Шәле егетләренең күзе Сәкинәдә. Казан кызы бит, җитмәсә, үзе шундый чибәр!

Клубта бииләр, җырлыйлар, түгәрәк уеннар уйныйлар.

Сәкинәне берәү генә озата кайта ала – гармунчы егет кенә. Кыз да аның озатуын тели иде. Егет гармун уйный-уйный кызны озатып куя да, капка төбендәге бүрәнәдә бераз сөйләшеп утыргач, гармун уйный-уйный кайтып та китә. Сәкинә, ишегалдына кергәч, капканың теге ягына посып, гармун тавышы тынганчы тыңлап тора. Ошый иде Сәкинәгә Шәле кичләре. Егете дә бик ошый иде.

Әмма тора-бара гармунчының Сәкинәне озатулары ни өчендер сирәгәя барды. Сәкинә дә моңа аптырамады. Очрашкан чакларда алар бер-берсенә елмаеп сәлам бирешә, сәлам алыша иде.

Алар шулай дус булып кала белде. Ул үзе егетне ошатса да, Сәкинәнең сизгер күңеле егет белән очрашканда дәртләнмәде. Аның күңел күзе гармунчыны үзенә пар итеп күрә алмады.

Ә Шәле кичләре онытылмаслык булып күңелгә кереп калды. Иң самими, иң ихлас, иң саф хатирәләр саклый Сәкинә Шәле табигате, Шәле кешеләре турында.

Җәйге каникуллардан соң Казанга кайтып, тагын техникумда укуын дәвам итте кыз. Язмыш Сәкинәнең юлына тагын бер асыл егетне китереп куйды. Бөтен ягы да җитешле-килешле иде ул Илгиз Мөхәммәтгатин атлы егетнең.

Сәкинәнең сизгер күңеле сизә, егет аны бик тә ярата, ләкин эчке сиземләве кисәтә дә: ашыкма, кызый, каударланма, бу әле синең парың түгел, ди. Чыннан да, алар аерылышты: егет солдат хезмәтенә китте.

Укуын тәмамлагач, Сәкинәне Актаныш ягына, Калинин районы үзәге Пучыга эшкә юлладылар. Ул Пучы райпотребсоюзында икътисадчы булып эшләячәк. Ура!

## Адәм белән Хәүва

Җәннәттән куылгач, Адәм белән Хәүва җир йөзенә аерым-аерым: берсе – Сәйлүн утравына, икенчесе Мәккә ягына килеп төшә. Бер-берсен сөюче ике җан бер-берсен эзли китә. Аларны күңел тоемлавы компас кебек бер-берсенә якынайта. Ерак араларны, куркыныч урманнарны, диңгезләрне узып, алар, ниһаять, гомергә аерылмаска кавыша.

...Минтимерне диплом практикасына туган ягына кайтардылар. Бу 1959 ел иде. Ул яраткан эшенә кереште. Аның зиһене-фикере, таланты, теләге, яшәү рәвеше җир-туфрак, механика-техника белән укмашкан иде.

Ләкин бөтен шушы барлыгы белән ул тәкъдир тарафыннан билгеләнгән сөекле ярын да эзли иде. Тыштан эш белән мавыккан булып күренсә дә, аның бөтен гамәле, фәгалияте бер теләккә, сөекле ярын табып, гаилә коруга юнәлтелгән иде.

Юк, Минтимер мөкәммәл хатын эзләми иде, чөнки андый хатыннар булмый, алар дөньяда юк, ул хыялыйлар-шагыйрьләр уйлап чыгарган бер гүзәл шәкел генә.

Минтимер Тукайның хур кызына атап язылган шигырен бик тә ярата.

Әгәр җәннәттә күрсәм мин йөзеңне,
Күрермен ай йөзеңдә үз йөземне.

Беләм инде: мине әсир итәрсең,
Сихерләрсең, мине әфсүн итәрсең...

Гүзәлсең син, матурсың син, матурсың,
Матурларның матурыннан матурсың.

Гүзәлсең син, зөбәрҗәтсең, асыл ташсың,
Ләкин җир кызы төсле үк түгелсең.

Күркәмлегең, дөрес, һәртөрле мактауга лаек,
Шулай да җир кызы синнән сөеклерәк.

Ә Минтимер җир кызын эзли иде.

Ләүхелмәхфүздә язылганча, аларның очрашуына күп калмаган иде инде.

## Юл башы

*Яраткан эшең, сөйгән ярың,*
*милләтеңнең үзбаш булып яшәве*
*ул – бәхет!*

Батулла

Ни өчендер бүген Сәкинәнең күңеле сөенә, ни өчен икәнен ул үзе дә тәгаен белми иде. Мөстәкыйль эш башлавына сөенәме унтугыз яшьлек кыз? Булачак һөнәрен практика вакытында ук яратып өлгергәненә куанамы әллә? Пучы

авылы кешеләренең, эш урынындагыларның үзенә карата ягымлы булганына шатланамы?

Яшь белгеч буларак, аңа торырга йорт бирделәр. Ул чебешләр, бәбкәләр алып җибәрде, кыскасы, тулы хуҗалык белән авылда яшәргә уйлый иде.

Аның янына тагын бер яшь белгечне керттеләр, Рита исемле кыз иде ул.

Сәкинәнең олы бер шатлыгы беренче тапкыр хезмәт хакы алу булды. Башка кызлар, кулларына акча керүгә, күлмәкләр, бизәнү әйберләре, алка-йөзек сатып ала башлады. Сәкинә исә сөекле сеңлесе Асиягә ап-ак куян тун, икенче хезмәт хакыннан әнисенә, абыйсына матур-матур келәмнәр алып бүләк итте. Кызның башы күккә тигән иде ул чагында, бүләк тапшырганда, әнисенең, туганнарының күз яшьләре белән куанганнарын күреп, ул да бәхетле иде.

Кешегә куаныч китерүдән дә олы бәхет бармы икән ул?

## Очрашу

Аһ, ул заманнарда клубтагы кичәләр! Яшьләр күп, яшьләр дәртле, егетләр кызлар алдында егетлек күрсәтә, өздереп гармун уйный, бии, җырлый, кызлар өчен бәйләнешеп тә ала. Кызлар басынкы, тыйнак, гүзәл, ләкин эчләрендә богауланган дәрт-гайрәт ята. Тымызык күлдә корт уйный.

Минтимер ул кичне клубка никтер ашкынып килде. Анда кичәнең иң кызган чагы иде. Яшьләр әле яңа гына биеп туктаган, хәл алалар, тамашачылары да күп, иннек-кершән яккан, күзләренә сөрмә тарткан, тырнакларын кынага буяган кызлар эскәмиядә утыра, егетләр бер читтәрәк кунак кызларының кайсын кем озата дигән мәсьәләне хәл итә, малай-шалайлар мич артында кайнаша.

Минтимер ишекне каерып ачты, бөтен кеше ишек тавышына борылып карады. Йөз күз Минтимергә карый, Минтимер ике күзе белән йөз күзгә бага.

Минтимер клуб ишеген иплән кенә япты да бусага төбендә басып калды: аның карашы әле яңа гына күзе төшкән бер кызда тукталды. Таныш түгел кыз иде ул. Үзе ап-ак кофта кигән, карасу сарафаннан, исең-акылың китәрлек озын кара толым да үзенә бик килешеп тора. Кунак кызымы, әллә эшкә кайткан бер-бер яшь белгечме?

Кызның карашы да Минтимернеке белән очрашты. Шул мәлдә ике йөрәк арасында тәкъдир җепләре тартылды да бугай инде.

Сәкинәнең тәне буйлап кайнар дулкын йөгерде. Бу – ул эзләгән яр, ул эзләгән мәхәббәт иде.

Шулвакыт баянчы Сара Садыйкованың «Көтәм сине» көен уйный башлады. Ул чакта бу көйне «Беренче татар тангосы» дип йөртәләр иде.

«Теге егет биергә мине чакырсын иде, башкалар чакырганчы чакырсын иде, монда чакырган егет белән биюдән баш тарту әдәпсезлек санала, башкалар чакырса, теге егет бүтән кызны чакырыр», – дип уйлады Сәкинә, уе шундук Минтимергә барып та иреште. Ул туп-туры атлап кыз янына килде дә аны биергә чакырды.

– Сез минем белән биемәссез микән? – диде егет.

Сәкинәнең дулкынлануына чик-чама юк иде. Минтимер дә тыныч түгел, ләкин ул үзен ир-егетләрчә тота. Бию башланды. Пар-пар булып яшьләр бии, кайсыдыр биегән вакытта көйне сүзләре белән җырларга ук кереште.

Син кайларда йөрисең икән,
Алтыным, көләч йөзле иркәм,
Кайтырсың дип мин өмет итәм,
Мин сине һаман көтәм, көтәм...

Минтимер дә сүзләрне кабатлый, кыз да чак кына ишетелерлек итеп җырлый иде.

Гаҗәеп илаһи бер мизгел иде бу. Каян, ничек шулай килеп чыкты? Нинди ярашканлык, нинди самимилек, нинди сафлык! Минтимер кызга бакты, кыз биегән уңайга башын кыңгыр салып, идәнгә текәлгән, ләкин ул идәнне күрми, аның бар игътибары, күңел күзе Минтимердә генә. Ул егетнең күзенә карарга кыймый. Бу гүзәллеккә бу тыйнаклык бик ятыша, юк, бу тыйнаклыкка бу гүзәллек бик яраша. Бөтен яшьләр җырлый:

Синнән башка бер ямь юк миңа,
Син кайтмасаң, бәйрәм юк миңа.
Таң балкуы кебек кайт, иркәм,
Мин сине көтәм, көтәм, көтәм...

– Нинди матур җыр! Кем сүзләре икән ул? – дип сорады кыз кыюсыз гына.

Шулчак аларның карашы очрашты – хисләр дулкыны ике йөрәккә берьюлы китереп сукты. Бу караш ике ялгыз йөрәкне берләштерде, тоташтырды. Минтимер шунда үзенең гашыйк булганын аңлап алды. Сәкинә исә моны күптән, җыр дәвамында ук аңлаган иде. Минтимер, дулкынлануын тыя төшеп:

– Сүзләре Әхмәт Ерикәйнеке, көе Сара Садыйкованыкы! – диде.

– Нинди гүзәл җыр, сүзләре дә, көе дә...

– Биючеләре дә... – дип өстәде Минтимер.

Сәкинә челтерәп көлде. Бию тәмамлангач, алар утыргычка таба китте.

Яшьләр дә Минтимер белән Сәкинә арасындагы күренмәс җепләрне күрде, сизде кебек. Биюдән таралганда барысы да инде әлеге парга карап соклана иде.

– Каптырды бу гүзәл кыз асыл егетне! – диде кемдер.

– Миңкәй каптырды асыл кызны! – дип куйды кайсысыдыр.

Бер күрүдә гашыйк булу дигәннәре менә шушыдыр инде ул. Сәкинәнең болай да тулы-матур тормышы тагын да тулылана төште.

## Хатлар

Тормыш ике гашыйк арасына киртәләр дә кора башлады.

Калинин районы бетерелеп, Сәкинә туташ Казанга – әнисе янына кайтып китәргә мәҗбүр булды.

Ике арада кайнар мәхәббәт хатлары йөри башлады. Хат көн саен Казанга китә, көн саен Пучыга килә. Хат ташучыларга эш артты...

...Минтимернең атасы улыннан канәгать иде. Ул күзәтә. Эшнең рәтен белә малай, мәгънәсе бар, кешеләр белән сөйләшү маһирлыгы бар, шөкер!

Тик менә йөргән кызы гына юк бугай. Шәрип абзый күзәтә. Тирә-юньне тыңлый. Ә бөтен яңалык базарда була. Базарның колагы сак, күзе үткер.

Шәрип абзый сөлек кебек чем-кара айгырын шәп тарантаска җигеп, һәр ял көнне базарга йөри: гаиләсе өчен, колхоз өчен кирәк-ярак караштыра, һәркем аның белән олылап исәнләшә. Күренеп тора: бу кеше халык арасында бик тә

абруйлы. Карсак буйлы, төптән юан чыккан, галифе балагын ялтырап торган күн итек кунычына тыгып куйган, кара кашлы, кара күзле, кара чәчле әлеге ир игътибарны үзенә тартып тора иде.

...Бервакыт Сәкинә үзе дә сизмәстән таныш хатынынннан сорап куйды:

– Бу агай кем була? – диде.

Ул – Пучыдан, колхоз персидәтеле Шәрип абзый Шәймиев! – дип җаваплады хатын.

Шәрип абзыйның да карашы Сәкинә туташка төште. Ул, карый торган товарын куеп, аны күзәтә башлады.

– Бу кем кызы? – диде Шәрип абзый, үзе дә сизмәстән.

Камыт сатып торучы агай әйтте:

– Райпотребсоюзда иканамис булып эшли, Казаннан кайтты, – диде.

Шуннан соң ул җае туры килгән саен Сәкинә турында сораштыра башлады: малайга – хатын, өйгә килен кирәк ләбаса.

Кызның да күңел түрендә бу олпат кешегә хөрмәт уянды, хөрмәт белән бергә тагын ниндидер, үзенә билгесез хис тә барлыкка килде. Рух туганлыгымы, җан уртаклыгымы – ни дә булса бар, ләкин Сәкинә әле бу турыда уйларга базмады.

– Улым, әллә кая каранма! – диде хуҗабай. – Мин сиңа – кыз, үзебезгә килен таптым, ул райпотребсоюзда эшләүче кыз Сәкинә булыр! Ике дә уйлама, шуңа өйлән!

Минтимер елмайды, алар Сәкинә белән күптән таныш, һәм араларында инде мәхәббәт тә бөреләнеп килә иде.

Ата кодалады, улы үз җаен карасын!

## Тәвәккәл таш яра

Сәкинә киткәч, Минтимернең көн саен Казаннан хат алганын, ул, хатны алуга ук, берәр аулак урын табып, кат-кат укыганын Шәрип абзый сизде, күрде һәм аңлады: аның яучылаганы бушка китмәгән икән.

Атаның кәефе күтәрелде, ул оланы өчен сөенә иде. Ләкин хат алышу озакка китсә, хисләр суынырга да мөмкин. Шуңа күрә Минтимергә тимерне кызуында сугарга кирәк иде.

Шәрип абзый, күчтәнәчкә ике каз алып, Минтимер улына кыз сорарга Казанга китте.

Сәкинә, туганнары янына кайткач, «Теплоконтроль» заводына эшкә кергән иде, шуның өстенә Мәскәү финанс-сәүдә институтында читтән торып укуын да дәвам итте. Бер ел да узмагандыр, аның тормышында биниһая зур үзгәрешләр булды. Туганнар белән чәй эчәргә генә җыенганнар иде, ишектән карга баткан, өстенә тун кигән бер кеше ишелеп килеп керде.

– Ахунова Сәкинә шушында тора, диделәр, әссәламегаләйкем!

– Исән-саулармысыз! – диеште аптыраган хуҗалар.

– О-о, Шәрип абзый! Хуш килдегез! – дип, Сәкинә кунак янына атылып килде дә аңа чишенергә булыша башлады.

Хуҗалар да шатланышып кунакка ярдәм итте.

Бер җаен табып, Гөлсем ханым пышылдап кына кызыннан сорап куйды:

– Кызым, бу кем?

– Бу – мин сиңа сөйләгән егет Минтимер Шәймиевнең атасы Шәрип абзыкай! – диде Сәкинә.

Ир-егетләр күчтәнәчләрне өйгә алып керде.

Сәкинәнең абыйсы Мөбарәкҗан көләргә тотынды:

– Чыпчык-карга күтәреп китмәсен, ди абзый! Көчкә ташып бетердек...

Таныштылар, аңлаштылар, чәй табыны янына утырыштылар.

– Мактап кына йөрисез икән! – диде Гөлсем апа.

– Шушындый уңган кызны хурлыйлармыни! – дип сүзгә кушылды Шәрип абзый. – Ул бөтен Актаныш ягын үзенә гашыйк итте, рәхмәт сезгә шундый кыз үстергәнегез өчен!.. Озын сүзнең кыскасы: мин, Гөлсем ханым, сезнең кызыгыз Сәкинәне улым Минтимергә яучылап килдем...

Сәкинә, әнисеннән теләктәшлек көтеп булса кирәк, Шәрип абзыйга карамыйча гына, анасына багып әйтте:

– Шәрип абый, минем әле читтән торып финанс институтын тәмамлыйсым бар, кияүгә чыга алмыйм, – диде.

– Анаңнан алда сүз йөртмә, апаем! – диде кунак.

Сәкинә бүлмәчкә кереп китте. Ул анда әллә елый, әллә куана идеме – белгән юк.

Сәкинә сеңлесе Асия белән бүлмәчтә утырган чагында, тәвәккәл кунак Сәкинәнең абыйсын, анасын күндереп бетергән иде инде.

– Чык әле, кызым! – диде ана кеше.

Асия белән Сәкинә зур якка чыкты. Сәкинәнең еламсыраган чыраен күргәч, Шәрип абзый әйтте:

– Кызым, институтны аны кияүгә чыккач та бетереп була, алай җиңелрәк тә булыр. Минтимер мәгънәсез егет түгел, аңлар! – диде.

Атасы урынына калган абыйсы Мөбарәкҗан да, анасы Гөлсем дә, хәтта энесе Галимҗан белән сеңлесе Асия дә Сәкинәнең кияүгә чыгуын бик тә тели иде кебек.

Хәер, Сәкинәнең үзенең дә Минтимер белән гаилә корасы килә иде, бәлки, ул, йола кушканга, бераз киреләнгән атлы булып кына торгандыр. Һәм, ниһаять, Сәкинә Минтимергә кияүгә чыгарга риза булды!

Шәрип абзый, хуҗаларга рәхмәт әйтеп, көр күңел белән өйдән чыкты.

– Ай-һай, кода гаярь кеше! – диде Мөбарәкҗан, кунакны озатып кергәч.

Бу көнне сүз Минтимернең атасы, Сәкинәнең булачак каенатасы турында гына булды. Атасына охшаса, Минтимер сиңа таш койма кебек булачак, булдыклы нәсел! Үкенмәссең, иншалла!

Абыйсы хаклы булып чыкты: Сәкинә – Минтимергә йорт-учак сакчысы, Минтимер Сәкинәгә ачы җилләрдән саклаучы тау ышыгы иде.

Кияү белән кәләш ярәшелгән килеш очраша торды, шулай итеп кыш, яз узды, җәй дә килеп җитте.

Никахны Казанда укыттылар. Актаныш ягыннан да, Күн-Шәле ягыннан да, Казаннан да, тагын әллә кайлардан туганнар, танышлар, кунаклар җыелды. Бик матур булды яшьләрнең никахы. Иң сөенгәне Галимҗан белән Асия булгандыр, мөгаен, чөнки алар җизнигә тиенде. «Җизни, җизни, синнән җаным бизми» дип, алар Минтимер янында бөтерелде. Минтимер балдызына матур күлмәк-яулык, Галимҗан каенишенә затлы пәке бүләк итте. Пәкене биргәндә, ул әйтте:

– Йола буенча, җизни кеше каенишенә кылыч, хәнҗәр бүләк иткән, – диде. – Хәзер кылыч-хәнҗәр йөртергә ярамый. Шуңа күрә мин сиңа пәке бүләк итәм. Бу пәкене ярамаган эшләргә тотма, бары тик каләм очлаганда, чаңгы бавын рәтләгәндә, сыбызгы-курай ясаганда гына куллан.

Никах мәҗлесеннән кайткач, бер шаяны әйтте:

– Никахлы яшьләр хәзер кияү мунчасына барырга тиеш! – диде.

– И-и, – диде Гөлсем апа, – монда мунчабыз юк шул, Шәледә кияү мунчасы әзер.

– Юк, җәмәгать! – диде Минтимернең якын дусты, яшь артист Наил Әюпов. – Кияү мунчасын туйдан соң Минтимер туган йортта ягабыз!

Минтимер алдан ук, Чаллыга хәтле кайтыр өчен, пароходка билетлар алып куйган иде.

Сәкинә өчен дә, Минтимер өчен дә бу сәяхәт хыялый бер төш рәвешендә генә истә калыр. Булдымы икән шундый матур көннәр, булдымы икән шундый бәхетле мизгелләр? Булган очракта да алар инде чынбарлык түгел, бары тик хыял гына, ләкин тормышка ашкан хыял.

Узар гомерләр, хезмәт баскычларыннан югарыга менгәндә, Сәкинәсе аңа терәк, киңәшчесе, балаларының анасы, оныкларының әбисе булыр. Әмма пароходта кайту – ул сөйләп бетергесез моңлы да, ямансу да, шул ук вакытта бәхетле мизгелләрнең хатирәләре булып та гомерлеккә калыр!..

Заманнар узгач, журналистларның берсе Президент Шәймиевтән:

– Иң бәхетле көнегезне хәтерлисезме? – дип сорады.

Минтимер җавап бирергә ашыкмады. Байтак вакыт узгач, әйтте:

– Иң бәхетле көн дисезме? О, бу бик күптән инде, Сәкинә белән ак пароходта йөзеп барганда булды...

Минтимер Шәрип углы Шәймиев Татарстан Президенты булгач, аның хакында китап чыгарырлар. Ул шул китапның иң беренче нөсхәсен сөеклесе Сәкинә ханымга бүләк итәр. Анда шундый сүзләр язылган булыр: «Сөйгәнем Сәкинәм! Үз гүзәлен ак пароходка утыртып, туган ягына алып киткәндә әле почык борынлы егет үзенең Татарстан корабында капитан булачагын, ә гүзәленең халык тормышындагы хәлиткеч еллар давылында юл күрсәтүче йолдызга әвереләчәген күз алдына китердеме икән? Мәхәббәтең, игелегең өчен рәхмәтем чиксез! Минтимер, 30 декабрь, 1995 ел».

Гаҗәеп самими сүзләр, искиткеч ихлас хисләр.

Аллага шөкер, ул шулай булачак, әмма алда әле көчле агымлы, астында кыя-ташлар тырпаеп торган давыллы дәрьяларны исән-сау кичәсе бар.

Ә хәзергә Чулман өсте тигез, аста таш бусагалар юк, маяклар дөрес юлны күрсәтә, хәвеф-хәтәр якынлашканы сизелми. Бүген аларны яр буйлый чәчәкле болыннар, чыелдык акчарлаклар, серле урманнар, матур авыллар, балыкчылар озата бара.

Пассажирлар да, туганнары, кунаклары да уйный-шаяра-көлә буфет тирәсен кат-кат әйләнә, кайсыдыр шаяны алар каютасының ишеген шакып китә, кайсыдыр тәрәз каршыннан:

– Кияү белән кәләш озак йоклый! – дип шаяртып уза.

Пристаньда, яр башында Шәрип абзыйның «Волга»сы тора, ул кунакларны каршы алырга Актаныштан Чаллыга килгән. Юл буе шаяра-сөенә кайттылар. Ә туй тагын да күңеллерәк узды.

Авылда кунакларны бер төркем яшьләр каршы алды, күрәсең, алар клуб тирәсендә кайнаша торган һәвәскәрләрдер, үзләрен бик кыю, иркен тоталар. Машинадан төшүгә, киленне гүзәл чигешле мендәргә бастырдылар, ике сабый касәләрдән аңа бал-май каптырды.

– Гомерегез балда, майда гына узсын! – диделәр.

Бал-майдан соң яшьләр җыр башлады. Оркестрлары – буяулы тәти кашыклар, бер барабан, бер курай, бер сыбызгы, бер гармун һәм ике җиз

самавыр капкачы. Берсе, каен тузының юка элпәсен кабып, сандугач тавышы чыгара башлаган иде, җиз самавыр капкачлары оркестрдагы фанфаралар кебек чаңлатып сукты, барабан кагарга тотындылар. Аларга курай-сыбызгы, гармун килеп кушылды. Шактый ярашып уйный иде һәвәскәр музыкантлар, кемдер ике тапкыр һавага мылтык дөпләтте. Биш кешедән торган җырчылар котлау җырын башлады, яшьләр яндырып биергә тотынды, бию кызганнан-кыза барды:

Туй шәп була, шәп була,
Шәп була туегыз, шәп була.

Улыгыз кияү була,
Кызыгыз хатын була.
Шәп була туегыз, шәп була,
Туй шәп була, шәп була.

Анда никах укыла,
Анда мунча ягыла.
Шәп була туегыз, шәп була,
Туй шәп була, шәп була.

Анда бер шәйләр була,
Кызыгыз хатын була.
Шәп була туегыз, шәп була,
Туй шәп була, шәп була.

Улыгыз әти була,
Кызыгыз әни була,
Балагыз тәти була.
Шәп була туегыз, шәп була,
Туй шәп була, шәп була.

Кызыгыз үсеп җитә,
Аннан кияүгә китә.
Шәп була туегыз, шәп була,
Туй шәп була, шәп була.

Анда мунча ягыла,
Анда бер шәйләр була,
Кызыгыз хатын була,
Улыгыз әти була,
Атагыз бабай була,
Анагыз әби була.

Шәп була туегыз, шәп була,
Туй шәп була, шәп була.

Шушы көйгә бөтен урам дулап биеде. Һавага акчалар, конфетлар чөелде, бала-чага шул акчаларны, конфетларны алу өчен әвәрә килә башлады.

Чыннан да, туй шәп булды. Минтимер кияү белән Сәкинә кәләшне никах туе белән котлап, артист Наил Әюпов «Кандыр буе»н җырлады. Бу искиткеч матур җырның моңы, Наилнең оста башкаруы әле дә булса колакта чыңлап тора.

Туйда ата кеше бу бәхетле парга дүрт башына дүрт ялтыравыклы никель шарлар беркетелгән тимер карават, керосинка, бер өстәл, ике урындык бүләк итте. Минтимернең абыйсы Хантимер бүләккә җиз самавыр әзерләгән иде.

Шулар өстенә киленнең бирнәсен дә санасак: юрган, урын-җир әйберләре, ике алюмин кашык, ике алюмин чәнечке, ике алюмин тәлинкә... Аз түгел, бер дә аз түгел яңа гына тормыш башлап җибәргән яшь гаилә өчен.

## Сөйгән яр

«Нәрсә ул мәхәббәт» дигән сорауга фикер ияләре дә, язучы-шагыйрьләр дә гасырлар дәвамында җавап эзли, әле дә булса төгәл җавап табылмаган. Бәлки, ул сорау үзенең куелышы белән үк дөрес түгелдер? Ихтимал! Бәлки, ул сорауга җавапны эзләргә дә кирәк түгелдер? Һәркемнең яратуы үзгә. Монда аерым бер калыпка, аерым бер үлчәүгә салып, мәхәббәтнең анатомиясен ботарлап карарга ярамыйдыр.

Мин сине үлеп яратам, дип тә яратмаска мөмкин. Мин сине яратмыйм, дип тә яратырга мөмкин. Мин сине яратам, дип яратырга мөмкин. Мин сине яратмыйм, дип яратмаска мөмкин. Бер сүз дә әйтмичә дә яратырга мөмкин.

Күп кабатлаудан «мәхәббәт» сүзе тузарга, мәхәббәт үзе дә таушалырга мөмкин. Ике аякны аерып басып, муен тамырларын кабартып, «мин сине ярата-ам» дип сәхнәдән акыралар икән, анда ихлас, самими мәхәббәт булуында шик бар.

Мәхәббәт, гыйшык тоту ике генә кешенең сере, ике ярның гына шәхси эше булырга тиеш. Аны урамга чыгып кычкыру, кешеләргә сөйләү ул – җинаять.

Нәрсә ул сөйгән яр? Нәрсә ул ярәшү? Нәрсә ул ярашып яшәү? Нәрсә ул яраклашып яшәү? Нәрсә ул яратышып яшәү? «Алла адәм баласын яратты» гыйбарәсе нәрсәне аңлата?

**Яр** – күп мәгънәле сүз. **Яр** – утын яр. Ягъни утынны икегә аер. Утын **яр**касы шуннан килеп чыга. Урманны кишәрлеккә (делянкага) **яр**у. Иген басуын чалгы яки урак белән **яр**ып чыгу. **Яр**ыш шуннан килеп чыга. Елганың ике **яр**ы. Ихтимал, «аеру» сүзе дә **яр**удан килеп чыккандыр. «**Яр»** сүзе бербөтен нәрсәнең ике **яр**тысы мәгънәсен белдерә. Сөйгән **яр**. Сөйгән **яр**лар бергә кушылса, бербөтен гаилә була. «Ярык», «ярылган» сүзләре икегә **яр**ылган мәгънәгә ия.

Алла адәм баласын **яр**атты дип язабыз, сөйлибез, ягъни «ясады», «барлыкка китерде» була.

«Ясады», «барлыкка китерде» икән, «яратты» түгел, «яралтты» булырга тиеш. «Яралгы, яровой» сүзләре нәкъ менә «яралу», «үрчү», «нәсел калдыру» мәгънәсендә килә. Яратты – сөйде булыр иде. Яралтты – барлыкка китерде, ясады. Аллаһы Тәгалә адәмне яратып (сөеп) яралтты (барлыкка китерде).

Бер елганың ике **яр**ы. Аның сөйгән **яр**ы (яртысы) була.

«Ярәшү» «ярашу»дан алынмадымы икән? **Яр**ашу – сөйгән **яр**ларның үзара килешеп яшәве. Ярәшү – ике **яр**ның бергә кушылуын теләп ярәшәләр. Ике сөйгән **яр**ның бергә яшәвен теләп, без аларны **яр**әштек. Һәм аларны никахлап куштык. Ике **яр** бер гаилә корды. Никахлы ике **яр**га без яхшы теләкләр теләдек: бергә яшәгез, **яр**ашып яшәгез, **яр**атышып яшәгез, дидек. **Ярашып** яшәү ул – чын мәхәббәт дигән сүз. Бер-берсен сүздән генә түгел, күз карашыннан да аңлап яшәү ул – **ярашу**; иренә ни кирәген алдан сизенү, хатынына ни кирәген алдан сизенү ул – ярашу; бер-береңне хөрмәт итү ул – **ярашу**, бер-берең өчен җан ату ул – **ярашу**; бер-береңә хуҗалыкта ярдәм итү ул – **ярашу**. Ярашып яшәүчеләргә сокланырга кирәк! Чөнки нәкъ менә алар чын гашыйклар, нәкъ менә алар чын мәхәббәт нурында коена.

Ярашып яшәү ул – олы мәхәббәт!

**Яраклашу** – приспособление. Яраклашып яшәгәннәрне дә хөрмәт итәргә кирәк. Ир белән хатын өйләнеште, ди. Балалары булды, ди. Ир – хатынын яки хатын ирен яратмаганлыгын аңлады, ди. Иремне яратмыйм икән дип, баласын күтәреп, ата-анасы янына кайтып киткән хатынны аңлавы, аның бу гамәлен аңлатуы кыен. Ә бала? Бала атасыз калды. Хатынымны яратмыйм дип, баласын ташлап чыгып киткән ирне дә аңлавы кыен. Ә бала? Бала атасыз үсәчәк. Баланың хокукы турында ике якның берсе дә уйлап карамый. Яшьлегем уза, яшәп калыйм дип, баласын ятимнәр йортына биреп, үз җаен караган ата-ананы да аңлавы кыен. Ә бала? Бала тилмереп гомере буе ата-анасын көтәчәк. Алар өчесе өч җирдә бәхетсез булачак.

Бәс, иреңне яратмаганыңны аңлагансың икән, түз, ялгышың өчен җәзасын күр. Яратмаган ярың белән яшә. Яратмаганыңны ireңә сиздермичә, шушы яратмаган ирең белән тор, бала тулы гаиләдә үсәр. Хатыныңны яратмаганыңны аңлагач та түз! Хатаң өчен бу дөньяда җавап бир, яратмаганыңны сиздермичә, балаңны тәрбия кыл.

Элекке заманда күпме ир-хатыннар бер-берсен яратмаган килеш тә яшәгән, аерылып китмәгән, балаларын ятим калдырмаган, тәрбия кылган. Алар балалары хакына яраклашып яшәгән һәм ата-ана бурычын намус белән башкарып чыккан.

Тарихыбызда, әдәбиятыбызда, халык хәтерендә Йосыф-Зөләйха, Таһир-Зөһрә, Миркәй-Айсылу, Фәрһад-Ширин, Кәрим-Заһидә кебек гүзәл мәхәббәт каһарманнары бар.

Минтимер белән Сәкинә дә шулар янәшәсендә түгелме?

## Ана

Сәкинә буйга узгач, Минтимер үзгәрә төште. Ул хатынына тагын да назлырак бага, эше тыгыз булганда да, йөгереп кайтып, хәләленең хәлен белешә, аны йөрергә алып чыга. Авыр әйбер күтәртми, матур музыка тыңлата, сахрага алып чыгып, табигать матурлыгын күрсәтә иде. Сәкинәне бала табу йортына салгач та, табиблардан аның хәлен һәрдаим белешеп торды.

Бер атнадан ул хатыны белән баласын алырга китте. Шәфкать туташының кулыннан сак кына биләүне алды. Биләү эчендә нидер кыймылдый башлады, аннан соң елауга охшаш аваз ишетелде: бу – Минтимернең каны, бу – Минтимернең токымы шулай аваз сала иде.

Өйгә кайткач, ул сак кына улының яңагыннан үбеп алды, бәбәйдән сөт исе, Сәкинә исе, җан җылысы килә иде. Аның күзеннән бәхет яшьләре бәреп чыкты. Минтимер, кадерле җан иясе яткан биләүне кочагында сак кына тирбәтеп, әрле-бирле йөренә башлады. Шулчак аның күзе никах, туй вакытында төшкән фоторәсемгә төште, һәм ул, түр диварда эленеп торган шул никах фотосы янында туктап, улына эндәште:

– Менә, Айрат улым, әнкәең синең шундый иде, хәзер тагын да матуррак, – дип, сөекле баласына, сөекле хатынына сөекле шагыйре Такташның «Мәхәббәт тәүбәсе» шигырен салмак кына сөйләргә кереште:

Мәхәббәт
Ул – үзе иске нәрсә,
Ләкин
Һәрбер йөрәк аны яңарта...

Табын янында әвәрә килүчеләр колак очлары белән генә шигырь тыңлый иде.

Ә мин үзем бөтенләйгә
Тәүбә иттем андый эшләрдән,
Читтән генә хәзер көлеп йөрим
«Гыйшык!»
Диеп йөргән кешеләрдән...
Шулай да әле, кызлар,
Алла хакы өчен,
Миннән бераз читтә йөрегез,
Йә тәүбәмне шунда боздырырсыз,
«Гашыйк» итеп куеп берегез!..
Юк шул,
Гыйшкым хәзер иясенә
Кире алынмаска бирелгән,
«Аның» рәсмен беркем бервакытта
Ала алмас минем күңелдән.
. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .

Ә ай күктә һаман сүгнеп йөри,
Җил йоклады исә төн белән;
Айның хатыны да юк,
Ай ялгыз ул,
Төн үткәрсен соң ул кем белән...
Җил, хәерсез, ятып йокламаса,
Җирдә алай-болай иткәли,
Төнлә йөргән кайбер кешеләрнең
Бүрекләрен урлап киткәли...
Ә ай көлә,
Айга кызык була,
Ай ялгыз ул картлык көнендә,
Өйләналмый калган,
Шуның өчен
Кайгы нуры күренә йөзендә...

Сәкинә түзеп утыра алмады, урыныннан торып, бала тоткан ире янына килде, бер кулын сак кына биләүгә куеп, икенчесе белән иренең биленнән кочып, башын аның иңенә кырын салып тын калды. Айрат җиденче мартта дөньяга килде, үзенә күрә аның әнисен Халыкара хатын-кызлар көне – 8 Март белән котлавы иде бу.

Өч җан иясенең идиллиясе узып китте, инде көнкүреш мәсьәләләре итәктән тарта башлады. Алда бәби туе тора иде. Туй җырында җырланганча, кешенең гомере туйлар аша уза. Өй туе, никах туе, бәби туе, сөннәт туе, Сабан туе, бакыр туй, көмеш туй, алтын туй, алмаз туй...

Бу җан ияләренә шушы туйларның барысын да туйларга язсын, Раббым!

## Шәйми токымының эш ысулы

*Котылыр өчен эшләргә кирәк!*
Жан Поль Сартр

Нәрсәдән котылыр өчен эшләргә кирәк? Төрмәдән котылу өченме? Коллыктан котылу өченме? Милли изүдән котылу өченме? Хәерчелектән котылу өченме? Үз нәфесеңнән (комсызлыктан) котылу өченме? Наданлыктан

котылу өченме? Бурычтан котылу өченме? Икътисади буналыштан* чыгу өченме?

Француз язучысы Сартрның шушы дүрт сүзе нинди тирән мәгънәләрне үз эченә сыйдырган! Ә җөмлә гап-гади сүзләр белән язылган.

Даһилык гадилектә! Гадилек даһилыкта!

Шушы мәгънәдәге сүзне нәкъ шул вакытта (сугыштан соңгы елларда) бер-берсен белмәгән ике кеше әйткән, берсе – Сартр, икенчесе – Шаһишәрип абзый. Колхоз персидәтеле Шаһишәрип егерме алты ел җитәкчелек кылганда бу сүзне авылдашларына еш кабатлый торган була:

– Котылу өчен тырышып эшләргә кирәк!

Җитәкче булсаң, үз вазифаңны яхшы аңла, үз һөнәреңне яхшы бел, үзеңнең төгәл кеше, пөхтә һәм сүз кешесе икәнеңне исбат ит. Кешеләргә ягымлы бул, кирәксә, таләпчән дә, кырыс та була бел. Шәхси үрнәк күрсәт. Халык алдында гыйбрәт булма.

Кырыс бул, гадел бул – үзеңне һәрчак хөрмәт итәрләр!

Элек түрәләрне, гадәттә, читтән китереп куялар иде. Читтән килгән түрә синең матур табигатеңне саклыймы? Ул халык күңеле турында уйлыймы? Аңа план булсын, калганында аның эше юк. Югыйсә югары җитәкчеләрне үз ягыбызда үскәннәр арасыннан сайлап куярга кирәк тә бит. Ул беркая да китә алмый. Урыныннан төшкән очракта да халык арасында кала. Дөресен генә әйткәндә, элек җөмһүриятебезнең олы җитәкчеләре барысы да диярлек килмешәк булды. Һәм халык аларга ышанмады, каршы чыкмаса да, барыбер аларга шик белән карады.

Шулай да бер искәрмә дә бар иде. Семён Денисович Игнатьев, Татарстан өлкә комитетының беренче секретаре булып өч кенә ел эшләп калса да (1957-1960), милли сәясәтне акыллы кора белде. Халык аны яратып өлгерде, ул татарларга, Татарстанда яшәүче башка милләтләргә тигез, гадел караштa булды. Аның кешеләргә карата миһербанлы мөгамәләсен сиксән яшьлекләр әле дә булса хәтерли. Ләкин аның бу сәясәте Мәскәүгә ошамады һәм аны, оештыру сәләте куәтле булуына карамастан, Татарстаннан алып, башка вазифага күчерделәр.

Казаннан китеп барганда, имеш, Игнатьевтан:

– Семён Денисович, вы же так хорошо начали работать, а почему вас переводят? – дип сораганнар.

Игнатьев, сагышлы гына елмаеп:

– Меня зачислили в татарские махровые националисты! – дигән.

Узган гасырның алтмышынчы елларыннан Татарстан җитәкчелегенә татарларны куя башладылар. Гомумән алганда, ул татарлар Мәскәү кубызына биючеләр иде. Бигрәк тә милли мәсьәләдә.

Әле күптән түгел генә вафат булган шундый түрәләрнең берсенә язучы Нәби Дәүли йорт җиһазы сорарга килгән, кибетләрдә андый җиһаз юк, дефицит, булса да, еллар буе чират көтәргә туры килә. Олы түрә әйткән, имеш:

– Нәби ага, син дөрес килмәгәнсең бит! Монда мебель фабрикасы түгел, монда обком! – дигән.

Икенче бер язучы олы түрәгә язылып кергән. Кергән дә әле яңа гына чыккан китабын аңа бүләк иткән.

– Ни йомыш, Ибраһим абый? – дип сораган тегесе.

* Буналыш – эшнең буылып торуы, кризис.

– Менә нәшрият китапларымны чыгармый, ярдәм итә алмассызмы?..

Олы түрә Ибраһим ага бүләк иткән китапны сыпырып, әйләндереп караган да әйткән:

– Ә бу сиңа китап булмый... таякмыни? – дигән.

Андый мәзәкләр төгәл дөрес булмаса да, түрәләрнең сәнгать кешеләренә, сәнгатькә мөнәсәбәтләрен ачык аңларга ярдәм итәдер.

Гомумән, әдәбият-сәнгать кешесе түрәләрнең эшчәнлеген әдәбиятка-сәнгатькә мөнәсәбәте буенча бәяли. Һәм ул шулай булырга тиеш тә.

Асылда, соңгы ике Илбашыбыз гына ихластан ватан өчен, Татарстан өчен җан ата. Чөнки алар икесе дә Татарстанда туып үскән, үз республикасының чын патриотлары.

Идарәченең иң төп сыйфатларыннан берсе ул – буйсынарына* эш куша белү маһирлыгы, эшне кушканнан соң бераз вакыт узгач, әмеренең үтәлгәнен, үтәлмәгәнен тикшерү. Үтәлгән икән, буйсынарыңның күңелен күр! Хуплау сүзе әйт! Матди ярдәм күрсәт! Үтәлмәгән икән, сүз белән шелтәлә, материаль ягына сук! Әштер-өштер генә башкарган икән, һөнәрдәшләре алдында аның майтарган әпен-төпен эшен күрсәт!

Халыкны аны курку белән өмет арасында тотарга кирәк дигән мәсләк – миһербансызлар мәсләге.

Кайбер түрәләр акыру, кычкыру ысулы белән эш майтарырга тырыша, буйсынарлары да алардан куркып-калтырап тора. Андый түрәләрнең, гадәттә, эшләре дә алга бара кебек. Ләкин халык күңелендә андыйларга хөрмәт юк, алар аның акырганын ишетмәс өчен генә эшли. Бу бәндә кеше күңеленә миһербан чәчми. Андый җитәкче хөкүмәткә мал тапшыру планын арттырып үти, хөкүмәтнең амбарына аш сала, кешеләрнең бәгыренә таш сала.

Андый кеше атасыннан, анасыннан, мулласыннан «Кылган гамәлләрең миһербан белән сугарылсын!» дигән үгет алмаган шул.

## Елмаю

Минтимер кычкырып сирәк көлә, ул бары тик елмая гына, аның елмаюы үзенә күрә бер тасвирлама таләп итә.

Зур баш, киң маңгай, кара чәч, Шамкай көнләшерлек куе-кара кашлар, бик җитди, хәвефле чакларда да елмаерга гына торган татар күзләре. Елмайганда ул эчке бер итагать белән, тарсыныбрак, минем көлүем башкаларга уңайсызлык китермәсме дигән кебегрәк, авызын җыя төшеп, иреннәрен бөрештеребрәк елмая. Минтимер елмайганда бөтен тирә-як елмая кебек, аннан ниндидер нур бөрки, ул кешеләрдән кәеф урламый, ул үзе кәеф тарата. Яшьләр аны «позитив» дип атый, Минтимердән әнә шул миһербан нуры агыла.

Аның белән якыннан аралашкан чит ил кешеләре дә, үзебезнекеләр дә әйтә:

– Минтимер Шәриповичның беренче сүзеннән үк синең киеренкелегең юкка чыга, син үзеңне иркен тота башлыйсың. Аннан миһербан агыла... – ди.

– Төшемдә Минтимер Шәриповичны күрсәм, һәрвакыт яхшыга була, – диләр Шәймиев белән бер тапкыр очрашмаганнар да.

Һәм бик күпләр шулай сөйли.

Атасы Шәрип абзый еш кына: «Эшчәнлек кешеләргә карата миһербан белән

* Буйсынар – буен сындырып, түрә каршында иелеп торучы.

сугарылмаса, ул коп-коры була. Ул эшчәнлекнең файдасына караганда зарары күбрәк», – дия торган иде.

Минтимер атасының шушы сүзен гомере буе күңелендә шәмаил итеп йөртте.

Эшчәнлек кешеләргә карата миһербан белән сугарылмаса, ул эшчәнлекнең файдасына караганда зарары күбрәк.

Бу сүзләрне атом-төш, техника галимнәренә дә, корольләр, патшалар, президентларга да ятлатырга, өйрәтергә, каннарына сеңдерергә кирәк.

Шушы шәмаил аның хезмәт юлында юнәлеш күрсәтүче булды, авыр-кыен мәсьәләләрне хәл иткәндә дә аңа шушы шәмаил ярдәмгә килде. Ул беркайчан да үзенә таш белән атканнарга таш белән атмады, алардан үч алу юлына басмады.

***Үч кайтарылырга тиеш. Кем боларны (үзенә зыян салганнарны) гафу итсә, ул кешенең гөнаһлары кичерелер.*** (Коръән, 5: 45)

Хәтерлим, заманында бер яшь язучыга иҗат итәр өчен бер бүлмәле фатир биреп, телефон да кертеп куйганнар иде.

Минтимер Шәймиев Илбашы булып сайлангач, әлеге язучы, аның эшчәнлеген киметергә-кимсетергә теләп, бик төртмәле, чәнечкеле әсәр язып бастырган иде.

Шушы пародия чыккач, халык шау килде:

– Бу авторга көн бетте, Илбашына кизәнгәне өчен аны кичермәячәкләр инде, – диде.

Һәм язучыга телефон керттергән директор тиз генә моның телефонын кистереп тә ташлый, аннары бүлмәсеннән дә куып чыгара, яшь язучы урамда кала. Шулай итеп директор, өстән күрсәтмә төшеп җиткәнче үк, түрәләргә ялагайланып, язучыга җәза бирә. Ләкин өстә тынычлык, шау-шу юк, язучыны эзәрлекләүче юк. Язучы үзе дә өстән күсәк төшүен көтеп яши, ләкин күсәк юк. Матбугат та бу турыда ләм-мим. Урталыктагылар да авызларына су капкан.

Бәлки, Илбашына кайбер куштаннар әйтеп тә карагандыр: авызлыкны тешләгән теге язучыга җавап бирик, аны акылга утыртыйк, дигәндер.

Минтимер Шәймиев үз мәсләгенә, атасы, бабасы мәсләгенә тугры калды: үч алмады, язучыны башкалардан кыерсыттырмады, яклады һәм отты!

Күз алдыгызга китереп карагыз сез: әгәр дә совет чорында шушы язучы олы түрәгә пародия язып чыкса, ни булыр иде? Язучының башы зинданнан чыкмас, чыкса да, аңа көн күрсәтмәсләр иде.

Минтимер Шәймиевнең эшчәнлеген бер пародия белән генә бәреп егып булмый шул.

Чын пародия ул Илбашы дәрәҗәсендә, сәнгать үлчәмендә, югары сыйфатлы булырга тиеш. Әйтик, артист Эмиль Талипов пародиясе. Талантлы актёр Илбашының тышкы кыяфәтен, атлап йөрешен, аңа гына хас хәрәкәтләрне, тавыш интонацияләрен, тыйнак елмаюларын шулкадәр оста тотып алган, нәкъ «Точь-в-точь»тагы кебек сәнгать әсәре килеп чыккан. Нур чәчеп торган пародияне күпме карасаң да карап туймыйсың. Сәкинә ханым белән Минтимер әфәнде дә бу сәнгать әсәрен кат-кат карады, көлде, ләззәт алды, әлеге пародия Минтимернең үзе кебек миһербан нурлары чәчә иде.

Миһербанлы-елмаюлы сәнгатең өчен рәхмәт, Эмиль кардәш Талипов!

Минтимер сөекле хатынына һәр сәфәреннән дә истәлекле бүләкләр, кием-салым алып кайта. Ни гаҗәп, ул алган күлмәк Сәкинәсенең үзенә үлчәп тегелгән кебек матур утыра, бик килешә. Минтимер төсләрне дә хатыны зәүкына туры китереп сайлый белә. Бу инде ярашканлык галәмәте, аларның зәвыклары да тәңгәл килә.

Ә каян килә ул тәңгәл зәвык? Абага чәчәгеннән килә. Сыек зәңгәр, яшькелт төсне ярата Минтимер, ул төс фирүзә дип атала һәм Сәкинә ханымга бик тә килешә.

...Төнлә абага чәчәген өзәргә дип урманга баргач күрде ул шундый төсне. Төнге урман шомлы да, куркыныч та, төн кошлары хәтәр тавыш белән кычкыра, ябалак ухылдап куя, кыргый мәчеләр кеше тавышы чыгарып мияулый, агачлар очындагы ачыклыкта, зәңгәр күктә хисапсыз йолдызлар җемелди... Кинәт Минтимер абага чәчәген күрде. Могҗизалы төн иде ул. Куе абагалык уртасында бер абага чәчәк атты. Ясмык зурлыгындагы искиткеч нәфис, зәңгәрсу, яшькелт төстәге асылташ, үзе алмаз кебек җемелди. Минтимер, тын алырга да куркып, агач артына посты. Ни хикмәттер, чәчәк әкрен генә һавага күтәрелде, бер урында асылынып торды да очып йөри башлады. Шуннан бөтен абагалык җем-җем чәчәкләр белән тулды. Күктәге йолдызлар абагалыкка төшеп очып йөри кебек. Минтимер поскан җиреннән чыкты да, кәпәче белән тотарга дип, асылташларны куарга кереште. Шунда бер асылташны тотты да, асылташ чыгып китмәслек итеп, кәпәчен кысты. Бәхет кошын тоткан кебек, ул җан-фәрманга авылга таба йөгерде. Өйгә кайткач, кәпәчен киндерә белән бәйләп лапас өрлегенә элеп куйды. Өйдәгеләрне уятмас өчен, печәнлектә генә йоклады. Йокысы йокы булмады. Таң атар-атмаста ул печәнлектән төште дә, кәпәчен сак кына чөйдән алып, яктыга, ишегалдына чыкты, киндерәне чиште. Кәпәч төбендә ниндидер коңгырт бөҗәк бөгәрләнеп ята иде. Минтимер каушап-аптырап калды. Нишләргә белмәгәч, кәпәчен кире абзарга алып керде. Караңгыга керүгә, әлеге коңгырт бөҗәк гүзәл асылташка әверелде. Ул бөҗәкне тагын ишегалдына алып чыкты, бөҗәк тагын коңгырт кортка әйләнде. Малай алданганын шунда аңлады. Бу бөҗәкнең койрыгында яктырткыч матдә була икән. Минтимер аны ireккә җибәрде. Алдану кәефсезлеге тиз узып китте. Ләкин Минтимер «абага чәчәге»нең төсен, аның илаһи гүзәллеген күзенә, күңеленә сеңдереп калды. Булса да булыр икән гүзәллек!

Әнә шул фирүзә төс Сәкинәгә бик тә килешә иде. Сыек зәңгәр күлмәк киеп, фирүзә асылташлы алкаларын да тагып җибәрсә, Сәкинә Минтимернең зиһенендәге «абага чәчәге» хатирәләрен яңарта иде.

Ә менә ул Һиндстаннан чыннан да ханбикә-солтанбикәләргә генә бирелә торган бер бүләк алып кайткан иде. Бер бөек рәссам ясаган чүлмәк рәсеме иде бу. Чүлмәк Һиндстан асылташлары белән бизәлгән. Гаҗәеп серле, хикмәтле чәчәкләр бу кувшинны тагын да балкытып тора. Ә Сәкинә өчен иң кыйммәтлесе – рәсемнең арка ягына, «чигеп», Минтимернең үзе чыгарган шигыре язылган иде:

Асылташлар чүлмәге.
Искитәрлек чәчәге.
Сәкинәмә бүләгем –
Кабул итче, гүзәлем.

*23.08.1999*

## Ант

*(Президент Минтимер Шәрип улы Шәймиевнең республика халкы алдында биргән анты).*

*Халыкка тугры хезмәт итәргә, Татарстан суверенитетын ныгытырга һәм якларга, Татар ССР Конституциясе һәм законнары буенча гына эш кылырга, ватандашларыбызның хокукларын һәм азатлыгын сакларга, миңа – Татар*

*Совет Социалистик Республикасы Президентына ышанып тапшырылган бөек вазифаларны намус белән башкарырга тантаналы төстә ант итәм.*

*1 июль, 1991*

## Ялгызлык

Минтимер Шәймиевнең киң җилкәсенә, зур башына дәүләт җитәкчесенең бетмәс-төкәнмәс, иксез-чиксез, олы-авыр вазифалары ишелеп төште. Үзе әйткәндәй, аңа гел вакыт җитмәде.

Атна саен дип әйтерлек Мәскәүгә чакыртулар, анда азау ярган җитәкчеләрнең, күңел күзләре ачылмаганнарның янаулары, хәтта «с пристрастием» сөйләшүләре турында аның беркемгә дә, сер сыярдай якын дусларына да әйткәне булмады. Хәтта иң якын кешесе, иң якын киңәшчесе, иң якын теләктәше Сәкинә ханымга да ул барысын да сөйләмәде. Сәкинә ханым сизенә иде, сизенә иде аның сизгер күңеле. Минтимергә авыр, көннән-көн авыр бимазалар килгәнен ул аңлый иде.

Командировкаларга киткәндә иренең һәрчак елмаеп, «тиздән күрешербез, Сәкинәм» дип әйтүләренә, җае чыккан саен шаяртуларына күнеккән ханым соңгы вакытта иренең Мәскәүгә чыгып киткәндәге моңсу карашын, әйтергә теләп тә әйтелми калган сүзләрен тоя, сагышлы карашын күреп, аның бәгыре өзгәләнә иде. Ул киткәч, Сәкинә иренең Мәскәү аэропортына исән-сау барып җиткәнен белешеп, кат-кат шылтыратып, тикшереп тора, Кремльгә киңәшмәгә кереп киткәч тә, бер җанына урын табалмый йөди. Нишләтерләр аны мәскәүләр? Нишләрсең, тотса мәскәүләр якаң?

Минтимергә авыр, бик авыр иде. Ә иң авыры – ялгызлык! Күпме дусларың, сөекле хатының була торып, күп кенә мәсьәләләрне уртага салып сөйләшеп, киңәшеп, бер бушанып алырга да ярар иде. Юк, ярамый шул. Мәскәүдә ул бигрәкләр дә ялгыз. Кайчак Минтимер үзен чынбарлык тормышта түгел, нindiдер аңа таныш булмаган, аңа каршы мохиттә яшидер кебек тоя иде.

Аның эшләре Актанышта, Мөслимдә, Минзәләдә ал да гөл иде. Ул үз эшен белә, эшне оештыра белә, аның тырышлыгын, башкарган эшләрен вакытында күреп, вакытында бәяли торганнар иде. Министр, обком секретаре, хөкүмәт Рәисе булып эшләгәндә дә, эше катлаулы булса да, ул мондый кыенлыкларны күрмәде. Кыенлык кына түгел, кыйналу иде бу. Бөтен депутатлар өчен, урамга чыккан бөтен халык өчен, ачлыкта утыра торган егерме кеше өчен берьялгызы кыйналу иде. Сәкинә ханым шунысына игътибар итте: аның ире, Мәскәүгә киткәндә, үз гәүдәсен төз тота, аннан кайтканда исә йөгенгән була, әйтерсең лә ул төне буе авыр йөк ташыган, әйтерсең лә аны җирнең тарту көче тагын да ныграк тартып, баса-бөкрәйтә төшкән!

Сәкинә, ни булды, мәскәүләр нәрсә диде, дип, ирен йөдәтмәде. Ул болай да чамалый иде анданиләр булганын...

Менә бу юлы да Минтимер, өйгә керүгә үк чишенә торган кеше, өстен-башын салмыйча, таушалган йөзе, моңсу күзе белән сөеклесенә карады, тирән көрсенеп, диванга утырды да сүзсез калды. Сәкинә ханым барысын да аңлады: бу юлы тагын да ныграк кысканнар Татарстан Президентын.

Минтимер иркен сулады, елмайды, аның елмаюы һәрвакыттагыча моңсу иде.

– Даже в тюрьму сыярсың, тотса мәскәүләр якаң, – диде Минтимер Тукай сүзләре белән.

Сәкинә ханымга да җиңел булып китте.

– Әйдә, карчыгым, куй чәеңне, төкер башларына! Мин бүген бик арыдым!

– Чәй әзер! – диде хуҗабикә.

Чәйдән соң Минтимер ял итәргә ятты. Сәкинә ханым, арыган ирен борчымаска тырышып, сак кына, аяк очларына гына басып, йокы бүлмәсеннән чыкты, иренең кәгазьләр букчасын алып куйыйм дигәндә, документлар арасыннан бер кәгазь кисәге очып идәнгә төште. Ханым кәгазьне алды. Буниндидер ачык хат һәм ул ике телдә язылган иде.

*Якташ Минтимер!*

*Әгәр дә Татарстанның ике яклап буйсыну проекты расланса, син үз урыныңда калырсың һәм рәхәт чигәрсең, ләкин «куркак» кушаматына ия булырсың. Әгәр дә син җөмһүриятебезне мөстәкыйль дәүләт итә алсаң, син урыныңны сакларсың һәм халкыбызның сәяси каһарманы булып калырсың. Сакла татар халкын, углан Минтимер! Татарстан халкы гына түгел, тигез хокуклылык һәм азатлык теләүче башка халыклар да сиңа өмет белән бага!*

*Язучылар: Батулла, Фәиз Зөлкарнәй, Рафис Корбан, Ркаил Зәйдулла, Газинур Морат, Зиннур Хөснияр, Мәгъсум Хуҗин.*

*23.08.1990*

Сәкинә ханым хатны букчага салып куйды. Ул каушаган, аптыраган иде. Аның ирен ике яклап та кагалар. Мәскәүләр – «буйсын!» дип, татарлар «буйсынма!» дип кыйный. Аңламыйлармыни соң алар? Яклыйсы урында болары да төрткәли, дип, Сәкинә тавышсыз гына елый иде.

Бервакыт Сәкинә ханым дус хатыннары белән Ирек мәйданына нәмаешка* барган иде. Халык мәйданны тутырган, гөж килә, Ирек мәйданы кайный иде. Анда-санда өндәмәләр язылган транспарантлар күренә. Берсенә: «Минтимер! Булма камыр, бул тимер!» – дип язганнар. Зур гына кәгазьдә Минтимер, Горбачёв һәм Ельцин сурәтләнгән, бу карикатура иде. Минтимер камыт кигән, авызлыкланган, арбада Горбачёв белән Ельцин аягүрә баскан, аларның бер кулында – дилбегә, икенчесендә – озын чыбыркы. Горбачёв белән Ельцин Минтимерне чыбыркылап куа. Тегесе кешни-кешни ыргып чаба.

Сәкинә ханымга әллә ничек, читен булып китте, ул тизрәк мәйданнан китәсе итте.

Сәкинә ханым иренең эштән кайтканын түземсезләнеп көтте. Ул үзенә урын табалмый иде. Карикатура аның тәмам тынычлыгын алды. Эче пошканнан телевизорны кабызган иде, анда да шул ук рәсемне күрсәтәләр. Сәкинә ханым тиз генә телевизорны сүндерә торган төймәгә басты.

Минтимер кайтты. Хатыны аны елмаерга тырышып каршы алса да, елмаюы барып чыкмады. Минтимер сизде: хәләленең кәефе юк иде.

– Ни булды, җаным? Кем рәнҗетте минем Сәкинәмне? – дип сорады хуҗабай, шаярган булып.

Сәкинә яшереп маташмады, турысын әйтте:

– Сине, олы җитәкчене, мыскыл иткәннәр бит! – диде.

– Һи, исең киткән икән! – диде Минтимер.

– Нигә син шундый хулиганнарның колакларын бормыйсың! Они слишком много себе позволяют!

* Нәмаеш – митинг, тупланыш, демонстрация.

Минтимер елмайды, елмаюы көлүгә әверелде.

– Сәкинәкәем! Дөрес ясаганнар, талантлы ясаганнар, шельмалар. Алар, Минтимер, Мәскәүгә үзеңне авызлыклатма, үзеңә камыт кигерттермә, үзеңне арбага җиктермә, дип әйтә бит.

Сәкинә ханымның күңеле ачылып китте. Минтимернең бу карикатурага ачуы килми икән, ни өчен әле мин борчылырга тиеш дип, ул тәмам тынычланды.

Инде өйдә тәмам иминлек урнашты, рәхәтләнеп бер ял итик дип торганда, Мәскәү телефоны шылтырады. Минтимер трубканы алды. Бераз тыңлаганнан соң:

– Да, я буду! – дип, трубканы кире куйды. – Кремль чакыра!

– Нәрсәгә?

– СССР халык депутатларының чираттагы корылтаена! – диде Минтимер кәефсез генә.

– Әле корылтай башланырга ике көн бар бит!

– Димәк, минем Михаил Сергеевичка иртәрәк керәгем чыккан! Сыйларга чакырадыр!

Сәкинә ханым иренең тел төбен яхшы аңлады, «сыйларга» сүзе «кыйнарга» булып ишетелде.

## Татарстаннан килгән хулиган

1990 ел, 10 июль.

Әлеге корылтай СССР Конституциясенә кайбер үзгәрешләр кертүгә багышланган иде. Бу бик тә мөһим мәсьәлә, монда каты бәрелешләр дә булуы ихтимал.

Минтимер Шәрипович Горбачёв бүлмәсенә керүгә үк аңлады: ул «автономный»лардан берүзе генә чакырылган булып чыкты. Гадәттә, автономиялеләр төркеме аерым, союздашлар төркеме аерым чакырыла торган иде. Минтимер Шәриповичның сораулы карашын Михаил Сергеевич шундук аңлап алды. Шәймиев тә Михаил Сергеевичның теләген ачык күрде. Татарстаннан башка автономиялеләр «безгә союздашлар хокукын бирегез» дип гауга куптармаячак. Бер Татарстан гына икътисад ягыннан союздашларның күбесенең борынына чиртә. Горбачёв Минтимернең эчке теләген тоя, аңлый һәм аннан бераз сагая да иде.

Шулай булып чыкты да, Горбачёв ык итте, мык итте, кырыс сөйләшеп тә, юмалауга да күчеп карады.

– Ну, будьте же вы благоразумны, Минтимер Шарипович! Не делайте вы этого!

Ике як та килешә алмыйча аерылды. Ике көн буена Минтимер үзен кая куярга белмәде. Эчпошыргыч, шомлы көннәр иде ул.

Корылтай көне килеп җитте. Съездлар сараенда гадәти бер шатлыклы да, киеренке дә мохит хөкем сөрә иде. Минтимер танышлары, башка төбәкләрнең башлыклары белән исәнләште, хәл-әхвәл сораштырды, ләкин ул тышкы мохиткә игътибарсыз кала бирде, аны Горбачёвның тәкъдиме борчый иде: дәшмә, тын утыр, без үзебез беләбез ни кыласын, диде ич ул.

Кавказ, Урта Азия, Балтыйк буе җөмһүриятләре аерым-аерым, кызып-кызып бәхәсләшә, ә «автономнар» алар арасына кереп аралаша алмаудан гаҗиз иде.

Менә корылтай башланды. Союздаш республикалар вәкилләре аеруча үҗәт

кылана иде, азау ярганнар, дилбегәнең бушаганын сизгәннәр, авызлык тешләп, алар алга ыргылды. Бу съезд бер дә совет заманнарыныкына охшамаган, ул чакта барысы да риза, барысы да кул күтәрә иде. Ә бүген исә Съездлар сарае умарта күче кебек гөжләп тора. Мөнбәргә чыккан һәр союздаш республика башлыгы киңрәк, иркенрәк вәкаләтләр таләп итә, үтенми, сорамый, таләп итә. Горбачёв та, президиумда утыручылар да каушаган, аптыраган иде.

Советлар Союзының таркалу куркынычы тәмам алга килеп баскан иде.

Президиумда утыручы Горбачёв, СССРның бөтенлеген саклап калыр өчен, Федерация Союзын төзергә тәкъдим итте. Беркатлы Горбачёв! Җен чүлмәктән чыгып килә ич инде.

Минтимер күзәтеп-күреп, аңлап утыра. Кавказ, Урта Азия, Балтыйк буе җөмһүриятләре симез калҗаны каптырачак, Татарстан белән башка автономиялеләр «шәҗәрә»ләрен учлап калачак!

Федерация Союзы төзү мәсьәләсе тавышка куелырга тиеш иде. Минтимернең сабыр йөрәге урыныннан кубарылып чыгардай булып тибә. Ашык, Минтимер, менә форсат чыкты, әйт сүзеңне, синең артта – Татарстан. Мондый уңай форсат кабат булмаячак! Тәвәккәллә, Минтимер!

Шунда протоколда каралмаган бер могҗиза булып алды, Минтимер Шәймиев, урыныннан торып, мөнбәргә таба китте, рәислек кылучы Горбачёвтан рөхсәт тә сорап тормыйча, мөнбәргә күтәрелде.

Горбачёв башта аңламады, Минтимер микрофонга иелгәч кенә аңлап алды: тыштан тыныч күренгән бу татар гыйсъян куптарырга маташа түгелме соң?

– Мин сезгә сүз бирмәдем, товарищ Шаймиев! – дип кычкырды Горбачёв. Ул, янында утырган СССР Югары Советы Президиумы Рәисе Лукьяновка иелеп:

– Этот тихоня Шаймиев хулиган оказывается! – дип тә өстәде.

Тегесе:

– В тихом озере черти водятся, не даром он татарин! – диде.

Минтимер, йөрәге күкрәк читлегеннән чыгардай булып ярсыса да, тыштан тыныч кала алды, ул, берни булмагандай, микрофонга бераз иелә төшеп әйтте:

– Я предлагаю внести поправку: членами Союза Федерации должны быть и автономные республики на равных правах! – диде.

Горбачёв катгыян каршы килде:

– Вы опоздали уже, Шаймиев! – дип кычкырды ул. – Почему вы не подали своё предложение в письменном виде?

– Времени не было, Михаил Сергеевич! Но я прошу мою поправку ставить на голосование!

Халык вәкилләренең күбесе, Минтимер Шәймиев керткән тәкъдимне яклап, ачык тавыш бирде. Бу тәкъдим СССР Конституциясендә канунлаштырылды. Шушы мизгелдә автономиялеләр союздашлар белән тигез хокуклы булды.

Чынлыкта Минтимер Шәймиев тарих юнәлешен башка якка үзгәртте. Машалла!

## Гүрбашчы

Безнең халык җор да, зирәк тә бит ул. СССРны таркатканы, ягъни Советлар Союзы дигән ясалма дәүләтне кабергә күмгәне өчен, ул Горбачёвны – гүр башчысы, күмүне оештыручы – Гүр-баш-чев дип атый башлады.

Михаил Горбачёвны Генераль секретарь итеп куйганнарына Минтимер

Шәймиев куанган иде: үзе демократ, сөйкемле, буйсынарлары белән мөгамәләсе яхшы. Ләкин Минтимернең куанычы озакка бармады. Горбачёв хакимияткә килүгә, ордым-бәрдем «коры канун» кертте, шуңа күрә халык аны «Минеральный секретарь» дип тә атап йөртә башлады. Ягъни мәсәлән, мәҗлесләрдә хәмер эчмичә, минераль су гына эчеп утырырга тиеш иде СССР ватандашлары.

Россиядә гел шулай: бер идеяне аһ итеп күтәреп алалар да ура кычкыралар, ә аның азагы гел хурлыклы рәвештә «каравыл» кычкыру белән тәмамлана килде.

Россиядә, СССРда хәмергә каршы болай көрәшеп буламыни? Аракы бу илдә сыек валютага әверелгән, карчыкларга печән-утын китертү аракысыз башкарыла алмый. Берәр йомышны үтәгәнгә дә бары тик аракылата түләргә кирәк. Йөзем бакчаларын бетергәч, аракы сатуны бик нык чикләгәч, халык күпләп көмешкә куарга кереште, ялган аракы ясау артты, наркоманнар күбәйде. Кешеләр техник спирт, денатурат, идән асты аракысы эчеп кырыла башлады. Бу фәрманы белән Горбачёв халыкка, яхшылык кылам дип, зыян гына эшләде. Аракы белән көрәшәм дип, ул наркоманияне арттырды.

Әйе, күңел күзе сукырлар, яхшылык эшлим дип, гел яманлык кылучан була.

Николай патша, бәйрәм ясыйм дип, халыкны бушлай әче бал, сыра-сумса белән Ходынкага ымсындырып китереп, тыгылыш, өелеш ясап, меңләгән ватандашларын издереп үтерде.

Ленин, кешеләргә бәхет алып киләм дип, аларны бәхетсез итте.

Сталин, халыкны дошманнардан азат итәм дип, күп миллионлаган халыкны юк итте. Аның табуты артыннан баручы меңләгән кеше бер-берсен таптап үтерде, кемдер аяк астындагы капкачларны ачык калдырып, кешеләр йөзәрләп-йөзәрләп җир астына егылып һәлак булды. Һәр канализация чокырыннан егермешәр-утызар мәет тартып чыгардылар. Сталин кабергә кергәндә дә халкын күпләп кырып китте. Урыны җәһәннәмдә булгыры!

Хрущёв, коммунизм таңын аттырам дип, халыкны ярым ач яшәтте.

Брежнев, Әфганстанга ярдәм итәм дип, әфган халкын кырдырды.

Горбачёв, СССРны саклап калам дип, Алма-Ата, Баку, Тбилиси, Балтыйк буенда халыкның канын койды, йөзем бакчаларын турап, наркоманияне тагын да арттырды.

Ельцин, Чечняга яхшылык кылам дип, калаларын җимереп ташлады.

Болары тагын нишләр?

Ахмакка намаз укырга кушсаң, таш идәнгә бәреп башын ватар, ди.

## Ельцин

Борис Николаевичның бик тә мөһим бер очрашуы бар иде. Сергей Шахрай, Михаил Полторанин, генерал Ёрин, маршал Грачёв белән. Барысы да җыелган, алар Президентны көтә иде. Ул бераз соңга калып килде, барысы белән дә кул биреп күреште.

– Собрал я вас, господа, чтобы известить вас, что пора покончить с Золотой Ордой – Казанью! Мы хуже Ивана что ли, а? Необходимо ввести войска в Татарию!

Барысы да сагаеп калды, ләкин берсе дә авыз ачып сүз әйтмәде. Ельцинның элек тә Казанга гаскәр кертергә теләгәнен һәрберсе белә иде. Димәк, ул кызган, бәлки, кыздырганнардыр, бәлки, котырткannардыр. Җыелыштагыларның күпчелегенең Шәймиев гамәлләренә болай да эче поша иде, күңелләре белән

алар Ельцинның тәкъдименә каршы да түгел кебек, ләкин мондый канкоешка сәбәп булырлык тәвәккәллекне үк күтмәгәннәр иде.

– Шаймиев захотел себе вернуть ханство! Предлагаю подтянуть танковые части, моторизованные подразделения к Казани, Приволжский военный округ должен стать под ружьё! Всё!

Тынлык урнашты. Шахрай үзенең кара мыегын сыпыра, Ёрин ялтыратып шомартылган китель төймәсен бөтерә, Грачёв теш төбен суыра. Михаил Полторанин сул кулына кечкенә куен дәфтәре тоткан, уң кулындагы алтын каләмен әле бер, әле икенче якка әйләндерә.

– Жду вашу реакцию! – диде Ельцин.

Берсе дә сүз башларга кыймады. Барысы да, Ельцин ни кушса, шуны башкарачак кебек тоелды.

– Молчание – знак согласия, да? – дип тынгысызлана башлады Ельцин. – Пора покончить с этой анархией!

Полторанин сак кына тамак кырып куйды.

– Ай-да, Михаил Никифорович! – диде Ельцин.

– Борис Николаевич! – дип сүз башлады Полторанин. – Бу – бик катлаулы мәсьәлә. Бу Сүәеш каналы, Куба кризисларыннан ким түгел. Хәзер Казанга гаскәр кертсәк, көтелмәгән вазгыять туарга мөмкин. Бу – Россия ватандашларын кыру булачак. Гаскәр кертүгә үч итеп, татарлар «Дружба» нефть үткәргечен, качалкаларны шартлата башласа, социалистик илләр газсыз калачак, катастрофа булачак. Гаскәр керткәч, атарга, тыныч халыкка атарга туры киләчәк, бу Ходынка гына булмаячак бит, иптәшләр. Безне бөтен дөнья гаепләячәк! Анда татарлар мәйдан тутырып демонстрациягә чыга, танкларны шул халык өстенә җибәрәбезме?

Полторанин тынып калды. Берсе дә сүз әйтмәде. Шулай тын гына таралыштылар.

Полторанинның кисәтүе Казанны коткарды бугай: Татарстанга гаскәр кертелмичә калды.

Минтимер Шәймиев бу турыда белә, чөнки Ельцин аны Мәскәүгә махсус чакыртып сөйләшкән иде. Ләкин Шәймиев, йомшак кына сөйләшеп, үз сүзендә каты торды.

1990 елларда Мәскәүгә чакыртып «эшкәртүләр» бик еш була торган иде.

Минтимер Шәймиевнең бимазаларын, йокысыз төннәр уздыруын ике генә кеше белә иде: Сәкинә ханым белән Илбашы үзе генә.

Ләкин Ельцин үзе дә бит каушап калган иде... Аны урап алган сәясәтчеләр, хәрбиләр дә нишләргә белми. Хасбулатов та, кая керер тишек тапмыйча, Татарстан юлбарысы өчен тимер читлек үрә башлады. Әмма Минтимер Шәймиевне алай гына кабып йотып булмый иде. Шулай да Татарстанны куркыныч шаукым чорнап алган, шаукым гына да түгел, аны шом баскан иде. Дөресен генә әйткәндә, җөмһүриятебезнең хәле бик тә мөшкел иде.

*(Дәвамы киләсе санда)*



Айдар
Хәлим

# СИН МИЛЛӘТНЕ ИТТЕҢ ТУКАЙЛЫ

## Без исән!

Ташлар басты, ташлар басты безне,
Биш гасыр ташлардан изелсәң,
Таш күзеннән җандай чәчрәп чыгып,
Әйтү ләззәт икән:
– Без исән!
Җимертелгән Шәһри Казан сыман
Атылырга рәткә тезелсәң,
Җәһәннәмнән кабат күтәрелеп,
Әйтү ләззәт икән:
– Без исән!

Безне талап, алар баемады,
Хәер сорашалар – син күрсәң!
Без һаман бай, чөнки таңнан торып,
Милләтебез эшли –
Без исән!
Без исән!
Без исән!

Айдар ХӘЛИМ (1942) – *шагыйрь, прозаик, публицист; «Гомеремнең ун көне», «Өч аяклы ат», «Татар моңы», «Хунвейбин» һ.б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Г.Исхакый исемендәге әдәби премия лауреаты. Чаллыда яши.*

* * *

Мин тагын тауларда. Сөяк кебек,
Ташлар иңри кичле-иртәле.
Картайсам да, сөяк сызлауларын
Җырлый алам икән бит әле!..

Сызлый, сыкрый, иңри, өзли җелек.
Өзләп, нәрсә эзли башлаган?
Без тереме? Тере икән, димәк,
Без туганбыз шушы ташлардан...

Әйе, шушы өзләү – эзләү иде,
Сине күзләү иде, Җәмилә!
Бакчасарай ташларында сине
Күрми түзмәү иде, Җәмилә!..

Әйткән идең ул чак: килерсең, дип,
Бер очрашырбыз, дип, Җәмилә.
Картлыгымда Сөюгә китердең
Яшьлектә булмаган Ямь белән.

Шигырь язган тәнкыйтьчеләр сыман
Ясый алмаганга шигырьне,
Синең хакка моң гармунавазын
Җан-чыгырдан коеп төшердем...

Үзеңнән җибәрмә, күрче, мине –
Гармунавазчыны, кырынга –
Бу көндә дә аппаралар, бәйләп,
Үзем теләмәгән урынга?!

Җирләр аеры, һавалар бер безнең,
Димәк, бер үк безнең дәва да –
Бакчасарай ханын, аһ, Җәмилә,
Камырдан булса да әвәлә!..

Камыр Батыр, бәлки, ыруыбызның
Чын батыры булыр, кем белә? –
Кайткан җилдә нәзакәткә чум да
Карашың бор миңа, Җәмилә...

* * *

*Мәшһүр мандолиначы Исмәгыйль*
*Һилаловның якты истәлегенә*

Тау өстеннән җил-канатта очам,
Егылудан куркмыйм, җир – аман.
Канатлы булырга васыять иткән
Безгә Хак Пәйгамбәр Сөләйман.

Таланган ташлардан кан тама, дип
Җиргә төшсәм, – ул таш уты икән.
Телләремдә тәмлим! – Ут дигәнем
Йөземнәрнең алсу суты икән...

Күрәм, таулар сәндерәсе буйлап,
Кырымда булыр дип бер җәннәт,
Йөзем чырагълары бәйләп йөри
Хак Пәйгамбәребез Мөхәммәд.

Нәрсә булды? – Тырнак очларында
Зеңгелдек моң чиртеп күкләрдән,
Күрәм, кырмыскалар кайтып килә,
Һәркайсы мандолин күтәргән...

Сөргеннәрдән тормыш кайта...
Тормыш
Кукуруз чәкәнедәй саргайган.
Бу чәкәнне сарган яшел биләү-
ләрнең чит-читләре карайган...

## «Амур дулкыннары» турында баллада

*Кадрия кызыма*

Киев. Вокзал. Мәйдан. Эссе. Томба.
Ашыгыч чакрып гүя җилләрне,
Тынлы оркестр «Амур дулкыннары»н
Кинәт каян
Уйнап җибәрде?

Төш түгелме? Хакмы? Каян чыккан
Бүген бу моң? Гамәл? Бу гамьнәр?
Кайнар канны боз сыман әхвәлләп
Керде бу мөкәммәл мәкамнәр?

Җиз моңнардан гаҗиз, моң тарафын
Эзләп, бер чаптым, бер йөгердем.
Вокзал телсез иде. Вә, ниһаять,
Вә вәҗед-вәҗигый* ни күрдем:

Сул канатта, чатырда, мәхшәрдә,
Кояшның кайнаган күзендә
Квартетмы уйный?! Уйнап уйный!
Вә вәҗед, вә вәҗигъ түземдә!..

Салкын мәгъдән, сыра, аракыдан
Исрек, кендектән шәр мәхшәрәт
Ашый-эчә, кадими моңны гына
Аңлый алмый иде, хәшәрәт!..

* Вәҗед-вәҗигый *(гарәп.)* – матурдан-матур, гүзәлдән-гүзәл.

Дүрт моңавазчыга* биш тыңлаучы,
Юк, алтынчыбыз бар – мин идем.
Адәмнәрнең моңны тыңларга да
Теләмәүләреннән тиле идем...

«Әнә, кызым!..» күрсәтимче, дисәм,
Мең бөгәлле бакыр торбалар,
Җитәгемдә балам юк икән бит –
Буш учта чыңрый тик торналар!..

Бу эссене, Амур дулкыннарын,
Торналарны бергә куш иде! –
Җитәкләргә дә бит өлгермәдем,
Йә, хуш, сабый, йә, йә, хуш инде!..

Болар миннән сине алганнар бит,
Мине ят бер кеше иткәннәр,
Илгә кайтарып та җиткермичә,
Сөргеннәргә алып киткәннәр!..

Болар – мәңге бала күрмәгәндәй,
Буш ялтырда бала иркәләп,
Ишегалдыннан да читкә чыкмый
Чикерткә эзләгән күркәләр...

Син юк, син юк, син нигә юк? –
Сине кем соң миндәй иркәләр?
Болар сине бездәй бөркет түгел,
Үзләредәй кош-корт итәләр...

...Үзем ярлы, уем гарьле. Сезне
Ходай насыйп итсен бай иргә.
Оркестрның буш эшләпәсенә
Ун гривна** салдым хәергә...

## Лашманчы юлы***

Кара көздә,
Кышкылыкка утын
Хәстәрләтеп чыбык-чабыктан,
Урманчылар җик күрсәтә иде
Урман сирәкләтеп халыктан.

Без болай да сирәк калган ласа!
Сугыштан кайтмагач әтәйләр,
Тупасланып беткән балта белән
Бездән урман сирәкләтәләр...

* Моңавазчы – оркестрант *(автор кулланган яңа сүз).*

** Гривна – украин акчасы.

*** Лашманчы *(немец сүзе – laschmen)* – урманчы. Пётр патша указы белән кораблар төзер өчен урман кисәргә алынган татарлар. Гомумиләштереп әйткәндә, безнең көннәргә килеп җиткән хәрби хезмәтне тылда алыштыра торган хезмәт армиясе (трудармия).

Алдан инәй, арттан – өч бертуган
Сабый – кече берсе-берсеннән,
Лабылыкта, влачны каргыйбыз:
– Дөмексеннәр иде!.. Үлсеннәр!..

Туң агачка үтмәс балта белән
Тондырдың – киселми, ярчыла.
Ябалдаштан шыбыр-шыбыр килеп
Коелалар бозлы тамчылар...

Үзебез ач, ачлык – әнкәбезнең
Йөзен ертып төшкән җыерчык.
Ул яңгырдан яфраклар астына
Төенчек яшерә – кыерчык.

Шул ипине уйлап утын сөйрим,
Үзем лычма булып яңгырдан.
Төпкә суккан саен яфраклардан
Тамчы ява – салкын ялкында!..

Арка үзәгенә салкын ялкын –
Гүя эреп тимер уела!
Баш миеннән арка мие буйлап
Бозлы су аккандай тоела!

Үзебез сирәкләнеп исән калгач,
Бик тә сирәк түгел микән без?!
Илгә кирәкмәсәк, лашман тартып,
Агач сирәкләргә кирәк без!

Лашман юлы – дошман юлы булды,
Нишләтәсең, түздем, түзәмен.
Бүген булса җылыталмый йөрим
Шулчак туңган арка үзәгем.

## Җимерек оядагы сыерчык

Караш төшә бит ул. Ходай биргәч,
Күз карашын кая куясың?
Күрәм, карамада чалышаеп,
Ас-өс килгән сыерчык оясы.

Әмма тормыш бара чалышта да,
Булмагандай үлем дөньяда.
Шахтёр кебек кара бер сыерчык
Өзелепләр сайрый оярда...

Бала чыгара ул. Балаларын
Җимерек йортта күреп алтынга.
Мин охшаттым ана сыерчыкны
Йортсыз калган ятим хатынга...

Гүя ул яулыгын чалыш бәйләп,
Җимерек тупсасына баскан да,
Ләгънәт укый, фронтлардан килгән
Похоронка хатын ачкан да.

Ул бәхетсез, тик яктысыз түгел:
Оясына төшә кояшы.
Кошлар ояламый, кояш якка
Карамаса анын оясы...

## Семён Денисович Игнатьевка*

Бүген таллар йөгереп килделәр дә:
«Без, – диделәр, – хәтәр заманда
Күеп, юкка чыгып беткән идек,
Исән калдык, исән һаман да...»

Семён Денисович!
Бу талларның
Яше-карты, олы-кечесе
Рәхмәт укый сиңа, бүләк булып
Безгә төшкән «урус кишиси».

Син мәктәпле иттең тал яфрагын,
Якты сулар сибеп тамырга,
Туган телле – хлорофиллы иттең
Гайрәт өстәп сабыр камырга...

Татар шигыреннән фән чатнатып,
Син, зонадан чыккан зыялы,
Казан уртасына һәйкәл куеп,
Син милләтне иттең Тукайлы.

Үз кадребезне без белмибез шул.
Кадер белер өчен ил кирәк.
Синең кебек асыл ир, җәүһәр зат,
Синдәй йөрәк, күкрәк, бил кирәк.

Сине сагынып бүген җырлар җырлый
Яшел армиясе талларның.
Синең хактин, Семён Денисович,
Киләчәге бар бит аларның...

**Редакциядән:**

*Бу айда каләмдәшебез үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*

* Игнатьев С.Д. (1904-1983) – СССР Иминлек саклау эшләре министры (1951-1953), КПССның Башкортстан (1953-1957), Татарстан Өлкә Комитеты Беренче Секретаре (1957-1960).

Марсель
Галиев

# ТИМӘ, ЯШӘСЕН!

РОМАН-НОВЕЛЛА

## Казарма

Карлар тәгәрәтеп Яңа ел якынлаша... Минем чит җирдә бу бәйрәмне каршылавым беренче тапкыр бит әле. Һәркайда әзерлек бара. Гадәттәгечә, кичке барлау һәм отбой алдыннан тулы рота белән унбиш минутка һава алыштырырга чыгабыз. Бер аякка басып, йөз тавышка җырлап, ишегалды мәйданын әйләнәбез. Без җырлаганны алкышлап, чыршы ботакларыннан карлар коела. Күн итекләрнең каты табаны астыннан карлы юл такыраеп кала.

Бүген менә иртәдән бирле ике кубрикта да эш кайный. Караватларны бер якка этеп, күбесен коридорга чыгарып, мәйданны бушатабыз. Юешләп, паркет идәннең керләнеп беткән төсен кырып-чистарту башлана. Тимерагачтан (ясень) эшләнгән паркет, бизәкләре белән ачылып китеп, чистаргач, аңа зур-зур савытларда китерелгән алсу төстәге мастиканы сылыйбыз. Аякларга иске шинель кисәгеннән әтмәлләгән нәрсәләрне кигереп, идәнне, ниндидер бию башкарган кебек, әле бер аяк, әле икенче аяк белән алыш-тилеш китереп ышкыйбыз. Мастика күзгә күренеп тигез буяла, сеңә бара. Сержантлар «чи калмаганмы», ягъни, сыйфатлы сеңдерелгәнме, буяу йокмаган урыннар калмаганмы дип, тикшереп йөриләр. Казарма кайный.

Үзең дневальный булгач кына казарманың пөхтәлектән көлеп торырга тиешлеген аңлыйсың.

Кубрикта ике взводтан ике дневальный швабра белән идәнне тузаннан чистартып чыга. Караватлар гаҗәп калын, тыгыз, җылы, карасу-зәңгәр төстәге одеяллар белән җыештырылган. Урта бер җирендә ак җәймәне катлы-катлы таслап, билбау ясап куела. Аннары, бау сузып, тумбочкалар рәтен, ак мендәрләрне, никель караватлар башларын тигезлисең. Рота старшинасы килеп карый, кыл кебек тигезлектән бер сантиметрга чыгып торган урын күреп алса да, бармагын суза, син шул бармак юнәлешендә барып, караватнымы, мендәрнеме төзәтеп куясың.

Аннары син, канәгать булып, казарма эчен күздән кичерәсең. Зур-зур тәрәзәләрдән кергән яктылыктан паркет идән көзге кебек ялтырап тора, таеп егылырлык шомалык. Караватлар бер кылга тезелгән. Тәртип, пөхтәлек, затлылык.

Яңа елны илгә хәбәр итеп, курантлар яңгырыйсы көнне иртән иртүк коридорга ап-ак келәм җәелде. Кыр-кырлары зәңгәр-кызыл сызык белән

---

*Дәвамы. Башы 2016 елның 10-12нче саннарында.*

каймаланган бу келәмнең озынлыгы утыз метрлар булыр. Шундый яктырып, бәйрәм рухы биреп торган бу купшы аклыкка тупас күн итек эзе калдыру гөнаһ кебек тоела. Башта, кыймыйча, чит-читенә генә баскаладык та, аннары кыюланып, өстеннән йөри башладык.

Укулар башланды. Калын-калын дәфтәрләр өләштеләр. Үтәли тишеп, шнурланган, бау очлары сургучлы мөһер белән беркетелгән. Димәк, бер битен дә ертырга, югалтырга ярамый.

Класслар гаҗәеп зур. Кайсына ярты самолёт сыйган. Эреле-ваклы бомбалар. Пушкалар. Гашеткасына баскач, гөрс-гөрс аваз сала. Бомба эләргә өйрәнәбез. Бомба урынына ыргаклы чылбырлар гына.

Штурман кабинасындагы ЭСБР-49 дип аталган прицел шаккатырды. Миңа, ялтыр-йолтыр әйберләр яраткан кешегә, бу – үзе бер могҗиза иде. Нинди генә детале юк. Хәтта бармак башы хәтле генә түгәрәк көзгесе дә бар. Безне, кирәге чыкса, штурман булырлык дәрәҗәдә укыталар. Үз гомеремдә беренче мәртәбә физикадан мәсьәлә чиштем. Тагын чишәсе килеп тора. Мавыктыргыч, кызыклы дөнья икән бит бу. Саннар, формулалар сиздерми дә үзенә тартып ала. Моның котырткыч гипнозы бар. Вакытында туктарга кирәк. Ярый әле, мәктәптә битараф калганмын. Бу саннар пәрәвезе мине урап алып, чишелеш дигән кызыктыргыч хикмәткә этеп барасы булган икән бит.

Яңа ел көннәрендә хатлар килү тукталды. Кинәт, сулыш кысылгандай булды. Үз-үземне кая куярга белмичә йөрим. Почта үзәге урнашкан бинага да барып карыйм. Бикле. Баскычын кар каплап киткән, анда борынгы почтальон – күгәрчен эзләре генә.

Ниһаять, өченче январь көнне дөнья йөзе ачылып китте. Дневальный тумбочкасына хатлар өелүгә, дәррәү купты казарма тормышы; аяк атлаулары, йөз чалымнары, куанычлы ымлыклар, эчке хисен тыя алмыйча кычкырып куюлар – үзгә бер куелыкта кайнап алды.

Хатлар – солдатның бөек юанычы.

Миңа гына унлап хат. Иң беренче мин, әлбәттә, Фәниядән килгән өч хатны укып чыктым. Числолар, өзелмичә, рәттән бара. Тәки сүзендә тора бит, әй! Өч ел дәверне эченә йоткан гранит кыяның без бит әле беренче ташларын гына кыеп төшердек. Алда – сындырып сыналасы күпме гомер.

Казарма йокыга талгач та, мин төнге сәгать бергә кадәр ленкомнатада үз-үзем белән шахмат уйнап утырам. Михаил Ботвинник һәм Рәшит Нәҗметдиновның уеннарына багышланган ике китабым бар. Шуларның йөрешләрен өйрәнәм. Шахмат уенының поэзиясен тапкан дип бәяләнгән бу ике бөекнең гаҗәеп, акыл җитмәслек комбинацияләре сокландыра.

Мәскәүдә басыла торган хәрби газеталарның атасы – «Красная звезда»да шахмат мәсьәләләренә дә урын бирелә. Аларны чишү – минем яраткан шөгылем. Чишеп кенә калмыйм, кызыклы җавапларны газета редакциясенә дә юллыйм.

Беркөнне табиблар килеп, бөтен ротага укол кадап чыктылар. Ярты сәгатьләп вакыт үткәч, коридорга чыгып тезелергә дигән команда булды. Чыгып тезелдек. «Смирно!» дигән команда булды. Шулвакыт, беренче ротаның алгы рәттәге берничә егете шапылдап, йөзе белән идәнгә ауды. Ни булды дип аңга килергә өлгергәнче, икенче взводның рәтләре киселгән кебек ава башлады. Үзебезнең взводта да алда торган берничә егет аугач, минем дә күз алдым караңгыланып китте. Ике рәт арасында торганлыктан, аумыйча, идәнгә шуып төшеп, һушымны җуйганмын. Култыклап, урындыкка кертеп утырткач, айнып киттем, бөтен тәнгә салкын тир бәреп чыкты.

Җәмгысы, ротадан утыз-кырыклап курсант шушы хәлгә дучар булды. Әлбәттә, сафта торганда уртадагы, арттагы рәтләрдән дә һушы китүчеләр булган, без бит маңгай белән, йөз белән шапылдап төшүче беренче рәтләрне генә искәрдек.

Нинди укол кададылар, ни өчен?

Соңыннан күпме талпынсак та, без бу сорауга анык кына җавап таба алмадык шикелле.

Гомергә кичермәслек бер ялгышымны хәзер дә оныта алмыйм. Аяктан кергән салкын кире чыкмый, дигәнне үземдә сынап карарга теләгәнмен ахрысы.

Чаңгыга чыгар алдыннан командир кисәтте югыйсә: «Ун чакрымны үтү мәҗбүри түгел, кемнәр үз көченә ышанмый, калырга мөмкин, җитмәсә, көне дә салкынайтып җибәрде», – диде.

Ә мин, җүләр, тыңламадым. Ун чакрым араны үтеп, үз-үзем каршында көчем барлыгынраслыйсым килде. Алдырып киттем тәвәккәлләп. Пермь тирәсендәге таулы чыршы урманнары ышыклаган кебек була да, яланга чыккач, үткен җил битне чагып ала. Ике-өч чакрымнан соң аяклар өши башлаганын сизәм, юлда тукталып, аягын уып утырганнарны да күрәм, әмма тукталмыйм, үҗәтләнеп һаман алга барам. Аяк бармаклары да, чыныгып, өшемәс булды.

Ун чакрымны үтеп, часть ихатасына кайтып чаңгыларны салгач кына акылга килдем: күн итекләр шакыраеп каткан, аяк барлыгы бөтенләй сизелми. Командир тизрәк казармага кайтырга әмер бирде.

Берничә солдат көч-хәл белән итекне кубарып салдырдылар. Бигрәк тә баш бармаклар нык туңган, боз кебек, шакылдап тора. Моны күргәч, һушым китте. Минем хәлдәгеләр ротада егермеләп икән, санчастьтан табиблар килеп җиткән. Безгә алагаем зур киез итекләр кигереп, санчастька, берничә көн ятып дәваланырга алып киттеләр. Аякларның үтереп әрнүенә чыдар хәл юк. Бозы эрегәч, аяк бармаклары пешкән кебек кабарып чыкты. Бернинди укол да, майлар да ярдәм итми.

Мин шунда, беркем мәҗбүр итмәгәндә, бер кирәкмәгәнгә адарынып, үз сәламәтлегемә эре калибрлы винтовкадан аткан булганмын икән...

Илнең төрле тарафларыннан җыелсак та, инде бер рота булып, уртак казармада яши башлагач, нindiдер сизелер-сизелмәс кенә туганлык хисе, «бу – безнеке» дигән якынлык тойгысы уяна бара шикелле. Әллә нинди шартларга эләксә дә, кеше үз оясыннан ятсынып, өнәмичә, яши алмый, күрәсең.

«Солдат спит – служба идёт» дигән сүз армиядә юкка кермәгән. Солдатның ике куанычы беренче урында тора: ашау һәм йокы. Боларның икесе дә кирәкле микъдарда, аз гына җитми кала. Кайчакларда хлеборезкадан берәрсе түтәрәме белән кара ипи алуга ирешсә, аны сындырып кына, мул тоз ягып ашауның ләззәтен дөньяның бүтән бер ризыгы белән дә чагыштырып булмый...

Өйдән миңа «Зоркий» фотоаппаратын салдылар. Менә хәзер акча эшләүгә керешәбез: батальонда өч йөздән артык курсант. Шуларның портретларын ясарга була. Аннары һәр взводка аерым бизәп, уку елларын куеп, күмәк фоторәсем эшләргә мөмкин. Бу шөгыльгә мин Бацынны тарттым. Карусыз ризалашты. Татар булса, сагаер, шикләнер, икеләнеп калыр, астыртын хәйлә күрер, кешегә файда була дип көнләшер, үземә файда әз калмыймы, дип эчтән бетеренер иде. Ә Володя, чын славян кавеменнән буларак, аны-моны уйлап тормады.

Хисап йөртеп, алым-биремнәрне санагач, табыш шактый керергә тиеш

иде. Ләкин тәҗрибәсезлек харап итте. Ярый әле акчаны бер-ике взводтан гына җыеп өлгергән идек.

Нәрсәдә хата килеп чыкты? Портретлар эшләнеп, аларны тезеп, һәр взводныкын аерым бизәп, самолётлар сурәтен беркетеп эшләгәннән соң, моны яңадан төшерү өчен минем фотоаппаратның көче җитмәде. Шәһәргә чыгып, фотолаборатория белән бәйләнешкә керү бик мәшәкатьле тоелды.

Шулай итеп, безнең акча күрәү хыялы барып чыкмады. Без моңа офтанып тормыйча, кул гына селтәдек.

Шәһәргә ялга чыкканда, иң кирәк әйбер фотоаппарат икән. Паркта кызлар белән танышу өчен иң җайлы чара – бергә фотога төшү. Аннары инде адрес алышу китә. Пермь кызлары тартыну, оялуны белмиләр. Төрле гаскәриләр хезмәт иткән, солдат күреп гадәтләнгән шәһәрләрдә, гадәттә, шулай була. Урал кызлары суырып үпсә, үпкән эзгә кан сава. «Взасос» дигән сүзнең мәгънәсенә мин шунда төшендем.

Казармада вирус кебек сизелмичә дә, бер гаугасыз, тын гына бер чир – әйбер чәлдерү чире таралды. Киемнәр һәм аңа тагылган билгеләр бертөсле бит, барысы да бер урында таслап, пөхтәләп эленгән. Нәрсәдән башлана бу чирнең әүвәле? Әйтик, берәүнең шинель якасындагы авиаторлар билгесе беркетелгән урыныннан сынып чыга. Ул ике дә уйлап тормыйча янәшәдәге курсантныкын алып тага, шулай итеп, китә бер-бер артлы чәлдерешү... Берәү дә артыгын сүгенми, кычкырышмый, әнә шулай тып-тыныч, астыртын гына таралып ята бу чир. Югыйсә, беренче булып югалткан солдатка, тиеннәргә сатып алып, петлицадагы эзенә яңаны тагып кына куясы бит...

Әмма вирусның азып, бүтән күзәнәкләргә күчә торган гадәте бар. Монда да шулай... Инде хәзер бушлатларны урлатмас өчен эченә хлорка белән зур итеп исемнәрне яза башладык. Шинельнең артында ике сәдәфкә эләктерелә торган, хлястик дигән хикмәте бар. Кемдер шуны төшереп калдырган инде. Китте урлашу. Тагын яңа гадәткә күнегә башладык: шинельне салып элгәндә, хлястикны ычкындырып, тумбочкага яшереп куябыз. Юк кына әйбер үзе, әмма ансыз шинель итәге ыспай рәвешен җуеп, тарала да китә инде.

(Бусы җәй җиткәч булды: пилотка йолдызының кадавычы ике җәптән тора. Беркеткәндә бик тиз сынып чыгучан. Шуңа күрә, әз генә борылган арада йолдызыңны чәлдерсәләр – моңа әзер бул, тыныч кал, хохоллар кебек, бинипая юан тавыш белән сөрән салма, барыбер үзеңнекен таба алмыйсың, чөнки бөтен йолдызлар да бертөсле.

Аптырагач, мин моңа чара таптым бит: пилотка маңгаендагы урынны кызыл төскә, йолдыз итеп буядым да куйдым. Берәү дә искәрми, кызыл төс чагылып китәме – шул җиткән.)

Ә бер көнне... җитди караклык кылынганлыгы турында яман хәбәр бөтен ротаны сискәндерде. Армиядә шундый кырыс гадәт хөкем сөрә: урлаган кеше түгел, ә урлаткан кеше гаепле... Командирлар сүзне урлаткан кешене битәрләүдән башлыйлар. Чөнки ул, ачык авызлыгы аркасында, бөтен кешене җайсыз хәлгә куя.

Беренче взводның бер курсанты шактый суммада акчасын урлаткан икән. Китте тикшерү, чыш-пыш, үзара фаразлар... Баш очына гүя кылга эленгән кылыч асылды. Карак табылганчы һәммәбез дә тигез: по-до-зре-ва-е-мый... Казармада киеренке халәт урнашты. Бер гаепсез башың белән: «Мин ул, мин алдым!» дип кычкырып, кайчакта, бу киеренкелек сүрүен умырып төшерәсе килә.

Беренче взводта Урлашев дигән фамилияле удмурт егете бар иде. Без, татарларга, шаяртырга җитә калды. «Шул түгел микән, урлашасы туганда ук маңгаена язып куелган», дип үзара көлештек. Карак барыбер табылыр ул, татар булмаса гына ярар иде, дип эчемнән зарилап телим. Якташлар белән бу хакта пышан-пышан килеп, үзара борчулы гәпләшеп тә алабыз. Чувашлар да тыныч түгел, сагаебрак йөриләр...

Өч-дүрт көннән соң каракның эзенә төштеләр бит. Рус егете Кайгородов булып чыкты. Без, татарлар, и сөенештек инде. «Кайгородов – паскуда», «Кайгородов – гнида», «Кайгородов – вор» дигән кебек сүзләрне, таш итеп атышалар гына. Ә татар егете урлашкан булса... «Татарин – падла!», «Вот гнида татарин», «Татарин – вор!» дип чаң кагарлар иде. Рус кешесенең яман эше үзенә генә төшә, ә татар яманлык кылса, карасы бөтен милләтне корымлый. Шуңа күрә без икеләтә эшчән, икеләтә акыллы, икеләтә батыр булып кына үз-үзебезне раслый алабыз...

Әнә бит, сафка басарга соңарып, ашыга-ашыга килгән татар курсантыннан:

– Один татарин, в две шеренги становись! – дип көлгән булалар. Мин әлеге сүзнең асылын аңларга тырышып карыйм: телне белмәүгә ишарәме бу, үз шеренгасын да таба алмаган томаналыкны искәртүме – белмәссең...

Моны, һич көтмәгәндә, рота командирының сәяси эшләр буенча урынбасары – капитан Дементьев бөтен саф каршында аңлатып бирде. (Ул сугыш азагында «сын полка» булып утлар-сулар кичеп алган.)

– Ә нигә көләсез? – диде ул, тып-тын калган взводны күздән кичереп. – Бер татар чынлап та берьюлы ике шеренгага баса алган. Әйе. Чөнки бер татар ике кешелек сугышкан. Командир, шуңа күрә, взводында бер татар булса, аның ике кешелек батырлык кыласына ышанган...

Шуннан соң руслар тарафыннан көлеп файдаланыла торган әлеге әйтем бүтән кабатланмады. Чөнки мәгънәсе татарны кечерәйтүгә корылмаган икән бит...

Ә теге... кеше акчасына кызыгып, нәфесен тыеп кала алмаган егетне рота алдына чыгарып бастырдылар. Майор Антонов үзе чыгыш ясады. Егетнең хәле кызганыч иде. Муен тамырыннан өзелеп төшәр дәрәҗәгә җиткереп башын игән. Ничек кенә хәленә керергә тырышсаң да, аклап та, аңлап та булмый торган яман очрак шул бу. Нинди нәзберек кылда тора язмыш дигәнең. Бер мизгелдә кешене актан карага әверелдереп куя ала. «Вольно. Разойдись!» командасы яңгыраганчы ук Кайгородовны алып чыгып киттеләр. Шуннан соң ул казармага әйләнеп кайтмады, бүтән частька күчергәннәр дип ишеттек.

Яз җиткәч, практик дәресләр чын самолётлар янында башланды. Буе – утыз метрдан арткан ТУ-16 самолёты Казан заводында эшләнгән. Бер салган ягулык белән алты мең чакрым араны үтә. Ракета йөртүче ТУ-22 самолёты да шундый ук язмышлы. Болар – еракка оча торган авиация бөркетләре. Шундый да сылу, соклангыч итеп эшләнгәннәр. Карыйсың да, кеше акылының бу – соң кимәленә җиткән камиллеге, моны кабатлап та, арттырып та булмас, диеп уйлыйсың.

Безнең бөркетләрдән арырак истребительләр – ыспай «ЯК»лар, «СУ»лар тезелеп тора. Бу – җиңел, җитез кошлар бүтән роталарга карый.

Берничә чакрым ераклыкта башка бер частьнең «тере» хәрби аэродромы күренә. Очыш көннәрендә һава чатнап тора, тавыш тизлегеннән дә узып очучы истребительләр безнең өстән һаваны ярып узалар. Андый чакта... Кыр казлары турдан узганда, алгысынып карап калган йорт казы шикелле, безнең «ТУ» да очарга кызыгып, талпынып куядыр шикелле.

Әмма ул, бөтен детальләре исән булуга карамастан, очышын гомерлеккә җуеп, безнең өйрәнү әсбабына әверелгән инде.

Самолёт янына килеп туктауга, иң беренче син нәрсәгә игътибар итәргә тиешсең? Сүзне шуннан башламыйсың икән – «икеле» ыргагына эләгәсең. Очыштан кайтып төшкән самолёт корпусы – һавада чакта хәтәр көчле электрланган була. Экипаж командиры, кабина ишеге ачылуга, иң беренче эше итеп, нәзек тимерчыбыктан ишелгән шнурга беркетелгән, бер башы очлы кызыл тимер кисәген җиргә ташлый. Шул мәлдә самолёт корпусы туплаган электр кодрәтен җир үзенә тартып ала.

Син, механик буларак, самолёт янына килүгә, иң беренче әнә шул кызыл «калкавычның» җиргә төшкәнме, юкмы икәнен карарга тиешсең. Әгәр лётчик оныткан булса... Килеп кагылуга көчле ток бәреп, сине кара күмергә әйләндерә... Бәләкәй чагымда ток шаукымын үз тәнемдә кичергән буларак, мин моны гомерлеккә хәтердә калдырдым.

Күн итекләрне салып ташлап, самолёт өстенә, канат ягына чыкканда, йомшак табанлы чүәкләрдән генә йөрибез. Җаның нindине тели, кирәкле инструментларның барысы да күз уңында, тоник зәңгәр төстәге, капкачлы, бикләвечле «дипломат»ларга тезеп аерым-аерым беркетелгән. Дәрес соңында, командир карап-тикшереп чыга, бөтен инструментлар да үз оясындамы, нәни генә бер корал җитмәсә дә, аны табып урынына куймыйча, самолёт стартка баса алмый. Миңа бу тәртип ичмасам!

Инструкторыбыз – сержант Разумовский. Мәскәү университетының физика-математика факультетында өченче курста укыганда армиягә алганнар. Һәр сүзнең җеген-җеккә китереп, тыныч кына аңлата. Сүгенү яисә кызып китү – аңа һич тә килешми торган ят сыйфат.

Классларда теория өлешен офицерлар укыткан булса, монда кулга тотып үзең эшләп карауга ул җитәкчелек итә.

Бомбалар «учебный» дип аталса да, авырлыклары чын, күпме дип язылган, шуңа тәңгәл килә. Иң зур бомба – тугыз тонналы. Ангарда тора. Үзе бер самолёт кадәрле, аэродромга алып килү өчен көчле моторлы махсус тягач эшләнгән.

– Аны элеп караячакбызмы? – дигәч, сержант Разумовский башын селкеп куйды. Кирәге чыкмас... Андый бомбалар эшләнми инде хәзер... – диде. Әзерләп элгәнче сугыш бетеп куярга мөмкин.

Беркөнне 250 килолы бомбаны самолётның «бомбаотсек» дип аталган корсагына элү бара. Чуваш егете Ульяновның муенында – пульты. Арча егете Җәүдәт, дүрт аяклы баскычка менеп, бомбаны стабилизаторыннан тоткан. Бомбага эләктерелгән йозак очлары махсус ялгашка җиңел керсен өчен, ул стабилизаторыннан тотып бомбаны тирбәткәләп тора. Пультның бер ягындагы кнопкага курсант озаграк басып алдымы, бомба кинәт чайкалып куйды, йозагы ычкынып китте, кычкырган тавышка аста кайнашкан курсантлар чыгып өлгерделәр, баскычтан Җәүдәт тә атылып төште. Нинди авыр бомба, бетонга төшеп бәрелеп, резина туп сыман берничә мәртәбә сикереп алды. Шунда гына искәрдек, Җәүдәт бөгелеп төшкән, кулы кан гына... кылыч кебек үткен тимерле стабилизатор аның кул бармакларын сөягенә кадәр кыеп алган икән. Ярасын тиз генә бинт белән бәйләп, санчастька озаттык үзен.

Очучы кабинасы идәннән түшәмгә кадәр төрле приборлар белән чуарланган. Боларны белү, истә калдыру өчен нинди акыл кирәк? Шуңадыр, лётчик бер ай ялда булып кайтса, аны башта тренажёрга утыртып, бер ай буена хәтерен яңарталар, шуннан соң гына аңа очарга рөхсәт бирелә.

Миңа «ТУ»ның иң ошаган кабинасы – очучыларныкыннан арттарак, самолёт сыртына урнашкан штурман-стрелок кабинасы. Бөтен тараф күренеп торган пыяла гөмбәз эчендә, креслода утырасың. Кресло прицел һәм игезәк көпшәле пушка белән бергә өч йөз алтмыш градуска әйләнеп тора. «Пушка» дигәч тә, юан көпшәле туп турында сүз бармый. Самолётныкы пулемёт көпшәсеннән әз генә юанрак. Мин шул гөмбәз эченә кереп утырам, күрше аэродромнан бер-бер артлы истребительләр күтәрелә. Өстебездән «СУ»лар шулкадәр тиз оча, төзәп өлгерә алмыйм, менә берсе, менә икенчесе... Әнә өченчесе минем прицелга ак чебен кадәрле генә булып якынлаша, гашеткага басып өлгерәм – гөрс! Тавышы гына чыга шул, атмый, атмасын белгәнгә төзим дә мин истребительгә, ә ул берни белми очуын дәвам итә, кайчандыр җирдә кара буразналар сызган малайга күк киңлегендә ак буразналар гына калдырып китә.

Ай буе, көн саен, биш сәгать дәвамында винтовкадан ату күнегүләре алырмын дип башыма китермәгән идем. Мондый бәхетнең ишелеп төшүе сирәк була.

Свердловск шәһәрендә ату ярышлары булачак икән. Безне, төрле ротадан алты кешене, сайлап алдылар. Җир астында эшләнгән махсус тир бик шәп итеп җиһазланган. Мишеньнәр автомат рәвештә куела. Атканнан соң пуля эзләрен илле метрга йөгереп барып карау юк, монокольләр аша гына күзәтәсең. Бер тәнәфестә кесәмдәге хатны беркетеп киткән идем, илле метрдан язу ап-ачык күренә.

Кулыбызда – спорт мастерларына гына бирелә торган винтовка. Төрле рәвештә: ятып та, чүгәләп, сыңар тезгә таянып та, үрә басып та атуда үзебезне сынап карыйбыз.

Инструктор – өлкән лейтенант үзе дә спорт мастеры титулын яулаган. Халыкара ярышларда катнашкан тәҗрибәле мәргән.

Яткан килеш ату аңлашыла... ә менә бер тезгә таянып яисә баскан килеш, аткан чакта кулың талып, калтырарга мөмкин бит әле. Моны булдырмас өчен, винтовка каешы әллә ничек, шактый катлаулы итеп терсәктән тарттырыла, корал, кул, гәүдә470бербөтен була да кала.

Винтовка ике куроклы, беренчесен бармагың белән тартып әзерләп куясың да... йөрәк тибешен, тынынны чамалап, икенче бармагыңны курокка сузасың. Юк, бу мизгелдә бернинди селкенү, тартылу юк... Җир шары энә очында, тының үпкәдә, һәм йөрәгеңнең ике тибеше арасындагы үле ноктада бармагың икенче курокка өрфия юкалыкта тиеп кенә ала – гөрселди дөнья, шаукымлы дулкын тәнгә тарала.

Аннары, үз мишенеңә ун патронны бер-бер артлы сибеп чыккач, монокольдән карыйсың. Мишеньнең «күз алмасына» – унлыкка бәрү... әле ядрәләрнең берсе өстенә берсе тигән дә булса... Күңелең җир астында икәнен дә онытып, күккә сикерә. Корал тотып, төби, ата белгән миллион ирләрнең хыялы бит бу! Азарт, ләззәт алуның иң югары кимәле.

Туктаусыз ата торгач, кул тала, күз ара, йөрәк сикерә башлый. Киеренкелек бөтен тәндә тартылган кыл кебек зеңләп тора. Ә күңелдә – рәхәт җиңеллек.

Көн саен ату күнегүләре ала торгач, үз-үзеңә карата шундый уй да туа. Мин хәзер йөз чакрым тизлек белән барган машинадан, йөз метр ераклыктагы куянның кылый күзен атып алалам... Бу мактануда хаклык бармы? Хаклыкны аклау өчен хакыннан тормаска кирәк.

Ничә йөз патрон атканмындыр бу ай эчендә. Гомердә бер генә килә торган бәхетле очрак.

Кинәт кенә башланды да, кинәт кенә ябылды да бу бәхет... Спорт винтовкалары белән хушлашырга туры килде. Свердловскига бара алмыйбыз икән. Ярышны көзгә күчергәннәр. Яңа шәһәрләр күреп, Урал офыгын күңелемдә киңәйтмәкче идем – булмады.

Атна-ун көн үтте микән, капитан Дементьев мине чакыртып алды. Партия, комсомол вожагы буларак, фикерен ул кистереп кенә әйтми; уратып-уратып сөйли башлый, инде якыная дисең, юк, тагын салулап китә, көтә торгач, килеп чыга бит барыбер туры юлга.

Мине, штаттан тыш хәбәрче сыйфатында, хәрби журналистлар конференциясендә катнашырга җибәрмәкче. Свердловск шәһәрендә узачак икән.

– Нинди хәбәрче булыйм мин, бер юл яза белмәгән башым белән, – дим.

– Киләчәктә өйрәнерсең, – дип, капитан җилкәмә кулын сала. – Әнә, Ленкомнатаны нинди стендлар белән бизәдең. Ял итеп кайтырсың. Ротадан бердәнбер сезнең кандидатурага тукталдык.

Шулай итеп, мин, телгә, күңелгә кергән Свердловскига барып, берничә көн торып кайттым. Батальоннан өч курсант идек. Училищены яңа бетереп килгән лейтенант җитәкчелегендә Свердловскиның истәлекле урыннарын гизеп чыктык.

Язмыш әгәр Европа ягына илтеп ыргытмаса, яңа шәһәрләр күрә-күрә Сахалинга кадәр барасы да барасы икән әле.

Бер карасаң, искәрми дә үтә торган, гадәти дә кебек, бик үк гадәти дә булмаган бер вакыйга булды. Еллар үткәч тә искә төшерәм дә асылын аңлый алмыйча гаҗизләнеп куям. Ничек алай килеп чыкты соң ул?

Йокы алдыннан рота белән кичке прогулкага чыктык. Бүген... старшина рота белән командалык итүне сержант Гаевскийга тапшырган. Әнә ул күкрәген киеребрәк атлый, тавышы бөердән калка. Мәйданны әйләнеп чыгасы колонна беренче борылышка җиткәч, гадәттә, җыр башлана торган иде. Кайсы чакта Гаевскийның әмер бирүе эт өргән кебек дорфа чыга, бүген дә шулай булды:

– Запева-ай! – дип, ул ягымсыз тавышын җилкә аша гына ыргытты. Һәр взводның запеваласы, ягъни җыр башлаучысы бар. Тәртип буенча, беренче взводның запеваласы башлап җибәрергә тиеш иде. Сержант Гаевский аның янәшәсенә килеп, янә төбәп кычкырды:

– Запевай!

Ул арада без инде прогулка мәйданын бер урап чыгып, казарма янына килеп җиткән идек.

Ни хикмәт, икенче взводның да җыр башлаучысы авызына су капкандай бара.

– Рота, на второй круг, марш! – дигән команда яңгырады. Сержант Гаевский нишләргә белми, аның беркайчан да болай каушап, оятка калганы юк иде. Ул хәзер өченче, дүртенче взводка мөрәҗәгать итсә, чигенү булыр иде. Шуңа күрә ул яңадан беренче взводның запеваласына, бөтенләй янәшә килеп:

– Курсант Завьялов, запевай! – дип кычкырды. Юк, Завьялов аны ишетми, күрми. Рота һаман шулай үҗәтләнеп атлый бирә. Беркем, беркем белән сөйләшми, «ым» какмый – телсез, саңгырау тоташ бер агым.

Өч мәртәбә әйләнгәннән соң, сержант Гаевский ротаны казарма каршында туктатты. Җир астыннан калыккан кебек рота командиры майор Антонов пәйда булды. Аның бу төндә штабта дежур чагы икән. Җиңенә кызыл бәйләгән.

Майор хәлне бик тиз аңлап алып, әллә нинди вәгазьләр сөйләп, янаулар

белән куркытып тормыйча, команданы үз кулына алды. Тагын кузгалдык баягы эзебездән. Әмма майорның да «Запевай!» командасына берәү дә буйсынырга җыенмый иде.

Гаҗәп хәл, бу бит алдан котыртып оештырылмаган иде. Тыгыз сафта, бер тында, бер аяктан атлаганда, бер йөрәк булып тибә башлыйсың икән. Иңгә-иң терәлеп барган бу масса гомум бер уйлы, гомум бер максатлы кодрәткә әверелә; моны бернинди каршылык та җиңә, буйсындыра алмый, күрәсең.

Майор түгел, маршалны китереп бастыр хәзер, юк, бу кодрәт үзенең мин-минлеген салып таптатмый инде, бу мизгелдә җимерү стихиясенә күчәр өчен бер саксыз очкын җитә.

Юк, без аңсыз, дуамал масса түгел идек. Бар да тыныч кына бара. Майор Антонов ике мәртәбә мәйданны уратканнан соң, частьнең капкасын ачарга кушты, инде отбой сәгате үтеп, төн икенче яртысына авышкан иде, марш-бросок ясатып, ул, дүрт-биш чакрым йөгерткәннән соң, тузанга баткан ротаны казарма алдында кайтарып туктатты да «Смирно!» командасы бирде:

– Запевалы первого, второго, третьего, четвёртого взвода, два шага вперёд! Объявляю вам трое суток ареста!

Ул арада карабинлы солдатлар пәйда булды. Шулай итеп, штыклы карабинны аркаларына терәп диярлек, дүрт җырчыны гауптвахтага озаттылар.

Майор Антонов эчтән ярсыган, еш-еш сулу ала, йөзе тимгел-тимгел агарып чыккан иде. Бу мизгелдә майорны кызгану да, аны күрәлмау тойгысы да юк иде бездә. Үз арабызда бер әйдәкләүче булмаган килеш, кинәт шушылай кабынып китеп, кешедән өстен торып бирелгән тупас командага буйсынасы килмәү ләззәтен татыдык, бездә көч бар икәнне расладык түгелме!..

Эчтән һәммәбез дә әйтеп бетергесез горурлык кичергәнбездер. Бу – онытылмас күңел тантанасы иде. Йокыны санламый торган хәлгә килеп, шактый озак тәэсирләнеп яттык.

Иртән күрәбез, төнлә гауптвахтага озатылган курсантлар барысы да үз урынында. Рота старшинасы да килгән. Аның тавышы каймаклы, командалары да кеше биеклегендә яңгырый.

Шунысы гаҗәп: әйтерсең, төнлә сәер бер саташу гына булган, ул хакта ник бер сүз куертылсын. Беркем берни күрмәгән, берни ишетмәгән, бар да әйбәт. Тын гына йомылды бу хәл. Югары инстанцияләргә барып ирешсә, бунт дәрәҗәсенә житеп, шактый купайтыласы иде әлеге вакыйга.

Ә без, гади курсантларның, күз карашында эчке бер горурлык көйри, үзебез генә белгән бердәмлек тойгысын кичереп, серле генә елмаеп йөрдек ул көннәрдә.

Хәтердән ничек җуясың, кеше затының акыл белән аңлатып булмый торган халәт-рухиятенә бәйле бик гыйбрәтле бер мисал бу, уйлый белгән зат өчен...

Җиңү көненә әзерлек ике ай алдан башланды. Пермь шәһәренең үзәк мәйданында бәйрәм парадында катнашачакбыз. Һәр иртәдә, чәйләп алганнан соң, тулы ротаны туплап, трибуна каршыннан үткәрәләр. Тынлы оркестр уйнап тора. Трибунада мәктәбебез начальнигы полковник Карцев һәм аның яраннары честь биреп кала. Бөтен рота бер аяк тавышына көйләнеп, төгәл ритмда бара.

Шунысы гаҗәп: оркестр марш уйный башлауга, күңелнең ниндидер бер кылы тетрәнеп ала, тирәннән, күкрәккә сыеша алмыйча, дулкын күтәрелә, күздән яшь чыга язып, керфекләр арасына кысылып кала. Бер генә булса, бер хәл, көн дә шулай кабатлана.

Эчтән үземне битәрлим: нишләп болай йомшыйм соң әле, бу бит хәрби

марш, бернинди моңы булмаган тантаналы көй, солдатның уен-гамен таркатып ташлап, күтәренке рух, бердәм дәрт бирергә тиешле музыка.

Әмма күңелгә әмер биреп буламыни?! Ул тәнгә, акылга буйсынмыйча үзайры галәм булып яши, хисләнә, дулкынлана, көтмәгәндә үзенең барлыгын сиздереп куя.

Көндез, плацка чыгып, шул ук оркестр астында күнегүләр ясыйбыз. Монда инде тулы батальон ишелеп чыга. Гадәти сафта өч рәт булып тезеләсең. Ә монда парадтан үтү кагыйдәсе буенча, уникешәр рәт булып барырга кирәк. Иңгә-иң терәлеп, карабинны кулга тотып, йөзләрчә солдатның кыл кебек баруына ирешү ансат кына бирелми. Көн саен, кат-кат, тагын-тагын бөтен барлыгыңны күнектерү кирәк.

Безнең взводтан әлеге дә баягы Юныс Исәнбаевны, бүтәннәрдән дә стройда шундый «сено-солома»га йөри торган берничә курсантны төшереп калдырдылар... Муштра белән генә игә китереп булмый. Болар тыгыз сафта бер сулышта, бер ритмда барырга яраксыз, дип табылды.

Батальон командирының әмер биргәндәге тавышы шулкадәр көчле яңгырый, усал да түгел, дорфа да түгел, әллә ничек, йөрәккә ятышлы, кешелегеңне кимсетмичә буйсындыру көченә ия.

Баталь-е-оон! дип, сузып аваз салуга ук йөзләгән солдатның кыл кебек тартыла башлавы... «с» авазы йотылып: «Мир-ноо!» командасы яңгырауга, сафлар буйлап дулкын йөгерүе... һәр солдатның сулышын тыеп, күкрәкне биегәйтеп катып калу мизгеле... Юк, бер йөрәк ритмына корылган бу кодрәтне, эчендә торып үзең кичермичә аңлату мөмкин түгел.

Батальон командирының гәүдә тотышы, кыяфәте, тавышы сокландыра, мондый мәһабәтлеккә буйсыну да рәхәт, рухыңны кимсетми.

Их, дип эчтән кызыгып куям. Дневальный чакта рота белән командалык иткән бар. (Иртәнге тезелү, ашханәгә алып барулар.) Бер генә тапкыр батальон белән дә командалык итәсе иде. Шул мәлдә кайчандыр офицер буласы килү хыялы, кабат уянып, мине үчекли-үчекли күңел аръягына китеп югала.

Җиңү бәйрәмендә үттек без Пермьнең үзәк мәйданыннан. Чәчәкләр, шат йөзле кешеләр диңгезе, аллы-гөлле шарлар. Аяз күк йөзе...

Без – оркестр маршына көйләнгән йөзләгән курсант... Һәр рәткә уникешәр булып, бер җепкә тезелгәнбез. Һәммәбездә бер максат, бер уй, бер йөрәк тибеше. Бердәм ритмга чыкылдатып басып барганда аяк астында җир тетри кебек. Бу мизгелдә кеше җаны аерым тибә алмый, шушы кодрәт эченә таралып, бер йодрыкка кушыла.

Шушындый халәттә әгәр батальон командиры халыкка атарга приказ бирсә... каршыгызда кемнеңдер ата-анасы, апасы-абыйсы түгел – «Ил дошманнары тора, атарга!» дисә... Карабиныңны халык күзенә төзи алыр идеңме, юк, мин атарга теләмим, дип, шушы кодрәт эченнән аерылып чыга алыр идеңме?

Күпме еллар үткәч тә, вакыт-вакыт бу сорауны үземә төбәп гаҗизләнәм дә... анык җавап таба алмыйча, тагын алдагыга калдырам...

Ә теге марш көе яңгыраганда күңелнең нидән болай нечкәреп үрсәләнүенең сәбәбен мин соңыннан аңладым. Урыны-урыны белән татар моңы сирпелгән ул тантаналы, дәртле музыка Салих Сәйдәшевнең «Кызыл Армия» маршы булган икән.

Төннәрен, элеккечә, шахмат мәсьәләләре чишеп утырам. Җавапларны Мәскәүгә юллый торам. Бервакыт карыйм: фамилиям басылып чыккан! Кайчандыр Константин Симонов, Илья Эренбург, Алексей Толстой эшләгән,

Сталин янына көнаралаш кереп йөргән генерал Ортенберг җитәкләгән мәшһүр «Красная звезда» газетасында исемең күренсен әле!

Мин бу газетаны вертикаль күршем Володя Бацынга күрсәттем: «Знай наших!» янәсе...

Володя котлады да:

– Менә син шахмат белгече бит инде, әйт әле. Пешка алга бара-бара соңгы шакмакка җиткәч, Ферзь була, шулай бит. Корольдән кала икенче көч иясе. Ә нишләп ул, артка чигенә-чигенә, соңгы шакмакка җитеп, кабат пешкага әверелми?

– Ферзь чигенми бит. Гел алга гына бара, – дигәч, Володя килешмәгәнен белдереп, башын чайкап куйды. Минем дә күңелгә шик керде: тарихта гыйбрәтле мисаллар байтак ич: күпме ферзьләрне тәхет эргәсеннән сөреп, юкка чыгаралар.

Шахмат уенының кагыйдәсен төзегән вакытта Һиндстанның акыл ияләре моны күз уңыннан ычкындырган түгелме?!

Миңа берничә мәртәбә генә үзебезнең часть биләмәсендә каравылда торырга туры килде. Шунысы сәер: төнге постта, гадәттә, багана башына куелган лампочка төбенә нурын җыеп чәчә торган түгәрәк калай беркетелгән була. Син шуннан җиргә сибелгән якты түгәрәк эчендә әзер мишень булып әрле-бирле таптанасың. Шунда минем Кара куакта җир сөргәндә яктылык сызыгыннан төн карасына чыгарга куркуым искә төште. Ә монда киресенчә... Яктылык сызыгыннан атлап кермичә, караңгы яктан гына йөрим. Шикләндерә. Ярый әле аркадаш карабиным корулы.

Хәтерлим әле, бер салкын иртәдә, таң атып килә, карасам... карабинның кайтарып куелган штык йөзе сыкыланган, җем-җем итеп тора. Шунда миңа әллә ни булды, гүя йолдыз нуры, сүзгә әверелә алмаган шигърият тылсымы күшеккән күңелемә кагылып китте... Гел күз алдымда тора: карабинга беркетелгән сыкылы хәнҗәр...

Иң авыр пост – штабта, часть байрагы төбендә тору. Урыны нинди бит әле: чиркәү түрендәге алтарь кебек итеп, витраж тәрәзәләр белән бизәп эшләнгән. Син аллы-гөлле яктылык эчендә төп-төз басып торырга тиешсең. Көндез, эш вакытында, штаб коридоры кайнап тора, баш киемлеләр честь биреп, яланбашлар байракка хөрмәт күрсәтеп, тантаналы адымга күчеп яныңнан үтеп-сүтеп йөри. Син шуларның барсына да үзеңнең тере икәнлегеңне, таш багана түгеллегеңне сиздереп торырга тиешсең. Карабиныңның түтәсен идәнгә тигереп, «оружие к ноге» дигән командага буйсынып, янәшәңдә тотасың. Кичен штаб тынып калгач, бераз сулу алырга, янәшәңдәге акча сейфына артыңны төртеп алырга да була, әмма калгып китсәң, карабиның кулыңнан ычкына да, мәрмәр идәнгә шапылдап төшә. Тавышка аскы каттан дежур офицер йөгереп менмәс, димә. Әле аның кайбер вак җанлысы, урамга чыгып, тәрәзә аша махсус күзәтеп торырга да мөмкин. Бәйләнергә сәбәп кенә эзләп йөрүче, иңендәге көтүче чыбыркысыннан портупеяга күчкән офицерлар була, андый вакчыллар, казармага кереп, курсантның тумбочкасын тикшереп, урын-җирен күтәреп караудан да тайчынмыйлар.

Гарнизон каравылы – икенчерәк, төп туплану урыны шәһәрдә, хәрби трибунал буласын көтеп ятучы төрле җинаятьчеләр ябылган изолятор урнашкан бинада, шул ук бинада корал кую, сактан соң ял итү урыны да. Аннан төрле объектларга каравылда торырга тиешле курсантларны шәһәр буйлап, машинада тараталар.

Мин беренче номерлы сак урыны – шушы тикшерү изоляторының

ишегалдына билгеләндем. Безнең взвод командиры капитан Искорцев мине юри якынга куйгандыр, юлга вакыт китми, посттан бушаган ял вакытында минем белән шахмат уйнарга күбрәк вакыты кала. «Нигә бүтәннәр белән уйнамыйсыз?» – дим дә. «Они – слабаки», дип чыраен сыта.

Ул көн аяз, матур иде. Тимер чыбыклы биек, кысан таш дивар эченнән күкнең аяз зәңгәрлеге тагын да җетерәк күренә. Мин постта. Җилкәмә карабин асылган. Күләгәмне ияртеп егерме адым болай, егерме адым тегеләй атлыйм. Рәшәткәле тәрәзәләргә йөгертеп кенә күз төшереп алам. Эчтә караңгы. Шомлы. Бернинди тавыш ишетелми. Нинди язмышлар икән бу рәшәткәләр артында?

Каядыр ерактагы бер объекттан постын тапшырып кайткан мордвин егете Кашаев, тагын бер-ике курсант ишегалдына чыгып, тәмәке көйрәтә торган урынга килеп утырдылар. Кабызып, төтенли дә башладылар. Взводташ булса да яратмыйм шул мукшы егетен. Миңа аның кыяфәте үк ошамый иде. Борыны очлаеп бетәр алдыннан гына кырт киселгән шикелле, иреннәре ябылып бетмәгәнгә күрә, алгы, көрәк тешләре һәрчак күренеп тора. Үзен ул соңгы сүзне әйтеп, нокта куярга тиешле акыллы баш дип саный. Һәрвакыт татарларга карата берәр кире сүз әйтеп суктырмыйча калмый. Бәлки аны кайчан да булса татар кешесе кыерсыткандыр, шуны оныта алмыйча, соңлап булса да үчегүен тыеп кала алмыйдыр.

Кояш кыздыра. Минем әле пост сәгате башланды гына. Тәндә арыганлык сизелми. Бар да әйбәт. Шул әйбәтлекнең кинәт бозыласына бернинди ишарә дә юк, була да алмый. Пост мәйданы уч төбендә. Тегеләрнең сүзенә колак салгалап үтәм. Яннарына килеп утырырга хакым булмаса да, янәшәдән сүзләрен тыңларга була.

Тагын шул Кашаев акыл сата. Татар кызлары, имеш, җан җирләрен (ул тупас сүз куллана) бритва белән кырып, пеләшләндереп йөриләр икән. Кыргыйлык бит инде бу, – ди.

– Кит аннан, булмас! Сакал төге кебек каты булса, тырнап бетерә ич ул.

– Кашайга ышансаң... Ни чыкмаса аңардан чыга.

Ефрейтор Колоколов, гадәтенчә, йокымсыраулы тавыш белән:

– Гигиена ягыннан караганда бу – чисталыкка керми микән... – дип куйды.

– Господа! – дип, Кашаев имән бармагын күтәрде. – Миннән түгел, татардан чыга. Чудной народ. Сез аларның кайнар мичкә кереп юынганын беләсезме соң? Аларда бит мунча юк!

Бусына ук мин түзә алмадым. Каравыл уставын бозу дип тормыйча, яннарына килеп бастым:

– Сүзеңне кире ал, Кашаев. Татарлар мичтә түгел, ә мунчада юына!

– Кире алмыйм! Мин үз күзләрем белән күргәнемне сөйлим.

– Күрәләтә ялганлыйсың, сволочь!

Кашаев миңа бармагын төбәп, авызын кыйшайтып көлә башлады. Бу җирәнгеч көлү мине генә түгел, ата-анамны, бөтен нәсел тамырларымны кузгаткан мыскыллау булып, актарылып чыкты. Мин, үз-үземне белештермичә, карабинны иңнән суырып алып, затворын секунд эчендә чыкылдатып, атарга әзер килеш тегенең күкрәгенә төбәдем. Кашаев агарып чыкты, диварга таба чигенә башлады. Янәшәдәге курсантлар да аягүрә бастылар. Ул арада тавышка йөгереп чыккан капитан Искорцев арттан килеп, бер кулы белән карабинга ябышты, икенче кулы белән муеннан кысып алды. Шул мәлдә ничек курокка басылды, сизми дә калдым. Пуля Кашаевның аяк очындагы таштан очкын чыгарып, рикошет ясады да, сызгырып һавага очты.

Капитан карабинны миннән йолкып алганда предохранительгә куеп өлгерде. Аннары, еш-еш сулап, мине алыштырырга тиешле солдатка, постны кабул итәргә әмер бирде.

Безне, Кашаев белән икебезне, ефрейтор Колоколов күзәтчелегендә буш бүлмәгә кертеп яптылар. Ишекне бикләп үк куймадылар шикелле.

Минем кинәт баш авырта башлады. Баш эчендә чаң сугалармыни. Кашаевның тавышы, «Мин шаярттым гына бит...» дигән аклану сүзләре сандалга бәргән чүкеч тавышлары аша аңыма имгәнеп барып җитә дә, җитми дә шикелле, югаласы, бу мизгелдән югалып, икенче яссылыкка күчәсе килә.

Капитан Искорцев башта Кашаевны чакыртты. Отделение командиры буларак, Пётр Колоколов та пошаманга калган иде. Булган хәлне кире кайтарып, төзәтергә инде соң икәнен икебез дә аңлыйбыз, үкенечне сүзгә әйләндермичә тын гына утырабыз. Бүлмәдә Кашаевның аурасы беткәч, баш авыртуым да басылган кебек булды.

Бераздан капитан Искорцев мине чакыртып алды. Кердем. Өстәлдә фигуралары тезелгән шахмат тактасы тора. Капитан, күз кырые белән генә шул якка ымлагандай:

– Испортил песню, дурак... – дип куйды. Табигате белән усал түгел ул, әмма офицер буларак, таләпчән-кырыс рәвешне тотарга кирәклекне дә онытмый иде.

– Синнән көтмәгән идем...

Капитан торып басты, сүзләрен көч куеп, басым ясап чыгара башлады:

– Үзең сакларга дип, килгән уголовниклар камерасында бикләп калдырам бит үзеңне! Син нәрсә, төшеңдә Наполеон булып уянмагансыңдыр бит бүген? Не позволим! – дип, ул өстәлгә сугарга дип йомарлаган йодрыгын икенче учы белән кысып, тыеп калды. Аннары утырды да, карандаш алып, аны бармаклары арасына кыстырып, йодрыгы белән шартлатып сындырды. Бармакларын ышкый-ышкый шактый сүзсез утырды. Капитанның һич көтмәгәндә болай кәефен бозганыма эчтән үз-үземне талкып утырам. Ул хаклы бит, коралга тотынуны кичермәсләр...

Капитан кинәт кенә:

– Атар идеңме? – дип сорап куйды.

– Минем ничек атканны беләсез бит. Атарга уйласам... Сез килеп тотынгач, әллә ничек, үзеннән-үзе атылып китте.

– Андый чакта кискен хәрәкәт ярамый шул... – дип, капитан күз төпләрен авырттырып ышкып алды. – Мин каравылда ЧП булганы хакында рапорт язсам... Китә бит тикшерүләр... Патроннарны санап тапшырасы... берәү җитми. «Кая куйдың?» диячәкләр.

Шул мәлдә мин кесәмнән шомарып беткән, ялтыраулы карабин патронын алып өстәлгә бастырып куйдым. Каян алдың, димәде капитан, төрле юллар белән юнәткән патрон һәр солдатта диярлек булганлыгын ул белә иде. Патронның төбен әйләндереп карады – исән. Капитанның маңгай җыерчыгы язылып киткәндәй булды.

– Пүчтәк нәрсә өчен... күлеп кенә үткәреп җибәрәсе бит... Мичтә юыналар, имеш. Юыналар бит, шакшы йөриләр, дигән сүз түгел! Менә мин үзем Владимир өлкәсендә рус авылында туып-үскән кеше. Бездә мичләр зур итеп салына. Рәхәтләнеп шунда юына идек... Олысы-кечесе...

– Татарлар мунчада юына, мич төбендә ипи пешерә, – дидем мин үҗәт кирелегемне янә калкытып.

– Һәй, – дип капитан миңа кул селкеде. – Бар, чыгып тор!..

Ефрейтор Колоколовны да чакыртып капитан нидер сөйләште.

Каравылдан кайтып, гадәти укуларга күчкәч тә минем җан бәргәләнүдән туктамады. Баш миен мең-мең сорау кайната. Капитан нишләр, үзенә дә күләгә төшереп, бу хәлне кузгатырмы? Ни генә булса да, калкан итеп милли мөнәсәбәтне алга куярга кирәк. Бу – аклануның төп маймылы...

Ләкин, исәпле башны иеп йөргән атна азагында көтелмәгән хәбәр иңдерелде һәм ул бөтен ШМАСның рухын үзгәртеп җибәрде (Оборона министрының ШМАСны яңадан офицерлар әзерли торган ПВАТУга (Пермьское Военно-авиационное училище) әйләндерү турында приказы чыкты. Димәк, без яшәгән кубрикларда булачак офицерлар яшәячәк, без укыган классларда алар укыячак. Заманында кем яптырган бу гөрләп эшләп торган училищены? Гомерен көтүчедән башлаган Хрущёвмы? (Димәк, бу дорфа, дуамал, белемсез илбашының хаталарын төзәтү башлана...)

Ә без... декабрьдә укуны тәмамлап, ил буйлап авиация частьларына таратыласы солдатлар, без нишләрбез?

Свердлаудан шахмат буенча спорт мастеры килгән, сеанс үткәрә икән, дип Бацын кайтып әйтмәсә, белми каласы идем бит. Киттем клубка. Уйнарга теләүчеләр шактый икән. «П» хәрефе сыман тезеп куелган өстәлләрдән урын алып, шахмат фигураларын тездек. Күз йөртеп алам: майордан башлап курсантка кадәр төрле дәрәҗәдәгеләр утыз ике баш җыелганбыз. Аклы-каралы шахмат гаскәре каршында дәрәҗәләр тигез. Аклар белән уенны башлау өстенлеге, әлбәттә, кунакка бирелә.

Килеп керде. Баш кагып «Виктор булам», – дип исәнләште. Чандыр гына гәүдәле, гап-гади бер егет икән спорт мастеры. Кердә-керешкә ул иң кырыйдагы тактада пешка белән «е-4» йөрешен ясап, шуны ук башка такталарда да кабатлап, тиз генә барыбызны да үтеп чыкты.

Китте уен. Тәмәке төтене. Ухырып куйган үкенечле ымлыклар. Викторның чырае мәрмәр кебек, бернинди дулкынлану, киеренкелек сизелми, әйтерсең лә клавишларга басып китә, ә кешеләр аның өчен юк. Озын шарфын муенына салган. Кабарынкы күз кабаклары аша күзләре үтәли тишеп фәкать уенга, уенга төбәлгән.

Озак уйлап, сак кына уйныйм. Иң мөһиме – ялгыш йөреш ясамаска. Ялгышыңны көтеп кенә торган уенчыларны җенем сөйми. Партнёрың ялгыша икән, әйт, тизрәк фигурасын алып учыңа йомарга үрелмә. Береңнең кылычы сынгач, китереп кадау белән бер бит ул. Көт, яңа кылыч алганын көтә бел. Җиңәсең икән, тигез көч белән, хәйләсез җиңәргә гадәтлән.

Нинди очракта, нинди комбинация ясарга – мин боларның шактыен ятлап бетергән инде. Егетнең кулы нык, әмма ул да әллә кая китә алмый, шул әзер сукмаклардан бара, дип үземне тынычландырып куям. Шахматта комбинацияләр чиксез, кеше акылы колачлап бетерерлек түгел, диләр. Ай-һай, ышанып бетмим. Алтмыш дүрт шакмакка чиксезлек сыя алмас...

Чандыр егетебез яшь күренә. Кай арада мастерлыкка ирешкән? Мин әле беренче разрядка да барып җитә алганым юк. Беренче, дисең, өченчедән башла, мокыткаем.

Әнә, берәү шатырдатып такта өстеннән фигураларны коеп төшерде. Икенчесе... өченчесе... Тарала башлады җиңәргә дип килгән җиңелүчеләр кавеме.

Утыз ике тактага текәлеп баш миен изалаган уенчылардан, иң соңыннан өчәү калдык. Капитан Искорцев та ике курсант. Уеннан котылганнар безнең

янга өелеште. Яратам да, яратмыйм да мондый мизгелне. Колак төбендә тынын өреп, көч биреп торган тамашачы булу – кызык та кебек, үссенебрәк уйныйсың. Шул ук вакытта ауралар буталадыр, төрле энергия берегеп, уйны саташтырадыр дигән курку да бар. Арада бит хуплаучылар гына түгел, көнләшүчеләр дә булырга мөмкин.

Кунак егетебезгә мәйдан тарайды хәзер, фигураларга үтешли кагылып кына китә алмый. Ныклап безнең янда озаккарак тукталды. Ике каш арасында ике сызык та пәйда булды.

Иң башта ул ике кулын күтәргән сыман итеп: «согласен на ничью» дип кулны кысты, аннары күрше ротадагы курсантка кул бирде. Капитан Искорцев белән шактый өзештеләр. Бультерьер кебек, тешләгән җирен чәйнәп бетермичә, туктамый торган капитан, тәки ахырга кадәр ерып чыкты бит. Партия беркемнең дә җиңмәве белән тәмамланды.

Кунак егетебез – спорт мастеры елмаеп хушлашса да, ул елмаю иреннәр арасына ясалма эленгән иде; бу кара халыктан чыккан солдафоннарны бер сулыштан, тулаем җиңәргә дип ният иткән булгандыр да... Арада көйсезләр табылды бит менә...

Казарма ягына кайтырга дип капитан Искорцев белән бергә чыктык.

– Поздравляю с победой, – дип, ул кулымны кысты.

– Какая победа, ничья же, – дим.

– С мастером спорта – ничья, это уже победа, друг мой. Не зря тогда сберёг я тебя...

Капитанның уе һаман әле шахматтан күчәргә теләми, уен шаукымы чыгып бетмәгән сыман иде; бәлки аның нияте дә җиңүдә булгандыр.

– Яһүдләрдә, туганчы ук баланы шахматка өйрәтә башлыйлар. Аннары, теле ачылгач инде, тренер яллап, стипендия билгеләтәләр. Менә шуннан теләмәсә дә шахматист үсеп чыга инде, – дип, капитан җилкәмә кагылып алды. – Ә син ничә яшьтә уйнарга өйрәндең?

– Сигезенчедә укыганда...

– Һо-оо, соңрак икән шул. Ул яшьтә инде яһүд малае шахматта пенсиягә чыга.

Минем каядыр бик тирәндә йөргән яшерен хыялга китереп басты бит капитан. Киләчәктә шахматта күрелмәгән уңышка ирешермен дигән өметне чәлпәрәмә китерде. Чынлап та балигъ булып барганда гына уйнарга үзлегеңнән өйрәнеп, кая омтылмакчы буласың, авыл каргасы! Янәшәңдә акыллы зат торып, нәкъ вакытында хакыйкать җебен тартып тормаса, син үзлегеңнән аңа еллар буена да ирешә алмаячаксың.

– Шахмат уеныннан мәгънә алып, аны тормышта куллана белергә кирәк, – диде капитан. Аның төбендә логика дигән хикмәт ята. Син өч йөрешне алдан уйлап куя белергә тиешсең. Партнёрың да шулай. Синең бер йөрешеңә ул өч йөрешне исәптә тота. Син аның бер йөрешенә – өчне. Менә шулай итеп, логика лабиринтлары башлана. Тормышта да бик кирәк бу, акылың бер каптырмалы булып калмасын өчен!

Мин үзем белеп тә белмичә йөргән хакыйкать асылын ачып бирде бит әле капитан. Нигә әллә ничә тармаклы уйлап азапланам. Болай булса, тегеләй булмый, тегеләй булса – болай булмый, дип ак белән кара төсне генә танып яшәү рәхәтрәк югыйсә. Шахмат җене котыртып алып кереп китә икән лә мине. Логика дигән бөдрә йонлы тәкә, муен чокырын кашытып, әйдәкли дә чытырманлы сукмакка борыла...

«Красная звезда» газетасында тагын исемең чыккан әнә, бирелгән шахмат мәсьәләсен иң беренчеләрдән булып чишеп җибәргән дип язганнар, куан шуңа...

***

Август уртасында (1966 ел) хат язышуны туктаттылар. Сентябрьдә, анасын җуйган корт күче кебек, тузылачакбыз. Хәзергә тизләтелгән программага күчтек.

Ротадан унике курсантны, шул исәптән мине дә, майор Антонов кабинетына җыеп сөйләштеләр. Каян килгәндер, таныш түгел подполковник, майорлар да бар. Калырга, укуны шушында, хәрби училище исеме бирелгән уку йортында дәвам итәргә тәкъдим ясыйлар. Керү имтиханнарына да ташлама ясала янәсе.

Унике курсанттан өчәү генә калырга, укуын дәвам итәргә ризалык бирде.

Казармада әлегә кадәр бер көйгә салынган тормыш бара иде. Әллә ничек, курсантларның тәртибендә, үз-үзен тотышында, күз карашында, мөгамәләсендә үзгәреш сизелә башлады. Янәшә берегеп яшибез дигән туганлык хисе үзеннән-үзе суына бара кебек. Без бөтенләй чит икәнбез, бер-беребезне бүтән беркайчан да күрмәячәкбез, дигән хакыйкать эчтә бер елга якын яралып килгән якынлык, бердәмлек хисен күзгә күренеп сүндерә башлады. Моны сизеп, күреп тору – моңсу иде.

Минем, уку беткәч, туган якка ун көнгә ялга кайтачагым күптән хәл ителгән. Бер-бер нәрсә чыгып, тоткарлый гына күрмәсеннәр, дигән курку һәрдаим уяу тора.

Карусыз буйсыну һәм таләпчән буйсындыруга корылган солдат тормышы. Әгәр шушы ике бизмән арасында гаделлек ятса... Дорфа, явыз, кешене изүдән канәгатьлек ала торган командир кисәкләрен сугыш вакытында, җаен туры китереп, чүки торган булалар.

Мин үзебезнең отделение командиры – ефрейтор Колоколовтан уңдым, тыныч холыклы, шәп егет. Ачылып сөйләшергә яратмаса да, эчтән хөсетлеге сизелми. Ә менә беренче отделение командиры – ефрейтор Голованов тәкәббер холкы белән күпләрне үзенә каршы куйды. Китәр алдыннан Головановны башына капчык кидереп ярачаклар, дигән хәбәр юктан бар булмагандыр...

Безнең взводта Пензадан ике татар бар иде. Мәзәк итеп, сузып, мишәрчә сөйләшәләр. Аларның сүгенүе дә җыр кебек иде. Боларның Әсгат исемлесе, үз эченә йомылып йөри торган, карасу йөзле, саллы йодрыклы, нык бәдәнле егет иде. Яз башында, каравылда торган чакта шундый хәл була: Әсгат постта. Голованов, разводящий буларак, өч солдатны ияртеп, постларны алыштырып йөри. Әсгат янына килеп туктагач, Голованов чалбар сәдәфен ычкындырып, үз йомышын эшләп торган җиреннән, җилкә аша гына карап: «Пост сдать!», «Пост принять!» дип кычкыра. Бу кадәре үк кимсетүгә ачуы кабынган Әсгат, штыклы карабины белән кизәнеп, Головановка ташлана. Аны чак тотып өлгерәләр. Бу хәл, читкә чыгып, зурга җибәрелмичә, үз взводыбызда гына йомылып калды. «Бәхете, патрон булмады», – дигән Әсгат. (Кайбер постларга патрон бирү каралмаган иде).

Менә шул вакыйгадан соң Голованов белән Әсгат арасында бернинди якынаю да була алмады.

Ә без Кашаев белән аңлашкандай булдык. Ул, «шаярттым гына» дип, гафу үтенде. Күрше рус авылында күргәнне татарларга аударып, мичтә юыну гадәте бездә бит ул, дип әйтмәсләр микән дип, руслар янында юри сөйләдем. Юк, таныргга теләмиләр...» – диде. – «Без бит гомергә күрше яшәгән халыклар, тату булыйк», – диде. Кул кысышсак та, салкыны калды барыбер.

Саксыз уятма, һәр кешенең үзәгендә бүре ята.

Министр приказыннан соң яшәү рәвешебез, суга таш ыргытканда пәйда булган бөжралар кебек, «бар иде, юк инде» арасында тирбәлә башлады. Декабрьдә бетәсе укулар сентябрь башында төгәлләнергә тиеш. Аннары безне илнең төрле тарафларына таратачаклар.

Инде кубрикта караватларны, мендәрләрне бау тартып тигезләмибез. Тотрыклы тәртип күнегелгән кысалардан чыга башлады.

Сентябрьнең беренче иртәсендә уянгач, аптырап калдык: Головановның да, Кашаевның да караватлары буш. Ни уйларга да белмибез. Сержант Гаевский серле генә итеп:

– Алар командасын төнлә җибәрделәр. – диде. Башка взводлардан да шундыйрак ике-өч курсант «юкка чыккан». Их, сизми калдык, дип кемнәрдер уынып йөри.

Казарма тормышы уч төбендәге кебек. Әмма барыбер үзара мөнәсәбәтләрдә, солдат үзе генә белгән яшерен почмаклары кала, дип уйлый идек. Димәк, казарманың барсын да күзәтеп торган о л ы к ү з е, барсын да ишетеп торган о л ы к о л а г ы булган...

Һәр көнне яңа хәбәр белән уянабыз. Курсантларны, төркем-төркем туплап, озату башланды. Хушлашабыз. Хәмер эчү, болагайлану юк. Бар да тыныч, вакытлыча гына аерылышабыз, каядыр безне уртак җыелу урыны – самолётлары тезелгән, балкып торган аэродром көтәдер кебек.

Соңгы көнне мин Ленкомнатага кереп, үзем ясаган рәсемнәрне, планшетларны карап чыктым. Күз нуры түгеп, күпме тырышлык куеп ясалган, хәзер инде беркемгә кирәк түгел, барсын да умырып ташлаячаклар.

Ике кубрикта, дүрт взвод гөр килеп яшәгән җиребез бушады да калды. Менә-менә яңа курсантлар килеп җитәргә тиеш. Без дә китәргә җыенып беттек. Ике капитанның берсе – Дементьев кул биреп хушлаша, икенчесе – Искорцев безне озата чыга.

– Теге вакытта зурга җибәрмәдегез, рәхмәт, – дим аңа. Капитан вак мәсьәлә дигән кебек, кулын гына селки.

– Синнән бигрәк, катырагы миңа эләгәчәк иде, – ди. Сиңа сүзем шул: «Кулыңа корал кердеме, акылыңны тезгенли бел!»

Хушлашабыз. Әйбәт кеше белән саубуллашканда, әйбәтлек кайнары учка күчеп кала бит ул.

Татарның «бахыр» сүзеннән яралган «Бахаревка» станцасына чуаш егете Фомин белән икәү генә юлга чыктык. Ул да Казан аша туган ягына ялга кайта.

Мин кышкы киемнәр тыгызлап тутырылган солдат капчыгы асканмын, кулда – чемодан. Анда – иң авыр байлык – дус-ишләрдән килгән хатлар һәм иң кадерлесе – алтынчы декабрьдән унбишенче августка кадәр Фәниянең, бер көн дә калдырмыйча, язган хат бәйләме. Өч ел буена сәйлән кебек тезелеп барачак бу хатлар өзелеп туктады бит менә... Бер айдан артык, бер хәбәрсез...

Кайтып җиттек үзебезнең башкалага. Казан вокзалы, элеккечә, борынгы хәтерен кызыл ташлы диварларына таратып, моңаеп утыра.

Хушлашканда Фомин, як-ягына каранып, кеше ишетмәсен дигәндәй:

– Сиңа рәхмәт, – диде. Мин аптырап калдым. Бу кыска буйлы, бүтәкә кебек йомры-тыгыз гәүдәле чуаш егетенә истә калырлык бер яхшылык та кылганым юк иде бугай.

– Үзең беләсең, мин карандаш тотып түгел, көрәк тотып алдым бу ялны, – дип Фомин китеп барды.

Мин киемнәр салган солдат капчыгымны кире килешли алырмын дип, Сәгыйрь абзыйларда калдырып тордым. Бөгелмәгә поезд белән армия хисабына шактый уравыч юл белән кайтыла бит, нигә көнендә кайтып төшмәскә, дип, самолётка билет алдым. Хәтер дәфтәрен актарып кайтырга самолёттан да рәхәт нәрсә юк.

Фоминнан тик торганда «рәхмәт» алу сәбәбен тәки казып чыгардым бит. Кышкы бер төндә, ленкомнатада төнге берләрдә генә плакатны язып бетереп, тышка бәдрәфкә чыгарга булдым. Зур бәдрәф бинасының эче караңгы, җитмәсә нидер кыштырдый, керергәме-юкмы дип таптанып тора идем, көрәк тоткан курсант Фомин килеп чыкты. Уңайсызланып калды. Аклангандай итеп:

– Сержант Гаевский «ел буе чистартып торсаң, отпускка җибәрәм», диде дә, тыңладым инде. – Син бу турыда, зинһар, берәүгә дә әйтмә... – диде. Нишлисең бит, үзеңә кирәктә, таяндыра көрәк тә...

Бөгелмә аэропортыннан авылга кайтып төшкәндә караңгылык куерган, кичке сәгать җиделәр иде. Тау өстеннән карап:

– Мин кайтып киләм, мин, – дип бөтен авылга кычкырдым. Әмма тавышым үземнән ерак китә алмады бугай. Утлары белән балкып, кочагын җәеп, каршы алыр кебек авылым берни сизми, аяк очымда таралып, караеп ята. Агач яфракларының шыбырдавында көзге кырыс моңсулык бар.

Бер хәбәрсез кайтып кергән солдатны күргәч, әти белән әни тынсыз калып, берара ни әйтергә белми тордылар.

Хәл-әхвәл белешеп, чәйләп алгач, минем гәүдәм генә монда утырганны, күңелнең каядыр омтылганын сизеп, әни:

– Клубның бүген ял көне, – диде.

Бер айдан артык бернинди хәбәрсез яшәдем бит мин. Фәния кайда, авылдамы, дигән сорау куркыта мине. Җан тарыга. Сулыш җитми. Олы бер дөньядан кайтып төшеп, кинәт кысанлыкта ябылып калдым шикелле.

Чыгып киттем югары очка, хром итегемне шыгырдатып. Коры яфракларны итәге белән кагып искән җил күңелне тагын да ямансулата. Сирәк кенә багана башларында мескен ут җемелди. Билгесезлектән җылыйсы килә. Мин болай калдырып киттеммени, авыл, нишләдең син, нишләдең?

Фәнияләр өенең алгы яктан өч тәрәзәсе балкып торыр иде, бүген әллә ничек, бик сүрән, басынкы күренә. Урамда ник бер кеше очрасын. Авыл үзгәргәнме, әллә инде мин төшеп калганмын бу арбадан.

Фәнияләр күршесендә куаклар арасыннан тәрәз утлары җемелдәп күренә, тавышлар да ишетелә сыман. Кердем ихатага, бер-ике үсмер егет тәмәке тартып тора. Алар мине танып күрешәләр. Өйдә читтән килеп эшләүче бер егетне солдатка озату мәҗлесе бара икән. Кыстыйлар, юк, кермим, сыя алмыйм мин өй кысаларына.

– Фәния исәнме, ул кайда? – дип сорыйм. Егетләр бер-берсенә карашып алалар. Күңелем «жу» итеп китә. Әллә берәр фаҗига булганмы?!

– Ул Азнакайда эшли бугай, – ди берсе.

– Авылга кайтып йөри ул, өйдәдер, – ди икенчесе.

Сәгатькә карыйм: тугыз тулып килә. Йокы гаскәре инде бу вакытта авылны аударып чыгарга әзерләнә. Өлгерермен бәлки, дип, ашыга-ашыга киттем шул якка таба.

– Саумы, аркадаш капка баганасы? Сине дә сагындым бит мин...

Минем аларга беркайчан да тупырдап барып кергәнем булмады. Солдат кешегә хәзер ярыйдыр инде.

Ишек кагам. Эчтән өйалдына, тамак кыра-кыра, Солтан абзый чыга.

– Кем ул? – ди.

– Мин бу, Солтан абзый, ач әле.

– Кем син?

Бу дөньяда коточкыч авыр сорау бу минем өчен. Ничек аңлатыйм соң үземнең кем икәнне?

– Кем син?

Маңгайга чүкеч белән бәргән кебек. Бөтен тән күзәнәкләре кызыша башлады. Кем мин? Аны ничек кыска гына әйтеп аңлатырга?

– Мин бу, Солтан абзый, ачкач, күрерсең, – дим.

– Нишләп мин белмәгән кешегә ишек ачыйм ди. Ачмыйм!

Ул арада Фәймә апа да оялдына чыгып Солтан абзый янәшәсенә килеп басты күрәсең.

– Кем син? Нигә исемеңне әйтмисең? – дип, ул йомшак кына сорый.

– Фәния өйдәме, Фәймә апа, – дим.

– Кем син? – дип кабат теге әче сорауны бирә ул да.

Шулай ярты сәгатьләр азаплый торгач, кем икәнемне аңлата алмасам да, ишекне ачып җибәрделәр болар. Парлашып, шаккатып торалар.

– Үзебезнең... үзебезнең...

– Баштук әйтми торасың. Танымадым бит, тавышың калынайган, – ди Фәймә апа, күрешергә дип баллы кәрәз исе сеңгән кулын суза.

Ул арада Фәния үзе килеп чыкты. Әти-әнисе арасыннан ерып үтте дә, кочакка ташланды.

Октябрьнең саф-салкынча төне. Күк гөмбәзендә шыгрым йолдызлар. Тыгызлыкка сыеша алмыйча, урын даулап, иң кыюлары җиргә төбәп атыла.

Шул йолдызларны учка җыеп, бүрәнә өстендә утырабыз.

– Апаң нефтьче-оператор булып эшли хәзер... Менә, эшче куллары нинди, тотып кара, чирканмасаң, – ди Фәния. Битем белән учына чумып, исним:

– Кара алтын исе килә, – дигән булам.

Әллә ничек, сүзгә-сүз ялгана алмый. Арада – ятсыну упкыны. Бу хәрби киемне әйтерием, кителе дә бит аның скафандр кебек кысып тора, җитмәсә погоннар да бөгелми, кызларны кысып кочаклар өчен яратылмаган...

– Көн туган саен, бер хатың килеп торды. Моны ничек бәяләргә? Скульптор булсам, сиңа һәйкәл куяр идем.

Фәния рәхәт елмая. Сүзендә торуы өчен эчке бер горурлык кичереп елмая.

– Бу тәнәфестән соң, тагын ике ел буена язасым бар бит әле.

– Самолётка утырганда үткәрмәделәр. Ике йөз егерме хатыңны да алып калдылар...

Фәния, күзләрен зур ачып, куркынып:

– Син аларны яндырмаган идеңмени? – ди.

– Юк, саклармын, олыгайган көндә икәү янәшә утырып бер укырбыз, дигән идем.

– Алып калдылар дисең, бөтенләй бирмәскәмени?

– Шикләнделәр инде. Солдатка көн дә хат язган кыз – йә җүләр, йә артык нык ярата, йә бик акыллыдыр, диләр. – Сез әйткән өч сыйфат та аңарга килешә, дим. Җүләр булганга нык ярата, нык яратканга бик акыллы, дим.

Фәния «җүләр» дигән сыйфатны башкаларыннан аерып куярга теләгән сыман, бер мәлгә уйланып калды да, көлеп җибәрде:

– Шаяртасың дип уйламыйм да икән. Минем даирәдә бит сул ягын

әйләндереп сөйләшүчеләр юк. Бик дөрес, бик кызыксыз кешеләр генә... Әни һаман искә төшерә әле теге сүзеңне...

«Теге сүз» узган җәйдә генә булган иде, югыйсә, әллә күпме еллар узып, Каф таулары артына китеп күмелгән кебек... Ул көнне Фәния клубка чыкмады. Көттем, клуб ябылганчы көттем дә, ачудан кыюланып, ишекләрен шакырга булдым. Фәймә апа көттерми генә ишекне ачты да:

– Авырый ул, чыга алмый, – диде.

– Үзен күрмичә, ышанмыйм, – дим.

– Бүгенгә борчып йөрмә инде, йокласын, – ди Фәймә апа. Шомырт кара күзләрендә усаллык очкыннары сизелми, әмма үҗәтләнә һаман. Аптырагач, мин Фәймә апаның кулыннан тотып, тупсаның бу ягына чыгардым да, ишекне ябып куйдым:

– Кызың чыкмагач, аның урынына үзең торасың инде, таңга кадәр, – дидем.

– Җүләрләнмә, Солтан абыең чыкса, кирәгеңне бирә хәзер!

Сүз арты сүз чыгып и сөйләшәбез, Фәймә апа онытылып китә дә, тагын искә килеп, кереп китәргә тартыла, шулай итеп таң беленгәнче тордык.

– Иртүк эшкә барырга бит безгә.

– Нинди эш булырга мөмкин...

Көтү куар алдыннан гына әсирлектән котылган Фәймә апа икенче көнне бик гаҗәпләнеп әйтә икән: «Нинди эш булырга мөмкин», ди бит.» Безнең умартачы булып эшләгәнне белмимени ул, вәт сәер кеше, ә?!» Фәния аңа: «Белә, әни, бик белә, аның сөйләшү рәвеше шундый бит», – дигән.

Фәниянең «теге сүзеңне» дию шуңа ишарә иде.

Күнегә алмый йөрим авыл тормышына.

«Подъём!» дигән әче команда яңгырамаган килеш, йокыдан тору дөрес түгелдер кебек. Болай, озак ятып, кемнеңдер йокысын урлыймдыр шикелле. Кайда, нишләргә икәнен гел әйтеп торуны карусыз тыңларга күнеккәч, сәер икән, һәрбер адымыңны үзеңә уйларга кала, бәйдән ычкынган көчек үз койрыгын куып әйләнә бит, шуның кебек мин дә.

И авылның ул чактагы матур гадәте! Советлар Союзы Герое кайтканмыни, мине өй саен ашка чакыру башланды. Табыннар мул. Ачык йөз. Сый-хөрмәт. Бернинди хәмер шешәләре күренми. Аны кирәксенгән кеше дә юк. Гөр килеп утырабыз.

Шунысы гаҗәп: өй ризыгын тансыклап, йотлыгып кайтканмын югыйсә, ә нишләптер ризык тамактан үтми; бер-ике коймак, чәкчәк кабып, чемченеп кенә утырам. Кайту шатлыгымы бу – бөтен нәрсәдән өстен бәхетле хистән гүя тән теләге түгел, ә күңел теләге тулыша. Син – түр башында. Сине кыстыйлар. И ул ак яулыклы, эчкерсез, нурлы түтиләр, кайларга китеп югалдыгыз, дип инәлепләр кычкырсаң да юк инде... *(Күп булса биш-ун ел үтәр, өйләргә телевизор килеп кереп, түр башында Иблис булып утыра башлагач, ботарланыр, имгәнер, кубарылыр, сындырылыр, таланыр, авылдагы милли гадәтле яшәү тирәге.)*

Беркөнне Фәния дус кызын алып кайтты. Зилә. Гаҗәп чибәр кыз – гел елмаерга сусаган күперенке иреннәр. Кичке эңгер иңгән куе зәңгәр күзләр. Аякларын балериналар кебек алга омтылдырып атлап баруы... Күз карашыңны өтә, аңны томалый бу чибәрлек. Нишләргә? Ябылуда үткән айларым өчен көтелмәгән бүләгеме язмышның? Нигә ул мине котырта? Икебез генә калган мизгелдә, мин үрелгәч, иренен киртәләп куйсын иде учы белән. Юк, ул читкә тибәрми, иблискә карашы белән һаман үзенә тарта, күңелемне кабалый. Ул дустына хыянәт итәргә әзер. Ә мин мәхәббәтемә хыянәт итүгә бара аламмы?

Юк, мин тирән уйларга бирелмим. Миңа шушылай кызык. Тормышның үтешли кабынып алган бер мизгеле...

Безнең күзләрдән тояк очкыннары сибелгәнен Фәния сизми шикелле, ә бәлки сизгәнен сиздерми утырадыр.

– Синең иртәгә туган көнең бит. Бүген үк котлап бүләгемне бирсәм, ачуланма, – дип ул төргәк чыгарып әкрен генә сүтте. – Мин аны ай буе бәйләдем, – дип төргәктән кара йон җептән бәйләнгән перчаткалар чыгарды. Мин алырга өлгергәнче, перчаткаларны сузылып Зилә алды да, ялт кына үз кулына киеп карады, аннары миңа сузды. Фәния агарып чыкты, аның бу кыланмышын өнәмәгәне йөзенә чыкты.

Перчаткалар нәкъ минем кулга таман итеп бәйләнгән иде.

– Хәтерлисеңме, бармакларыңны аерып куеп, кулыңның рәсемен ясап җибәр әле, дип язган идем... Менә шул... Үзең ясаган өлгедән, – диде Фәния.

Икенче көнне Азнакайда мин бөтенләй уйламаганда Зиләне очраттым. Фатиры үзәктә, постаменттан Ленин кулын сузып торган якта икән. Әнисенең дә өйдә юк чагы. Зилә «ашкын, күңел!», дип яши торган тәвәккәл кызый булып чыкты. Ул көнне авылга кайтып тормаска монда бөтен уңайлыклар тудырылган иде.

Иләсләнгән күңел рәшә дулкынында тирбәлә. Аек акыл каядыр артка чигенде. Кыргый җәнлеккә төзәү, ату, тигезү ләззәте... Бу – борынгыдан килгән аучылык кәсафәте канда уйный башласа, акыл чүгеп кала...

Иртән уянгач, сискәнеп киттем, танымый торам. Ул әле йокы тирәнлегендә, иренен кыйшайтып мес-мес сулап ята. «Мин ничек күренәм? – дигән уяулык сүрүен җуйган йөз кыяфәте, бизәнү битлеген салып, бер эчтәлексез калган. Мин сокланган кичәге матурлыкны төн урлаган. Әллә соң мин шайтан котыртуына бирештемме?.. Нинди хата, нинди үкенеч...

Мин тиз-тиз киенеп, ишек катына килүгә, – кай арада уянган диген, – арттан килеп сарылды, муенымны пышылдаулы тыны урап алды.

– Китмә... Бергә булыйк... Мин көтә беләм... Ике елдан әйләнеп кайтуыңны бер яшьлек улың белән каршы алырмын...

Мин аңа борылып карамыйм. Кичәге соклanудан бүгенге чиркануга кадәрге арада – күңел даласы. Анда – ирек тәме. Анда тояк эзе юк. Анда җил тышауланмаган.

Беренче карашка юаш, оялчан, беркатлы күренгән егетне пәрәвез ятьмәсенә урамакчымы?.. Юк, булмас, үз ирегенә кул салдырмас... Кирәк чакта, уянып, араннарны күкрәге белән җимереп чыгасы тайны тотып тыям димә, иркен даласына томырылачак.

Фәния белән күрешергә кыймыйча болай да санаулы берничә көнем үкенечле газапта узды. Иртәгә китәм дигән көнне генә очраштык. Ул инде барын да белә, Зилә алдан килеп, үзен акларга өлгергән. Фәния дәшми. «Китәм инде», дигәч тә, кайтарып бер сүз әйтми.

Әй, эчкерсез капка баганасы, сыендыр безне төнгә күләгәңә.

*«Минем өчен тормыш уен гына. Кырыс якларын әйләнеп узам. Бу дөньяның сакалын тартып уйныйсы, үчеклисе килә минем, кайчакта җылап алыр өчен... Яшәү кагыйдәләренә мин тыштан гына буйсынам, эчтән исә таптыйсым, җимерәсем килә.*

*Мине һәрдаим, үзем дә белмәгән, аңлап бетерә алмаган куркыныч тойгы – олы сагыш эзәрлекли. Шуннан котылып тору, онытылу өчен иңгә кунып чыркылдашкан кош кебек миңа кызларның янәшәмдә булуы кирәк. Алар*

*минем әнә шул олы сагыш баскан күңелне вакытлыча булса да, юата, иркәли, ваемсызлыгы белән дәвалаган сыман була.*

*Монда мәхәббәт тә, хыянәт тә юк. Самими уен гына бар. Ә сиңа карата булган тойгы, әллә кайчаннан бирле шытып, тамырланып, сәмави нур алып, буйга сикергән мәхәббәт тирәге – ул башка. Ул аерым утрауда, аңа гадәти параллельләр, меридианнар челтәре килеп ялганмый. Ул икебез генә сугарып бар иткән поэма. Аны тамырыннан өзәргә хакыбыз бар микән...*

*Беләм... килешү авыр. Хисләр олыгаер бервакыт. Мин дә тынычланырмын. Ә болай... чыркылдашкан кошларны иңгә утырту – үтешли мавыгу, бәйсез уен гына. Алар мине өшеткеч, хасталы, олы сагыштан йолып ала, коткарып кала. Көнләшү, юктан ара бозулар «минеке» дигән кыргый атавизм калдыгы. Без барыбыз да – галәмнеке...»*

Әйттемме мин бу сүзләрне, әйтмәдемме – капка баганасы шаһит. Фәниянең күзләрендә рәнҗү сулкылдый. Аны юату өчен сүзләр дәвасы көчсез. Маңгайны маңгайга терәп басып торабыз. Керфеккә керфек бәйләнә, яшькә яшь кушыла. Кайнар тамчылар, авыраеп, битне яралап төшә. Хушлашабыз. Тагын ике елга. Әллә бөтенләйгәме?..

Бераз киткәч, борылып карыйм. Һаман шул урында, багана ышыгында басып тора. Ашыгып кире киләм. Юк, кереп киткән. Капка баганасы, үз күләгәсеннән аның силуэтын чагылдырып, мине өметләндергән генә.

Бөгелмәгә китәр алдыннан вокзалда билет алырга күрсәтәсе «предписание» дигән кәгазьне алып карасам, йөрәгем «жу» итте. Анда бит маршрут «Бөгелмә – Инза – Мәскәү – Смоленск», дип язылган. Ә минем кышкы киемнәр Казанда.

Тиз генә өр-яңа лезвие алып, хәрефләрне кисеп, төзәтеп, «Инза» дигәнне «Казан»га үзгәртеп куйдым. Рәзинә апага күрсәтәм, берни сизми. Ювелирларча эшләнгән, шәп, дип үз-үземне мактап куям, әлбәттә, эчтән генә...

Бөгелмә вокзалында мине «тоттылар». Инза Мәскәү тимер юлына карый икән. Ә Казан – Горький тимер юлында... Кем уйлаган бит, бер юнәлешкә ике тармаклы тимер юлы бара дип...

Билет бирмәделәр. Проводник солдат кешене рәнҗетә димени, болай гына утыртты, буп-буш вагонда Казанга чаклы берьялгызым утырып бардым. Поезд кузгалуга үлеп ашыйсым килә башлады. Табындагы бәлешләр, гөбәдияләр, кызыктырып, күз алдымнан үтә. Үкенү – хистән тамак ягына күчте менә...

Унынчы октябрь, кояшлы җылы көн. Бауман урамыннан киләм, козырёк астыннан ишелеп чәч бөдрәсе тирбәлеп бара. Хәрбиләр каршыга очрый, нишләп мондый җылы көндә шинель, бүрек кигәннәр бу мокытлар, дип аптырыйм.

Казанны беренче тапкыр күргәндә шаккатырган теге манараны үтүгә, җиңенә патруль тасмасы бәйләгән капитан һәм ике солдат туктаттылар мине.

– Капитан Карпенко, – дип честь бирде офицер. – Оборона министрының кышкы киемгә күчү турындагы 1 октябрьдә чыккан приказы сезгә таныш түгелмени? – диде.

– Таныш түгел. Мин авылдан килеп ятам, ялдан, – дим.

Карпенко хәрби билетымны алды.

– Комендатурадан барып алырсыз, – дип адресны язып бирде. – Аның өчен башта чәчегезне алдырасыз, китель якасындагы купшы нәрсәләрне сүтеп ташлыйсыз. Бил каешыгыз чын каеш, уставка каршы килә, алыштырасыз. Погоннарыгыз да уставча түгел. Анысын частегезгә кайткач үзгәртерсез. Хром итегегез... Болай булмый. Кирзага алыштырып киегез.

Шулай итеп, мин патруль капитан әйткәннәрне үтәп, документымны алып чыкканда кич булган иде инде.

Вокзал комендатурасында минем төзәтелгән кәгазьне әйләндерә-әйләндерә карадылар.

– Бөгелмәгә ничек кайттыгыз? – дип сорадылар.

– Самолёт белән, үз хисабыма.

– Син бай икәнсең бит. Бер сум җитмеш ике тиен штраф түлә, алай булгач, – диделәр.

Мәскәүгә барып җиткәч, поезд Кызыл мәйдан янына килеп туктар, күпме тапкырлар рәсемен ясаган Кремльне, ниһаять, якыннан күрермен, дип уйлаган идем.

Кеше өстендә кеше мыжгып торган Казан вокзалына килеп төшкәч, аңладым, монда Кремль кайгысы юк икән. Ничек метрога төшәргә, Белорусь вокзалына кай якка барырга – менә мәсьәлә!

Агымга ияреп төштем метрога. Каршыга поезд килеп туктады. «Белорусь» вокзалына бару өчен шушы поездга утырыргамы?» дип сорыйм. Бик затлы киенгән ханым минем солдат капчыгыма, иске чемоданга чирканып кына карап куйды:

– Укыгыз, стенада язылган бит, – диде.

– Арада поезд тора ич, укый алмыйм... – дим.

– Поезд киткәч укырсыз, – диде бу салкын гына.

Мин телсез калдым. Менә сиңа Мәскәү, күпме табынып йөргән башкалада шушындый кешеләр яши микәнни?!

Шул мәлдә яныма бер ир кеше килеп басты.

– Сезгә Белорусь вокзалынамы? Киттек, – дип чемоданымны алды. Барам мин моның артыннан, әле уңга борылабыз, әле сулга, эскалатор белән бер өскә менеп, бер төшә торгач, ниһаять, поездга утырдык. Бик тиз килеп җитте үзе. Күтәрелдек өскә. Җилле ишекләрдән чыгуга, ярдәмчел ир кешем:

– Әнә, каршыда Белорусь вокзалы, – диде. Мин, шулкадәр күңелем булып, нинди яхшы кешеләр бар бу дөньяда дип, чемоданымны кулыннан алыйм дип, үрелгән идем:

– С вас, молодой человек, рубль пятьдесят, – димәсенме. Каушый-каушый гына акчаны санап бирдем. Вәт сиңа Мәскәү!

Смоленскига билет юнәткәч, вокзалның бер аулак почмагына барып йомылдым да, поезд килгәнче җиде сәгать буена бер яры да кузгалмадым. Каядыр мин күрергә хыялланган Мәскәү дөньясы шаулый. Бу хәлемдә миңа башкаланы борчырга ярамый. Әз генә башыңны чыгар яктыга, берәрсе орылып китәчәк, бәйләнергә бер-бер сәбәп табачак. Чөнки син – аска салып ятсаң да, өскә ябынып ятсаң да тузмый торган дөя йонлы шинель кигән солдат, бары солдат кына...

## Утырып уйлар уйлар өчен...

Бобруйск вокзалына килеп төшкәндә таң беленмәгән иде әле. Вак кына яңгыр сибәли. Караңгы болытларның түше җиргә тигән шикелле. Смоленскиның туплану пунктыннан кузгалган без – утызлап солдатны, иске, калтырча автобуска утыртып, каядыр алып киттеләр. Тирләгән тәрәзәне учым белән сөртеп, тышка карап барам. Борынгы йортлар шәйләнә. Таш түшәлгән юеш, тар урамнар буш. Шулкадәр ямансу. Алда ни көтә мине? Ниләр күрергә язган? Билгесезлектән җан сыгыла. Җылыйсы килә.

Әгәр монда да шулай булса... дип, Смоленскида алты-җиде көнләп яшәп

алган шыксыз казарманы күз алдыма китерәм. И рәхәт чикте соң бер тинтәк сержант, безне буйсындырудан әйтеп бетергесез тәм табып, кинәнеп калды. Һәр иртәдә ул безне Ватан сугышыннан калган җимерек хәрабәләр арасына алып бара. Шунда үзле, кызыл балчыкка батып канау казыйбыз. Кемгә кирәк бу эш, ни өчен – моны берәү дә белми. Без бит монда үтешли генә тукталганбыз, төпченергә, сорашырга бернинди хокукыбыз да юк.

Кичен керләнеп каткан киемле сержант аламасы безне тезеп куя да, кызмача баштан нидер сөйли, сөйли, сөйли... Иртән, майсыз тары боткасы белән сыйлаганнан соң, тагын канау казырга алып китә. Бу мәхшәр отыры шулай берничә көнгә сузылса, берәребез, акылдан язып, ул сержантны бәреп үтергән була иде.

Смоленскиның тагын бер урыны хәтердә калды. Тар гына инеш күперен чыгып барганда: «Карап калыгыз, Днепр елгасын кичәбез!» – дип арабыздан кемдер кычкырды. Мин гаҗәпкә калып автобус тәрәзәсеннән артка борылып карадым. Днепрны Украинаның зур елгасы дип укып, карталардан карап үскәнгә, каядыр төньяк тарафтарак, Смоленски җиренә дә кагыладыр дип башка килмәгән...

Бобруйскиның йомран кебек йомры ташлы урамнары да, йортларының бизәлеш рәвеше дә икенчерәк. Европа шәһәрләре бәлки шушындый чалымдарак буладыр. Шул тар урамнардан борыла-сарыла күпмедер баргач, автобус дүрт-биш катлы заманча йортлар тезелгән иркенрәк урамга килеп чыкты. Киң, тимер капка каршында тукталып бераз торганнан соң, безне эчкә үткәреп, өч катлы бина каршында бушатып калдырдылар. Дивизия штабы икән бу. Эчтә җылы, рәхәт. Коридорны тутырып урнашып алдык. Бер кырыйдагы ишек өстендә «Тише, идут полёты» дигән утлы язу бер янып, бер сүнеп ала. Ишек ачылганда эчтән чыкыр-чыкыр ниндидер аппаратлар эшләп торганы ишетелә. Икенче яктагы кабинеттан погонлы кызлар кереп-чыгып йөриләр. Минем солдаткаларны беренче күрүем. Ыспай күн итектән, зәңгәр юбка, яшел костюм, зәңгәр беретка кигәннәр, хәрби кием бик тә килешеп тора үзләренә. Боларны күргәч, вак яңгырлы ямансу иртәне бүлеп, кояш чыгар кебек, өмет уянып куйгандай булды.

Сәгать тугыз тулганда штабка хезмәткә килүче офицерлар агыла башлады. Арада солдатлар да, граждански киемле хатын-кызлар да күренеп ала.

Безне, яңа килгән «сарыкларны», туплап, якындагы бүтән бинага алып киттеләр. Ни дисәң дә, без бит төрле шәһәрләрдә ШМАС бетергән белгечләр, таныклыгы булган механиклар саналабыз. «Мал бүлешү» – кемнең кайсы полкка эләгәсе ачыкланачак хәзер.

Офицерлар арасыннан берсе – маңгаена ишелеп төшкән куе кара чәчен кулы белән артка көрәп, елмаебрак сөйләшкәне хәтердә калды. Ул үзен дивизиянең комсомол эшләре буенча политотдел начальнигы урынбасары, капитан Пинчук дип таныштырды.

– Сез хезмәт итәчәк бу дивизия «гвардейский» дип атала. Сез һәммәгез дә менә шушындый гвардия билгесе тагып йөрергә тиеш булачаксыз, – дип, ул түшендәге орденга охшаган билгене күрсәтте.

Моннан соң без, дәрәҗәсенә карап, хәрбиләргә: «Товарищ гвардии солдат», яисә «Товарищ гвардии генерал» дип дәшәргә тиеш булабыз икән.

Исемлек буенча карап, солдатларны бүлешер алдыннан капитан Пинчук шундый сорау бирде:

– Арагызда матур почерк белән яза белгәннәр бармы?

Мин, як-ягыма каранып, сагаеп кына кул күтәреп бастым да, фамилиямне, Пермьдәге ШМАСта укыганлыгымны әйтеп урыныма чүмәштем.

– Рәсем-плакатлар ясый белүче бармы? – дип капитан янә сорау бирде.

Кул күтәрүче тагын бер мин булып чыктым.

– Сызым сыза белүче?

Белгәнемне белгәнгә күрә, мин бу юлы да дәшми кала алмадым.

Капитан Пинчук, миңа ым кагып:

– Три в одном, – дип елмаеп куйды. – Берём вас в роту управления.

Шунда мин язмышым хәл ителгәнне аңладым. Укытучым Рафика апаның: «Мондый һөнәр белән төрмәдә дә югалмыйлар...» дигәне искә төште.

Кемнең кайда билгеләнүе ачыкланып беткәч, яныма куш түгәрәк сыман мул чырайлы старшина килеп басты. Яше кырык бишләрдә булыр. Юантык кына гәүдәле.

– Старшина Осипенко, – дип кул биреп күреште. – Тебе повезло. Ты у меня будешь кататься как сыр в масле, – дип, калын иренле авызын бөтен битенә киереп елмайды. Мин дә, үземнән өлкән кешегә ярашып, елмая башлаган идем... старшинаның елмаюы кинәт сүнеп, йөзе җитди-төмсә рәвешкә керде.

– Чё ты лыбишься?! – дип кырыс кына әйтеп тә куйгач, аптырап калдым.

Як-ягын тигез кыркылган куаклар каймалаган аллеядан ул мине каядыр алып китте. Тукталып, вакыт-вакыт сорау бирә. «Татарин, значит. Знаем вашего брата...» Старшина тагын баягыча таралып елмайды. Мин дә аңа кушылып елмаерга ашыктым. Күз ачып йомган арада старшинаның кызгылт чырае кырысланып, ике каш арасына кисәтүле җыерчык сызылды:

– Чё ты лыбишься?!

Мин шунда аңлап алдым: бу бит старшинаның чынлап елмаюы түгел, ә үзе дә сизмәгәндә авызы болай гына ерыла икән ләбаса. Медицинада моны «тик» дип атыйлар бугай...

Карасу-кызыл кирпечтән салынган борынгы бина ишегеннән кереп икенче катка күтәрелдек. Күңелем сизә: монда минем тукталыш озакка булыр ахрысы...

Яңа ызбага килеп кергәч, гадәттә, песи халкы иснәнеп, һәр почмакны карап, әшьялар белән танышып, барлап чыга бит әле. Мин дә шулай, ике ел буена яшәячәк казарманы күздән кичереп чыктым. Капма-каршы ике стена да тәрәзәләрдән генә тора. Ике якта да икешәр-икешәр рәт караватлар тезелгән. Урта бер җирдә теннис өстәле. Моны күргәч, күңел кытыкланып куйды; ниһаять, бу уенны өйрәнергә дә җай чыга, ахрысы. Түр стенада Ленин портреты тора, өске ягы авыш итеп элеп куелган.

Пермьнең затлы казармасы белән чагыштырганда оттыра, әлбәттә, әмма күңел тиз ияләшер шикелле: якты, җылы, калын диварлы бу борынгы бинаның ниндидер ягымлы нуры бар сыман.

«Идарә ротасы» дип аталса да, монда нибары кырык сигез карават куелган. Старшина ни җитте генә казармага хуҗа түгеллеген искәртергә теләгәндәй, караватлар арасыннан йөреп, мине таныштыра башлады. Сулдан караганда беренче рәттә – югары түрәләрне йөртүче шофёрлар, икенче рәттә – метеорологлар, уңнан беренче рәттә штабниклар – сызымчылар, дешифровщиклар, «секретчик»лар, икенче рәттә исә аэродромда генерал самолётын әзерләүче механиклар урыны икән. Миңа штабниклар рәтеннән карават билгеләнде.

Кайбер караватларда шинель генә ябынып йоклаган солдатлар ягына аптырабрак карап алуымны искәреп, старшина:

– Болар төнге сменадан кайтып ятканнар, – диде. Монда тәртип бозучы шалапайлар юк, дигән шикелле, аңлатуны кирәк тапты. – Сез – унбер классны бетергән «молодой»лар хәзер өчәү булдыгыз. Калганнар – барысы да диярлек

ВУЗлардан, икенче, өченче курстан алынганнар. Генерал шофёры Сагайдаков – академиядән...

Әйберләрне урнаштырып, бит-кулны юып алганнан соң, старшина мине Ленин бүлмәсенә алып керде. Яңа ремонтланган. Стеналар шып-шыр. Буяу исе утырып өлгермәгән. Түрдә иң зур байлык – сүнгән күзле телевизор тора. Дүрт аяклы бу могҗизаны беренче тапкыр болай якыннан күрүем.

Старшина ишекне ачып, «Дубовой, ко мне!» дип, казарма ягына сөрән салды. Менә хәзер имәндәй нык гәүдәле солдат килеп керә инде дип көтәм, баксаң, кыска буйлы, чандыр гәүдәле, бил каешын корсагы астына салындырып буган ефрейтор, йокылы күз төпләрен сөртә-сөртә килеп керде.

– Вот наш Дубовой, ему цены нет – краснодеревщик пятого разряда, – дип таныштырды старшина. Аның кинәт балкып елмаюына алданып кушылып китмәс өчен Дубовой йөзен читкә борды. Мин дә эчемнән, бу юлы гипнозлый алмыйсың, туган, дигән кебек, старшинаның ерылып китеп, колак очына тоташасы мул иренен күрмәмешкә салыштым.

Володя Дубовой белән икебезне олы эш көтә икән. Ленкомнатаның ялангач стеналарын киендереп, стендлар ясап, бизәп, ике ай эчендә гөл итеп, тапшырырга тиеш икәнбез.

– Берегезгә – агач, берегезгә – буяу эше, – дип, старшина тагын елмаю өянәген балкытып алды да, төшкә кадәр ял итегез, дип китеп барды.

Мин өскә шинельне генә ябынып, черем итеп алдым. Казарма эче корт күче кебек гөжләгәнгә уянып киттем. Сәгать уникe тулган, солдатлар үз эш урыннарыннан кайтканнар икән. Бераздан, сафка тезелгән сыман итеп, эленке-салынкы гына атлап, ашханәгә киттек. Монда – мәхшәр. Йөзләрчә кешегә исәпләнгән савыт-саба көннән-көн кими бара, аларны якындагы белорус авылларына алып барып, чемерга (белорус самогоны) алыштырып кайталар икән. Өстәлләрдә кружкалар берән-сәрән генә күренә. Иң беренче шуңа ташланалар, кеше эчкәннән калган дип тормыйча, тизрәк үз өстәлеңдәге чәйнектән кисельме-компотмы салып өлгерергә кирәк. Җирәнеп, кружкаңны юдырырга чират торсаң, кисельсез каласың. Ашханәдә сыңар калак та күренми, бөтенесе солдатлар кесәсенә күчеп беткән. Бер мин – калаксыз, атакага мылтыксыз ташланган солдат хәлендә чарасыз басып торам. Аптырагач, кул селкедем дә, янәшәдәге түләүле ашханәгә киттем. Бу – беренче көнне шулай. Аннары... мондагы «ашау фәненә» берничә көндә өйрәнергә туры килде. Юылмаган кружкага компот салып эчү дә нормага әйләнде. (Озакламый, һәр полкка йозаклы тимер сейфлар ясатып, савыт-саба ягын хәл иттеләр.)

Казармада беренче төнем «гарасатлы» булды. Саташып, бастырылып чыктым. Коточкыч афәт килә имеш: таулар актарыла, кыялар ава, ташлар оча, күк гөмбәзен яшен утлары кискәләп чәрдәкли, зәһәр улап, юлындагы бөтен нәрсәне яндырып, утлы лава ташкыны килә. Минем гәүдәмне көчле давыл бөтереп ала да, биеккә чөеп җибәрә. Аска борылып карыйм: Җир шары гүли, континентлар җөеннән сүтелеп, кисәкләргә аерыла. Мин бөтерелеп, караңгы упкынга очам. Юк! Бу мин түгел, бу – тәненнән аерылган җаным гына. Миңа кире кайтырга, үз гәүдәмне, җан-оямны эзләп табарга кирәк! Газаплы уянып, төштәге мәхшәрдән өндәгесенә сикерәм. Ахырзаманмы бу?! Тәрәзәләр зеңли, диварлар дер селкенә; актарыла, кубарыла, тетри, гүли бар дөньясы. Бу мәхшәрне акылыма сыйдыра алмыйча торып утырганмын.

Ятар алдыннан гына танышкан күршем – сержант Владислав Шульгин уянып, янәшәмә тартыла:

– Аңлыйм хәлеңне... Башта шулай була. Аннары самолёт тавышларына күнегәсең. Мондый төнге очышлар атнага ике тапкыр була, – диде.

Гаҗәп бит, тирә-юнемә карыйм, бөтенесе дә таралып, рәхәтләнеп йоклап ята. Аэродром бер чакрым ераклыкта югыйсә. Ә дистәләрчә тонналы самолёт авырлыгын җирдән аеру өчен, куәтле форсаж тизлеккә куелган турбина тавышлары гел янәшәдә кебек, төнне яргычлап үкерә, чытырдап уала, колакны ярып керә, тәнне талкый, йөрәккә бәрә – моннан котылу чарасы юктыр сыман... *(Ә котылу чарасы бар – күнегү, ияләшү икән. Тагын шулай төнге очышлар вакытында ике-өч тапкыр өметсез бәргәләнгәннән соң, ярсулы самолёт тавышларын санга сукмаска дип тән белән җан үзара килештеләр ахрысы. Хәзер инде тавышлар никадәр көчлерәк булса, шулкадәр тынычланыбрак савылып йокларга өйрәнеп киләм бугай...)*

Тыштан караганда, бар да әйбәткә юрала шикелле...

Ниһаять, мин күпне кичергән Белоруссия җирендә. Аяк астында идәнем, баш очында түшәмем бар. Юл йөрүләр, күчену мәшәкатьләре артта калды. Хәзер инде бу дөньяда үземнең барлыгымны искә төшерергә була. Монысы – көнкүрештәге матавыклардан күпкә хәтәррәк. Вакытлы борчулар белән мавыккан булып, гүя үз-үземнән качып йөрдем дә, менә хәзер, күзгә-күз калып очраштым.

Әллә нинди, җанны тарыктыра торган көннәр бу.

Онытылып, тәрәзәдән карап торам. Вак кына яңгыр сибәли. Таш юлга җиз яфраклар түшәлгән. Шәрә калган мәһабәт тополь ябалдашлары, караеп, җанны тырный. Моңсу, шулкадәр моңсу. Күңелгә кар аклыгы җитми. Кичә кич телевизордан Антарктидагы пингвиннарны күрсәттеләр. Коточкыч салкынлык. Үзәккә үткәзеп буран җуылдый. Пингвин халкы җылыны саклар өчен, тыгызланып, елышып, бербөтенгә әверелеп баскан. Бер пингвин гына нишләптер читтә калган, тыгыз төркемне аерып эчкә керергә азаплана, әле тегеләй, әле болай килеп карый – юк, сыеша алмый, кушыла алмый, бичара, зәһәр җил аны талкый, аяктан ега, читкә тибәрә... Мин дә шул пингвин хәлендә түгелме?

Хәрби хезмәткә өч елга алынгансың икән, тоташы белән хезмәт ит, бүленмә, нәфесеңне тыя алмыйча ялга кайтып килсәң, яңадан кереп китү мең газап булачак, дигәннәре дөрес икән.

Аңламый идем элек, үз-үзенә атып, йә кулын, йә аягын гариплэтеп сугыштан кайтканнар булуына ышанмый идем. Менә хәзер ышанам инде. Шундый халәттә мин: сыңар кулыңны өздер, кайтарабыз, дисәләр, һич икеләнүсез риза булыр идем.

Шулкадәр ямансу. Мондый халәттә кулыңда салкын корал булса?..

Үз-үземнән үч аласы килә. Эчтә – җан яралы, ә тыштан тән сәламәт. Шушы тигезсезлек ачуны китерә.

Тимер баскычтан өченче катка, түбә астына күтәреләм. Анда – күгәрченнәр хакимлеге. Ачык тәрәзә катына килэм. Баягы вак яңгыр, карлы бозга әверелеп, тәрәзә уемыннан бәрә. Билдән чишенеп ташлап, шул төшкә барып басам. Миңа авырырга, эчтәге җан халәтенә төшәргә кирәк... Бозлы, энәле җил арканы пешекли. Үтәли бәргән суыктан тән калтырый башлады. Миңа шулай рәхәт. Миңа шулай кирәк!

Суык җелеккә үткәнче тордым түзеп, бервакыт аяк астына күзем төште: бер күгәрчен каршыма баскан да мөлдерәп карап тора. Шундый акыллы караш, җәлләгән дә кебек мине, шелтәләгән дә кебек... күкрәге эчендә йөрәге типкәне сизелеп тора. Миңа оят булып китте. Суык киемне суынган тәнгә шудырып, тизрәк чормадан төшәргә ашыктым.

Берничә сәгать буе җылына алмыйча йөрсәм дә, Ходай саклады, салкын тимәде, күрәсең, эчтә кайнаган утлы лаваны җиңеп керә алмады.

Иң хәтәре – яшәү куанычын җуйдырган ямансу халәт. Тома ялгызлык. Чит-ят дөнья.

Солдатның иң кадерле юанычы нәрсәдә? Әлбәттә, хатларда. Әлегә минем бу хәбәрләшү челтәре өзелгән, дусларга яңа адресымны җибәреп, ил киңлекләренә сузылган җепләрнең очын кабат ялгарга кирәк.

Ятими моңсулык чыганагы исә – тирәндәрәк, үз-үземнән дә яшерелгән күңел мәгарәсендә, чыгу юлын таба алмыйча гасабилана. Сызландыргыч сәбәпнең асылы шунда... Яраткан ярыңнан хат килмәячәген, үзеңнең дә язарга ихтыяр көчең җитмәячәгеңне белүдә... Мин бит Фәниядән көн дә хат алуга шулкадәр күнеккән идем. Сагыну сусынын баса торган дәва булган бит ул хатлар. Кадерен белмәгәнмен. Башлап кем бу чуалган йомгакны иелеп алырга тиеш? Минме, улмы? Үз вакытында горурлыгыңны читкә куеп, аңлаша алмау, хикмәтле бер сүзне әйтергә өлгермәү аркасында күпме мәхәббәт кораблары кыйбласын җуеп, томанда адашкан, кыяга бәрелеп, челпәрәмә килгән. Бу борынгы хакыйкатьне белеп янә хаталану – мәхәббәт язмышының котылгысыз газабы мәллә?

Мин, ашыга-ашыга каптёркага кереп, Пермьнән үк мине озата килгән иске, бетәшкән чемоданнан кара перчаткаларны алам. Учыма кысам. Битемә куеп иснәп карыйм. Ничек шулай озын бармакларыма чат китереп, оста итеп бәйли белгән ул аны?

Кара төс соры шинельгә килешеп тора. Перчаткаларны кулга киеп урамга чыгам. Кыш хәбәре – көзге сарылыкны сипкелләп, бүген беренче кар күренә. Нәзберек, кыюсыз кар бөртекләре җиргә төшеп җиткәнче үк эри сыман. Минем перчатканы котлап, эрерәк яу син, карлы нигъмәт, кыюрак бул, яктыга манып ташла минем соры дөньямны!

Кибеткә кереп, шоколад алып чыгам. Паркны урап үтәм. Офицерлар йортына керәм. Шинель җиңе капламасын өчен перчаткалы кулларым күренерлек итеп хәрәкәтләр ясап барам. Шулай ике сәгатьләп йөреп, хозурланып кайтып килгәндә... кәефемә күләгә төште бит. Һәр бармакчасын аерым-аерым савып, перчаткамны бер салып, бер киеп, ләззәтләнеп барганда... Карасам... бармак очлары сүтелә башлады. Аптырап, җеп очын тарткан идем, бөтен иңе белән сүтелергә тотынды. Куркып калдым... Нәрсә бу, нидән болай бу? Күз алдымда перчаткаларым таралып төште, берничек тә коткарып булырлык түгел. Әллә соң Фәниянең миңа карата булган рәнҗеше шулай ерактан тәэсир итәме? Нинди сер ята моның асылында? Фәния бүләк итеп сузган мәлдә дус кызының эләктереп алып, миннән алда киеп каравы искә төште. Хорафатларга бик үк ышанып бетмәсәм дә... бу очракта уйлана калдым. Ниндидер сер, мистика бар бугай монда...

*(Бернинди дә мистика юклыгын әни миңа, җәй көне кунакка кайткач, гади генә аңлатып бирде. Миңа биреп җибәрергә дип ап-ак йоннан өч пар носки бәйләп куйган. Ике парын дусларыңа бирерсең, ди. «Гел актан да актан, кара җептән матуррак була бит, шундыйны бәйлә әле, әни», – дим.» И-и-и, улым, кара сарык йоны бик нәзберек бит ул, җебе чәрексез була, тиз өзелә», – ди әни. Шуннан соң ул миңа бергә-бер итеп, ак җепкә караны кушып бәйләргә гадәтләнде. Ә мин уйлана калдым. Димәк, кояш нурының тәэсире ак төскә бер төрле, кара төскә – икенче төрле төшә, дип үз нәтиҗәмне чыгарып куйдым. Кавказ егетләре минем өчен тагын бер ачыш ясадылар: шашлык кыздырырга алар кара сарык итен генә файдаланалар икән. Ите йомшаграк та, тәмлерәк тә ди. Әле анда да*

# МИҢКӘЙДӘН – БАБАЙГАЧА

**Һәр заманның үз илбашлары һәм илгәсәрләре була.**

**Беренчеләре – төзи, икенчеләре – җимерә.**

**Беренчеләре ил-иләтнең тормыш-көнкүрешен, рухи хәл-халәтен көйле итәр өчен җан ата, икенчеләре – көйсезләндерә.**

**Беренчеләре – алгарыш әйдаманнары, икенчеләре – торгынлык диктаторлары.**

**Ләкин без тарихтан вәйранга бәрабәр коруларны да яхшы беләбез. Әйтик, каберташлардан укмаштырылган нигез өстенә салынып куелган гыйбадәтханә нәрсә ул? Архитектура корылмасымы, әллә инквизиция һәйкәлеме? Яисә халыкларны коллыкта тотып, иреген ирексезләп, бөтен дөньяда коммунизм төзергә адарыну ни-нәрсә? Балаларча «суллык» авыруымы, әллә бар кешелек алдында кылынган хәтәр җинаятьме?**

**Инде килеп, Русия тарихында бөек реформатор саналган, Аурупага карындыклы булса да тәрәзә уйган Пётр Беренчене алсак та, чынлыкта ул да үз сәясәтен коточкыч кансызлык, шайтани явызлык белән гамәлгә ашырган. Бу җәһәттән урысның мәшһүр шагыйре һәм дипломаты Ф.Тютчев аның турында: «Бөек Пётрга кадәрге урыс тарихы тоташтан җеназа булса, аңардан соңгысы – уптым җинаять эше», – дип юкка гына язып калдырмагандыр.**

**Хәтердә әле, узган гасырның 90нчы еллар башында Мәскәү телевидениесенә биргән бер интервьюсында Минтимер ага Шәймиев әлеге патшаны үзенең кумиры дип тә белдергән иде. Һәм бу аңлашыла да. Ни дисәң дә, без бит гомер-гомергә тарих дәреслекләреннән, әдәби китаплардан идеаллаштырып сурәтләнгән урыс патшалары турында укып үстек. Ләкин тора-бара тормыш-яшәеш, Минтимер аганың Илбашы буларак кылган үз эш-гамәлләре «кумирлык»ка нисбәтән бик зур төзәтмәләр кертте. Хәзер инде кулны йөрәккә куеп та әйтергә ярый торгандыр: Минтимер Шәймиев, Татарстан, татар халкының хакын хаклап, моңарчы бер генә җитәкченең дә кулыннан килмәгән игелекле эшләрне башкарып чыга алды. Юк, монда сүз җөмһүриятебез авылларын тоташ газлаштыру, Чулмансу аша күпер салу, Кол Шәриф мәчетен һәм Болгарны торгызу, федераль үзәк белән Шартнамә төзү, берьялгызы диярлек федерализм принципларын яклау-саклау, Русия кануннарын әйләнеп узып булса да, тузган торакны бетерү программасын гамәлгә ашыру, башкалабызны заманча шәһәрләр рәтенә чыгару кебек, тарих елъязмасына алтын хәрефләр белән теркәлерлек эш-гамәлләр турында гына бармый. Иң мөһиме – ул гасырлар дәвамында хәкарәтләнгән, авызлык кидерелгән, имгәтелгән Татар Рухын кабат үрләтеп җибәрүче, шуңа алшартлар тудыручы, бөтендөнья татарларының да үз Президенты булуга иреште. Халкыбыз бу ил агасын күптән инде олылап, яратып, үз итеп, Бабай дип атап йөртә. Бәләкәй Миңкәйдән халкыбызның аксакалына – Бабайга әверелгән олпат шәхесебез ул безнең. Сингапур могҗизасының атасы Ли Куан Юның «Без булдырабыз!» дигән канатлы гыйбарәсен дә ил агасы юкка гына күтәреп алмагандыр.**

**Газинур МОРАТ**

*сайланып кына, кара сарыкның сул як түш итен генә алалар имеш. Сарык дигән җәнлек беркайчан да йөрәк ягына ятмый икән, димәк, гәүдәсенең сул ягы гел корыда, кояшта тора...)*

Казарма тормышы – уч төбендә, әкәм-төкәм кебек үз кабыгыңа яшеренә алмыйсың.

Мин ышыкланган ялгызлык пәрдәсе әкрен-әкрен ачыла башлады.

Үзбәк егете Адил белән кул бирешеп таныштык.

– Син мөселмандыр бит, – дигәч, диннән ерак торган кеше буларак, сискәнеп куйдым. Баскыч мәйданчыгында ул, билдән чишенеп ташлап, ике потлы герне чәнти бармагы белән күтәреп, чөеп уйный икән.

– Офицерлар йортындагы спортзалга штанга күтәрергә бергә йөрербез, – диде Адил. Аптырап калдым. Минем штангам – каләм дә буяу пумаласы ич. Мәскәү вокзалында чакта киосктан штанга сурәте төшерелгән значок алып түшкә кадаган идем, Адил шуны искәреп алган. Аңлашкач, көлештек.

– Ну, татарин, а я обрадовался, думал штангист пришёл, – ди Адил. Ул монда тәртип сагында торучы, яхшы мәгънәдә «пахан» икән. Берәр низаг куптымы, ашыгып килеп җитә, тупасланмый, сүгенми, тыныч кына бизмәнне тигезләп куя. Гаделлеккә сүз белән ирештерү өчен беләктә көч барлыгы да сизелеп торырга тиеш шул...

Иртән һәркем үзенең хезмәт урынына китеп таралышкач, казарма тып-тын кала. Ленкомнатада Володя Дубовой белән икәү генә мәш киләбез. Кулга – кул эше, башка – баш эше. Штабның политбүлегеннән йә капитан Пинчук, йә инструктор Лагунь төрле әсбаплар алып киләләр, киңәш иткән булып, күрсәтмәләр биреп, үзләренең барлыгын искәртеп китәләр.

Дубовой бик хәрәкәтчән, җитез кеше. Эш коралына тотынуында мәгънә бар. Ул югары чиндагы офицерларның өендәге җиһазларын яңарту белән шөгыльләнә икән. Чын агачтан эшләнгән мебельләрнең тышкы кабыгын үзгәртеп, ялтыравык буяуга мандыру модага кергән дәвер иде шул. Бу эштә Дубовой гарнизонда алыштыргысыз оста булып танылып өлгергән. Өй шартларына, офицер хатыннары пешергән тәмле ризыкларга күнегеп, үзенә – баш, үзенә – түш булып эшләп йөргән җиреннән монда – Ленкомнатада ике айга беркетеп калу аңа бик ошап бетми иде.

Аңа утырып уйлар уйлау өчен буй бирелмәгән, эчкерсез егет. Әйтер сүзе – тел очында, тәгәрәп төшәргә генә тора. Шыр ачык, беркатлы кешеләрне өнәп бетермим, безнең дулкыннар бик үк туры килеп бетмәс ахрысы.

Якшәмбе көн иде. Дубовой белән Ленкомнатада эшләп яткан чагыбыз. Телефон шылтыраганы ишетелде. Безнең ишек янында гына дневальный посты. Бераздан ефрейтор Пилипенконың ишектә түгәрәк башы күренде. Аның калын өске ирене ябылып бетми, шуңа күрә ул дөньяга күз белән түгел, ә авызы аша карап йөри шикелле.

– Егетләр, тиз генә штабка! Старшина Осипенко исемләп чакырды, – дип ул безне ашыктыра башлады. Старшинага гел куштанланып йөргән бу ефрейтор кисәгенә буйсынырга тиеш түгел дә без, дневальный буларак әйтә бит, тыңларга булдык, нишлисең, штаб – дивизиянең Олимпы...

Барып кердек штаб бинасына. Дежурный офицер үткәреп җибәрде. Икенче катка күтәрелдек. Кызыл келәм җәелгән озын коридорның урта бер җирендә, борылып кергән уемтык яныннан үткәндә ефрейтор Пилипенко пышылдап кына: «Монда генерал кабинеты...» – дип күн белән тышланган ишек ягына ымлады.

Хикмәт шунда: якты тәрәзәле коридор башында часть байрагын куяр өчен рамлап, бизәкләп, пыялалап постамент ясап киткәннәр. Келәм өстендә пыяла ватыклары чәчелеп ята, шуны җыеп, эзен дә калдырмау – безнең мөһим хәрби бурыч икән. Иелеп, пыяла кисәкләренә сак кына кагылып, чүпли башладык.

Кинәт нидер булды. Ефрейторның куркынган ысылдавы ишетелде. Иелгән җиремнән ашыкмый гына күтәрелсәм ...Каршыбызда генерал басып тора! Ефрейтор Пилипенко күкрәген алга чыгарып, үрә каткан, ефрейтор Дубовой да, хәрбилеккә дәгъва кылмаган тарау гәүдәсен турайткан шикелле. Бер сулышлык арада – дивизия командиры, Советлар Союзы герое, генерал Дудаков үзе!

Ни өчен монда килүебез хакында Пилипенконың рапортын тыңлап та тормады ул, өчебез белән дә кул биреп күреште. Мин каушаудан, аптырап калудан исемә килә алмыйча эленке-салынкы басып торам икән. Генералның кителендә, медаль планкаларыннан өстәрәк Алтын йолдыз билгесе балкый. Мин шуңа хәйран калып текәлгәнмен. Зур да түгел, кечкенә дә түгел, нинди камил үлчәмдә, затлы итеп, сәнгати зәвык белән эшләнгән ул генералның күкрәген бизәп торган алтын билге...

Дудаков үз кабинетына кереп киткәч, ефрейтор Пилипенко миңа ябырылды:

– Син нәрсә, генералга честь бирмәдең, истукан сыман басып торасың, гауптвахтага озата иде бит үзеңне!

– Кем озата? Кайчан? Нәрсәгә? – дип Пилипенконы тынсыз калдырдым. Мәгънәсез мизгелне җиңеләйтер өчен, мәгънә соралмаган сүз әйтеп куя торган гадәтем бар.

– Өч көн кулны юмаска, егетләр, генерал белән күрештек бит, – диде Дубовой.

Әз генә буш вакыт булдымы, теннис өстәленә тартылам. Кеше уйнаганны карап торганда гына бар да җиңел күренә, үзең ракетканы кулга алгач, бөтенләй икенче икән. Чыкылдап, өстәлгә бәрелеп сикергән җиңел шар, мине үртәп, әле уңнан, әле сулдан сызылып кына үтә дә китә; ракеткам белән, чебен куган сыман җилпенеп, күпме генә чәбәләнсәм дә тигерә генә алмыйм бит. Бер уенны өйрәнгәндә дә болай ук мескенлеккә калганым юк иде. Кешеләрдән оят!

Иң шәп уйнаучылар – кореялы егетләр Ли белән Чагай булып чыкты. Ли – зур күзле, дүрткырлы каты кара чәчле, погоннары килешле ятып торган ыспай җилкәле, Чагай исә җәлпәк йөзле, арасында көмеш чал бөртекләре җемелдәп киткән шундый ук каты кара, куе чәчле егет, «ничек күрә микән ул?» дигән сорау уятырлык дәрәҗәдә кысык күзле, әмма тенниста аның кебек оста, елгыр айкалып уйнаучы юк. Аның ракетканы нәзакәтле итеп тотуы, йә сыйпатып кына, йә көч белән кистереп, йә, күз буяган кебек, шарны бөтереп җибәрүләре – үзе бер сәнгать. Мин аның уйнавына хәйран калып, сокланып, һәрбер хәрәкәтен йотып кына барам.

Чагай белән Ли җитәкчелегендә берничә егет штабта, әллә нинди хикмәти приборларны хәрәкәткә китереп, алмашлап, тәүлек саен, бөтен Җир шарының метеокартасын эшләп баралар. Җирнең кайсы ноктасында яшенле яңгыр, кайсы океанда цунами, кайсы кыйтгада торнада кубарылачак – бу егетләр барысын да белеп һәм белдереп торалар. Төнге сменадан соң Чагай иртәнге алтыда кайтып йокыга тала, сәгать унбердә уяна. Төшкә кадәрге бер сәгать ара теннис уйнауга китә. Бу минем өчен иң сәгадәтле минутлар. Уйный белмәвемнән көлеп торырга тамашачы юк. Ә Чагай – сабыр. Бер дә иренмичә, авырыксынмыйча ракетканы ничек тоту, кулны ничек йөртүдән башлап, уенның отыры куера барган серләренә төшендерә килә.

*(Ерак Көнчыгышта туган бу эчкерсез, киң күңелле егет дүрт-биш ай эчендә мине үзе белән уйнарлык дәрәҗәгә җиткезде. Ә казармада аңардан да оста уйнаучы юк иде. Гәүдәң җиңел, теләк-елдамлыгың көчле булганда, теннис кебек четерекле уенның да асыл серләренә төшенеп була икән. Чагайга мең рәхмәтле булып, остаз итеп карасам да, уен барышында онытылып китеп, җиңәсе килү дәртеннән кыдрычланып тотынсам да Чагайны мин бер тапкыр да җиңә алмадым. Бу мавыктыргыч уенга хиреслек җене аңа тумыштан бирелгәндер шул...)*

Казарманың табигый туган үз закончалыклары бар. Хезмәт срогы азагына якынлашкан стариклар (дембельләр) кайчакта бераз һавалы-дорфа кылансалар да, аларга каршы сүз әйтү әдәпсезлек санала. Әгәр берәр «старик» исемем белән түгел, ә «татарин» дип кычкырып дәшсә, мин сискәнеп куям. Арт чүмечемә «та», «та» килеп, ике пуля бәреп кергән кебек тоела. Нинди куәтле, шаукымлы яңгыраш сыйган бу «Татар» дигән сүзгә?! Мәктәптән үк, аң-акыл буыны сыек чакта ук, балага дәһшәтле татар-монгол яулары турында зарарлы тарих укытып, курку-нәфрәт сеңдерүдән калган зәхмәтме бу? Нидән шулай сискәндерә мине үз милләтемнең исеме? Нигә үртәләм? Рус кешесе әйткәнгәме? Бу сүз яңгырашына ул бәлки үзенең соңга калган үчлеген, үпкә-рәнҗү, янау-кисәтү тойгысын сыйдырам, дип уйлыйдыр...

Бу хакта мин кем белән дә фикер алыша алмыйм. Чөнки казармада миннән кала бер татар да юк. Хәзер инде мин төш күргәндә дә русча сөйләшә башладым. Өнемдә әлегә үз телемдә уйланам. Кайчагында төртелеп калам, кайбер сүзләрне бик тирәннән, диңгез төбенә төшеп, кабырчык эченнән энҗе бөртеген каезлап алган кебек табам да, кадерен тел очында биетеп, тәмен искә төшерәм. Сизәм бит: туган телемдәге сүзләр кәрваны каядыр ераклаша бара, «теге дөнья теле»нә әверелеп бара түгелме?

Рота командиры булып капитан Исаков санала. Яһүд милләтеннән. Ул ЛИ-2 самолётында очучы. Урынбасары – капитан Латыйпов. Тумышы белән Казаннан. Ул без балачактан күреп үскән АН-2 самолётын иярли. Аның төп гамәле – парашютчыларны алып менеп, һава киңлегенә сибеп калдыру...

Болар атнага бер-ике тапкыр казармага сугылып, хәл-әхвәл белешеп чыгалар. Капитан Латыйповның телендә – Казан, Иделдәге оҗмах утраулары, тизрәк отставкага чыгып, туган шәһәренә кайтып китү, җәйләрен, шул утрауларда тел өстендә шаулап эри торган балык тотып яту хыялы тәмләнә...

Бервакыт ул Ленкомнатага кереп, минем эшләгәнне карап утырды да, икәүдән-икәү генә калудан файдаланыпмы, минем хәлләр турында сораша башлады. Бер мәртәбә дә татарча сөйләшкәнен ишетмәгән капитанга мин, сүз иярә сүз чыгып кына, кайчакта «татарин» дип дәшүләренә кимсенүемне әйттем. Һәр сүзенә басым ясап, батырып сөйләргә гадәтләнгән капитан, сулышын көрәп алып, урыныннан торып ук басты:

– Нишләп кимсенәсең?! Синең ни хакың бар бу олы исемнән кимсенергә?! Аны бит ата-бабаларыбыз, борынгы дәверләр аша, байрак итеп, бүгенгегә китереп җиткергән. Утлар-сулар кичеп. Шәһәрләр, илләр төзеп. Үлмәс дастаннар язып...

Әйе, бүтәннәрнең милләт исемен бик атамыйлар. Син әйтеп кара: «Үзбәк» диген, «Чукча» диген, «Чувашин», «Мукшы», диген! Яңгырыймы? Йомык авазлар, шулай бит! Ә менә «Татар» дигән сүзне кимендә биш-алты чакрымга ишетелерлек итеп кычкырып була. Бусын болай гына мисалга китерәм. Хикмәт тирәндә ята: «Татар» дигәндә, бөтен тән күзәнәкләре уянып, дәрт алып кала.

Яшисе килә башлый. Менә шуңа күрә безнең милләт исемен рәхәтләнеп кабатлыйлар. Һәрхәлдә, сине кимсетү өчен түгел, бу саллы сүздән көч алып калу өчен әйтәләр бит аны. Сәламәт рухлы булыйм дисәң – милләтең белән горурлан!

Әле генә ниндидер олы бер залда чыгыш ясаган сыман әрле-бирле йөргән капитан Латыйпов кинәт тынып калды. Сузаеп төшкән бөкре борын канаты астына кереп, юка ирене кысылган кебек булды. Бераздан ул, «ялгыш сүзләр әйтеп ташламадыммы», дигән икеләнү белән, миңа үтәли караш ташлады да:

– Мин заочно тарих-филология факультетын тәмамладым, – диде. – Отставкага чыгу белән укыту эшенә керешәчәкмен, Алла бирса.

Инде чыгып китәргә дип ишекне ачкач, кире япты да, миңа якын килеп, тавышына бик олы бер серлелек төсмере биреп:

– Дөресен әйткәндә... Һәркем татар булырга кызыга... Асылына кайтасы килә, – дип, кырт борылып, чыгып китте.

«Старик»лар каршында минем абруй үсеп китте бит әле. Исемем янәшәсенә әтинең дә исемен куеп дәшә башладылар. Берсенең дембель чемоданына, әллә каян күренеп торырлык итеп, тавыш тизлеге белән оча торган үзебезнең «ТУ» самолётының сурәтен төшереп биргән идем. Шуннан соң китте чират... Һәрберсе үзенең чемоданын тотып килә. Минем эчми-тартмый икәнемне белгәч, күңелне күреп, әҗергә ни бүләк итәргә белмичә аптырашта калдылар.

Тора-бара күнектем. Кайчакта «татарин» дип дәшсәләр дә, исем китми башлады. Хәзер инде ул сүз минем колакка «та-та» килеп кискен яңгыраган кебек тоелмый, казармада син бу кавемнән – бердәнбер, дигәнне искәртә шикелле. «То-то...»

Ленкомнатада эш бара. Старшина Осипенко нечкәләп тормый, стеналар язу-бизәк белән тулып торса, аңа шул җиткән. Капитан Пинчук исә бик вакчыл, метекчән. Ике-өч көнгә бер килеп, җентекләп карап китә.

Кирәк-ярак табу ягыннан Дубовой – алыштыргысыз. Гарнизонда аның белмәгән кешесе юк. Теләсә нинди ярыкка сыеп керә ала, оялу-кыенсыну кебек сыйфатларны ул күптән инде таптап узган.

Беркөнне Офицерлар йортына кинофильм карарга дип баргач, ул мине сәхнә артындагы әллә нинди лабиринт баскычлардан алып төшеп, завхоз бүлмәсенә алып керде. Анда ни генә юк: җиз тоткалы, «самавыр» аяклы өстәлләр, бизәк уемнарына йөгертелгән алтыны купшакланып беткән кәнәфиләр, вакыт тузаны җелегенә сеңгән бәллүр люстралар, көмеш канделябрлар дисеңме – бар да искергән, ямьшәйгән, калҗайган, гариплэнгән... әмма берсе дә узган дәверләр тәкәбберлеген җуймаган, шуңа күрә бу әшьялар кызгандырмый, кызыктыра гына.

Шул әйберләр борынгылыгыннан яралган шикелле, әллә каян гына йомры гәүдәле, чама белән илле яшьләрдәге ир кеше пәйда булды.

– Бонифатий, – дип таныштырды Володя Дубовой. – Дөнья бәясе кеше, кирәк булса, елан мөгезен дә табып бирә.

– Арттырасың инде, – дип Бонифатий, сул күзен кыса төшеп, мут елмайды. Безгә, эш өчен, куе чия төсендәге бәрхет кәгазь кирәк иде.

Күп нәрсәне кулыннан үткәргән Бонифатий сирәк була торган нәрсә сорауга күнегеп беткән ахрысы, маңгаен җыерып, йөнтәс кашларын бер-берсе белән сөзештереп, уйланып торды да:

– Эзләп карарга була, – диде. – Үзебездә булмаса, Минскидан, анда юк икән, Мәскәүдән, анда да дымы корыган булса, Парижның үзеннән кайтартырбыз!

Беркөнне Володя Дубовой көне буена каядыр олагып торды, эңгер төшкәндә генә ашыгып кайтып керде. Култыгына киндер капчык кыстырган.

– Күгәрчен ауларга менәбез. Түбә астында кунаклыйлар алар. Караңгыда күрмиләр. Йокыга киткән җирләреннән капчыкка җыеп кына алабыз, – дип ул мине ашыктыра башлады. Минем аптырап калуымны күреп, иңемнән селкетеп алды:

– Бонифатийга кирәк. Ул сорады, – диде.

Бу исемнең магиясе аңымны томалады. Безнең ясап бетерәсе стенд язмышы Бонифатийның тизрәк бәрхет кәгазь табып бирүенә бәйләнгән бит.

Тимер баскычтан мендек чормага. Миңа таныш, авыр тәэсир калдырган урын инде бу. Кая карама, анда – сталагмитлар булып, күгәрчен тизәге очлаеп өелгән. Әчкелтем-тынчу ис. Мин капчыкның авызын тотып торам. Дубовой йокылы күгәрченнәрне җай гына эләктереп килеп, капчыкка шудыра тора.

Чирканам, ул якка карамаска тырышам.

– Нишлибез без, Володя, болай ярамый бит, – дим. Ә ул:

– Бонифатийның күңелен күрергә кирәк, аңлыйсыңмы?! – дип өнәмичә ысылдый.

– Ничәләп күгәрчен кирәк соң аңа?

– Бер капчык чүмәләмә! – дип, Дубовой кыраклап көлә.

– Ул кадәрне ничек күтәрәсең ди?

– Кайчакта бик тә беркатлы син, ә!.. Татарлар хәйләкәр халык дигән булалар тагын. Үз арагызда гына хәйләкәрдер сез... Борчылма, егерме биш-утыз күгәрчен җитә аңа.

Чормадан төшеп тышка чыккач, һаваның сафлыгыннан тамак төпләре кытыкланып куйды. Урам утлары чагылган юеш җир өсте шәмәхә төскә кереп җемелди.

Дубовой миңа кичке алтыдагы сеанска билет калдырды да, авырайган капчыкны җирдән сөйрәп диярлек, волейбол мәйданчыгы янында торган УАЗикка таба китеп барды.

Мин казармага кереп тормадым. Ял бирдем үземә. Кинога кадәрге ике сәгатьне ничек тә ашыктырырга кирәк. Кибеткә барып, кесә тутырып, билле прәннек алдым. Шуны күши-күши офицерлар яши торган дүрт-биш катлы йортлар арасыннан, бала-чагалар уйнаганны карап уздым. Монда чыр-чу, кызыктыргыч тормыш кайный.

Офицерлар йортына кино башланыр алдыннан гына барып кердем. «Хиросима һәм Нагасаки» дигән фильм буласы икән. Туйкәдә сигезенче класста укыган чакта бу киноны караган көнем бик ачык хәтердә – 12 апрель иде ул. Юрий Гагарин космоска очкан көн. Әллә нинди очынулы хисләрдән күңел иләсләнгән иде. Экранда барган коточкыч фаҗигане аңлап, кабул итеп тә бетермәдек шикелле. Вакыйга безгә кагылмый, бик еракта барган әкият шикелле генә, аңыбызга тирән уелмыйча үтеп китте бугай ул чакта. Кинодан соң без, бер төркем малай-кызлар, сулы-шулпалы карны лычтырдатып, үз авылыбызга җәяү кайттык. Телләрдә гел Гагарин булды.

Ә экрандагы тетрәндергеч күренешләр, өзек-өзек булып, еллар аша искә төшкәләп, акылыбыз белән бергә олыгая, гыйбрәтлерәк була бардылар.

Менә бүген, тәэсирләрне яңартып, бу киноны тагын йөрәгем аша үткәрдем. Черчилль хөрмәтенә «Юанкай» дип аталган атом бомбасының япон халкының баш түбәсендә ярылганын күрдем.

Атом-төш шартлатылганда кабынган искиткеч матур төсләр байлыгы, бернинди рәссам хыялы тудыра алмаган гигант балкыш булып, күк йөзен ялмап ала, дип сокланучылар да бар бит әле бу дөньяда...

Казармага кайтып кереп, шинельне салып элгәндә сизәм – ниндидер тәмле ризык исе борынны ярып керде. Хуҗалык бүлмәсенең ишеге ачык, анда гөр килеп сөйләшәләр. Дубовой тавышы, аның өзек-өзек сүзләре ишетелә: «...Если бы он знал, низачто бы не согласился...» Мин килеп кергәч, ул:

– Вот и он сам! – дип шатланганын белдерде. – Ты когда-нибудь рябчиков ел, давай, пробуй, отменно получилось...

Күрәм, өстәлдә, калька кәгазе өстенә карасу төстәге ит кисәкләре өелгән. Нечкә генә бот сөякләре тырпаешкан кош түшкәләре. Идәндә корымлы чиләк тора. Рябчик... рябчик... дип эчемнән кабатлыйм. Рябчик боҗыр була түгелме соң? Каян килеп... Ул арада кемдер шигырь юлларын китерә: «Еш ананасы, рябчиков жуй, день твой последний приходит, буржуй!» – Маяковский әйткән, егетләр!

Коридорга эленгән Ленин портреты артына яшерелгән грелка өстәлдә урын ала. Бүлкелдәп торган грелка эчендә белорус самогоны – чемер... Менә трапеза башлана. Авызлар чапылдый, тешләр эшкә керешә, сөякләр чыкырдап уала. Дубовой кунакчыл тавыш белән күпләрне чакырса да, нигәдер, ашкынып керүче сирәк, кыргый кош ите тансыклаганнар биш-алтыдан артмас. Мин һаман әле аңга килә алмыйча басып торам. Каян бу? Нәрсә бу?! Дубовой миңа ит кисәге сона. Шул мәлдә түбә астындагы күгәрчен тизәге исе сирпелеп киткәндәй булды. Руслар әйтмешли: слышу запах... Күңелем актарылып чыкты. Үз-үземне белештермичә Дубовойның иңennән умырып тотып, селкетә башладым:

– Нишләдең син?! Ничек кулың барды?!

– А что такого! Это же деликатес... Вы же едите конину...

– Гөнаһсыз кошларны үтерергә ничек кулың барды?! – дип кычкырам, ә Дубовой тасраеп карап тора. Аннары ул да кызып китте:

– Вот татарин, а! Странный ты человек. Ты мне не указ, в своей Татарии будешь указывать!

«Ду» килеп кычкырышабыз моның белән. Ул арада Адил каударланып килеп керде. Кергән уңайга: «Национальность задеваешь!» – дип, Дубовойның изүеннән тотып, гәүдәсен сыңар кулына күтәрде. Дубовойның аяклары идәнгә тияр-тимәс, сәгать теле кебек селкенеп тора.

– Ты что, Одиль, а может я сам – тоже татарин. У нас в Воронеже чернявых полно. Я больше похож на татарина, чем он, – дип, ул Адилның көчле кул тискиендә буыла-буыла акланырга тотынды.

– Смотри мне! – дип, Адил ефрейторның күн итекләре салына башлаган аякларын идәнгә төшереп бастырды да: – Помиритесь! – дип бүлмәдән чыгып китте.

Бонифатийга дип мине алдап җыйган күгәрченнәрне Дубовой капчыгы белән аэродромга алып барган. Шунда үзебезнең механиклар белән пешекләп, чистартып, чиләктә пешергәннәр икән.

Мин тынычлана алмыйча төне буе борсаланып чыктым. Минем дә катышым бар бит монда, ничек юармын бу гөнаһымны? Тормышта болай тиз ышанучан-беркатлы булып яшәү ярамый бит инде. Белмәдем, дип үз-үземне туктаусыз битәрләп аклану гына җиңеләйтә диме гөнаһның авырлыгын!

Төшкә дә шул кошлар керде. Имеш, Мәскәү Кремлендә яшәүче күгәрчен килеп төшкән икән, дим. Гөнҗәлә бүрекле, эре гәүдәле күгәрчен, гел кукраеп, йоннарын кабартып, ысылдап тора. Күзләрендә кызыл очкыннар чатнап-чатнап китә. «Кош каргышы төшсә нишләрсең, ничек яшәрсең?» – ди. «Мин белмәдем, гаебем шул чаклы гына, белмичә эшләдем, дип танам, бәргәләнәм икән.

«Акланма!» – ди Кремльнең баш күгәрчене...

Дубовойга бүтән бер дә эндәшмәм дигән идем, икенче көнне Бонифатийдан бәрхет кәгазь табып кайтты да... күңел йомшады инде. Димәк, Ленкомнатадагы эшебезгә соңгы ноктаны куяр көн җитте, моннан соң инде без Дубовой белән сирәк очрашачакбыз.

Монда эш беткәч, мине Офицерлар йортына, китапханәгә берничә көнгә эшкә җибәрделәр. Офицерларга гына бирелә торган китап байлыгын тәртипкә китерүдә ярдәм кирәк икән. Мин монда гаҗәеп бай китаплар дөньясына чумдым. Буш вакыт булдымы – китапка кадалам. Шишковның «Хәсрәт дәрьясы» дигән романын татарча укыганым бар иде, иң беренче итеп шуның русчасын укып чыктым.

Тетрәнеп укыдым да... Руста бу иң көчле роман, моңа кадәр булмаган, моннан соң да булмаячак, дигән фикергә килдем.

## Штаб

Озак көттергән Белорус кышы җылымса аклыгы белән тын гына иңде. Көн дә иртән эре-эре кар ява. Ява, диюең килешеп тә бетми шикелле. Кар таҗлары, сәмави бизәген сакларга теләгәндәй, талгын-тыйнак кына, үз бәясен белеп кенә, чирканчык алып, җиргә куна да тоташ аклыкка әверелә.

Мурыган көзге моңсулыктан сыгылган күңелем, саф аклык хозурыннан кинәнеп, канатларын турайта башлады. Юаныч алып килгән шундый җылымса-юаш кыш фасылы да булыр икән.

Мул кар явып торган шундый бер иртәдә мине дивизия штабына чакырттылар. Нигә, дигән сорау куймыйча гына, йомшак кар түшәлгән таныш аллеядан барам.

Башыңны күтәр, тураеп кара дөньяга, бәргәләнмә, күңел! Иншалла, бар да әйбәткә булыр... Санама айларны, көннәрне санап, йөрәгеңә сагыш бөҗралары урама, килер ул азатлык кыңгыравын яңгыратыр көн, сиңа да килер, салып ыргытырсың хәрби киемнәреңне. Хәзергә, яшь карны таптап килгән күн итегеңне ишек катында кагып, штаб бинасына килеп керәсең.

Өченче каттагы кабинетта, сине дивизиянең комсомол вожагы – капитан Пинчук һәм инструктор старшина Лагунь көтә. Икесе дә кырыслык битлеге кимичә, елмаеп сөйләшә торган ачык йөзлеләр.

Пинчук гадәттән тыш куе, кара, мул чәчен вакыт-вакыт кулы белән маңгаеннан көрәп алып сөйләшә. Аңа егерме тугыз яшьләр булыр. Старшина Лагунь өч ел хезмәт иткәннән соң контракт буенча калган. Курач-юка гәүдәле старшинаның сүз җилеменнән үк милләте белорус икәне сизелеп тора. Кайчакта онытылыпмы, «тряпка» дигәнне «трапка» дип, «наряд» дигәнне «нарад» дип белорусчалатып җибәрә.

Хәрби кырыслык сизелеп тормаган җирдә минем күңел таралып китә, үз итеп, эчкерсез сөйләшә башлыйм.

– Моннан соң эшең шушы кабинетта булыр. Ике ай буена. Менә өстәл сиңа, урындык, шкаф. Калган кирәк-яракларны табарбыз, – диде капитан.

Болар миңа алдагы айларда гамәлгә ашырылачак олы бер сернең пәрдә читен генә ачып күрсәттеләр. Март аенда ил буенча комсомол билетларын алыштыру кампаниясе башланачак икән. Ул бик җитди, җаваплы эшкә мине дә тартмакчылар. Миннән кала тагын матур яза белгән өч егет кирәк булачак ди. Төп эш урыны – офицерлар йортыннан бер бүлмә сайланган, хәзергә анда ремонт-буяу эшләре бара имеш. Хәзергә минем төп шөгылем – шул бүлмәне бизәү өчен комсомол эшчәнлегенә караган плакатлар ясау...

Менә бит, беренче килеп төшкән көнне изелеп, мескен булып шушы штаб коридорында утырган, монда бәхетле кешеләр генә эшли торгандыр дип, кызыгып карап торган идем. Хәзер язмыш мине шушы дивизия штабының өченче каттагы кабинетына кертеп утыртты. Димәк, руслар әйтмешли: «глаз положил».

Миңа эш башлап җибәрү өчен ни-нәрсә кирәген бөртекләп кәгазьгә төшерергә куштылар. Штабның хуҗалык эшләрен башкаручы, матди байлыкка хуҗа кеше – майор Железняк икән. Юантык гәүдәле, фуражкасын маңгае өстеннән арткарак шудырып үзенчә киеп йөргән бу майор гаҗәеп юмарт булып чыкты. Аның подвалдагы склады дөньяның бөтен байлыгын сыйдыргандыр кебек иде. Майор Железняк «юк» дигән сүзне белми, ни сорасаң, шуны бар итеп алдыңа куя. Булмаса инде, «табарбыз» дип, алдагы көнгә калдыра, һәм шул әйберне табып сине канәгатьләндерүдән үзенә бер ләззәт кичерә иде сыман. Гадәттә, матди байлыкка кулы тигәннәргә мондый киң күңеллелек хас түгел.

Мин майор Железняктан рулоны белән яхшы ватман кәгазе, акварель һәм гуашь буяулар, төрле озынлыктагы линейка, лекало, буяу карандашлары кебек һәр кирәк-яракны бөртекләп җыеп, кабинетка алып мендем.

Менә хәзер эшкә керешергә була: комсомолның биш ордены, ил белән кичкән биш эпохасы турында гомумиләштереп, заманча стильдә ясалачак плакатларның сурәте инде минем уемда әзер, ачык шәйләнә.

Эш сәгате иртәнге тугызда башлана, көндезге уникедән икегә чаклы төшке ашка вакыт бирелә, аннары сәгать алтыга чаклы сузыла. Штабтагы бөтен бүлекләр дә шушы кагыйдәгә буйсына икән.

Кабинетта икәү генә калган чакларда старшина Лагунь мине сөйләндерергә ярата. Юк кына сүздән дә елмаеп, рәхәтләнеп көлгән булып, шундый бирелеп, гаҗәпкә калган булып тыңлый – беркатлы сабый диярсең. Шундый да бирелеп тыңлаучы булганда мин очынып китәм, сүзләр бер-берсен тартып китереп, агыла башлый.

Кай төннәрне мин казармада, одеял белән бөркәнеп кенә «Америка тавышы»н тыңлыйм. Күршем сержант Шульгинның «спидола» дигән бик шәп, кыйммәтле радиоалгычы бар. Үзе тыңлап туйган чакларда ул аны миңа биреп тора. Бер көнне, старшина Лагунь белән гәпләшеп утырганда шул радиодан ишеткән бер вакыйганы әйтеп ташладым бит. Безнең илдә бер матбугат органында да басылып чыкмаганын мин белгәнмени! Старшина Лагунь, самими елмаеп утырган җиреннән кинәт калкынып куйды:

– Син моны каян ишеттең?

Мин каушап калдым. Ул дәвердә әле телевизордан яңалыклар карау яисә газеталардан көтелмәгән хәбәрләр уку дигән төшенчә бөтенләй юк иде. Димәк, мин алгарак киткәнмен. Совет кешесе яңалыкны искергәч кенә белергә тиеш. Каушавымны сиздермәскә тырышам. Мондый чакта бик гади һәм мәгънәсез уйдырма кулайрак.

– Кичә офицерлар йортына кинога килгән идек. Шунда граждански киенгән ике ир затының шул хакта сөйләшкәнен ишеттем, – дидем.

Старшина Лагунь ач яңагын сыпырып куйды, нидер әйтергә җыенган иде, кабинетка, гадәттәгечә каударланып, капитан Пинчук кайтып керде.

Капитанның кәефе шәп икәнен чамалап, старшина Лагунь Азнакайда Никита Хрущёвны ничек каршы алганыбызны миннән тагын бер тапкыр сөйләтте. Бая гына сөйләгәнне сүзгә-сүз кабатларга яратмаганлыктан, мин, әлбәттә, хәтер капчыгын киңрәк ачып, яңа төсмерләр кушып сөйләргә

тырыштым. Старшина Лагунь беренче тапкыр ишеткәндәй рәхәт чигеп, күлү өянәгән тыймыйча тыңлады. Капитан Пинчук исә, киләчәктә олырак урынга, партия эшенә сикерәсен онытмыйча, күлүнең чамасын тартып кына утырды. Кешене тыңлауга караганда үзе сөйләргә яратучан капитанга бу юлы кайбер сүз кыйпылчыклары эләгеп калган бит әле.

– Транспарант өстеннән сыер күтүе үтеп чыкканы чынлап та булган хәлме, арттырмыйсызмы? – дип соравы моңа дәлил иде.

– Булмаганны булган дип сөйли белү сәләте юк шул миндә, – дигәч, старшина Лагунь:

– Ай-һай, – дип башын чайкап куйды.

– Күргәнне сәнгатьле сөйли белү һәркемгә бирелмәгән шул, – диде капитан.

Фикерен аламаландырып, чүбекләп, анык кына әйтеп бирә белмичә, азаплый торган старшина Лагуньга киная булды бугай бу. Әмма ул моны сизмәмешкә салышты.

– Син Хрущёвка бәяне дөрес бирдең, ә менә Брежнев хакында ни уйлыйсың?

Уемны күңелдә талкып, искәртеп тормыйча, капылт кына әйтеп бирә торган беркатлы булсам да, бу юлы туры бәргән сорау мине чиркандырган кебек булды. Кечкенә бер белорус авылыннан чыгып, күтүче чыбыркысын портупеяга алыштырган бу старшина минем баш очында пәрәвез ятьмәсе үрә түгелме соң? Әмма сорау бирелгән, аңа җавапсыз калу да егетлек түгел.

– Самолёт трабыннан төшүе әллә каян күренеп тора. Калын кашлы, чибәр, мәһабәт. Ил башлыгы шундый булырга тиеш!

Үзенең үтә дә ябык-курач гәүдәсен исенә төшергәндәй, старшина Лагунь кызарып куйды.

Гаҗәп бит, бер уйласаң: җәмгыятьтә кешене кимсетү, кыюлыгын бетереп, күндәм мәхлукка әйләндерү өчен нинди генә чикләүләр, шартлы кануннар уйлап табылмаган. Моңа әкрен генә күнегә барасың, уеңа, телеңә богау салуны табигый хәл кебек аклый башлыйсың. Югыйсә бит, әйтергә кыҗрап та әйтелми калган фикерең күңелеңне кугәртә бара, маңгаеңа йончу сыр булып сызыла. Тоталитар ил-дәүләттә яшәүчеләр ни өчен кырыс-сытык чырайлы, мыжык холыклы була? Чөнки уеңда кабынган фикерне дөньяга чыгара алмыйсың; бары да эчкә җыелып бара, тибенеп, тырнап һәрдаим сине бимазалап тора, тәнеңне каралта, җаныңны сызлата, менә шул тулгаклап кайнаган эчке халәттән чырай киеренке ямьшәя, күз карашы тыныч нурын җуеп усаллана.

Армиядә төрле штабларда политбүлектә эшләүчеләр аерым бер катлау булып яши. Болар «җылы» урында. Чырайга да яшь күренәләр. Киемнәре дә пөхтә. Болар җайлашып яшәүнең асылына тиз төшенеп алалар. «Коммунизм», «ленинизм» кебек олы сүзләрне, марксистлардан күчереп алган цитаталарны бернинди хиссез генә кулланып, телне күңелгә тоташтырмыйча гына сөйләү осталыгына ирешкәннәр. Боларга хәрби дәрәҗә бирелү дә үз вакытында тәгәрәп килә. Әйтик, тавыш тизлегендә очучы самолётны иярләүче, җирдән аерылу, җиргә кайту кебек хәвефле мизгелләрне күпме кичергән экипаж командиры әле кырык биш-илле яшьләрендә дә өлкән лейтенант кына булырга мөмкин. Ә аның яшьтәше, политработник булып штабта утыручы курсташы җилкәсенә бу вакытта инде кимендә подполковник погоны менеп кунаклый.

Сугышны кичкән офицерлардан ишеткәнем бар: маршал Жуков политработникларны бер дә яратмаган диләр. Маршалның яратмавы, әзсез каламыни, әлбәттә, шактый язмышларны ботарлап ыргыткандыр.

Айдан артык бер кабинетта эшләү дәверендә дивизиянең комсомол

вожаклары – капитан Пинчук һәм старшина Лагуньга мин ияләшеп өлгердем. Әйбәт кешеләр сез, дип күзләренә карап әйтә алмасам да, аларга булган якынлык хисен эчтән яшерә алмый идем. Кайчакларда мин буйсынырга тиешле гап-гади солдат икәнемне онытып җибәрәм, артык үз итеп, шаяртып та алгалыйм. Менә бер күренеш: көнгә чыксаң, кабинет эче кайнап тора – керәләр, чыгалар, бертуктаусыз ачылып-ябылып торуга ишек күгәне чыдасын гына. Телефоннар кызышып бетә. Каядыр телефонограммалар китә тора. Ашыгу, кабалану, болгавырлык. Искә төшерәм: Азнакайда комсомол комитетына кергәч тә шундый хәлгә юлыга идем бит. Күрәсең, бөтен илдә шулайдыр, тынгысыз яшьлек ритмы үз-үзен котыртучы җитезлеккә корылган. Әйләнмәле тәгәрмәч эчендәге тиен күз алдына килә: коточкыч тизлек белән йөгерә тиен, ә үзе бер урында тора.

– Менә хәзер комсомол оешмаларын тораташ катырып куй – илдә берни үзгәрмәячәк, беркем сизмәячәк, – дип көләм дә, старшина Лагунь: «Кемне алдык без эшкә», дип, капитанга ым кагып елмая.

Капитан Пинчук Берлинга берничә көнлек командировкада булып кайтканнан соң, фотоларын күрсәтте. Рейхстаг бинасын тетеп, җимереп бетергәннәрдер дип уйлый идем, исән калган икән бит, яраларын ямап, кабаттан күтәргән эшчән алман халкы бу мәһабәт бинаны.

– Җиңү байрагын беркеткән гөмбәз шушымы? – дип сорыйм капитаннан. Капитанның бармагы төп гөмбәз турыннан икеләнебрәк кырыйга шуыша:

– Шушы булырга тиеш...

Старшина Лагунь байрак элүче геройлар Егоров белән Кантария хакында сүз кузгата. Шул уңайдан мин вакыт-вакыт хәтеремне тырнап алгалаган сорауны бирмичә кала алмыйм. Мәктәптә укыганда (кайсы класста чакта икәнен тәгаен генә әйтә дә алмыйм) җиңү байрагын элүчеләр өчәү булган дип аңыма кереп калган иде. Легендага кергән өч кешенең берсе ни сәбәпле тын гына «югалды». Ни өчен? Кем иде ул?

Минем бу соравым һавада эленеп калды. Капитан телефон номерын җыярга тотынды, старшина Лагунь, ык-мык килеп, сүз җебен ялгый алмады.

Әллә соң мин ялгыш шулай өчәү дип хәтердә калдырганмынмы? Бу сорауны кузгату мәгънәсезлекме? Ни өчен? Ни сәбәптән? Кайчан? Җавап табу минем өчен мөһимме? Бәлки бу – ялган легендалар тудыруга корылган җәмгыятьтә карусыз алданасы килмәү үҗәтлеге, гөнаһсыз үсмерчак хәтерен барлап карау, гадел дөреслеккә төшенәсе килүдәндер...

Озакламый мин, ниһаять, бу сорауга җавап таба алдым.

Нишлисең бит, холык-фигылемә тумыштан шундый туфрак салынгандыр инде: кирәк чакта эчке горурлыгымны тыеп кала алмыйм, хаксыз икәнемне сизгәндә дә үз сүземне бирми черәшәм, җайсыз сораулар куеп, җавап бирергә тиешлене уңайсыз хәлгә дә калдыргалыйм.

«Кәҗә рәхмәт әйтә, сакалын селкетә», дигән кебек, «әйе» дип, күндәм баш кагып торучыларны кызыгып кызганам. Андыйлар дөнья йонын уңайга сыпырып рәхәт яши. Моңа мин һәрдаим төшенә барам.

Бүген мин дивизия штабы белән хушлашам. Плакатлар, төрле кирәк-яраклар әзерләнеп бетте. Хәзер инде Офицерлар йортындагы кабинетка күчәргә дә була. Ачкыч үз кулымда.

Старшина Лагунь әйберләрне күтәрешеп, озата барды. Без биш кеше комсомол билетлары алыштыру буенча берничә ай буена бергә эшләячәкбез икән.

Икенче көнне, калдык-постык әйберләрне алырга дип, Пинчук кабинетына кергән идем, минем өстәл артында таза гәүдәле, мул чырайлы бер сержант утыра.

– Таныш булыгыз, – диде старшина Лагунь, – безнең яңа инструктор Лебеденко.

– Без кул бирештек.

Лагунь мине озата чыккач, болай диде.

– Без рядовой состав арасыннан инструктор итеп алырга синең кандидатурага тукталган идек. Әйбәт егет син, эчми-тартмыйсың. Тик... капитан белән икәү сине ике айга якын сынадык та... политик яктан өлгереп җитмәгән әле, дигән нәтиҗәгә килдек. Турысын әйткәнгә үпкәләмә инде син.

Минем көләсе килде. Нигә үпкәлим ди. Минем сүз запасы дөресне сөйләргә дә җитенкерәми бит әле. Ә инде «бар»ны – «юк», «юк»ны – «бар» дип сафсата сату өчен әллә күпме җансыз сүз байлыгы кирәк. Җитмәсә артистлык, кыюлык, ояла белмәү кебек мөһим сыйфатлар да мине читтән генә урап узган.

– Мондый эшкә татарны кую ярамас, – дигәнсездер әле, – дип, старшина Лагуньны юри котырткан булам. Ул кызып китә:

– Син нәрсә?! Муса Җәлил – политрук! Муса Җәлил – татар, Муса Җәлил илдә күрелмәгән батырлык кылган түгелмени!

– Шаярттым гына дип, старшина Лагуньны тынычландырам. – Рәхмәт, миңа андый камыт кидермәгән өчен, – дим.

– Старшина званиесе һәм ай саен егерме биш тәңкә акча эчеңне тишмәс иде дә бит...

– Егерме биш сум диюегез – заманчиво.

– Хәзер рядовой солдатка айга күпме түләнә?

– Ике сум җитмеш ике тиен. Энә белән җеп алырга җитә, комсомол взносы түләгәннән соң...

## Кабинет

Офицерлар йорты бик зур бинаны биләп тора. Саллы ишекләрен ачып килеп керүгә, син казарма шартларында яшәүче гади солдат икәнеңне онытасың. Монда бөтенләй бүтән тормыш кайный. Әле уңнан, әле сулдан, әле астан, әле өстән музыка тавышлары яңгырап, бер-берсе белән кисешеп, серле тибрәнеш хасил итә. Яныңнан бөтерелмә итәкле биюче кызлар чыркылдашып уза, затлы киенгән ханымнар хушбуй исе сирпелдереп, горур гына үтеп китә.

Монда өч йөз илле кешелек кино-концерт залы, китапханә, спорт залы, төрле түгәрәкләр өчен кабинетлар, тәмле шоколад, кофе исләре таратып буфет эшләп тора.

Коридорда безгә тәгаенләнгән кабинет ишеге янына кара төстәге фортепиано куелган. Кап-кара күзле, кара чәчле, грузинкага охшаган юантык гәүдәле ханым шул уен коралында алты-җиде яшьлек кызчыкны клавишларга басарга өйрәтә. Вакыт-вакыт кулына сугып куя. Эре күз яшьләре чыккан балага иелеп, елама, дип ысылдый.

Бер-берсенә охшаган сыман мондый «грузинкалар» Офицерлар йортында шактый күренә. Баксаң, алар грузинка түгел, яһүд милләтеннән икән.

Март башында кабинетыбыз җиһазланып бетте: тәрәзәгә пәрдә куелды, стеналар бизәлде, өстәлләр тезелде.

Дивизия штабында, политбүлектә эшләүче ханым Антонина Ивановна өч-

дүрт айга безнең җитәкчебез булачак. Аңа утыз биш яшьләр чамасы. Кырыслык битлеге кимәгән, һәрчак елмаеп, ягымлы сөйләшә.

Без дигәнем – дүрт егет: украин акценты белән йомшак итеп, сузыбрак сөйләшүче Полтава егете – Валентин, Харьковтан – Владислав, урманда ракеталар сагында торган җиреннән монда, шәһәргә чакыртып алынуына сөенеп бетә алмаган, кыска буйлы, Вологда егете – ефрейтор Михаил һәм мин.

Эшкә керешер алдыннан безне дивизия штабына, политбүлек начальнигы полковник Курганский кабинетына җыйдылар.

Комсомол билетлары алмаштыру бик мөһим, илкүләм кампания икән. Бу почётлы эшкә меңләгән солдат арасыннан сайланганнан сайланганнары гына алына, шуңа күрә үз-үзеңне тотышыңда, сөйләшү алып барганда, кием-рәвешеңдә һәркемгә үрнәк булырга тиешсең. Шушы дәвер эчендә без фәкать парад мундирында гына йөрергә тиеш булабыз. Дүртебез дә меңнәрчә билет тутырып, бер дә хата җибәрмәсәк, ВЛКСМ Үзәк комитетының Мактау грамотасы һәм алтын сәгать белән бүләкләнүебез ихтимал. Бозу очрагы булса, билет Мәскәүгә, Үзәк комитетка җибәрелә һәм ул билет номеры гамәлдән чыгарыла.

Полковник Курганский басым ясап, өстән торып сөйләми, ә киңәшләшкән кебек, йомшак итеп, үз тиңе күреп мөрәҗәгать итә иде сыман. Кыяфәте татарга охшаган; ирен читенә сизелер-сизелмәс елмаю поскан, елдам-нурлы карашы үзенә тартып тора.

Бу сөйләшүдән соң капитан Пинчук безне Офицерлар йортындагы кабинетка алып китте. Кабат әйләнеп кайта-кайта, бик бөртекләп, алда торган эшнең җитдилеген шәрехләп бирде.

Капитан безгә уңышлар теләп чыгып киткәч, Антонина Ивановна кулларын уып, ишекле-түрле йөреп алды:

– И-их, егетләр! Карап торам да... Менә дигән егетләр бит сез! Мин сезгә ышанам, менә дигән итеп башкарып чыгарбыз, Алла бирсә, – дип ул безне буфетка, чәй белән сыйларга дип, алып китте.

«На Бога надейся, но сам не плошай», дигән рус мажигы. Әзерлек барышында мин күп тапкырлар һәр яктан уйлап карадым. Өр-яңа билетның шыкырдап торган битенә корыч каләм очын кара тушька манып, таныш түгел кешенең исеме-фамилиясе, атасының исеме языла. Хәрефләрең матур итеп тезелеп барырга тиеш. Бу киеренке мизгелдә каушау, дулкынлану хисе тәнгә таралган кан тибешеннән каләм очына төшә. Шундый киеренкелектә уннарча, йөзләрчә билет тутырганда хата җибәрми буламы?.. Мин моңа һич кенә дә ышана алмыйм. Шуңа күрә, барысын уйлап, алдан хәстәрен күрдем. Беркем юк чагында, ашыкмыйча, иркенләп, үземнең осталыгымны сынап карадым. Әмма бу хакта берәү дә алдан белергә тиеш түгел иде...

Беренче эш көнен Антонина Ивановна коридорда ишеккә терәлеп диярлек торган фортепианоны «Безгә тынычлык кирәк» дип, икенче төшкә күчертүдән башлады. Ул безнең әнкә кебек, аның күзенә генә карап торабыз. Аның сейфында мөһер, яңа билетлар, документлар. Валентин, Владислав һәм мин каллиграфиянең камил югарылыгына ирешкән осталык белән билетлар тутырырга тиеш булабыз. Ефрейтор Михаилга исә фотоларны төгәл үлчәмдә кисеп, билетка ябыштыру кебек четерекле эш йөкләнде.

Беренче көнне без бик сакланып, нык тырышып, шактый дулкынланып бишәр билетны хәл иттек. Эш тәртибе болайрак иде: парад киеменнән солдат кереп каршыңа утыра. Син аның учёт карточкасындагы һәр пунктны укып,

үзеннән сорый барып, дөреслеген раслатасың. Аннары иске билетындагы исем-фамилиясенең дөрес язылганмы-юкмы икәнлеген тикшерәсең. Шуннан соң гына хәлиткеч эш – «акка күчерү» башкарыла.

– Иртәгә шушы ук полктан тагын унбиш солдат киләчәк. Аннары кичен, яңа билетларны тантаналы рәвештә генерал үзе тапшырачак, – ди Антонина Ивановна.

Ләкин, икенче көнне яңа күлмәк киеп, кичке тантанага әзерләнеп килгән Антонина Ивановнаны бер мизгелдә аяктан ега яздык. Бар да әйбәт бара иде, югыйсә, ару гына эшләп утырган җирдән Валентин кычкырып җибәрде:

– Убейте меня, ребята! Убейте! Всё пропало...

Валентинның бөтенебезне сискәндергән бу гасабилы кычкыруы төбендә ни ятканын чамаласак та, бер исемне язганда ике хәрефтә үк хата җибәрер дип көтмәгән идек. Антонина Ивановна агарып чыкты, тиз генә сумкасыннан валидол төймәсе алып капты, башын артка ташлап, күзләрен йомып хәтсез утырды. Бераздан, карлыккан тавыш белән:

– Нишлибез инде хәзер, генерал үзе тапшырырга тиеш иде бит?.. – дип, урыныннан торды. Һаман үз-үзен битәрләп утырган Валентинга карап:

– Акланмагыз, хата җибәрү берәүдән дә ерак йөрми, – диде.

Мин билетны алып, кайсы хәрефне кыркып, ничегрәк төзәтергә икәнен чамаладым да:

– Рөхсәт итсәгез, Антонина Ивановна, төзәтеп карыйм, – дидем.

– Юк, юк! – дип, ул ишетергә дә теләмәде. Билет аннулируется. Сообщим в ЦК, – дип коридорга чыгып китте. Без, егетләр, бер сүзгә килеп, Антонина Ивановнаны күндереп карарга булдык.

Бераздан ул керде дә, безнең сүз берләшкәнне сизгәндәй:

– Барыбер беткән билет инде, маташып карагыз, – дип, өметсез кул селкеде.

Мин алдан әзерләгән әйберләремне өстәлгә чыгарып салдым.

– Шылт иткән тавыш та, бер хәрәкәт тә булмасын, – дип, барысына да буфетка чәй эчәргә баруларын үтендем.

Менә хәзер сыналу мизгеле килде сиңа, егетем. Йә бар син, йә – юк. Бу дөньяның син генә чиртеп көй чыгара алырдай нечкә кылы булырга тиеш бит инде... Тәвәккәллә!

Кул астымда – егерме дүрт төстәге карандаш бәйләме. Чын корычтан эшләнгән, бер дә тотылмаган кыйммәтле лезвие салынган кап. Үткен пәке һәм мамык түтәрәме. Менә шушы әйберләр белән четерекле операциягә тотынырга була. Ничә тапкырлар үземне сынап, эшләп карасам да, барыбер каушата. Бу мизгелдә мин үземне бик нечкә операциягә алынган нейрохирург итеп тоям. Хикмәт шунда: күп документлар кебек үк, комсомол билеты да яхшы, тыгыз кәгазьдән бизәк-орнамент сеңдереп эшләнгән. Гади күзгә аның бизәкләре күренми, ә кызгылт -көрән төсе генә шәйләнә. Иң хәтәр мизгел – лезвиене ике бармак арасында бөгеп китереп, хата киткән хәреф турыннан кәгазьнең бик юка өрфия катлавын кыеп алу. (Тушь кәгазьнең «майлы» катламында гына, эчкә сеңмәгән була.) Болай иткәндә кәгазь чүбекләнми, шулай да, тырнак йөзе белән «яралы урынны» ышкып, шомартып аласың. Кәгазьнең кыеп алынган җире агарып кала. (Бу очракта сары, кызыл, көрән, куе сары төстәге карандаш сөрмәләрен үткен пәке белән кырып, порошокка әйләндереп, күпме микъдарда, ничек кушарга икәнен мин алдан ук тәҗрибә ясап, чамалап әзерләп куйган идем.) Менә хәзер иң мөһиме – дару-порошокны мамык белән сак кына ышкып, яралы турны кирәкле төскә кертү... Соңгы аккорд – хаталы хәреф урынына

төзәтелгән хәрефне язып куясың. Тагын бер сере бар: хаталы хәрефне тулаем кыеп алмыйсың, төзәтәсе хәреф элементларын чамалап, кайбер өлешләрен генә юк итәсең – яра мөмкин кадәр әз урынны алырга тиеш...

Шулай итеп, операция тәмам. Киеренке халәттә бөтен мускуллар тартылган, әллә инде сулыш та алмаганмын, йөрәк тә гүя тынып калган булган.

Шәп чыкты бу! дип, үз-үземне хуплаудан соң, бөтен әгъзалар бушанып, хәрәкәт сорый башлады. Күңел мәтәлчек ата. Рәхмәтле булып, йөгерек бармакларны язып, чәбәләндереп, массаж ясыйм, йодрыкны учка, учны йодрыкка бәреп куям.

Тегеләр чәй эчеп килделәр, өстәлдә төзәтелгән документ ятканын күрсәләр дә кулга алып карарга куркыбрак торалар. Ниһаять, Антонина Ивановна үз күзләренә ышанмыйча әле болай, әле тегеләй әйләндереп карады да:

– Шушы билет идеме соң ул, ныклап сез дә карагыз әле, – дип егетләргә бирде.

Төзәтү чынлап та ювелирларча башкарылган иде. Шулай да, билетларны генерал тапшырасы тантаналы кичәгә барыр алдыннан Антонина Ивановнаның эчтән борчылуы сизелә иде әле.

Икенче көнне ул, бар да әйбәт үтте, дип балкып килеп керде. Минем иңемнән кочып, бит очымнан үбеп алды, барыбызны да ягымлы карашы белән сыйпап:

– Сезнең белән разведкага барып була, – диде.

Бераз вакыттан соң без һәммәбез көнгә унар билет тутыра башладык.

– Ашыкмагыз, фәлән айда бетерергә дигән срок куелмаган бит! – дип Антонина Ивановна чыбыркылап торса да, һәммәбез көнгә унар билетны кулдан үткәрәбез. Бозылган билетны юк итмичә, төзәтә алу мөмкинлеген белү, безне эшебезгә җиңел карарга түгел, киресенчә, киеренкелекне йомшартып, каушамаска этәрде; шуның аркасында хаталар да сирәк китә иде...

Ышаныч ныгып, кул языла торгач, көнгә һәммәбез утызар билетны әйләндереп каплый башладык.

Эштән соң калып мин тушь белән рәсемнәр ясаштырам. Минскида «Во славу Родины» дигән зур форматлы, сигез битле округ газетасы чыга. Анда кулдан ясалган рәсемнәр дә бастыралар. Мин дә, кызыгып, редакциягә рәсемнәремне юллаган идем, «Тематик яктан килеп бетмәгән, бастырып чыгара алмыйбыз», дип хат килде. Мондый каршылык минем канатны салындырмый, киресенчә, үҗәтләндереп котырта гына. Барыбер ул газетада басылачакмын, дип кыдрачланып, яңадан-яңа рәсемнәр ясыйм.

Дивизиянең политбүлек начальнигы полковник Курганский кичен безнең казармага, яңа комсомол билетлары тапшырырга килгәч, блокнотымны алып, сызгалап утырган идем. Сурәт ярыйсы гына килеп чыкты, полковникны күреп белгәннәр – шунда ук танып алдылар.

Җибәрдем мин бу рәсемне Минскига. Озак көттермәделәр, «Вручение комсомольских билетов» дигән исем астында басылып та чыкты. Тик, Курганский нинди хәрби дәрәҗәдә, погонындагы өч йолдызны бик үк аерып булмаслык итеп төзәткәннәр. Полковник булса, хәрби сер ачыла микәнни?..

Ун көннәр үткәндер, мине полковник Курганский кабинетына чакырттылар. Штабка килеп, кабинетына үттем:

– Товарищ гвардии полковник, по Вашему...

Полковник мондый рәсмилеккә кул гына селтәде дә, миңа каршы килеп күреште. Шул ук сизелер-сизелмәс кенә елмаю, җылы караш.

– Газетада минем рәсемне чыгаргансыз икән. Командировкада идем, күрми калдым, табып китерә алмассызмы? – диде полковник.

– Була ул, – дип, мин Офицерлар йортындагы кабинетыбызга йөгерә-атлый барып килдем.

Курганский газетадагы рәсемне җентекләп карады да, елмаеп:

– Ошатып ясагансыз. Шундый талант булу – бәхет инде ул, – диде. Минем кайдан, кайчан армиягә алынуымны сорашканнан соң, кинәт кенә:

– Туган ягыгызга отпускка кайтасыгыз килмиме? – диде.

Көтелмәгән бу тәкъдимнән мин өнсез калдым. Әмма шатлыкны өркетмәс өчен тыштан сабыр гына күренергә икәнен дә чамалый идем.

– Иптәш полковник, – дидем мин, – дулкынланудан тоныкланыбрак калган тавышыма көч биреп, – мин бит әти-әниемнең бердәнбер малае... Алар инде олыгаеп киләләр. Бездә июнь урталарында печән «чире» кузгала. Менә шул печән әзерләү чорына җибәрә алмассызмы икән, әти-әнигә көтелмәгән ярдәм булыр иде?..

Полковник Курганский «аңлыйм хәлеңне», дигән кебек иңемә кулын салды, ишеккә кадәр озата килде:

– Килештек. Июнь башында минем хәтергә төшерерсез, – дип саубуллашып калды.

Шул көнне үк мин Омскига – балачак дустым Фаварискa хат язып салдым. Ул анда Трудармиядә прораб булып хезмәт итә. Иллә дә шәп булыр иде, икебез бер вакытта ялга кайтсак. Армия шартларында кем, кайчан күргән андый бәхетне.

Еллар аша шаккатып уйлыйм: берең – Бобруйскида, Европаның борын төбендә, икенчең – тайгалар артында адашкан Омскида. Арада – меңнәрчә чакрым киңлекләр, меридианнар. Каты канунлы армия кысаларында ирекле уй-хыялны гамәлгә ашырырга бернинди мөмкинлек булмаган килеш... Нинди ышаныч, нинди өмет – һич икеләнүсез, «бергә кайтабыз», дип сүз куешу өчен нинди башсызлык, тәвәккәллек кирәк булган.

Җай гына барган эшебез 3 апрель көнне (1967 ел) тукталып калды. Полк, дивизия штабы биналарының алгы ягында кара тасмалы байраклар иелеп тора. Бүген илнең Оборона министры, маршал Родион Яковлевич Малиновскийның Мәскәүдә, Кызыл мәйданда, җәсәден туп (пушка) лафетына куеп, соңгы юлга озаталар. Бу олы кайгының кара шәүләсе илнең бөтен хәрби берләшмәләренә дә сирпелгәндер.

Безнең гарнизонда да үзгә бер хәрәкәт. Полклар саф-саф булып аэродромга таба бөркелеп килә дә, очу полосасына тезелә бара. Олы елга кебек агып барган батальон сафында атлаганым бар иде. Ә монда – тулы бер дивизия, тетрәп торган диңгез, меңнәрчә йөрәк тибешенә кушылып, эреп югаласың.

Трибунада – генерал Дудаков, югары чиндагы офицерлар. Матәм митингы башлана. Малиновский – ике тапкыр Советлар Союзы Герое, Югославиянең Халык каһарманы, алтмыш тугыз яшьлек маршал... шундый дәрәҗәләргә менеп җиткән шәхес үлмәскә тиеш югыйсә... әмма тәкъдир бар шул, яшәү һәм үлем бизмәнен ул тигезләп тора.

Митинг соңында махсус әзерләнгән полклар, автоматларын өскә каратып, салют бирделәр. Шул мәлдә әллә каян гына ябырылып, күк гөмбәзен умырып төшергән авазлар салып, каргалар өере күтәрелде. Аэродром тирәсендәге агач ябалдашлары сискәнеп куйды бугай. Шомлы, сагышлы тантана тәмам. Язга үрелгән ботакларда тулышкан бөреләр шартлап ярылыр шикелле...

Илнең Оборона министры итеп маршал Гречко билгеләнгәч, армиягә кертелгән яңа тәртипләрнең мин искәргәне шул иде: штаб офицерлары китель

өстеннән портупея буып йөрергә тиеш булдылар. Портупея будыңмы – син инде күн итекләр кияргә тиешсең – кием формасы шуны таләп итә. Маршал Гречко үзе шундый форманы ярата икән. Җәйге челләдә ничек мондый кием белән йөрербез дип пошаманга калган офицерларны илгә кертелгән һәр яңалыкның озак яши алмау гадәте коткарды.

Комсомол билетлары алыштыру дәверендә миңа үзебезнең часть кыйпылчыклары урнашкан Пастовичи, Осиповичи кебек шәһәрләрдә булырга туры килде. Бобруйск шәһәреннән еракта, урман эчендә плацкарт вагонда яшәгән кислород ясаучы взвод белән дә таныштык. Солдат-повар пешергән андагы борчак ашының тәме әле дә хәтерне кытыклап тора (өч йөз кешегә пешергән белән, утыз кешегә дип пешергән аерыла шул).

Менә без Барановичига очарга дип аэродромга килдек. Антонина Ивановна җитәкчелегендә бөтен группабыз белән, атна буена шул шәһәрдә яшәячәкбез. Минем кулда портфель, капкачы арасына түгәрәкләп төрелгән плакатлар кыстырылган, калган егетләрнең дә кулы буш түгел. Бөтен кирәк-яракны төяп барабыз.

Арты чүгеп, нәни генә сыңар тәгәрмәчтә утырган ЛИ-2 самолёты, «ТУ» кебек мәһабәт лайнерлар янәшәсендә оялган кебек, посып тора. Шуның тимер баскычыннан күтәрелеп, эчкә үтәбез. Түрдәрәк пәрдә тартылган. Бераздан самолётны тирбәтеп берничә офицер килеп керде. Арада – генерал Дудаков үзе! Иң арттан безнең капитан Пинчук күренде. Генерал алга узып, пәрдәне шудырды да, «минем яшерен серем юк сездән», дигәндәй, ачык килеш калдырды. Кителен салып, кабинага узганда мин уйлап куйдым: генерал бит гадәттә чын хәрби самолётта – ТУ-16 да оча, ә бу самолётта ул «юл уңаеннан» гына, кайсы якка утырыр икән? «Мин – генерал», дип дәгъвалау юктыр, димәк очышның үз кагыйдәсе бар. Генерал Дудаков уң як штурвал артына утырды. Ә капитан Исаков исә сул креслоны, экипаж командиры урындыгын биләде.

Самолётыбыз тыгыз болыт юрганын ертып, өскә, кояш нурлары кинәнеп таралган зәңгәр чиксезлеккә чыкты. Күз карашын иркәләп, мәңгелекнең үзе агып бара шикелле. Хозурлыктан акыл саташа: кая очам мин? Кайсы заман кешесе мин? Һәм ул «мин» болыт упкыннары арасына төшеп югалыр кебек.

Генерал белән самолётка кереп утырган офицерлар арасында дивизиянең баш штурманы – подполковник Мостафин да бар, мин аны читтән генә күреп белә идем. Пинчук яныбызга хәл белергә дип килгәч, «монда сезнең земляк бар дип, Мостафинга әйтә алмассызмы?» – дидем. Миңа подполковник янына бару уңайсыз, ә ул минем янга килә ала. Килми икән, димәк, якыннан танышу язмаган...

Иллюминатордан карап бара торгач, бөтенләй онытылып сихерләнгәнмен. Сискәнеп киттем. Подполковник Мостафин янәшәмә килеп утырган икән, иңемнән кочып алды:

– Татар егетеме? Исемегез ничек? Кайсы төбәктән, Казаннанмы?

Шулай сөйләшеп киттек. Татарча белмәве хакында әйтеп, ул бераз моңсуланып алды. Ятим калган малай Киевта, балалар йортында тәрбияләнгән икән.

– «Рәхмәт» дигән сүз генә хәтердә калган, – диде ул. – Менә минем урынбасарым бар – майор Шаһиморатов, Уфа татары, телне әйбәт белә...

Подполковник Мостафин белән шактый сөйләшеп утырдык. Ягымлы кеше. Язмыш шулай китереп куйгандыр инде, детдомнан хәрби мәктәпкә китү аның өчен ятимлектән котылу, тотрыклы юл сайлау булып тоелгандыр.

– Отставкага чыккач, берәр татар авылына барып төпләнергә дә, тормышны яңабаштан корырга хыялланам, – диде ул.

Самолётыбыз калын болыт түшәге эченә кереп, шактый талкынып алганнан соң, төтенсу томан аша җир өсте шәйләнә башлады. Самолётның гәүдәсе «дерт»ләп куйды, шассилар оясыннан чыкканда шулай була. Димәк, төшәргә озак калмады. Подполковник Мостафин минем җилкәдән кагып саубуллашканда: «Проблемаң булса, мине тап, кергәлә», дип түргә, үз урынына китте.

Самолёт Барановичиның хәрби аэродромына төшеп утырды. Генерал Дудаков лётчик кабинасыннан чыгып, кителен кия башлады. Башка офицерлар да, төзәтенгәләп, генерал кырыена елыштылар. Мин портфелемне алып, тизрәк чыгу ягына, ишеккә ашыктым. Ачык ишектән күн итек башы күренүгә, кинәт оркестр уйнап җибәрде. Каушап калдым. Артка чигенергәме, алга атларгамы белмичә икеләнеп алдым да, баскычның ике-өч аратасын бер итеп атлап, җиргә сикердем. Оркестрантлар тезелеп басканнар, каршыда полковник (Барановичидагы дивизион командиры булырга тиеш) һәм аның яраннары үрә басканнар. Болар генералны олылап каршыларга әзерләнгәннәр, әлбәттә. Эре балык чыгасын көткәндә кармак тирәсендә буталган маймыч кебек, мин шым гына читкәрәк тайпылып өлгердем.

Генерал Дудаковның мондый нәрсәләргә исе дә китми шикелле. Сугыш гарасатын кичкән, күпне күргәннәргә хас сыйфат. Штаб янында кара-каршы килгәндә дә, син честь бирергә өлгергәнче ул инде рядовой солдат дип тормый, синнән җәһәтрәк кулын «под козырёк» куеп, үтеп тә китә.

Генерал Дудаков сугышта «Митчел» (Америкада эшләнгән) дигән самолётта очкан. 1941 елда ук Кенигсбергны бомбага тоту операциясендә катнашып, легендага кергән. Герой исеме алган.

Барановичида ракета йөртүче иң заманча ТУ-22 самолётлары тора. Еракка очучы бу самолётлар үзләре дә ракета кебек очлы борынлы итеп ясалган. Якыннан караганда, очлымы өстеннән карандаш сыман нәрсә алгарак чыгып тора, бусы – һава киңлегендә очып барган килеш кенә махсус самолёттан ягулык суыртып алу өчен эшләнгән.

Монда казармалар шәһәр йортларыннан калын-биек коймалар белән аерып алынмаган. «Ачык дивизион». Аэродром гына сак астында...

Антонина Ивановна җитәкчелегендә без, дүрт егет, кунак сыйфатында (әмма киеренке эш белән) Барановичи шәһәрендә яңа билетлар тутырып һәр солдатка өләшеп чыкканчы, бер атнага якын тордык.

Комсомол документларын алыштыру кампаниясе хезмәт дәверендә минем өчен истәлекле вакыйга булып калды. Күпме шәһәрләр күрдем. Күпме кешеләр белән аралаштым. Берничә ай эчендә, үзем генә дә меңнән артык билет тутырганмындыр... Минем каршымда, сорауларыма җавап биреп, нинди генә милләт егете утырмады... Бу очракта мин инде рус, татар, украин, үзбәк, азәри кебек еш ишетелгәннәре хакында әйтмим дә, ә менә кайчан да булса күрермен дип башыма да китермәгәннәрен искә төшерергә була.

Мин бер нәрсәгә шаккаттым: бинһая зур илдә, йөзләрчә милләт арасында без төрки кавемгә кергән халыклар гаҗәеп күп икән. Моны укып белү бер хәл, ә күреп белү – икенче икән шул... Менә минем каршымда табасаран егете утыра, бераздан аны кумык егете алыштыра. Рәсми сорашулардан соң, мин болай гына сөйләштереп алам. «Күз», «колак», «борын», «баш» сезнеңчә ничек була, дип сорыйм. «Әни», «әти», «күк», «җир», «кан», «сөт»... – китә

шундый сүзләр, барысы да уртак, охшаш... Күз алдымда милләтләр алышына тора: казакъ, үзбәк, каракалпак, якут, хакас, төрекмән, нугай,азәри... хәтта Молдавиядә яшәүче гагаузлар да безгә тугандаш икән... (гагауз егетенең фамилиясе Турчинов икәне хәтердә калган).

Мин, кызыксынып, төп сүзләрнең безнекенә охшашмы-юкмы икәнен белер өчен, осетин, грек, караим, абхаз, алман, яһүд, авар, чечен, ингуш егетләренә дә биреп карыйм, юк, кайбер сүзләр охшаган кебек тоелса да, алар инде бүтән «камыр»дан...

Миңа бу – кыяфәт, тел, рух аермалыгы ошый, акылны әсәрендерә торган әллә нинди эчке куәт, табигый үзенчәлек, олы сер ята бу халыкларның төрлелегендә...

***

Белорус җиренә яз шаукымы интегеп килми. Кояш та бөтен йөзенә ачылып, юмартлыгын яшерә алмыйча кинәнә; күз алдында төсләр үзгәрә бара. Әле генә алмагачлар шау чәчәктә була, аннары бакча, парк, урам скверларында тын гына сирпелеп, ак таҗ явымнары башлана. Син үзең дә сизмичә, җәйдән сөенче алырга килгән йомшак җилгә уралып җылы көннәргә кереп барасың.

Шимбә көнне кичләрен паркта музыка яңгырый. Койма белән әйләндереп алынган түгәрәк мәйданчыкта танцы башлана. Гарнизонны шәһәрдән аерып торган коймага махсус ишек уелган. Кичке җидедә ике якка ике сакчы баскан шул ишектән шәһәр кызларын танцы мәйданчыгына кертәләр. Төнге унбергә кадәр алар солдатларның күз уңындагы кунаклары. Гадәттә, кызлар шәһәрнең форштадт дип аталган шушы якындагы районында, үз йортлары белән яшәүчеләр төбәгеннән.

Кайбер елгыр-хәйләкәр солдатлар беренче елында ук өйләнеп алалар да, «к тёще, на блины» дип, гарнизон белән кәләш йорты арасында киләп сарып, сый-хөрмәттә яшәп алалар. Хезмәт срогы беткәч, күбесе, мәгъшукасын алырга онытып, туган якларына кайтып китәләр.

Танцы мәйданчыгында әнә шундый тол калган, алданган, рәнҗегән кызларны да күрергә мөмкин. Болар инде, төсен җуясы килмичә, әллә каян балкып торырлык итеп, купшы бизәнгәннәр. Әмма, нишлисең бит, гомер озая, итәк тә озыная бара, буыннар алышына. Отыры яшьрәк солдатлар килә барган саен, боларның базары төшеп, яшь кызлар рәтеннән арткарак чигенә торалар.

Кайный танцы мәйданчыгы. Гашыйклык, ау дәрте – аяусыз. Берәүнең дә үзенә тиңләнгән бәхетен бүлешәсе килми... Ә музыка хисләрне котырта. Йомры тезләр, бөтерелмә итәкләр, иңнәргә аккош муенидай бөгелеп яткан куллар, чәч җиленнән сирпелеп киткән хуш ис, утлы иреннәр, сыгылмалы билләр... Хәрәкәт, буталыш, өмет, алгысыну... музыка өермәсендә чагылып киткән күзләр, күзләр, күзләр йолдызлыгы...

Бүген дә мин янәшә торган өч кызга игътибар иттем. Алар гел бергә киләләр. Үзебезнең ротадан өчәү берләштек тә, тартылдык болар янына. Үзем юаш-оялчан булсам да, кызлар арасыннан иң чибәрен сискәндерә алу җене бирелгән миңа.

– Люба, – диде иң чибәре. Моңсурак карашында славян салкынлыгы. Мине нәкъ менә шундый: уе-сере эчкә, тирәнгә яшерелгән күзләр әсәртеп тынычсызлый. Любаның дуслары – апалы-сеңелле Валя белән Рая икенчерәк, күзләрендә мут очкыннар чәчрәп китә. Еш елмаеп, күп сөйләшәләр.

Төнге унбердә кызларны капкага кадәр озата барабыз. Иртәгә Березина елгасы буена кызынырга чыгабыз, батып үлүдән курыкмасагыз... сез дә

кушыла аласыз, дип тәкъдим ясыйлар. Очрашырга сүз куешабыз. Старшина Осипенкодан увольнительный кәгазе алыр өчен бүген кичке барлауга үз вакытында кайтырга, ипле генә йөрергә кирәк.

Березина – үз кадерен белеп кенә ага торган матур елга икән. Яшел чирәмле, өянкеле сөзәк ярлары Агыйдел буйларын хәтерләтә. Малай чакта кәс кисеп, буа ясап, Эстәрле инешен тирәнәйтеп, йөзәргә өйрәнүләр юкка китмәгән. Беләкмускулларда йөзә беләм, дигән ышаныч тибенә. Кайчандыр гаскәрен ташлап, Парижына качып барганда, Наполеон Бонапартны чак батырып үтермәгән тарихи елга бит бу. Мин моның аргы ярына йөзеп чыкмасам, гомергә үкенечкә калачак. Бигрәк тә кызлар карап торганда...

*Березина... Рәхәт яңгырашлы, ләйсәнле исем. Еллар узгач, мин ул елгага шигырь багышлармын дип уйламаган идем...*

*Березина исемен кырык елдан соң Парижда ишетеп, сүгенер дәрәҗәгә җитеп тузынырмын дип тә уйламаган идем. Телләрендә «Р» авазына кырау төшереп сөйләшкән французларга хөрмәтем бөтенләй кимеде.*

*Мәскәүдән чигенгәндә, таланып, гаскәрен җуеп, мәсхәрәләнгән Бонапарт алып кайта Парижга бу елга исемен. Французлар хәзерге көндә дә «начар, бик начар» халәтне «бе-ре-зи-на» дигән сүз белән белдерәләр икән. Моны белгәннән соң: «Мин Европалы, мин зыялы» дип күкрәк кагып йөргән французларны кызганып куйдым. Шундый күркәм елганың, шундый матур исемен бер тинтәк адәм сүзенә карап, кирәкмәс урында кулланалармы?! Березинадан оят!*

Каршымда – Березина тугайлары. Шәһәр бик еракта. Аның барлыгы да сизелми. Тын ярда без генә. Кызлар табын әзерләп куйдылар. Алдан хәстәрен күреп килгәннәр. Уртада – кызыл шәраб шешәсе кукыраеп утыра. Валя белән Рая бик уңган күренәләр, куллары ризык тирәсендә уйнап кына тора. Любага эшләү килешмәс тә кебек... Купальниктан аның гәүдә рәвеше, мода салоннарында кәскәс басып, сокланулы күпме күз карашларын кисеп үтәрлек итеп яратылган...

Белоруcларның тыныч холыклы, күндәм, бик кешелекле икәнен аңлый, күрә, сизә башлаган идем, өйләрендә булгач, аш-суга да оста икәнлекләре ачылды.

Валяларның өйләре Сакко һәм Ванцетти урамында, чыршы бүрәнәләре кара төскә кергән, текә түбәсе әллә каян күзгә ташланып тора. Без, берничә солдат һәм кызлар, шул өйдә табын корып утырдык. Валя белән Раяның әнисе күзгә күренә дә, күренми дә кебек. Өстәлгә аш-су чыгарганда гына шәйләнеп кала. Гөр килеп утырабыз. Минем өчен мондый мәҗлесләрнең бер җәзасы бар: хәмер эчәргә кыстау юмартлыгы... Рюмкага иренне генә тигезеп утырам.

Бервакыт күрәм, егетләр хәмерле рюмка күтәреп, стена белән мич арасына корылган чаршау артына кереп-кереп чыгалар. Анда мыдыр-мыдыр сөйләшеп тә алалар. Минем, аптырап, шул якка күз салуымны күреп, Валя, уңайсызланып кына:

– Анда минем әти ята. Алесь Гарасимович. Инвалид ул, – диде.

Бераздан егетләр чаршау артына мине дә чакырып алдылар. Кердем. Күрәм, аяк турын юрган белән төргән, шактый таза иңсәле ир кеше ятакта утыра, бер якта мич, бер якта стена – кысан гына урын. Кемдер мине:

– Вот он – самый натуральный татарин! – дип тәкъдим итте.

Йорт хуҗасы Алесь Гарасимович сугыш ветераны икән, хәмер тәэсиреннән бераз йомшап та киткән шикелле:

– Казань, Казань, – дип мине кочакларга үрелде. Мин, иелеп, аның янәшәсенә чүмәштем. – Спасибо Казани, такую женщину судьбина мне дала, – дип ул маңгаен минем маңгайга терәп җылап җибәрде. – Она святая, такой в жизни не бывает!.. Позовите Марию, пусть познакомится со своим сородичем.

Алесь Гарасимович Ватан сугышында каты яраланып, бот төбеннән ике аягын да өздергән. Минскида госпитальдә яткан, сугыш беткәч тә ул хатынына хәбәр бирмәгән. Сугыш алдыннан гына, 1941 елда өйләнешкән булганнар.

Ничектер, кешеләр аша ишетеп, хатыны Мария килеп аны өенә алып кайткан. Сабый баланы күтәреп йөрткән кебек, ирен кирәк чакта табибларга алып барган, массаж ясаган, мунча керткән, тәрбиядә генә тоткан.

Хуҗабикә кергәч, Алесь Гарасимович, торып басарга җыенган кебек калкынып, хатынын кочарга үрелде.

– Ты же у меня святая, Мария, вот познакомься, земляк твой! – дип мине дә якынрак тартып китерде.

– Мәрьям, – дип ишетелер-ишетелмәс кенә пышылдады хуҗабикә. Алесь Гарасимович, икебезне бергә кочаклап, үкси башлады:

– Я же как обрубок. Она меня!..

Хуҗабикә калкынып-калкынып сөйләгән ирен тынычландырып, башыннан сыйпады да:

– Вы уж извините его, – дип, чаршауны ачып, табынны карарга чыгып китте.

Озак тынычлана алмады Алесь Гарасимович... Вакыт-вакыт мине чакырып кертә дә иңемнән кысып коча:

– Казанны күрәсем килә дип, бер мәртәбә дә әйтмәде. Сизә идем бит, югыйсә... кемнең инде туган җирен күрәсе килмәсен. Әйткән булса да алып кайта алмас идем... Казанга минем Мария исеменнән сәлам әйт! Онытма, яме!

Минем дә күзгә яшь килде. Нинди язмыш... Өч бала үстергән, ә үзе сабый буйлык ата...

Их, мәнсез яшьлек, күп нәрсәнең асылына төшенеп тормыйча, үтешли генә күз салып китәргә күнеккәнсең шул. Нигә дип шул чакта ашыктың, ачлыктан киселгән ятимә кыз баланың Белоруссия җиренә эләгеп, детдомда үсүе, исән калып, Мәрьямнән Марияга әверелүе хакында кызларыннан түгел, ә үзеннән сөйләтергә иде бит... Шундый язмышка дучар булгач та, иренә тугры калып, тормышта күпләрне изгелек мисалы булып көнләштергән, сокландырган түзем-сабыр татар хатыны янында ник бер кәлимә сүз әйтмәдең, дип үземне еллар аша, кайта-кайта битәрлим.

Ул көнне өй һавасы, өй ашы, өй рухы минем күңелне иләсләндерде. Радиоладан тынлыкны «дер» селкетеп музыка җибәрдек. Өстәлләрне читкәрәк этәреп, танцыга дип парлашабыз. Любаның кулы иңемдә. Ягымлы сүз әйтеп күңелне юат син, йомшак кулың белән баштан сыйпа. Мин бит туган җиреннән өзелеп, еракка ыргытылган бер ятим. Нигә мин көткән моң көйрәми бу күзләрдә?

Казармага кайту белән мин Фәниягә хат язарга утырдым. Ничә айдан соң яңадан терелүме бу? Нигә болай эре итеп язам, сүзләр кантар-кантар булып төшә: икеләнү-шикләнүләр... Көнләшү-сагаюлар... Нигезсез фаразлар... Бар да чайпалып кәгазьгә түгелә...

***

Июнь башында дивизиядә яңа билетка чираты җиткән иң соңгы солдат кабинетыбызга аяк басты. Үзбәкстанда үскән Кырым татары Исмаилов Нәүфәл иде ул. Кылыч борынлы, каратут йөзле, чибәр егет, төбенәчә кырдырып

алдырса да, чәченең гадәттән тыш кара булганлыгы төк куелыгыннан ук сизелеп тора, бильярд шарына корым буяган кебегрәк...

Теркәү карточкасына «крымский татарин» дип язылган. Мин әллә ниләр уйлап, четерекле тарихка кереп тормадым; «себер татары», «әстерхан татары», «нугай татары» дигән атамаларны өнәми идем. Нишләп безнең милләткә карата гына географик атама тагып әйтелә микән, «себер урысы», «Уфа урысы» димиләр бит, дип аптырый идем.

Шуннан чыгып кына Исмаиловтан:

– Сызыйкмы «крымский» дигәнен, «татарин» дип кенә калдырыйкмы? – дигәч, ул риза булып баш селкеде.

Шулай итеп, соңгы комсомол билетына мөһер сугылды. Бөтенебез басып, «Ура!» кычкырдык. Антонина Ивановна: «Әйбәт егетләр сез!» дип һәммәбезнең бит очыннан үбеп чыкты.

Икенче көнне барыбызны да полковник Курганский кабинетына чакырттылар. Кыска гына нотык-котлаулардан соң, таралышыр алдыннан, Курганский мине үз янына дәшеп алды. Онытмаган бит!

– Июньнең унысыннан кайтырга җыеныгыз, – диде.

Шатлыгым күкрәкне бәреп чыкмасын өчен, мин йөрәк турыма учымны калкан итеп куеп алдым.

«Бер билетны да бозыкка чыгармадык», дип Комсомол Үзәк Комитетына отчёт биргән капитан Пинчук шат иде, безне кабинетка алып кереп, газы кымырҗып торган шешәле су белән «сыйлады». (Хәер, ничә ай бергә эшләп, безнең беребезнең дә хәмер эчү хакында сүз кузгатканыбыз булмады.)

Сизелеп тора, капитан Пинчукның бездән алай тиз генә котыласы килми иде: «Офицерлар йортындагы кабинет сезнең карамакта кала, иртәгә, элеккечә, нәкъ сәгать тугызда эшкә киләсез. Зур планнар бар, аңлатырмын», – диде.

Безнең гарнизон шәһәрчеге уртасында карт агачлары калгып утырган ташландык парк бар. Анда – түгәрәкләп коймаланган танцы мәйданы да, ташлары җиргә сеңеп, чак шәйләнгән сукмаклар, тагын ямьшәйгән берничә эскәмия күренә. Менә шул паркны «кеше» итүне капитан Пинчук кузгатмакчы була. Без, шушы командабыз белән, ике ай эчендә паркны төзекләндерү проектын эшләргә тиеш икәнбез.

«Ду» китереп эшне башладык. Кайда, нинди аттракционнар, аллеялар, ял урыннары булырга тиеш – үлчибез, сызымын сызабыз, рәсемен ясыйбыз, бәхәсләшәбез, идеяләр ыргытабыз. Увольнениегә чыгып, Бобруйскиның Үзәк паркына барып, аның дирекциясенә кереп киңәшләшәбез.

Үзәк паркта мин охшаткан сәер урын бар. Аллеяның як-ягында дистәләрчә юкә агачлары, нишләптер, җиргә ятарга кызыккан сыман, бөтенесе бер якка авышып үскәннәр. Кәүсәләре һәммәсе дә бер юанлыкта, шундый төгәл, параллель авышлыкта (35 градуслар булыр).

Шул аллеядан бераз баргач, туктадым да:

– Егетләр, бу агачлар арасына кергәч, нинди уй башыгызга килде? – дип сорау ташладым. Валентин, Владислав, Михаил бер-берсенә карашып тордылар да... Валентин әкрен генә:

– Авасы килә... – диде.

Чынлап та, минем дә күпме сынаганым бар, бу аллеядан үткәндә, агачларга тәңгәл рәвештә авышасы килү теләге уяна иде. Валентинның бу сүзеннән соң, дүртебез дә җитәкләштек тә, көлешә-көлешә гәүдәләребезне авыш тотып аллеяның башына кадәр барып чыктык. Юкәләр, «без гарип түгел, үзебез

шулай килешеп бер якка янтаеп үсәбез», дигән кебек, рәхмәтле шыбырдашып калдылар.

Безнең яңартылган паркның ике башында, искиткеч матур бизәлгән капкалар булырга тиеш. Капитан Пинчук бу капка рәсемнәрен бик ошатты, үзе дә чын-чыннан сөенеп, шушы стихиягә бирелеп китте.

Кабинетыбыз әллә нинди талант ияләре утырган архитекторлар бюросы кебек. Һәркем үзеннән нинди дә булса яңалык кертергә тели; бәхәсләшәбез, шаулашабыз. Матур иҗади алдану, очынып, хыялны бар итәргә теләү, үз-үзеңне ачу, расларга тырышу илһамландырган гомеремнең иң бәхетле, мәгънәле көннәре иде бу.

Шундый көннәрнең берсендә Фәниядән хат килеп төште:

*...Без икебез ике ярда хәзер. Син теләсәң дә, минем якка чыга алмыйсың. Мин теләсәм дә, синең якка чыга алмыйм. Моңа кадәр аерым булсак та, кайчан да булса кавыша алу өмете белән яшәгәнбездер, бәлки. Хәзер инде бар да бетте...*

*Мин хастаханәдә ятам. Врачлар температурамны төшерә алмыйлар. Сәбәбен дә әйтмиләр. Димәк, мине котылгысыз үлем көтә. Ә син мине элеккечә итеп күз алдыңа китергәнсең: кемдер миңа яисә мин кемгәдер гашыйк булып, кинәнеп яши дип көнләшү белдергәнсең. Ул дөнья минем өчен юк инде. Бу стеналар артында яшәү рәвеше, кешеләрнең уй-гаме, мөнәсәбәте бөтенләй башка. Мин моңа күнегеп барам. Бу – минем дөньям. Аңа син керә алмыйсың. Хуш. Сиңа бәхетле булырга язсын Ходай...*

Хатны кат-кат укыйм. Хәрефләр сикерешә. Гади генә сүзләр дә аңлашылмый кебек. Нинди сүзләр табарга миңа, кая язарга – хатның адресы юк.

Хәрефләр биешә. Хат юлларына текәлеп утырам да утырам икән. Укыйм да укымыйм да, күңелдә – упкын. Уйлар төшә дә югала, төшә дә югала.

Әгәр ул дөньядан китсә, минем өчен яшәүнең мәгънәсе калмый ич. Бүтән кешегә язмышын багышласа да, яшәсен генә... Ул яшәми икән, минем дә бу җирдә гомернең уты сүнәчәк.

Ярату, Мәхәббәт ул мәңгелек утлы бәҗра. Аны өзә алмыйсың. Өзә аласың икән, димәк ярату булмаган. Син бу илаһи хис биеклегенә менеп җитәргә базмаган бер җан асраучы гына...

Күңелдә корт күче кебек уйлар тузгый. Сүзләр кычкыра. Мин аларны тыя алмыйм. Сүзләр, бергә укмашып, дуамал көчкә әверелә, мине ярсыта. Хәзер үк, кичекмәстән, тимер юлга чыгып, ажгырып килгән поездның вагон тоткасына ябышып, каршы искән җилгә башны салып, туган якка ыргыласы килә.

Нишләргә?

Офицерлар йортына киләм. Егетләр кабинет тутырып эшләп яталар. Мин боларның дулкынына кушылып китә алмыйм. Нindидер сүз каталар, кагылып китәләр, сорау бирәләр, мин күрәм дә, күрмим дә, ишетәм дә, ишетмим дә... Шулай уема уелып утыра торгач, тынычлана барам. Акыл үз ярына кайтып төшә. Каян килә соң әле миңа өметсез уй? Бу – вакытлы тетрәнү генә. Бар да әйбәт булачак. Сабырлык – иң тугъры юлдаш хәзер.

Ике көннән мине болай да туган якка кайтарып җибәрәләр бит. Кой, әйдә, селтәп төшер хәсрәтле ябагаларны, тормышка кайт, егетем, сине юллар көтә!

Валентин белән Владислав мине вокзалга озата килделәр.

– Мин кайтканчы парк капкаларын алыштырып, бөтен нәрсәне бозып куя күрмәгез, – дигән булам. Егетләр, көлешеп, кул болгап калалар.

Гомель – Мәскәү поездында төш күрдем. Авылга кереп киләм, имеш. Урам буйлап, шатлыгын эченә сыйдыра алмыйча, кычкыра-кычкыра Фаварис йөгерә. Чемоданымны ташлап, аңа каршы мин йөгерәм. Алар өе янында да, безнең өй янында да түгел, урталыкта кочаклашып күрешәбез.

Мин Омскида хезмәт итүче Фавариска июнь башында, кайтасымны әйтеп, тагын бер хат язган идем. «Очраша алырбызмы», дигән икеләнүле сорау тынгысызлап, төшемә кергәндер инде.

Ни гаҗәп, өнемдә дә нәкъ шулай булды. Июнь аеның тургай моңына кинәнгән кояшлы матур көне. Үзебезнең өй турындагы чирәмле үрдән төшеп киләм. Үзен күрмим әле, тавышын ишетәм: Фаварис мине күреп алган, кычкыра-кычкыра чаттан йөгереп килеп чыкты. Бер-беребезнең кочагына атылдык. Күрешкән урыныбыз – төштә күренгәненнән йөз адым болайрак иде.

Фаварис миннән өч-дүрт көнгә алданрак кайтып, Челтер чишмәнең суын эчәргә, башын салкын агымында тотып, «корт чактырырга» өлгергән икән.

Өйдә – мин кайту бәйрәме. Рәзинә апа килеп җиткән. Әтинең чалгы чүкүе дә дәртлерәк. Әнинең коймаклары табаны «дер» селкетеп чыжылдый. Аяк арасында бөтерелгән песине йомшак кына сөя башлыйм да, ярату тезгенем ычкына, кызып китеп шапы-шопы китерә башлыйм икән. Песи, колакларын артка яткырып, үпкәләп китеп бара. Минем шулай сөюне кыйнау исәбенә кертә күрәсең.

Төштән соң, барлыгым белән юклыгымны искәртмәслек итеп кенә өйдән чыгып китәм.

Фәниянең Бөгелмәдә, нинди хастаханәдә ятканын Фаварис инде белеп алган. Икәү бергә барыйкмы, дисә дә, мин риза булмадым. Ни көткәнен үзем дә белмим бит әле...

Бөгелмә зур шәһәр булса да, адашып йөрмәдем, тиз таптым мин хастаханә урнашкан куе бакчалы оазисны. Ул яткан корпусны белешеп, икенче катка күтәрелдем дә пыялалы ишек катында көтеп торам. Нишләптер, аны минем янга ук чыгармаслар, шушы ишек аша салкын гына күрешербез кебек тоелды. Күрәм, бүтәннәр кебек халаттан түгел, ә ачык төстәге спорт киеменнән килә, якынлаша... Ишекне ачып чыкты да, мине кочаклап алды, кайнар яше муенымны пешергән кебек булды. Минем дә эчтә, бик тирәндә күңел сулкылдап куйды. Әллә нинди, моңа кадәр татымаган якынлык тойгысы аңымны томалады. Бер-беребез арасына упкын уйган айлар гүя кысылып килеп, күкрәк эчендә бер ритмга типкән йөрәкләргә сеңде дә бетте. Кадерлелек кадерен сүзсез алмашу мизгеле иде бу.

Аннары... бакча, агачлар күләгәсе, зәңгәр буяулы эскәмия. Арада – ятсыну.

– Озакка кайттыңмы?

– Бер күбәләк гомерен унга тапкырла.

– Математикадан алга киткәнсең син армия хезмәтендә.

– Сиңа дарулар килешкән. Тагы да чибәрләнгәнсең.

Сагышлы елмая. Ул чынлап та төс ташламаган. Бит очлары янып тора. Күзләрендә – яшәү дәрте очкынлана.

Икебез генә белгән көйнең сүзләрен җуйганбыз да, күз карашы белән генә бер-беребездән эзләшәбез кебек. Сүз йомгаклары каядыр еракка тәгәрәгән. Җеп очлары – күңел юшкынында.

– Монда бүтән дөнья, – ди Фәния, тезелеп киткән тәрәзәләргә карап. – Син аны аңламыйсың.

– Аңлар өчен нишлим? Мин дә авырыйммы? Икебез бергә...

– Җүләр син, – дип ул минем йолдызлы фуражканы салдырып алып, башына киеп куя.

– Сиңа килешә, иптәш гвардии лейтенант!

– Нинди «гвардии» дигән сүз ул тагын?

– Абзаң гади генә частьтә бил бөкми. «Гвардейский» дип аталган дивизия солдаты.

– Нишләп погонында бер сызык та юк?

– Мин бит хохол түгел сызыкка алданырга. Киләчәктә офицер погоннары тагып кайтыйммы соң?

– Кирәкми! Син бит тәртипле кысаларга керергә яратмыйсың. Сиңа бозу, җимерү килешә...

Ятсыну хисен җиңеп сөйләшкән, көлешкән булабыз. Әмма минем күңел барыбер ирекле түгел. Саксыз сүз әйтеп ташлап, үпкәләтермен кебек.

– Мин сине үз дөньямнан ераккарак чигерә барам, чигерә барам... Ә син кайтып төштең дә барсын да чәлпәрәмә китердең.

– Ә мин... Хат язмау ул, оныту дигән сүз түгел әле...

– Шушы айлар эчендә күпме хат яздым мин сиңа. Язам да ертам, язам да ертып ташлыйм.

Ул больница хәлләре, андагы кешеләр турында бирелеп сөйли, калын дивар белән чикләнгән икенче бер илдә яшәгән һәм гомердә шунда калырга уйлаган шикелле: «Сезнең дөнья, безнең дөнья», дип, аерып карап, мине еракка «этеп» куя шикелле...

Көн дә аралаша торгач, әкрен-әкрен, элеккеге халәтебезгә кайта башладык бугай. Әмма ни хәл итәсең, тән ярасы кебек үк, күңел ярасында да җөй кала шул. Вакыт-вакыт Фәния моңсулыкка бирелә. Нindидер олы бер серен миннән яшерә сыман... Бер якыная, бер ерагая, кочаклап алсам, кулын ирененә калкан итеп куя...

– Сине үз дөньяма аласым килми. Көт. Терелеп, үзем чыгармын синең дөньяңа, – ди.

Авылда беренче төн. Җан талкына. Тән йокы сорап изрәми. Борсаланып ятам-ятам да ишегалдына чыгам. Йокы мазасы бирми торган нинди шомлы тынлык соң бу?

Һавада – терек җәй муллыгының кинәнеп тулышкан исе. Ишегалды уртасында, чыклы чирәмдә яланаяк басып торам. Җир дымы, шифа булып, буыннарга үрмәли. Тәнгә рәхәтлек иңә. Җан-тәннең туган җир каршында ятсынуы бетә бара.

Йолдызлар чәчрәп янган күккә карап, сүзләргә төрелмәгән, күңелнең ниндидер илаһи догасыннан сәҗдәгә киткән кебек булам. Гомернең бәрәкәтле бу мизгелен искәреп кал, ди күңел тавышы. Кадерен бел генә: җирдә таяну ноктасы – үз нигезең бар. Нәкъ шул турда, күк тирәнлегендә йолдызлар сибелгән үз кишәрлегең бар. Әти-әниең исән-сау. Шушы мөкаммәл бәхетне аң белән тоймыйча, төнге күкнең җан тибешен тыңлап басып торасың. Төнге авыл тынлыгы – калын юрган кебек; каядыр эт өреп куйган авазлар, еракта, кырлар иңеннән чөрләп кенә ишетелгән трактор тавышы, кошлар йоклаган арада посып кына чикерткә сайравы – болар бит тынлык юрганының моңлы бизәкләре генә...

Таң беленә башлагач, кереп, юрган астына чумам. Рәнҗемә миңа, авылым тынлыгы... Кичер әйдә, чит җирдә, бүтән телгә, бүтән тавышларга күнегә башлап, бозылып кайткан улыңны кичер!

Тән күзәнәкләрен изрәтеп йоклата торган гарасатлы тетрәү, дәһшәтле самолёт тавышларын юксынам икән бит мин...

Иртән иртүк, кояш әле каеннар итәге астыннан чыгып кына килгәндә, без инде урман аланында. Чыклы үләнне чабу рәхәт. Чалгы йөзеннән җиләкләр сибелеп калганын, артта тигез кыркылган үлән камылында аяк эзләренең чигелеп баруын яратам. Күн итектән котылган аякларга рәхәт. Әти, үзенә бер кишәрлек алып, читтәрәк чаба. Янәшәдә генә чалгы чыжылдавы минем ритмны бозачагын белә ул. Әни чиләккә мәтрүшкә серберкесе, сабаклы җиләк салып чәй кайната. Мин чалгы каршына тәгәрәп килеп, өзелергә кызыккан, мәмрәп пешкән җиләкләрне, сабагы белән өзеп, җыям да, зелпе куагына элеп куям, Фәниягә алып барыр өчен.

Күкрәккә үләнле, чәчәкле, баллы куәт ургылып керә. Кояш югарырак чөелә барган саен кош-корт, бөҗәк-санак тавышлары да куера. Менә кайда ул авиация – быжан, авыр бомба таккан алты моторлы самолёт кебек, шом салып, тирәмнән вәкарь белән әйләнеп уза, кигәвеннәр баритон тавышын сүндерергә онытып бәрелеп китә, черкиләр энә күзеннән чыккан нәзберек безелдәве белән теңкәгә тия – бар да оча, барсына да истәлеккә минем кан кирәк...

Бик тиз үтеп китте ун көнлек ял, йотлыгып су эчкән ара...

Печәнне туры лапас түбәсенә өйгәндә ярдәмгә күрше-тирә ир-атлар җыелды. Ярдәмчел авылдашларның мәрхәмәтен һәрчак шулай тоеп яшәдем мин.

Башта Фаварис белән хушлаштык. Берничә көннән әти-әни капка төбендә мине озатып калды.

Фәния, «абага чәчәге кабып», табиблар күзенә күренмичә генә хастаханәсеннән чыгып, вокзалга килде. Гомеремдә икенче мәртәбә перронда озатып кала инде ул мине.

Поезд кузгала башлагач, атылып төшеп Фәнияне каерып үптем. Кулын калкан итеп куярга өлгерә алмады. Күзләрен зур ачып, куркынган кыяфәт белән:

– Их син!.. – дип өзгәләнеп калды.

Бу юлы Мәскәүдә күкрәк киереп йөрдем, «казан ятиме» булып утырмадым. Кызыл мәйданны иңләп-буйладым, Кремльне күрдем. Көтмәгәндә шулкадәр әйбәт абзыйга юлыктым, кая кирәк шунда иренмичә озатып йөрде. Гидларың бер кырыйда торсын. Тарихны белә, мавыктыргыч итеп сөйли. Шул кадәр рәхмәтле булып, соңыннан:

– Сезгә күпме түлим? –дигән идем, чын-чынлап үпкәләтә яздым үзен. Көчкә тынычландырдым. «Мәскәүдә, кая барма, акча сорыйлар бит», дип акланам.

– Яшәгән урыным Минскида, белорус мин, – диде танышым аерылышканда.

Гомельгә килеп төшкәч, Бобруйскига китәсе поездны көткәндә, вокзал мәйданында шәһәр манзарасын тамаша кылган мәлемдә, кемдер аркамны шакыды. Борылып карасам, патруль – җиңенә кызыл бәйләгән өлкән лейтенант һәм ике солдат тора.

– Нигә честь бирмәдең? – ди өлкән лейтенант.

– Минем арт чүмечемдә күз юк бит, – дим.

– Алай булгач, комендатурага керәбез инде, – ди.

Кердек. Минем түш тулы значоклар елык-ялык итеп тора. Документлар буенча тикшерә башлагач, җитмеш ике мәртәбә парашюттан сикергәнне белдергән значокны, кешедән алып торганым билгеле булды, салырга куштылар. Комсомол значогыма да бронза аслык куелган, аннан дугайланып, истребитель самолёты очып чыгып килә. Ярамый икән, бу самолётны күрсәтеп,

мин хәрби серне ачам лабаса... Шулай итеп, кителемдә бер-ике генә билге моңаеп калды.

Бик бөртекләп, минем тәртипсезлек хакында кәгаземә язып, мөһер суктылар. Частенда күрсәтәчәкләр моңа, дип уйлый инде өлкән лейтенант. Ялгыша, бичара, старшина Осипенко кулына керәчәк тә, ул аны карап та тормыйча, архивка озатачак.

Өлкән лейтенантка чирканып карап, астан йодрыгымны кысам. Империянең менә шушындый верноподданныйлары һәрчак шулай бет булып кадалачак. Табигате дөрес-уңай, астыртын-күндәм бәндәләрне дә җенем сөйми. Андыйлар кызыксыз, сәләтсез, куркак булалар. Миңа үзенең барлыгын раслап, кирәк чакта аударып-бәрелеп китә торган почмаклы кешеләр ошый...

Бобруйск мине кояшлы көне белән каршылады. Эш урыныма барып кергәч, күңелгә болыт төште. Күпме үзгәреш: капитан Пинчук Мәскәүгә академиягә укырга китеп барган. Саубуллаша да алмадык. Аның урынына өлкән лейтенант Вакарин килгән. Аның без хыялланган парк белән кызыксынырга исәбе күренми, диләр егетләр. Аларның күрәзәчелеге рас килде.

Таркаттылар безнең иҗат төркемен. Паркка исә шушылай, ташландык хәлендә калырга язган икән...

Капитан Пинчукка бераз үпкә дә калды. Хәер, китәсен алдан әйтеп йөреп, без солдат кавеме белән нигә дип киңәшеп торсын инде офицер башы белән.

Аерылышабыз. Егетләр белән ничә ай буе тату бер гаилә булып эшләдек. Валентин, Владислав, Михаил һәм мин. Ике украинлы, бер рус, бер татар...

Хушлашу моңсу булды. Һәркем кире үз полкына кайтып китте. Кочаклашып аерылыштык, бүтән мәңге күрешмәячәгебезне белеп хушлашабыз бит...

*Егерме еллар үткәндер. Чаллыда бер төркем язучылар «Татарстан» кунакханәсе каршында автобус килгәнне көтеп торабыз шулай. Баскыч төбендә бер авиация полковнигы безгә арты белән басып тора. Фуражкасы астыннан куе чал чәче күренә. Вакыт-вакыт сәгатенә карап куя. Нидер сизенеп, моның янына барып, кырыйдан күзәтәм. Бераздан борылды полковник, күзләр очрашты.*

*– Извините, товарищ полковник, Ваша фамилия, случайно, не Пинчук? – дим.*

*– Да, Пинчук. Откуда Вы меня знаете? – дип, сизелер-сизелмәс кенә елмайды. Бу таныш елмаюдан соң минем инде шигем калмады.*

*Бобруйскида, дивизия штабында Сезнең белән бер кабинетта эшләп алдым, комсомол билетлары алыштырган чорны хәтерлисездер, диюгә, полковник:*

*– Вспомнил! Ваша фамилия на «Г», на «Г» дип, төртелеп калды. Мин әйтеп биргәч, яктырып китеп, иңемнән кочып алды.*

*Ул Мәскәүдә, Муса Җәлил проспектында яши икән. Авиация турында китап язган, корректурасын күрсәтте. Теге, «минем урынга» инструктор булып билгеләнгән Лебеденко да шунда, бер урамда торалар икән.*

*Кызганыч, ул үзе эше буенча иртә китә, без соң кайтабыз, берничә мәртәбә ул мине эзләп номерга да кергән, шулай итеп, озаклап әңгәмә корырга, хатирәләр яңартып алырга җай чыкмады. Иртәрәк кайткан төнне эзләп керсәм, ул инде китеп барган иде...*

*(Ахыры киләсе санда)*



Рафис
Корбан

# КИЛӘ ҖЫРЛАР ЯЗЫП КАЛДЫРАСЫ

## Мин тиеш

Пәйгамбәр дә үлгән.
Килер бер көн,
Югалтырлар җирдә безне дә.
Кемдер әле кергән язга гына,
Кемдер инде яши көзендә...

Мин адаштым бугай фасылларда:
Әллә көз бу, белмим, әллә яз.
Мин бер язны кичкән идем инде,
Ике тапкыр килде мәллә яз?

Их, бу җирдә ялгышмаска иде!
Юллар шундый озын шул монда!
Җырны юлдаш итеп чыктым юлга,
Биек тау бар барыр юлымда.

Ә ул тауга мин менәргә тиеш,
Очраса да юлда ни генә!
Барган саен ул тау биегерәк,
Барган саен артка чигенә.

Тик ул тауга мин менәргә тиеш!
Мин белергә тиеш – ул тауда
Яңгырармы минем моңлы җырым
Дөнья инде минсез елларда?

---

Рафис КОРБАН (1957) – *шагыйрь; «Алмалы төн», «Бәхет телим», «Яра» һ.б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. А.Алиш исемендәге әдәби премия лауреаты. Казанда яши.*

Ул чакта да нәкъ минем күк берәү
Үзенә шундый сорау бирерме?
Дөрләп кайнар сөю учагында,
Көзен дә яз итеп күрерме?

Пәйгамбәр дә үлгән.
Коръән калган...
Берсен-берсе сөйгән ярларга
Килә җырлар язып калдырасы –
Изге дога итеп ятларга.

***

Шагыйрьләр – тел сакчылары, имеш.
Кемгә кирәк синең шигырең?
Эшкуарлар хәзер мәйдан тота,
Акча куып сыза гомерен.

Милләтең дә кирәк түгел аңа,
Мөһим түгел аңа динең дә.
Авылына кайтып мәчет сала,
Дога кыла кяфер телендә.

Иван белән рифмалаша Иман,
Бетеп бара телнең кадере.
Шагыйрьлегең синең кемгә хаҗәт,
Булмаганда шигырь әҗере.

Тик ялгышам бугай, шагыйрь дустым,
Дөнья тынгач соңгы туйдан соң,
Бар шул әле синең шигырь белән
Кабер ташын язып куясың.

## Терәү

Украина. Донбасс шахталары.
Кан коела кабат бу якта.
Ник бу хәтер шулай кыска икән?
Уйга сыймый күпме уйлап та.

Донбасс, Донбасс, сәйяр татарның да
Бәгыренә төшкән җир ласа!
Бәгырькәйләр өзелеп китмимени,
«Шахта» көен берсе җырласа?!

Бәхет эзләп киткән күпме татар
Аерылган туган иленнән.
Таш баскандыр анда күпме ирне!
Ә күпмесе язган теленнән!

Күберәктер телен онытканнар!
Шундыйлары күбрәк уйлата!
Украина. Донбасс шахталары.
Кан коела кабат бу якта.

Кан коела. Мин сәбәбен эзлим.
Сәбәбе бер: сәбәп – терәүдә!
Терәү тузса, шахта җимерелә,
Исән кала алмый берәү дә!

Шахтамыни?.. Украина үзе
Калган бүген торып терәүсез.
Мин сәбәбен эзлим, серен... Шуңа
Кем табала тәңгәл төгәл сүз?!

Күңелемә килә шахта баскан,
Телен җуйган мәхлук татарым.
Украина, монда сугыш бара...
Канга баткан Донбасс яклары...

## Туган як

Туган ягым минем Казан арты.
Шунда тәү кат сулыш алганмын.
Әнкәй сөйли: биш көн тынсыз яткач,
Алтынчыда разбой салганмын.

Туган ягым минем  Казан арты.
Шушы якта телем ачылган.
Әнкәемнең күкрәк сөте белән
Ачлык хисе җанда басылган.

Туган ягым минем Казан арты.
Илаһ миңа илһам төчкергән.
Әнкәемнең күкрәк сөте белән
Иман кергән миңа, көч кергән.

Туган ягым минем Казан арты.
Горурлыгым да ул, бурыч та!
Хыялларга канат куйган җирем,
Соңгы тукталышым тормышта.

## Керәшәләр

Суның бормалы җирендә
Ашытның биек яры.
Шул ярда тезелеп киткән
Керәшә оялары.

Текә ярда карлыгачлар
Тапкан сыеныр урын.
Талгын гына ага Ашыт,
Тыңлап керәшә җырын.

Керәшә җыры да матур
Тыңлый белеп тыңласаң.
Сандугач күк булмаса да,
Керәшә дә кош ласа!

Керәшәләр сокландыра:
Ничек тормыйлар куркып?!
Язмышлары кыл өстендә:
Өстә – күк, аста – упкын!

Язмышлар, әйтерсең, уртак
(Юк, егылмый керәшә!) –
Кешеләр дә кошлар кебек
Яшәү өчен көрәшә.

Тормышның упкыннары күп
Өстери торган аска.
Мин дә шул керәшәләр күк,
Тырышам егылмаска!

## Җәлил

Җырлый алмый, диләр, тоткынлыкта
Сандугачны, япсаң читлеккә.
Ничек яза алды икән Муса
Таш капчыкта иза чигеп тә?!

Көрәшмәсә әгәр җыры белән
Дошманына каршы, ул аның
Уйлагандыр шунсыз кидерәсен
Бөтен илгә коллык богавын.

Дөнья гизеп әгәр читтә йөрсәң,
Танышыйм дип шунда кул бирсәң,
Муса, диләр, шундук, Җәлил, диләр,
Татар булуыңны белдерсәң.

Батыр, диләр, бөек шагыйрь, диләр,
«Җырларым»ны яттан сөйлиләр.
Таш капчыкка япкан сандугачны
Кыю лачын белән тиңлиләр.

Читкә чыксам, юлым уңсын, диеп,
Җәлил үзе гүя кайгырта.
Ул үзенең горур җыры белән
Милләтемнең йөзен яктырта.

## Кайсын илендә

Күреп кайттым Кайсын Кули илен,
Кунак итеп дәште ул мине.
Кичкән чакта Чегем тарлавыгын,
Күргән кебек булдым Кулине.

Карап йөрдем Кавказ тау сыртларын,
Сокландырды Эльбрус мине.
Уйлап йөрдем таулар җырын җырлап,
Тау булалган Кайсын Кулине.

Эчтем учлап тау чишмәсе суын,
Ул да шигырь укый күк иде.
Тау чишмәсе җырын тыңлаганда,
Тыңлаган күк булдым Кулине.

Йөреп кайттым Кайсын эзләреннән,
Аңладым мин Кайсын Кулине.
Ул тауларын җырлап тау булган ич,
Сагындырды туган як мине!

## Татар күзләре

Мин татарны күзләреннән таныйм,
Карашыннан таныйм мин аны.
Карашлары аның мәхәббәтле,
Күзләрендә балкый иманы.

Күзләрендә балкый бар үткәне,
Гасырларның тирән эзләре.
Сагыш аша карый бу дөньяга
Хәсрәт эчкән татар күзләре.

Кайда гына аны очратсам да –
Бер картмы ул, әллә сабыймы –
Күңеленең сихри матурлыгын
Күзләренә карап таныймын.

И татарның күңел көзгеләре!
Укыйм сезгә «Сәҗдә» сүрәсен.
Бу дөньяда татар күзләренең
Беркайчан да нуры сүнмәсен!

**Редакциядән:**

*Бу айда каләмдәшебез үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*



Хисаметдин Исмәгыйлев

# ИСӘР

ХИКӘЯ

Алар авылга күптән түгел генә килеп урнашты. Бу икәү, авыл аксакаллары рөхсәте белән, сул яктагы урамда иске бер буш өйгә кереп яши башладылар. Зәйнәпләрнең өе алардан дүрт өй тегеләйрәк, авыл читендәрәк. Зәйнәпкә унике генә яшь иде әле ул чакта. Буе да бәләкәй булгач, ул үзенең яшьтәшләре арасында бөтенләй бала гына кебек күренә.

Бу йортта элек яһүдиләр торды. Сугыш башлангач, карт яһүд үзенең йорт җиһазларын юк кына хакка күрше-тирәсенә сатып, каядыр күчеп китте. Тормыш көтәр өчен иң мөһим кирәк-яракны ат яллап шәһәргә илттерде. Ә инде сатылмаган һәм үзләре белән ала алмаган йорт җиһазын, вакыты җиткәч кире кайтарып алырга вәгъдәләшеп, күршеләренә таратты. Яһүд бу татар авылына ничек шым гына килеп яши башлаган булса, шулай шыпырт кына китеп тә барды. Күрше-күлән сөйләве буенча, яһүди үзенең карт кына хатыны белән сугыштан качып, Польша якларыннан килгән качак булган. Алар киткәч, авылның «Сыңар балак» дип йөртелгән бер яклы гына урамындагы бу иске йорт, хуҗасыз калып, бер ел чамасы торды.

Һәм менә шушы йортка бик карт әби үзенең Сабит исемле турапы белән килеп урнашты. Бер тегү машиналарыннан башка юньле-рәтле йорт җиһазлары, табак-савытлары да юк үзләренең. Күршеләр кулдан килгәнчә ярдәм күрсәтте. Зәйнәпнең әнисе иске генә булса да мендәр белән юрган кертте. Башкалар табак-савыт белән ярдәм итте.

Әби, карт булса да, тегүгә бик оста иде. Һәм үзе кебек әллә кайчангы «Зингер» машинасында Зәйнәпкә яз чәчкәләре төшкән матур күлмәк тегеп бирде. Әбинең тураны Сабит, үзе бер төрлерәк булып, бик куркак иде. Карчыкның сөйләве буенча, алар күрше шәһәрдә оныгы Рауза белән бергә торганнар. Сабит – Раузаның улы. Сугыш башлангач, әбинең киявен сугышка алганнар. Бер төнне шәһәрне немец самолётлары бомбага тота. Шулчакны алар яшәгән йорт җимерелеп, карчыкның оныгы Рауза берсеннән-берсе бәләкәй өч баласы белән һәлак була. Әби белән Сабит тураны гына исән кала. Тик анда да әле бу яшүсмерне төш вакытына гына өй хәрабәләре астыннан табып алалар. Шыңшыган тавыш ишетеп, әби үзе һәм исән калган күршеләре ярдәмендә, Аллаһның рәхмәте белән, тәне дә чыелмаган оныгын хәрабәләр астындагы бер куышлыктан казып чыгаралар. Шул көннән бу бала куркак  булып һәм әзрәк җиңеләеп кала да инде.

---

Хисаметдин ИСМӘГЫЙЛЕВ (1953) – *язучы, Эстәрлебаш татар җәмәгатьчелеге рәисе; «Зимагурлар» исемле китап авторы. Башкортстанның Эстәрлебаш районы Тормай авылында яши.*

Сабит акылга бер төрлерәк булса да, эш ягыннан бик тырыш һәм көчле. Һәр кушкан эшне җиренә җиткереп башкара. Әби яңа тора башлаган урыннарында күрше-тирәгә, авылдашларына кулыннан килгәнчә тегү теккәли. Ә Сабит аларга бакча казыша, йорт тирәсендәге вак-төяк эшләрендә ярдәм итә, шулай тамак туйдыралар. Тик шунысы сәер: һавада немец самолётлары булсынмы, үзебезнең совет самолётлары тавышы ишетелсенме, Сабит, башын кая куярга белми, дуларга тотына. Кайда нәрсә күрә, шуның астына кереп яшеренергә тырыша. Якын-тирәдә йөргән булса, йөгереп кайтып үзләренең кар базына төшеп утыра, йә булмаса башка ышык урынга кереп кача.

Яше җиткәннәр һәм кулларына корал тота алган ир-атлар сугыш башлануга армиягә һәм башка эшләргә алынып, дошманга каршы сугышалар. Шуңа да авылда хатын-кызлар, яшь бала-чага белән картлар гына. Авыл халкы, язмышын Ходай кулына тапшырып, алда нәрсә буласын белми яши бирде.

Беркөнне Сабит югалды. Ә икенче көнне якындагы шәһәр кырында бик каты сугышлар булып, авылга да немец солдатлары килеп тулды. Алар авыл мәктәбенә һәм арурак өйләргә урнашып яши башладылар. Шушы хәлләрдән соң берәр атна үткәч кенә Сабит курка-курка үзләренең өйләре тирәсендә яңадан күренә башлады. Базда утырган икән, дип сөйләделәр.

Немецлар килгәч, яшәү тагы да авырлашты. Сабитлар тормышында да үзгәреш булып алды. Таулар арасында урнашкан ерак кына авылдан Сабитның әтисе ягыннан чыбык очы туганнары аларны эзләп тапты. Сабит белән әбине үзләренә алып китеп, бер атна чамасы кунак итеп, әзрәк бәрәңге, ярма да биреп кайтардылар. Беркөнне немецлар, язгы кырау кебек, ничек көтмәгәндә пәйда булсалар, шулай ук тиз генә авылны ташлап киттеләр.

Ул язны күрше карты Сабитны үзе белән ярдәмгә көтүгә алып чыккан иде. Аптырап кайтып авыл халкына сөйләде.

– Әйтерсең лә, – ди, – бу бала малларның телен белә. Көтүне шулкадәр рәхәт көттем, ял итеп кайттым. Бу бала берүзе көтүне йөретте, – дип, исәрне мактагач, авыл халкы аны көтүгә яллый башлады. Сабитларның өендә сөт-катык ризыклары да барлыкка килде. Тора-бара исәр авыл малларын берүзе көтәргә әвәсләнеп китте. Авылның авыл инде, теге оч малайлары Сабитны әзрәк кыерсытып, «исәр», «исәр» диеп ирештергәләсәләр дә, бераздан алар да тынды. Чөнки олы яшьтәгеләр андыйларны тиз басты. Аңлаганына хасталы кешене үртәргә, ирештерергә ярамаганлыгын болай аңлаттылар. Аңламаганга югары оч чатан Әхмәт бик тиз аңлатты. Әхмәт гражданнар сугышы барганда малай гына иде. Шул чактагы сугышта аягына пуля тиеп чатан калган.

Авыл таулар итәгендә булып, Сабит шул таулардан агып чыккан елга буенда көтү көтте. Кем өйрәткәндер, әллә электән белгәнме, Исәр көтү көткәндә бик тә моңлы итеп, үзе ясаган курайда уйнарга ярата. Тау буенда курай моңы ишетелсә, авылда барчасы:

– Бүген көтүне Сабит алып чыкты. Маллар туеп кайтыр. Әнә ничек итеп курай тавышы ишетелә, – дип сөйләделәр.

Сыер-кәҗәләре дә шул курай тавышына өйрәнеп беткән. Тирә-якка таралган маллар, Сабит курай уйный башласа, аның тирәсенә җыелышып яталар. Кайтышлый да артыннан ияреп кайталар. Тик Сабитның картәнисе генә сырхаулап китте. Йортның барча вак-төяк мәшәкате өелеп Исәр карамагына торып калды. Ул, кулыннан килгәнчә, бәрәңгесен дә утыртты. Көтү көтеп алган кәҗәсен савып, картәнисенә җылы сөт эчереп, аны тәрбияләде. Тик кайчакны нәрсә эшләргә кирәген генә оныткалый иде. Ярый әле картәнисе вакытында искәрткәләп торды. Күрше-күлән апалары да сугыштан качып килгән бу ике мескенгә кем ничек булдыра, шулай ярдәм итәргә тырышты.

Көзен Исәрнең коты очып, тагы кайдадыр югалып торды. Икенче көнне үк авылга тагы немец солдатлары килеп тулды. Болары тәүге килгәннәрдән шактый усал булып, берничә кешене урам уртасында атып та киттеләр. Бу хәл озакка бармады.

Язга таба каты гына бәрелешләр булып, Совет гаскәрләре авылны дошманнан азат итте. Һәм авылда яңадан Совет власте эшли башлады. Иң тәүдә югары оч чатан Әхмәтне бакча артына чыгарып аттылар. Имеш, партизаннар белән китмәгән, немецларга хезмәттәшлек иткән. Тик… соңыннан гына партизан отрядында булган ике бәндә килеп, атылганның каберенә йолдыз куйды.

Әхмәтнең әнисе, «улымны яңгылыш атканнар» дип сөйләп, дөреслек эзләп йөри башлаган иде, зәңгәр погонлы бер хәрби сельсоветка чакыртып сөйләшкәч тынды. Аннан авылның исән-имин калган халкын исәпкә алып, барсын да журналга язып, исемлеккә теркәп куйдылар. Һәр кешедән авыл дошман кулында булганда нәрсә эшләгәнен, нинди эш белән шөгыльләнгәнен җентекләп язып алдылар. Исәр яңадан авыл көтүен көтә башлады. Үзләренең өйләре кырындагы бакчага ул да бәрәңге утыртып, башка яшелчәләрне дә чәчеп куйды. Тик түшәктә яткан картәнисе генә көннән-көн аламаланып, хәзер инде тамагына да ашамаска әйләнде.

Май аеның ямьле бер көнендә Исәр тагы кайдадыр гаип булды. Ул көнне авылда көтү чыкмады. Кояш тау башына менеп кунаклагач кына, халык бер үсмер егетне көтү көтәргә үгетләп, малларын куды. Берничә бабай белән күрше хатыннары Сабитның өенә кереп, түшәктә сырхаулап яткан әбидән сораштырып та карадылар. Әби зәгыйфь тавышы белән:

– Белмим шул, оланнар. Кая киткәнен миңа әйтмәде. Ә менә алдагы төнне бик каты елап чыкты. Мин, нигә елыйсың улым, дигәнгә, «мине үтерергә әйтәләр, авыл халкын көтү куган кебек куып алып китәчәкләр, шуңа елыйм», дип кенә җаваплады. Башка бер сүз дә әйтә алмыйм. Каһәр суккан нимес зәхмәтләре тагы килмәсәләр ярый да бит? Шулардан бик курка. Мөгаен, тагы качып ятадыр. Авыл өстенә берәр бәла-каза килмәгәе. Алама хәл йә берәр фаҗига булырын алдан сизә. Бәла агач башыннан йөрми, адәм башыннан йөри. Сак булыгыз оланнар! – дию белән генә чикләнде.

Күрше хатыннары әбинең хәлен аңлап, аңа җылы шулпа керткәннәр иде дә, әби ул шулпадан да авыз итә алмады. Тау үләннәреннән әзерләнгән чәйләрен генә йотты. Әбинең тамагыннан аш үтмәде…

Авыл халкы Исәрне тирә-яктан да эзләп карады. Хәтта кар базларын да тикшереп чыктылар, Исәр табылмады. Әби әйткәннәрдән һәм Исәр һаман табылмаганга халык арасында шомлы хәбәр таралды. Бу нәрсәгә булыр икән диеп, авыл шөбһәләнеп тынып калды. Нindидер бер куркыныч давыл алдыннан гына була торган шомлы тынлык иде бу. Хәтта мәңге тынгы белмәс малайлар да ул көнне урамда уйнап йөрмәде. Әйтерсең лә авыл өстенә нindидер бер кара шәүлә ятты.

Ә иртәгесен, таң атмас борын, авылга немец юлбасарларыннан да хәтәррәк афәт килде. Кара таңнан авылны баштанаяк коралланган Совет солдатлары уратып алды. Китте мәхшәр, китте елаш. Барча халыкны урамга куып чыгарып, көтү куган кебек, авыл читенә җыйдылар. Хәтта таң әтәчләре дә кычкырмаган иде әле. Һәр өйгә кереп, халыкны урамга куган солдатлар:

– Иң кирәк әйберләрегезне генә алыгыз! Теләсә нәрсә күтәрмәгез. Кәгазь-документларыгызны онытмагыз! Сез – татарлар, барыгыз да фашистларга сатылып, аларга хезмәт итүчеләр. Барыгызны да авылдан сөреп, икенче урынга җибәрәләр, – диеп, халыкның котын алдылар.

Партизаннар отрядында фашистларга каршы көрәшеп һәм яраланып фронттан кайткан олы яшьтәге берничә абзый, киреләнеп, нәрсәдер исбатлап:

– Авылдан китмибез. Үлсәк тә шушында үләбез. Без юкка гына нимескә каршы көрәшкәнмени?! Менә орден-медальләребез, – дип каршы әйтә башлаганнар иде

дә, берсен шунда ук атып киттеләр, икенчесенең, приклад белән сугып, кулбаш сөяген сындырдылар. Мондый вәхшилекне күреп торган халык бөтенләй тынып калды. Алар хәрбиләр нәрсә әйтсә, шуны үтәде. Бала-чагалар, хатын-кызлар елашып үкседеләр. Ирләр дәшмичә тешләрен генә кысты. Беркем бернәрсә аңламады. Таң белән барча халыкны Сыңар балак урамы яклап Зәйнәпләр очына чыгарып утырттылар. Утырырга теләмәгәннәрне мылтык түтәсе җиргә чүктерде. Әле җир суык иде. Җитмәсә, кичә генә көчле итеп яңгыр да явып үтте.

Хәрбиләрнең командиры һәм сельсовет хезмәткәре халыкны исемлек буенча барлап чыкты. Халык арасында тик Исәр белән аның картәнисе генә юк иде.

Исәрнең күршеләре:

– Аның шулай югала торган гадәте бар. Контузия галәмәте. Бомбёжка астында калган. Хәзер килеп чыгар. Исәр ул, акылга бертөрлерәк бала, – диештеләр.

Зәңгәр погонлы майор чинындагы хәрби, халыкка ышанмыйча, үзенең ярдәмчесен һәм шул ук сельсовет хезмәткәрен Сабит яшәгән йортны тикшерергә җибәрде. Бераздан тегеләр кире килеп, Исәрне таба алмаганнарын һәм әбинең нинди хәлдә ятканын майорга хәбәр иттеләр. Тегесе:

– Ярар, зыян юк. Әбине махсус команда машина белән килеп алыр. Тегесе дә әллә кая качып китә алмас. Хәзер тотып алырлар, – дип сөйләнде.

Майор сәгатенә әледән-әле караштырды. Куылганнарны алырга килергә тиешле машиналар юк та юк. Бу тиклем халыкны тимер юл стансасына чаклы җәяүләп алып барып җиткерү мөмкин дә түгел. Җитмәсә, юл тауларда үскән урман аша үтә. Качып китү ихтималы бик зур. «Кача-нитә калсалар һәм каршылык күрсәтергә чамаласалар, каушап калмаска! АТАРГА!» дигән боерык кесәдә ята. Качу һәм каршылык күрсәтү турында уйлаучыларның уен аңлаган кебек, ике яклап авызын ачкан, эре калибрлы пулемёт күптән халыкка каратып төзәп куелган. Шулай булса да хәрбиләрнең командиры:

– Каршылык күрсәтү, качып китәргә уйлау, гомумән, урыннан рөхсәтсез тору булса, атабыз! – дип, халыкны алдан ук кисәтеп куйды.

Вакыт шулай үз җае белән сузыла торды. Тәүдә елашкан хатын-кызлар да беразга тынып калды. Авыл халкы үзара тын гына сөйләшеп, төрлечә фараз кылды. Нәрсә булыр бу? Әллә яһүдиләрне фашистлар аткан кебек, безне дә атарга алып бармакчылар микән? Алай дисәң, нигә документ-кәгазьләрне алырга куштылар? Нигә өч көнгә җитәрлек ризык белән юлда кирәге чыгарга мөмкин булган иң кирәкле әйберләрне генә төенчекләргә кушылды? И Ходаем, күкрәк балаларын да атарлар микәнни? Каберне кайда казырлар? Авыл зиратындамы, әллә читтә атарлармы? Ярар, без сатлыкҗан да ди, ә фашистларга каршы партизан отрядында сугышып йөргән теге урамның абзыйларын ни өчен алдылар да теге Булатны нигә атып үтерделәр? Әллә булмаса Совет гаскәрләре киемендәге бу хәрбиләр чынлыкта исә фашист солдатларымы? Алай дисәң, нигә урысча сөйләшәләр? Һәм башкалар, һәм башкалар… Халыкның барчасы аптырауда иде.

Авылның урысча белгән берничә аксакалы майор белән сөйләшергә чамалаганнар иде дә, барып чыкмады. Урыннарыннан торган картларны солдатлар акырып-җикереп һәм суккалап дигәндәй кире утырттылар. Төшкә таба халык тәмам алҗыды. Кемгәдер үз хаҗәтен үтисе бар. Балалы хатыннарга күкрәк сөте белән балаларын туйдырырга кирәк. Мондый эшләр тыгызлап утыртылган авыл халкына һич мөмкин түгел. Бигрәк тә авылда үскән татар хатыннары өчен. Ачлыктан качып, авылга яшәргә килгән берничә шәһәр хатыны, хәрбиләрнең корал төзәп затвор тарткалауларына да карамадылар. Читтәрәк үскән сәрби куагына үзләре белән алган түшәк япмаларын корып, хатыннар өчен бәдрәф кебегрәк урын әзерләделәр. Моны күреп, бер карт солдат майор белән сөйләшеп алгач, ирләргә дә икенче якта шундый ук урын ясарга рөхсәт бирелде.

Хәрби түрә бик ачулы иде. Аңа бит тагы алты авылны яшәгән урыннарыннан сөрергә боерык бирелгән. Ә монда һаман бер авылны тимер юл стансасына алып барып җиткереп булмый. Күктә тәүдә тәннәргә сихәт биреп җылыткан кояш хәзер инде рәхимсез кыздыра башлады. Халык сусады. Балалар ачыктылар. Башта тик кенә утырган балаларның күбесе ачыгып һәм сусап шыңшырга тотынды.

Менә өйлә намазына вакыт җитте. Дин тоткан картларның берсе урыныннан торып, кыйблага карап, азан әйтә башлады. Теге майор, тамагын ертып:

– Молчать, молча-а-ать! Перестаньте петь! – дип кычкырып караса да, барып чыкмады. Карт мулла азан әйтүеннән туктамады. Гүелдәшеп үзара сөйләшеп утырган халык тып-тын калды. Читтәрәк, беркемгә дә игътибар итми, чыркылдашып куышлы уйнаган шук малайлар да тынып, шым гына үз урыннарына барып утырдылар. Түрәләре кушкач, ике кяфер солдат, халык уртасында басып азан әйткән картны туктатырга чамалап, уртага үтәргә тырышып караганнар иде дә, барып чыкмады. Халык шулкадәр тыгызлап утыртылган, алар арасыннан җиңел генә йөрерлек түгел шул. Аннан да бигрәк хатын-кызлар, теге хәрбиләрнең әле аякларына, әле чалбар балакларына ябешеп, аларны уртага үткәрмәделәр. Хәрбиләрнең берсе хәтта хатыннар өстенә егылып ук китте. Торып басарга рөхсәт булмау аркасында авыл халкы барчасы утырып намаз укыды. Барча халыкны аптыратып, теге урамда яшәгән, динсез һәм сәрхуш, тәмәкник Гаффар да, картларга кушылып, намаз укыгандагы хәрәкәтләрне кабатлады. Яраланып яңа гына сугыштан кайткан, мәңге намазга басмаган комсомол һәм коммунист активистлар да тәүдәрәк берән-сәрән генә сәҗдәгә китсәләр, намаз ахырында барысы да халык белән бергә намазларын тәмамлады. Халыкка ничектер җиңелрәк булып китте. Алар өстеннән корал тотып, халыкны атарга әзер торучылардан да өстәрәк, биектә Аллаһ бар бит әле дигән хакыйкатьне искә төшерделәр.

Бала-чага бала-чага инде. Урыннарында утырып түзә аламы соң алар? Тагы чым-чыкыр килеп уйнарга тотындылар. Ә Зәйнәп уенга катышырга уйламады да. Кыз әнисенә кече энеләрен карашты. Үзенә быел унөч яшь тулды. Шулай булуына карамастан, буе яшьтәшләренә караганда бәләкәй. Әмма бик зиһенле һәм откыр кыз булып үсеп килә. Кыз Сабит күршесе турында уйлады. Чөнки Исәр һәрчак кулыннан килгәнчә аларга ярдәм итте. Кайтмый калган малларын да эзләп алып кайта, бәрәңге бакчаларын да казыша. Күршесен күрсә, авызын да җыеп ала алмый елмаер иде. Зәйнәп шул турыда уйлап, кече туганын аягына салып тирбәтеп йоклатканда, әниләренең һәм картәтиләренең үзара сөйләшкәнен ишетеп алды. Әнисе:

– Юкка җәйге көннәрдә аш пешерә торган бәләкәй казанны алмаганбыз. Ичмаса төенчеккә төйнәлгән ярмалардан ботка-мазар булса да пешереп алыр идек, – диеп уфтанды.

– Барыбер ут ягарга рөхсәт булмас иде. Күрмисезмени, ничек ажгыра бит, җаһил, – дип, хәрбиләрне каһәрләделәр. Халык кычкырыша-кычкырыша су сорап ризасызлык белдерә башлагач, майор, берничә ирне, солдатлар каравыллавында, су алып килергә җибәрде. Ярты сәгать тә үтмәде, пожар каланчасы астындагы сарайдан пожар аты белән сулы мичкә алып килделәр. Халык һәм балалар туйганчы су эчте. Халыкны саклаган хәрбиләр дә шул ук мичкәгә тутырылган салкын чишмә суын йотлыгып эчтеләр. Үзләренең биштәрләреннән, америка итләре тутырылган консерваларын алып, төшке аш ашадылар. Тушёнка исе барча халыкның танавын кытыклап, эчтә улый башлаган бүреләрне тагы да котыртып җибәрде. Зәйнәпнең әнисе казан алырга башына килмәүгә үкенде. Кыз тәүдә үзенең кырындагы төенчектән төсләре уңа башлаган яшькелт джемперын алып киде. Картәнисе, аптырап:

– Нәрсә, кызым, әллә шушы эсседә өшергә әйтәсеңме?

– Юк, картинәм, аркамны кояш нык кыздыра башлады. Эссе капмасын, – дию

белән генә чикләнде. Үз ниятен беркемгә дә әйтмәде. Зәйнәп, итәгендә йоклаган бәләкәй энесен картәнисе утырган паласка шудырды да, җайлап-җайлап, куышлы уйнаган балалар төркеменә барып кушылды. Хәзер аның өстендә Хәдичә әбисе теккән матур күлмәге алай еракттан ук ялтырап күренми иде. Уйнаган балаларга хәрбиләрнең бик исләре китмәде. Уйнасыннар, тик эч пошырып елашмасыннар гына! Күпләре балаларга кызыгып карап тора, чөнки аларның да күбесенең өйләрендә балалары бар. Алар да кеше, балаларын сагынганнар. Шунысы гына эчләрен кыра: болар бит барысы да сатлыкҗан басурман балалары.

Төшке ашны ашаган хәрбиләр, майның эссе кояшыннан әлсерәшеп, илле-алтмыш метр читтәрәк йокымсырап утыралар. Берничәсе арырак китеп, бөтенләй йокларга ук ятты, чөнки хәрбиләр төне буе йокламаган иде. Аларны төнлә генә бу авыл кырына машиналар белән китереп бушаттылар һәм, таң алдыннан гына яшерен пакетны ачып, боерык белән таныштырдылар.

Зәйнәп, солдатларның йокымсырап утыруларыннан файдаланып, балаларны җайлап-җайлап иң кырдагы йорт бакчасын уратып алган читән янына ук алып килеп җиткерде. Үзе шук малайларны котыртып, утырган халык тирәли йөгерешеп ярышырга чакырды. Балалар утырган халык тирәли дәррәү чабыша башлады. Ә Зәйнәп, җаен туры китереп, инде хәтсез генә үскән кычыткан, әрекмәннәр арасына чумды. Ничек итсә итте, кычыткannan чагыла-чагыла читәннең астында бер ятеш кенә тишекне зурайтып, икенче ягына үтә алды. Алда тагы берничә ихатаны үтсә, үзләренең йортларына да барып җитә, Аллаһы боерса. Бу тирәдән халык та, аларны саклаган хәрбиләр дә күренми. Кыз, бакчада инде хәтсез генә күтәрелгән бәрәңге сабаклары арасыннан шуышып барды да, тагы бер күршеләренең абзар артына чыккач, үзләренең бакчаларына торып йөгерде. Менә, тыны бетеп, үзләренең йорт алларына килеп керде. Йөгереп барып, япма астындагы пич өстендә утырган ике казанның бәләкәен куптарып алырга чамалады. Ах, кызый ни итсен? Ничек кенә көчәнеп тартса да, казан урыныннан кымшанмады. Көче җитенкерәми икән. Кыз тагы барча көчен җыеп, казанны актарырга тотынды. Юк кына бит әй. Барып чыкмый. Нәрсә белән актарса, алып булыр икән? Шулай аптырап, тирә-ягына каранып, берәр тимер йә булмаса агач кисәге эзли башлады. Шунда колагына:

– Зәйнәп, Зәйнәп! Зәйнәп дип әйтәм бит, – дигән ярым пышылдау тавышы ишетеп, коелып төште. Куркуыннан чак кире чыгып йөгермәде. Теге тавыш абзар эченнән килә иде шикелле? Һәм тавыш тагы кабатланды.

– Зәйнәп, син миннән курыкма. Бу мин – Сабит. Сиңа нәрсә кирәк?

Зәйнәп тә Исәрне тавышыннан таныды. Бераз тынычлана төшеп, тирә-ягына карап алды да аның оңгаена, ярым пышылдауга күчеп:

– Мин синнән курыкмыйм да ул. Син кайда? Үзең нигә куркып качтың? – диеп, кызый башын боргалап, күзе белән Исәрне эзләде. Бераз тынып тордылар. Шуннан Исәр:

– Мин синнән курыкмыйм, тик теге җаһилләр барыбызны да алып китәргә җыена бит, – диде.

Зәйнәп Сабитның кайдалыгын күреп, елмаеп җибәрде. Һәм:

– Курыкмагач, чык монда. Сабит абый, шушы казанны алышырга ярдәм ит.

Сабит, качып торган урыныннан, шикләнеп, тирә-ягына карана-карана, җай гына килеп чыкты. Үзе дикъкать белән нәрсәдер тыңлый иде.

– Син нигә безнең абзарга качтың?

– Сезнең абзарга качмасам, мине дә алып китәләр. Мин киткәч, картәнине кем карар? Картәни авырый бит. Озакламый әниләр янына, теге дөньяга китәргә җыена. Берүзенә аның бик кыен булачак. Аны кем юындырыр, кем ашатыр? – диеп сөйләнде.

Сабит кызчык кырына килеп басты да карашын кызның чем-кара күзләренә төрәде. Әйтерсең лә кыз йөрәгенә аның күзләре аша үтеп керергә тели иде. Моны сиземләп алган кыз, кызарып, карашларын казанга күчерде.

– Сабит абый, монавы казанны актарып алып бир әле, – диде.

– Казан сиңа нәрсәгә? Сезне бит барыбер еракка алып китәләр. Син китмә. Монда кал, – дип, ялварулы тавыш белән кызның йөзеннән карашын ала алмыйча, якын ук килде. Зәйнәп, моны күңеле белән сизеп, тагы да ныграк кызарды.

– Сабит абый, зинһар өчен дип әйтәм, алып бир инде. Анда барчасы да ачыкты. Балаларга ботка пешерергә казан да юк. Рөхсәт итсәләр, теге урамнар бер чиләктә аш пешерергә чамалыйлар, ахыры. Ә безнекеләрдә бер әйбер дә юк, – дигәч, Исәр «эх» тә итми пич өстендә утырган казаннарның Зәйнәп күрсәткәнен актарып, кыз алдына китереп тә куйды. Һәм:

– Икенчесен дә алып биримме? – дип, тагы кызның тумыштан ук сөрмәле төпсез күзләренә текәлде.

Зәйнәпкә бу мизгелдә Исәр әйтерсең лә Галәветдин лампасыннан чыгып, аның теләсә нинди теләген үтәргә әзер торган бик сөйкемле гыйфрит малае иде. Шуны уйлап, кыз бераз көлемсерәп тә куйды. Кызның йөзендәге елмаю чаткыларын күреп, исәр тагы да кыюланып:

– Зәйнәп, син башкалар белән китмә, – диде дә, әзрәк тынып торгач, хәзер инде кызның күзләренә карамый гына дәвам итеп:

– Зәйнәп… мин бит сине… яратам. Юкка гына мине Исәр диеп теге оч малайлары ирештерә. Мин бит бу җаһилләрнең киләсен дә, барча халыкны алып китәсен дә алдан сизәм. Мин укый да, яза да беләм әле. Менә кара, – диде дә, иелеп, Зәйнәп алдындагы туфракка, «Зәйнәп, Сабит сине ярата!» дип язып та куйды.

Зәйнәп бөтенләй кызарып, чак ишетелер-ишетелмәс:

– Беләм, Сабит абый, беләм. Тик мин китим инде, анда энеләрем, картәниләр ачыктылар. Казанны алып барыйм, – диеп, җиздән коеп эшләнгән казанның колакчыгына тагылган чылбырыннан күтәреп, бәрәңге бакчаларына таба атлап китте.

Исәр Зәйнәпкә карап һәм йөрәгеннән чыккан бик әрнүле тавыш белән:

– Зәйнәп! Китмә! Сиңа анда кыен булачак. Бик кыен булачак. Монда икәү яшәрбез. Син булсаң, картәни дә терелер, – дип, еламсырап дигәндәй Зәйнәпкә ялынып, артыннан карап калды. Тик кыз гына һаман алга атлавын белде. Арт капкага җиткәч, нәрсәдер уйлап туктады да, Исәргә карамый гына:

– Мин бит әле бәләкәй. Аннан әниләр дә мине югалтса еларлар, – дип куйды. Шуны гына көткән Исәр, кыз янына йөгереп килеп җитте дә:

– Беләм, Зәйнәп, беләм. Үсәрсең. Мин озак көтәргә дә риза. Тик монда гына кал, – дип, кыз кулындагы казанның икенче ягыннан килеп тотты.

Зәйнәп казанны үзенә таба тартты, тик Исәр генә казанны ычкындырмый:

– Зәйнәп, Зәйнәп! Кал минем белән, бергә яшәрбез, – дип кабатлады.

Кыз инде үзенең тукталып калганына үкенә башлап һәм Сабит күршесе аны җибәрмәс диеп куркып:

– Сабит абый, җибәр инде. Мин әнидән сорап булса да килим, – диеп хәйләләргә үк тотынды. Исәр кинәт кенә казанны үзе күтәреп алды да кайда иелеп, кайда шуышып дигәндәй ихата-киртәләрне үтеп, азаккы читән артына чаклы кызчыкны озатып куйды.

– Зәйнәп, мин бит сине яратам, – дип пышылдады.

Кызый бая читән астыннан шуышып чыккан урыныннан казанны аяклары белән этәреп, теге якка шудырды. Үзе читән астыннан шуып чыга башлаганда өстенә кигән джемперы, читәнгә эләгеп, һич ычкынырга теләмәде. Моны күреп

Исәр шуышып килде дә кызның киемен читән ботагыннан ычкындырырга чамалады. Шул чакны кыз үрелеп Исәрнең битеннән үбеп алды.

– Сабит абый, мин дә сине яратам, – диде дә ялт кына тишектән теге якка шуып чыкты. Һәм серле сүзләрен дәвам итеп: – Тәүге килгән чагыңнан ук яратам. Хуш, Сабит абый, хуш! – дип пышылдады.

Сабит ни эшләргә дә белми кызга берчә аптырап, берчә мәхәббәт тулы карашы белән аның күзләренә текәлде. Шунда кызның читән казыгына тотынып торган кулын шәйләп, аның бармакларына иренен терәде. Кызыкай кулын тартып алмады. Шуңа да Исәр, Зәйнәпнең бармакларын үзенең зур кулына йомшак кына алып, тагы пышылдарга тотынды:

– Зәйнәп, тукта, ашыкма. Мин сиңа менә нәрсә бирәм… Бу минем бүләгем. Сиңа дип сакладым. Беркемгә дә күрсәтмә! – диде дә, чалбарының кайсыдыр үзе генә белгән ямау астыннан баш бармак зурлык кына төенләнгән яшел тасма тартып чыгарды. Аннары кызның учына салып, үзенең кытыршы куллары белән аның учын йомшак кына кысты. Һәм тагы пышылдап:

– Син әниеңә әйт тә кире кил. Яме!

Кызый кулын Исәрнең учыннан җай гына тартып алып, читәннән читкә шуыша башлады. Бераздан егетнең еламсырап дәшкән пышылдавын ишетеп, артына борылып карады. Исәр:

– Зәйнәп, кил яме. Кире кил. Әгәр син килмәсәң, мине үтерәләр бит, – диеп читәннең теге ягында ике яңагын алмаш-тилмәш чәбәкли-чәбәкли еламсырап кабатларга тотынды. Егет чынлап та елый иде. Күз яшьләрен кызга күрсәтмәскә була, хәзер инде җиргә үк капланды. Исәрнең елаганын кызчык аның аркалары дерелдәп куюыннан аңлады. Үзенең дә күзеннән яшьләре атылып чыгып, ул, ирексездән, казан төбендәге корымга буялган куллары белән битенә тәгәрәп төшкән яшьләрен сөртте. Зәйнәп тә шушы минутта аңлап, күңеле белән сизенде, алар башкача күрешмәсләр инде.

– Хуш, минем Сабит абыем! Хуш, минем Исәрем, минем мәхәббәтем, – диеп кабатлый иде бу яшь кенә үсмер кызның иреннәре.

Шул сүзләрне эчтән кабатлый-кабатлый, кыз үзенең тәкъдиренә буйсынып, шуыша-шуыша, әрекмән, кычыткан үскән баягы чокыр кырына да килеп җитте. Әмма әниләре янына барырга җае гына туры килми торды. Менә җае да чыкты. Тау ягыннан, алар китәсе юлдан, ике җайдак күренде. Болар да баштанаяк коралланган хәрби кешеләр иде. Җайдакларны авыл халкын саклаучылар да күреп калды. Солдатлар җанланышып, шаулашып алдылар да утырган җирләреннән торып бастылар. Зур таш өстенә пулемётларын халыкка төзәп куйган сакчылар да, бар нәрсәләрен онытып, килгән атлыларны күзәтә башлады. Зәйнәп, нәкъ шул чакны җаен туры китереп, үзе кырыннан йөгерешеп үткән балалар төркеменә казанын күтәреп килеп кушыла алды.

Балалар, пичтән чыккан пәри баласы кебек пычранган кызны күреп, тәүдә аптырашып тын калдылар, аннары Зәйнәпне танып, тагы чыркылдашып көлешергә тотындылар. Зәйнәп, берсенә дә игътибар итми, тиз үк әнисе кырына барып чүгәләде. Бая ук кызыннан күз яздырган ана, Зәйнәпне балалар арасында күрмичә коты очып, тавыш күтәрергә әзерләнеп беткән иде. Бөтенләй морҗа пумаласы кебек пычранган һәм итәге ертылган кызын күреп, әни кеше тәүдә Зәйнәпне әрләргә тотынды. Тик, ул өстерәгән бәләкәй җиз казанны шәйләп, кызын кочаклап, шатлыгыннан елап җибәрде. Чөнки белә иде, сакчылар Зәйнәпне күреп калсалар, ике дә уйлап тормый һәлак итүләре мөмкин иде бит.

Менә җайдаклар сакчылар кырына ук килеп, берсе майорга нindидер пакет тапшырды да бүген машиналар булмасын әйтеп, җыелган халыкны тагы да ныграк сакларга кирәклеген искәртте. Тапшырылган пакетны иртәгә төгәл сәгать

иртәнге сигездә генә ачарга кушты һәм бу җайдаклар тагы да алга таба үз эшләре белән китеп бардылар. Тегеләр хәтсез генә китеп, сүзләр ишетелмәячәгенә тәмам инанган майор аларны катлы-катлы сүгенеп озатып калды.

Кич җитте. Халык бик тә нык шаулаша башлап, ашарга әзерләргә һәм җылыныр өчен ут ягарга кирәклеген таләп итте. Сакчылар да үзара сөйләшеп киңәшләшкәч, рөхсәт бирделәр. Чөнки ут яктысында качарга җыенучыларны алдан ук күреп калырга мөмкинлек туачак. Кем белсен, караңгыда меңгә якын халык әллә нәрсәләр эшләп ташларга мөмкин. Ул инде мондагы халык карт-коры, хатын-кыз белән бала-чага гына булсалар да – барысы да сатлыкҗаннар. Хөкүмәт шулай диеп карар чыгаргач, бу дөрес инде. Якындагы бер абзарны сүтеп, куылучы халык утырган урынга көндез су ташыган ат белән утын китереп ташладылар. Абзар хуҗасы үзенең абзарын сүткәнгә тавыш күтәрергә чамалаган иде дә, авылдашлары: «Кире кайткан көе бөтен авыл белән таштан яңа абзар салып бирербез», – диеп бердәм вәгъдә иткәч, тынып калды. Һәркем үзенең туган авылына озакламый кире кайтырбыз әле дигән өметтә иде. Зәйнәп алып килгән казан белән, кулдан-кулга дигәндәй йөртеп, бала-чагага булган кадәр һәм булдыралган чаклы ризык пешереп ашаттылар. Тик, бүген көтүгә куылмаган сыер-кәҗәләр генә, хуҗаларын чакырып, абзарда акырыштылар. Аларның шулай кычкырышуы кичке буш авыл өстеннән үтеп, әллә кайларга чаклы яңгырап, тауларга таралды. Бу җан өшеткеч тавышлар авыл халкының йөрәгенә утлы ук булып кадалды. Һәм ниндидер шомлы искәртү кебек тоелды. Бүгеннән башлап халык ниндидер билгесез һәм коточкыч аянычлы яңа тормыш белән яши башлады.

Кемдә нәрсә бар, балаларны шуның белән төреп, йокларга салдылар. Халык төне буе керфек тә какмады. Аларның хәле йокларлык түгел иде. Таң атмастан бу якларда май айларында еш була торган куе күкшел томан төште. Бүген ул бигрәк тә куе, хәтта бит-күзләргә сылашып тора иде. Таң атып, яктыра башласа да, кул сузымы җирдән бернәрсә дә чамаларлык түгел. Менә томан таралырга итә башлады. Шул чакта авыл халкын таң калдырырлык бик тә гаҗәеп нәрсә булып алды: халык кырында өсләренә чүпрәк капланган өч чиләк яңа сауган сөт белән әпәй һәм яртышар итеп төрле-төрле ярмалар салынган ике капчык пәйда булган. Сакчылар ничаклы уяу сакласалар да, беркем дә сизмәгән. Барысы да аптырашта калды һәм нәрсә уйларга да, ни дип фаразларга да белмәделәр. Тик Зәйнәп кенә әнисенә:

– Исәр китергән, – диде.

Әнисенең: «Кайдан беләсең?» – диюенә:

– Беләм инде. Сабит картинәсен саклый. Кичә казанны ул актарып алып бирде. Минем көчем җитмәс иде. Ул безнең абзар башында качып ята, – дип пышылдады, бер дә әһәмият бирмәгән төсле. Тик битенә генә сизелер-сизелмәс кызыллык йөгерде.

Әнисе күрше йортта түшәктә яткан карчыкны уйлап, догалар укып, Аллаһтан бу әбине үзенең рәхмәтеннән ташламавын үтенде. Менә әкренләп томан тарала башлады. Катлы-катлы булып катланды һәм җай гына диңгез ягына шуышты. Шул чакны каршы як тауга авыл көтүенең әкрен генә менеп барганы да томан катламы аша күренеп-күренеп калды. Бик тә гаҗәеп күренеш иде. Әйтерсең лә көтү томан өстеннән, җай гына йөзеп, кайдадыр китеп бара. Мираж дисәң, мираж түгел, ниндидер бер бик сәер күренеш иде… Барча халык тәүдә бу ни гыйльлә, әллә томан катламы аша күзебезгә генә күренә инде диеп торганда, кайдадыр бик еракта, тын һаваны тибрәтеп, әкрен генә бик моңлы итеп курай тавышы ишетелде. Шунда гына халык айнып китеп:

– Исәр бу! Исәр авыл көтүен көтәргә алып чыккан. И бахыркаем, ул, күрәсең, качкан җиреннән авылга кайткан, – диешеп, үзара пышылдашты. Бик

ерактан яңгыраган бу курай тавышын халыкны саклаган хәрбиләр дә ишетеп алдылар һәм, таулар арасындагы томан өстеннән йөзеп барган көтүне күреп, алар бөтенләй шөбһәләнеп күзәттеләр. Үзенең дулкынлануын баса алмыйча, майор, тау буенда йөзеп барган көтүгә карап, пулемёттан ут сиптерергә боерды. Курай тавышы берара тынып калды. Хәрби түзмичә, кичәге фельдъегерьләр калдырган пакетны вакытыннан алда ачты һәм, ямьсез сүгенеп, өстәге түрәләрне әрләде. Боерыкта машиналар юклыкка сылтап, куылучыларны җәяүләп моннан утыз чакрымнар чамасы ераклыкта үтә торган олы юлга алып чыгарга кушылган. Тагы да карышучыларны һәм фетнә таратучыларны кичектергесез, урында ук атарга боерылган иде.

Менә халыкка торып басарга кушылды. Авылда мулла исәпләнгән Сәлмән карт азан әйтергә тотынды. Майор үзенең солдатларына бабайны тиз арада туктатырга кушып, боерык бирде. Ярый әле араларында олы яшьтәге теге солдат, түрәсе кырына килеп:

– Берүк бабайга тия күрмәгез. Алар авыллары белән шулай хушлашалар. Җырласыннар әйдә. Югыйсә дөнья хәлен белеп булмый, барчасы берьюлы безгә ташланырга мөмкиннәр. Аннан бу кыргый татарларны тотып тыярмын димә. Үлгәннәрен дә белмәячәкләр. Берүк каршы булмагыз. Безгә аларны исемлектә күпме бар, шул чаклысын исән-сау стансага тиклем алып барып җиткерергә кушылган. Алла сакласын! Бу халык барсы берьюлы җенләнә башласа, әллә кайда китә алмыйсың, – дигәч, хәрби түрә үзенең тәүдә биргән боерыгын кире алды. Эчтән генә: «Картлач дөрес әйтә. Бу сатлыкҗан орда калдыгын, дуласа, тотып тыярмын димә. Кырагай түмәрләр», дип уйлады. Бу майор татарлар яшәмәгән урыс өлкәсендәге шәһәрдә үскән бер бәндә булып, миһербанлылыкның ни икәнен белмәгән бер нәрсә. Кыскасы, органнарда эшләп, карьера өчен, кушсалар, туган анасын да шушы татарлар арасына кушып сөрергә әзер булган ерткыч иде. Юкка гынамыни, аның Совет хөкүмәтенә тугрылыгын сынар өчен, 1937 елны ниндидер булмаган гаеп табып кулга алынган апасы белән җизнәсен атарга кушканнар иде. Ике дә уйламый:

– Революция һәм халык дошманнарына, кем булуына карамастан, тик үлем генә, – дип, бертуган апасы һәм җизнәсенә алтатырындагы пулялары беткәнче лепкәләренә атты. Җитмәсә, үләр алдыннан апасы, энесенең битенә төкереп:

– Иблис калдыгы, – дигәч:

– Теге дөньяда да табып, бу сүзләрең өчен тагы бер тапкыр атачакмын, – диеп тешен ыржайтты.

Кыскасы, бу бәндә, эт дисәң – йоны юк, кеше дисәң – юне юк, бер иблис калдыгы иде.

Азаннан соң барча халык муллага ияреп тәкъбир әйтергә тотынды. Һәм шул оңгайдан тәкъбир сүзләрен әйтә-әйтә юлга кузгалдылар. Халык елый иде. Һәм тәкъбир авазы хәзер инде томаны бөтенләй таралган саф һавада әллә кайларга ишетелде. Авыл күздән югалганда, таулар арасыннан яңадан курай тавышы яңгырады. Бик тә моңлы, авыл халкы моңарчы ишетмәгән борынгы татар көе үзәкләрне өзде. Сабит үзен сыендырган, хәзер кайдадыр билгесезлеккә куылып китеп барган авылдашлары белән менә шулай саубуллашты.

Исәр авылда картәнисе белән генә калды. Барча хәлне үзенчә аңлап, көн дә сыер-сарыкларны көтүгә алып чыкты. Берничә сыерны сауган булды. Барча авыл сыерын савып бетерә алмаслыгын аңлап, саудырган сыерларга бозауларын кушты. Авылда калган этләрнең барсын да бәйдән ычкындырып чыкты. Хуҗалары барда нинди генә усал булып күренгән этләр дә аңа берсүзсез буйсындылар. Хәтта кулларын ялап, койрыкларын болгап, аңа рәхмәтләрен үзләренчә – этчә җиткерәләр иде. Хуҗаларын сагынып шыңшып, кайчагында улашып алган этләрдән башка авылда һичкем юк.

Беркөнне Сабит елга буена төшеп, көне буе шунда качып утырды. Куркуы бушка булмаган икән, төш алдыннан авылга бер төркем хәрбиләр килеп, өйдән-өйгә кереп, барча йортны тентеп чыктылар. Чакырылмаган кунакларга амалап чыккан берничә этне атып ектылар. Яраланган этләрнең чинашып елашкан тавышына башка этләр, койрыкларын бот арасына кысып, дәшми генә шыңшып, кайсысы кая качып бетте. Авылны тентеп йөрүчеләр Сабитлар өенә дә кереп чыкты. Үзләренең командирларына бер чирле карчыкның тора да, юньләп сөйләшә дә алмый түшәктә авырып ятканын хәбәр иттеләр. Тегесе кереп карап, тикшереп чыкты да ярдәмчесенә әбинең чигәсенә пуля җибәрергә кушты. Анысы:

– Иван Васильевич, нигә шул тере сөлдәгә пуля әрәм итәргә? Үзе дә дөмегәчәк. Кулны пычратасы килми. Әле генә чишмә суы белән юынган идем. Әйдәгез, әнә солдатлар бер йортның кар базыннан берничә дистә ел сакланган бик яхшы шәраб тапканнар. Авыз итик шуннан. Җитмәсә, төшке ашка каз, сарык ите пешергәннәр. Шәп! – диде.

Чынлап та, тегесенең карыны ачкан иде. Һәм ул, ярдәмчесенең сүзен тыңлап, солдатлары урнашкан бер бай гына йортка таба атлады.

Качып калучылар юк микән диеп авылны тентегән солдатлар китте. Сабит кача-поса кире өйләренә кайтып кергәч, картәнисе, туранын аптыратып, яткан җиреннән торып утырды. Һәм егетне бераз шелтәләп тә алды:

– Кайда йөрисең, улым? Чәй куяр идең.

– Хәзер чәй кайнатам. Мин теге җаһилләрдән качып яттым. Югыйсә, мине дә куып алып китәләр иде. Мин китсәм, сине кем карар? Юк, мин китмим, – дип сөйләнде.

Әби тураны сөйләгәннәрдән бернәрсә дә аңламады шикелле. Әзрәк дәшми торгач:

– Чәй куйдыңмы? – дип сорады.

– Әйе, куям.

– Бар, алайса абыстайны – мулла әбисен алып кил. Шуннан Сәгыйдә әбиеңне, Сабира апаң белән Тәнзилә апаңны чакыр, – диде.

Сабит картәнисенә бераз гына аптыраулы карап торды да:

– Алар берсе дә юк. Барысын да алып киттеләр, – диде. Үзе самавыр морҗасына күмер тутырып, чыра белән ут куеп булаша иде. Картәнисе тагы:

– Нәрсә сөйлисең, улым? Кая китсеннәр алар?! Миңа үләргә вакыт җитте. Җаным тәнемдә чакта берәрсе «Ясин» чыксын. Үлемтеккә дип әзерләгән әйберләрем сандыкта. Шул-шул як мөештә. Шуннан алырлар. Хәергә әллә нәрсә юк инде. – Туктап хәл алгандай итте. – Булган әйберләрне сандык төбеннән үзләре хәстәрләп алырлар. Мин үлгәч, әллә кая китмә. Көтү көтә беләсең. Авыл көтүен көтәрсең. Сугыш беткәч, туган-тумачаны Казан артындагы шул-шул авылдан эзләп табарсың. Мин барсын да язып, Коръән эченә куйдым. Хәтереңә сеңдереп куй! Барча язылган адрес-кәгазьләр Коръән эчендә, – дип һаман үзенекен сөйләде.

Сабит картәнисенең авылдагы хәлләрне белмәвенә гаҗәпсенебрәк:

– Картәни, авылдагы барча халыкны стансага куып алып киттеләр. Без икәү генә калдык, – диюенә, картәнисе эчтән генә, бу бала тагы алышынырга әйтә микәнни? – дип уйлап куйды һәм, нәрсәдер исенә төшереп:

– Бар, бар, әбиләргә хәбәр ит. Җаным авызыма килеп терәлгән инде минем. Теге таулар арасындагы апаңнарга да әйтергә кирәк. Тиз килеп җитсеннәр, – диде.

Сабит картәнисенә барча хәлне иплән аңлатып та бирә алмады. Үзенең аңы белән, картәнисе дә аны ялгыз калдырып китәргә җыена ахры, диеп уйлап шөбһәләнде. Шулай да картәнисе әйткәч, таулар арасындагы авылда яшәгән апаларына хәбәр бирергә булып өйдән чыгып китте. Әби дә аңа башкача сүз сөйләп торырлык хәлдә түгел иде. Озак сөйләшүдән арып, кире урынына ятты.

Сабит кыш көне барып кунак булган апалары яшәгән авылга чыгып йөгерде. Юлны белә. Гомумән, ул, берәр кая барырга булса, гел йөгереп йөри иде. Әле дә шулай итте. Тик ул әле апалары яшәгән авылдагы кешеләрне дә куып алып киткәннәрен белми иде. Менә Исәр авылга барып керде. Тик авыл урамында тотрыксыз искән җилгә ияреп ертылган дәфтәр битләре һәм гәзит кисәкләре генә очып йөри. Анда-санда очраган этләр дә тизрәк берәр кая качып китү җаен карадылар. Тау буендагы сыерлар һәм башка маллар гына кайда керергә, кемгә барып бәрелергә белмичә кешеләрне эзләп йөргән Исәрне мөгрәшеп каршы алдылар. Бу авылда да кот очырырлык тынлык иде. Тик бар дөньяга битараф булган әтәч кенә, тавыкларын дәртләндереп, киртәгә басып кычкыруын белде. Бу авылда да һичбер адәмне очратырмын димә. Исәр, апаларын тапмагач һәм бу кешесез авылдагы шомлы тынлыктан, үзенең барча галәмгә ялгыз калачагын аңлады. Коты алынып, елый-елый кире авылларына торып чапты. Барча дөньяда Сабит һәм кайда барып бәрелергә белмәгән йорт хайваннары гына. Җитмәсә, хуҗаларын югалткан хайваннарның берничәсе Сабитка иярергә чамалады. Егет, бар көченә кайтыр якка торып йөгергәч, артыннан кычкырышып озатып калдылар.

Сабит үзенә төбәлгән карашны әллә кайдан сизеп алды һәм, туктап, тирә-ягына каранды. Алда, ерактагы юл борылышында, өч-дүрт атлыны күреп калды һәм тизрәк читкә, елгага таба торып йөгерде. Исәбе: ничек булса да елга буенда үскән таллар арасына тизрәк кереп яшеренү иде. Тик җайдаклар да аны күптән шәйләгән булганнар, ахры, атларын чаптырып, артыннан куа төштеләр. Бу үсмер егет менә-менә таллар артына кереп яшеренәчәк. Куып җитә алмаячакларын аңлап, туктадылар да аркаларындагы карабиннарын алып, Исәрнең артыннан ата башладылар. Сабит, инде таллар арасына яшерендем дигәндә генә, гөрселдәп җиргә барып төште.

Атлы хәрбиләр дә атуларыннан туктап: «Кемнең пулясы бу кырагай сатлыкҗан татар баласын аяктан екты», диеп бәхәсләшергә тотындылар. Берсе:

– Мин барыгыздан да төз атам. Минеке тиде, – диде.

– Юк, минеке тиде, мин – Ворошилов укчысы, – диеп, икенчесе күкрәгендәге калай билгегә төртеп күрсәтте. Бер-берсе белән кычкырышып, сүзгә килделәр.

Шулай да малайның үлеме, тереме икәнен белешергә була, җай гына атларын атлатып, Сабит егылган җиргә бардылар. Тик яшел үләндә аның хәтсез генә агарга өлгергән кан эзләреннән башка берни тапмадылар. Чөнки Исәр, егылган көе шуышып, кырда гына аккан тау елгасына тәгәрәп төште. Каршы ярга инде менеп җиттем дигәндә – тагы суга тәгәрәде. Бу турыдан ярга менә алмасын аңлагач, суга төшеп, су оңгаена кайда агып, кайда тәгәрәп дигәндәй ары китте дә су өстенә үк ятып үскән бер тал ботагына тотынып, тал тамырлары астына кереп яшеренде. Хәрбиләрнең атлары текә генә ярлы, ташлар арасыннан шарлап аккан суга төшәргә теләмәде. Солдатлар да, үләнгә буялган һәм җиргә хәтсез генә аккан канны күреп:

– Кайда китсен ул. Җәрәхәте үлемечле. Качып киткән икән, аңа шул кирәк. Этләшеп, җәфаланып үләчәк. Кемгә хаҗәт бер сатлыкҗан татар баласы?!

– Беркем дә ярдәм итмәячәк. Бөтен Кырым адәми заттан азат. Без генә монда хуҗа.

– Очраса да, тик безнең солдатларга гына очрар.

– Ярар, бу турыда сүз куертмыйк. Без беркемне дә күрмәдек, безгә беркем дә очрамады, – дип сөйләнделәр дә ары киттеләр. Һәм малай турында инде онытып, икенче – үзләренә мөһимрәк бүтән нәрсәләр турында сөйләшә башладылар.

Кем кайда нинди көмеш беләзек эләктергән дә, кем акча, алтын йөзек һәм алкалар...

Сабит өйләренә төнлә генә чак, көч-хәл белән кайтып керде. Ул кайтканда әби күптән суынып беткән иде. Исәр үзенең яралы аягын һәм корсагын таза чүпрәк белән бәйләп куйды. Тик билдән кереп корсактан чыккан ядрә җәрәхәте генә үтереп авыртырга тотынды.

Икенче көнне Сабит, бернәрсәгә карамый, кара таңнан зиратка барып, картәнисенә кабер казыды. Хәле юк. Ничек итсә итте, шартына китереп анысын да казып куйды. Казылган кабер кырында хәтсез генә уйланып утырды. Хәл җыйды. Әзрәк елап та алды. Күзендә яшьләре күптән кибеп беткән. Ул тик сулкылдап, калтыранып, тирән итеп тын алып кына куя иде. Үзенең яраларын уйлап, әле яңа гына казылган каберне тагы да әзрәк зурайтты. Килештереп ләхетен дә алды. Аннан өйгә кайтып, бөтен нечкәлекләрен белмәсә дә, сандыктан картәнисе әйткән әйберләрне алып, мәетнең кырына тезеп әзерләп куйды.

Шуннан нәрсәдер исенә төшереп, авылдагы мулла йортына китте. Өйнең ишеге биксез иде. Гомумән, бу авылда өйне бикләп йөрү гадәте юк. Ишеккә берәр нәрсә сөяп кенә куялар. Ул өй эченә кереп каранып торды да чыгып бусагага утырып уйга калды. Бу йортка нәрсәгә килгәнен дә аерым гына әйтә алмас иде. Корсактагы ярасы түзеп торгысыз сызлый. Менә кайдандыр бер мәче баласы килеп чыкты һәм Исәрнең аягына сырпаланып мияуларга тотынды. Ачыккан, ахры…

Сабитның күзе әле язылырга өлгермәгән бер зур гына кабер ташына төште. Ул таш кырында торган бәләкәй кул арбасына ташны көчкә-көчкә күтәреп салды. Артык көчәнүдән, корсагындагы ярасыннан тагы кан саркырга тотынды. Хәле юк, бусагага утырып тагы хәл алды. Кырында сырпаланган мәче баласына өйдән инде ката башлаган күмәч кисәге чыгарып бирде. Мәченең мырылдый-мырылдый күмәчне кимерүен бераз карап утырды. Тагы тирә-ягына күз салды. Мулла абзый, күрәсең, кемгәдер таш язарга әзерләнгән булган. Шунда ук әрҗәсе белән эш кораллары да тора. Сабит, ташка яза торган коралларны да арбага урнаштырып, әкрен генә зиратка юл алды. Арбадагы әйберләрне әзер кабер кырына илтеп бушатты.

Хәзер инде өйгә кайтып, картәнисен соңгы юлга әзерлисе бар. Үзе күргән-белгәннәрен исенә төшереп, әбине күлмәкләре өстеннән кәфенләде. Мәетне бәләкәй арбага чыгарып салды. Аның өстенә Зәйнәпнең әнисе биргән иске генә кәүирне япты. Әби картлыктан һәм ничәмә көннәр ашамаудан бөтенләй кибеп, җиңеләеп калган. Тик Исәрнең генә хәле бөтенләй бетте. Җитмәсә, каберлек авылдан читтә урнашкан бер биек кенә калкулык өстендә. Кайда мүкәйләп, кайда шуышып дигәндәй, бәләкәй арбаны көчкә зиратка алып барып җиткерә алды. Көне шуның белән үтте.

Төнлә, картәнисен төргән кәүирнең бер кырына төренеп, уяулы-саташулы зиратта кунды. Элек зираттан һәм үлгән кешеләрдән бик курка торган иде. Курку күптән китте. Аңа тик кадерле картәнисен, бу галәмдә бердәнбер якын кешесен, ничек тә соңгы юлга кадерләп озатырга кирәк! Исәр шул турыда гына уйлады.

Икенче көнне иртән үк, шартына китереп, мәетне ләхеткә урнаштырды һәм ләхет авызын каплады. Тик каберне бөтенләй үк күммәде. Үзенә дә картәнисе кырыннан урын калдырды… Картәнисе көчләп дигәндәй өйрәткән «Әлхәм» белән тагы берничә доганы эчтән генә кабатлаган булды. Амин тотты. Шуннан, каберлектә мулланың көйләп укыганын исенә төшереп, догаларны көйләп укырга чамалап, ниндидер бер көйгә охшатып мөгрәргә тотынды. Укып беткәч, «әппәр» итеп куйды да тагы уйга калды.

Хәзер нишләргә? Хәзер нишләргә? дигән сорауны үзенә кат-кат биреп утырды да, кинәт кенә исенә төшеп, кичә алып килгән ташка барып тотынды. Таш эшкәртә торган кораллар белән яза башлады. Хәле бөтенләй бетеп, саташулы йокыга да китkәләде. Исенә килеп, тагы үзе булдыра алганча, ташка хәрефләр чокырга тотынды. Зират эчендә бүген көне буе тук-тук... тук-тук

тукылдау тавышы ишетелеп торды. Ташка хәрефләр тезгән тавыш, күңелгә ниндидер шом салып, бөтенләй күз бәйләнеп караңгы куерганчы, авыл өстенә таралды. Тук-тук…тук-тук…

Бүген Зәйнәпләрнең эте дә Сабит кырында кунды. Исәр кичәге кебек, картәнисен төреп алып килгән кәүиргә уранып ятты. Ә эт аның аркасына терәлде. Шуңа да Исәргә бүген җылырак булды. Һәм ул эт белән, дусты белән гәпләшкән кебек, сөйләште. Аның белән киңәшләште.

Җәрәхәт тишеге бөтенләй каралып чыкты. Ярадан аккан кан туктамады. Җай гына саркыды. Хәзер инде аннан бөтенләй эренле сүл килә башлады. Исәр үзенең әҗәле менә-менә килеп җитәрен сизенә иде. Шуңа да ашыкты. Ташка язып бетергәч, картәнисенең баш очына бик әйбәтләп җиргә казып утыртты. Кабер эченә булдыра алган кадәр туфрак тутырып, ләхет кырын казып тирәнәйтте һәм үзе шунда кереп ятты. Җир суык иде. Өшүдән уянып китеп, көчкә кабердән чыкты да читтә генә яткан кәүир-паласны бөкләп астына салды. Бер ягын өстенә япты. Болай җылырак иде. Сабит хәлсез куллары белән үзенең аякларына туфрак өйде. Шуннан бөтенләй сузылып ятып, кәүир астыннан бер кулын гына чыгарып үзен туфрак белән күмә башлады. Хәле бөтенләй бетеп, туктап калды. Яңадан исенә килеп, тагы үз-үзен күмәргә чамалап, бертуктаусыз теге догаларны укый-укый, туфракны үз өстенә сыпырды. Аңын югалтып, чираттагы тирән йокыга талудан бүтән уянмады…

Бу эшләргә шаһит булып, кабер кырында яткан эте генә кичләтеп, буш авылны яңгыратып, сузып улап җибәрде дә тынып калды. Авылда этләр күп булмыйча, биш-алтысын теге кара таңда ук аттылар. Аннан берничәсен, хуҗаларын озатып иярә баргач, юлда үтереп калдырдылар. Калганнарын авылны тикшерергә килгәннәргә амалап каршы чыккан өчен аттылар. Шулай итеп, хәзер авылда теге урамнан бер-ике эт һәм бу «Сыңар балак» урамыннан Зәйнәпләрнең генә эте исән иде. Зәйнәпләрнең эте шулай улап, елый-елый Сабит күршесе белән хушлашты. Аңа кушылып, теге урамда исән калган тагы ике эт тә елады.

Сабит үлгәннән соң да әле күрше эте каберлекне саклап байтак төн кунды. Һавада мәет исен сизеп очып йөргән козгыннарны кабер янына якын китермәде.

Бер төнне бик каты итеп яшенләп яңгыр яуды. Яшен уклары чатыр-чотыр килеп барча һаваны кискәләде, дөбердәп күк күкрәде. Сабит яткан һәм күмелеп бетмәгән кабер кырындагы туфрак яңгыр суларына җебеп, кабергә ишелеп төште. Шулай итеп, табигать, соңлап булса да, үзе үк Сабитны җирләшергә ярдәм итте.

Яңгырдан соң икенче көнне Зәйнәпләрнең эте, ялгызлыкка түзә алмыйча, тагы кабер кырына килеп ятты. Ишелгән каберне карап, озак кына шыңшып торды. Менә кабер өстендәге туфрак аз гына селкенгәндәй булды. Эт сагайды! Аннан бер бөҗәкме, әллә коңгыз инде – килеп чыкты. Юк, бу бер кырмыска баласы иде. Бик этләшеп килеп чыкты, чөнки өстенә өелгән туфрак тавы бик авыр булып, ул чак өскә күтәрелә алды. Кара кабердән якты дөньяга килеп чыгуына шатланып, мыекларын селкетте. Күрәсең, яшенле яңгыр вакытында егылып төшкән кырмыска баласы булды. Юк, юк… Бу кырмыска баласы түгел, ә кырмыска баласы рәвешенә кергән ДӨРЕСЛЕК-ХАКЫЙКАТЬ, АЧЫ ХАКЫЙКАТЬ иде. Әлеге вакытта чын дөреслек өскә күтәрелеп чыга алмый. Аның көче дә юк, ул шушындый каберләргә күмелгән. Шуңа да дөреслек, кырмыска баласына әверелеп, өскә күтәрелде дә. Чөнки дөреслек, кырмыска баласы зурлык кына булса да, караңгылыкны ертып, өскә күтәрелергә, якты дөньяга күренергә тиеш!.. БУ БИТ – ДӨРЕСЛЕК!

Тик кырым татарлары өчен әле бүген, 1944 елның 18 маеннан, бу мөмкин түгел иде. Бу илдә борын заманнардан ук шулайрак булды. Килер заман, барча дөреслек өскә калкып, җир шарына таралып, бөтен халыкка билгеле булыр!!!

***

Менә, үткән гасырның кырык дүртенче елындагы май азакларындагы кебек, 2014 елның бик тә ямьле май аендагы бер көнендә иске каберстан кырына чит ил машинасы килеп туктады. Машинадан ике яшь кенә пар төште. Алар бик картайган бер әбигә дә төшәргә ярдәм иттеләр. Көмәнле яшь хатын әби туранының килене иде. Килен кеше, каберстанга кермичә, читтә, машина кырында калды. Әби белән тураны каберлеккә керделәр. Алар әкрен генә авылдашларының каберләрен карап йөрделәр. Карчык әрвахларга арнап догалар укыды. Иң кырдагы кабер кырында әби озак кына туктап торды. Кабер бик тә сәер иде. Чөнки җитмеш ел үткән булса да, яртылаш кына күмелгән икәне күзгә ташланып тора. Әби иелеп, инде кыйшая төшкән таштагы язуны укыды. Ташта болай дип язылган иде:

«Монда Хәдичә картәни белән мин – Сабит ята.

Мин – 1928-1944, 26 нчы май».

Ташның икенче ягында: «Зәйнәп, мин сине яратам. Зәйнәп + Сабит», дип язылган язуы да бар. Зәйнәп әби бу кабер кырында бигрәк тә озак басып торды. Аннан, хәле бетеп, таш кырына утырды да елый-елый яңадан дога укырга тотынды. Бу кабердә аның беренче мәхәббәте Сабит ята бит. Тәүге сөюе.

Тураны Айдар, картәнисенә комачауламас өчен, дәшми генә каберстаннан чыгып китте. Машина эргәсенә килеп утыргач, кәләшенә карамый гына:

– Картәни елый, – дип куйды.

Сүзсез калдылар. Бераздан каберстаннан әбиләре дә килеп чыкты. Әби ничектер яшәреп, кәефе яхшырып киткәндәй күренде. Азрак дәшми торгач, Зәйнәп әби, туранына карап:

– Балалар, читтәге кабердә бик яхшы кешеләр ята. Каберне әйбәтләп, җиренә җиткереп күмеп бетереп куярга кирәк. Улым, ишеттеңме? –диде.

– Әйе, эшләрбез, картәни.

Һәм әби тагы зират ягына күз ташлады да аннан, килененә борылып:

– Аллаһы боерса, ир бала туса, Сабит дип исем кушарбыз, – диеп куйды.

Шулай килештеләр. Бераз гына сүзсез утырганнан соң, Зәйнәп әби тагы:

– Кыз бала туса – Хәдичә дип исем кушарбыз, – диюенә, тураны Айдар:

– Иске исем бит. Хәзер кызларга андый исем кушмыйлар, – диде.

– Бүлдермә! Хәдичә – Пәйгамбәребезнең хатынының исеме. Ул исем беркайчан да искермәс! Коръән китабы кебек. Килен-балам, менә бусы миннән сиңа бүләк. Ә менә болары – кызың туса, кызыңа. Ир бала туса, булачак килененә үз кулларың белән бирерсең. Дөнья хәлен белеп булмый. Мин бик картайдым инде, – диеп, кулъяулыкка төенләнгән, кайчандыр Сабит бүләк иткән бик кыйммәтле йөзек белән алкаларны килененең учына салды.

…Бу йөзек-алкаларны Сабитның картәнисе, үләрен сизеп, туранына үзе биргән иде. «Кайсы кыз сиңа беренче булып үзенең яратуын белдерә, шул кызга өйләнеп, шушы алкаларны бүләк итәрсең», дигән иде.

Шулай итеп, Сабитның картәнисе Хәдичә әбинең бик матур алтын йөзеге белән алкалары яшь килен кулына тапшырылды. Зәйнәп әби, җилкәсеннән авыр йөк төшкән кебек, җиңел сулап куйды…

Алда аларны яңа тормыш, авылларын яңадан торгызыр өчен зур сынау, каты көрәшләр көтә. Ни дисәң дә, тормыш дәвам итә. Ә көрәшсез – җиңү юк!..

***Автордан:*** *1951 елны Ташкент өлкәсендә сөргендә туган кырым татары Сайдалиев Куртимернең бик картайган әнисе Зәйнәп әби сөйләгән хатирәләргә таянып язылды. Әби Анапа шәһәренең Анапский бистәсендә, Лермонтов урамында улы белән килене тәрбиясендә яши.*



Рүзәл
Мөхәммәтша

# ДОГАДА КУЗГАЛЫРБЫЗ...

## Әлли-бәлли-бәү

Күзен кан баскан дөньялык!
Йөрәгең калган булса,
Аңга кил!
Тавышланмачы!
Улымның йокысы сак.

Яңа изрәп киткән чагы.
Мышнавы өтек, авыр...
Уяныр да, чыны-төше
Бербөтендә буталыр, дим,
Бер бу төндә буталыр.

Шыпырт!
Корыч карчыгалар
Дистә мең чакрым читтә
Туп ташлауга –
Нарасыем
Сискәнеп, дертләп китә.

Шартлау зәһәренең күккә
Кайтып яңгыравына
Түзалмый, кысып юатам:
«Бары яңгырга гына бу,
Ару яңгырга гына...»

Яңаклары – алсу алма,
Алсу чәчкә – ирене...
«Коткар!» – дип куркып ябышса,
Нәрсә җавап бирермен?

---

Рүзәл МӨХӘММӘТША (1989) – *шагыйрь; «Каралама», «Бүре мин» исемле китаплар авторы. М.Җәлил исемендәге Республика премиясе лауреаты. Казанда яши.*

Мин бит аңа якты тормыш
Бүләк итмәкче идем,
Бәхте хакын үз кесәмнән
Түләп китмәкче идем, –

Ялгыштыммы?
Өметемне
Тамыр төбеннән кисеп,
Әманәт итәр көннәрдә
Миһербансызлык кинәнә,
Җиһанда – көек исе...

Җирнең күкрәк турысына
Ядрә китереп сукса,
Ыңгыраша балам...
Тыныч!
Шулкадәр йокысы сак!

Аңга кил! Котырынмачы!
Шаштыңмы, дөнья, кисәк?
Суелган офык фонында
Нинди салкын моң, дисәмме,
Нинди салкын моң, дисәм, –

Имәнеп киттем. Ярабби!
Кешеләр! Илем! Чорым! –
Газраил ич! –
Һәммәбезгә
Көйләве бишек җырын.

## Шул ук

Күк тә аман, аман туфрак та,
Тормыш шавын сузар сур[1] аман,
Хәл-әхвәлең ничек, милләтем?
Җавап шул ук: зинһар, сорама.

Баер чагы булган кояшның –
Без «таң ата» диеп алдандык,
Ил һаман шул һәм һаман шул илдә
Гыйлем урынына – наданлык,
Ирек урынына – пулемёт,
Мәктәп урынына – төрмәләр[2]...

Халыкларны сүтеп сөяккә,
Кузна уйнап рәхәт күрәләр.

Үзгәреш юк! Гасыр узса да.
Күңелеңә авыр алма син,
Хәлең ничек, дисәм, милләтем?
Җавап: шул ук.
Һади Атласи.

[1] Сур – мөгез быргы.
[2] Һади Атласиның «Яңа низам вә голямаларыбыз» (1906) мәкаләсеннән.

***

Күп ертылды йөрәк –
Саклап кына
Туздырырга, юкса, теләдем.
Җөе ничә купкан яраларны
Энә күзләп кабат тегәмен.

Чукыныплар китсен шәхес, иҗат,
Уймак чокырына сыйган дан! –
Мондый чакта куеныңа сеңеп
Җуеласы килә дөньядан.

Һәр яңа көн – яңа сугыш кыры,
Яңа көрәш.
Азмы көрәштем?!
Хәзер аңлыйм: гомер буе булган
Тик җил тегермәне –
Көндәшем.

Үз галәмен корып,
Нигездән үк
Ялгышуын күргәч, соң гына,
Гаҗәпмени – үгез егар егет
Кузый кадәр кызга сыгына.

Мондый чакта кәеф – челпәрәмә,
Күңел – китек, хәлләр – чамалы.
Кул тидерсәң, авыртуым кимер,
Тының өрсәң, җаным ямалыр.

Кашларымны сыйпа,
Үп чигәмнән.
Язылмаган күпме җыр тулы
Йөрәгемдә – ертык...
Әмма беләм:
Тибәр чакта әле ертылыр!

Без батырып тегәрмен яңадан,
Җәрәхәте ятсын кырык буй, –
Мине берни куркытмый...
Син барда
Икеләтә берни куркытмый!

## Исән-сау

Яңа кайтып кердек сыман,
Ябылмаган ишек тә...
Әллә җил әрсез, китүнең
Котылгысызлыгы әллә
Арка миен өшетә.

Почмакта сәгать текелди:
Тек-тек. Сагышлы вәзен.
Йәгез, бер дога!
Кузгалыйк!

Юл төенчеге әзер,
Ниятләгән эшләр тәмам,
Калмады кебек берни.

Сез дә исән-сау торыгыз,
Без дә исән-сау йөрик!

Бусага аша узганда
Моңны кая куярга?
Адашыпмы, тарыйм кинәт
Мәгънәле дә, мәгънәсез дә,
Мәгънәле дә уйларга:

Шундый мәл тотар якадан, –
Саубуллашкан чактагы
Җөмләләрне кабатларбыз
Бәхилләшкәндә тагы...
Көзгеләрнең йөзен каплап
Догада кузгалырбыз...

Сызган җан – тузган төенчек,
Җанга нәрсә салган булсак,
Юлга шуны алырбыз.

Хафаланырга язмасын:
Килдек нигә?
Киттек ник?
Яхшы сүздә, бәни җиһан,
Сез дә исән-сау калыгыз,
Без дә озак интекмик!

Көннәр берсеннән-берсе ак,
Сафлык, муллык бу йортта.
Иләс хисләр тамырдагы
Яшәү сутын куерта.

Шуңадырмы, кушылганда
Мәгыйшәт тыз-бызына,
Күңелгә җылылык иңә:
Бәхилләшмибез бит әле,
Саубуллашабыз гына.

## Ханәфи җыры

*(Лев Толстойның «Хаҗи-Морат» әсәреннән)*

Газиз анам, кабер өстем кипшерүгә, лөгатьтән[3]
Төшерерсең, онытырсың – тудырмагандай хәтта.

Зират йөзен сутлы чирәм каплауга, атам, картым,
Юанырсың – яшел арам[4] арындырыр хәсрәттән.

Яше җилләр сеңелемнең энҗе күз алмасында,
Бәгыреннән сагыш китәр, янә кайтмас, әлбәттә.

Әмма син, олы абыем, тынычлык тапмассың, юк,
Канымны койган адәмнән үч алмаган халәттә!

Һәм син дә, кече абыем, басынкыланмассың, юк –
Җәсур[5] гәүдәң җирләнгәнче янәшәмдә, беррәттән!

Йөрәк төбендә кургашын... Нигә сүз катмыйсың, ут,
Мин түгел идемме (кем соң?) сабырлыкка өйрәткән?

Җир, билфигъни[6], җәсәдемне йотарсың, тик әйт, атта
Мин түгел идемме (кем соң?) өстеңнән таптап үткән?

Тәкъдиргә камыт кидергән, әҗәлнең башын идергән
Мин түгел идемме? Кем соң?! Юлыктым гофунәткә[7].

Җанга үтте салкын. Өшим. Бәхил! Валлаһи, китәм!..
Нидер кубып төште, аһ, ул – мин салып калдырган тән.

## Очраклы эпитафия

Игелеге меңнәр йөрәгенә
Язылганда, сөртмәс булып һични, –
Кеше мәңге исән, исән кала.
Ахирәткә кичми.

---

[3] Лөгать – тел.

[4] Арам – рәхәтлек, тынычлык.

[5] Җәсур – курку белмәс.

[6] Билфигъни – чыннан да.

[7] Гофунәт – черү.



*Татарстан Язучылар берлегендә.*
*Сулдан уңга: Хәсән Сарьян, Зәки Нури, Мирсәй Әмир (идарә рәисе). 1965 ел.*

*Язучы һәм җәмәгать эшлеклесе Гафур Коләхмәтов (1881-1918) туган йорт. Пенза шәһәре.*





*Татар әдипләре Зөлфәт (сулдан икенче), Илдар Юзеев һәм Гариф Ахунов И.Лихачёв исемендәге заводта. Мәскәү. 1985 ел.*



*Күргәзмә залында.*
*Язучы Нәби Дәүли (сулда),*
*рәссам Лотфулла Фәттахов. 1978 ел.*



*Шигърият бәйрәме көнендә.*
*Лена Шагыйрьҗан, Мөдәррис Вәлиев,*
*Айдар Хәлим. 26 апрель, 2013 ел.*



*Язучылар иҗат йортында.*
*Сулдан уңга: Муса Гали, Рауль Мир-Хәйдәров, Мостай Кәрим.*
*Переделкино. Үткән гасырның 80 нче еллары.*



*Ландыш Габдрахманова Яңа Чишмә районының Акбүре авылында туып-үсә. Казан дәүләт педагогика институтының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлый. Шигырьләре республикабызның төрле газета-журналларында дөнья күрде. Аның шигъриятенә нечкә самими лирика алымнары, үзенчәлекле образлы сурәтләүләр хас.*

Ландыш
Габдрахманова

# ӨМЕТТӘН НӘЗЕК ҖЕП ЭРЛӘДЕМ

***

Теленгәндә бәгырь телемнәргә,
Үксегәндә җаным илереп,
Артык берни өмет итмәдем бит,
Тик җылы сүз көттем тилмереп...
Үтәли җил йөрде... Ышык эзләп
Үрсәләнгән йөрәк бер сызды...
Томан арасыннан сукмак ярып,
Көтмәгәндә син бит кул суздың...
Җиде ят бит үзең... Үзең якын...
Җылылыгын тоям кулыңның.
Җибәрәсем килми... югалтасым...
Бүләсем дә килми юлыңны...
Син китәрсең... әйе... мин калырмын
Төшләр ятьмәсенә чолганып...
Мин ышанам, бәхет кыйпылчыгы
Өннәремә китәр ялганып...
Юлың озын... минем күзләр калыр
Томан арасында күмелеп...
Артык берни өмет итү түгел,
Бер җылы сүз көтү... тилмереп!..

## Тынмасын...

Тыңласын төн кызы... Еласын!
Бүгеннән төннәргә кушылмыйм.
Күңелдә бары тик синең сын,
«Бәхетем – син», диеп, пышылдыйм.
Ишетсен тулган ай, мин, дисен,
Сереңне таңнарга таратам.
Белсеннәр, яшермим, күрсеннәр –
Мин сине өзелеп яратам!
Бураннар котырсын, зилзилә
Үчләшеп юлымны чорнасын.
Тик синең хисләрең, моң булып,
Җанымда беркайчан тынмасын!
Тауларда ташканда җырларым,
Чишмәләр көнләшеп ургысын.
Мин әзер сакларга, якларга
Ләззәтле сөюнең соңгысын!

***

Юл чаты. Ялгызым. Күңелне
Чорнаган мең катлы төеннәр.
Газаптан әрнегән чагымда
Елмаю саклаган иреннәр.
Бушлыкның кочагы рәхимсез –
Челләдә җил булып өтәли.
Суына эзләрем. Акылым
Төйнәлгән төенне сүтәлми.
Мең кабат яралам! Мең кабат!
Катмарлы әрнүләр тавында.
Билгесез юл чаты. Ялгызым.
Тырмашам әле мин тагын да.
Айкала-чайкала бәгырьләр.
Танымый, үз итми үз түрен.
Өметтән нәзек җеп эрләдем –
Ямарга ярасын күңелнең.

## Кайсы фасыл?

Вакыт тузанында кала эзләр...
Адымнарым... Кыштыр-кыштыр...
Кайсы фасыл хакимлеге бүген?
Аералмыйм... Бәлки, кыштыр...
Көз, ди, әнә, кемдер... Нигә күрмим
Алтын сирпелгәнен җиһанга?
Сукмак эзләп йөрим бәхетемә,
Кайгыларсыз туар таңнарга...
Томан сарган шәһәр урамнарын,
Җанны буа күксел сөреме.
Ходаемнан сабырлыклар сорыйм –
Кыл өстендә Әнкәм гомере...

Эзләр кала вакыт тузанында...
Сүзләр кала кебек... Әйтелмичә...
Әнкәй йоклый. Йоклый гына әле!
Күзне ачыттырып томан төшә!..

## Халәт

Син бәхетле әле, шыксыз кышым,
Бик бәхетле!..
Елый аласың...
Күз яшьләре белән каплый алсам
Үзәк өзгеч төннәр карасын,
Күпкә җиңел булыр иде кебек...
Сабырларым сынган бу мәлдә
Борыламын тәкъдир тарафына,
Кемнәр, диеп, тагын бу хәлдә?


Синең тавыш килә... Үксегәнең...
Югалганнар ап-ак тәңкәләрең...
Мөлдерәшеп гөмбәз чоңгылында
Көтәләрдер алар әнкәләрен...
Мин үзем дә күкләр хөкемендә –
Теләнәмен гомер газиземә.
Сабыр касәләрен чайпалдырмый
Бу бала соң ничек түзә, димә.

Синең тавыш килә... Үксегәнең...
Агартмакчы төннәр карасын...
Син бит миннән күпкә бәхетлерәк,
Шыксыз кышым,
Елый аласың!..

## Тантана

Кулларыңа орынганда, җаның
Тетрәндеме минем әрнүдән?!
Дәшмә! Сүзләр – артык! Алар – ялган!
Югалам мин... Көтмә бүгеннән!
Битлек элдем... Танымассың мине!..
Тар сукмакта башка таптанмам!
Синең дөнья – сазлык! Бүген анда
Битлекләләр итә тантана!
Ихласлыкка сусап, җылы эзләп,
Ыргылырсың минем учакка.
Абынырсың бозлы карашыма,
Калтырарсың салкын кочакта.
Яраларны ялган белән ямап,
Өметләнми башка аклыкка,
Күралмыйча сине... Һәм үземне...
Бата барам төсле сазлыкка.
Сүтелә дә китә яраларым...
Җөйләреннән кара кан тама.
Бушап калган күңелеңдә синең
Битлекләләр итә тантана.

# ЗӨЛФӘТЛЕК



2007 елның 16 апреле. Галиәсгар Камал исемендәге театрда Зөлфәтнең юбилее бара.

60 яшь... Ниһаять, чыгыш ясаучыларны тыңлап шактый арган шагыйрьнең үзенә сүз бирделәр. Сәламәтлеге шәптән булмаса да, үзен егетләрчә тотарга тырышып, микрофон алдына килеп басты. Бераз тын торгач, ачык тавыш белән:

– Мин – шагыйрь! – дип ярып салды. Бераз гөжләбрәк торган зал тын калды, ниндидер киеренкелек урнашкандай булды. Кемгәдер төбәп, үзенең шагыйрьлеген раслагандай әйтелде бу сүзләр. Ниндидер әрнү дә бар сыман иде. Аннан горурланган сыман: – Минем яңа китабым чыкты! – дип, кулындагы саллы китабын өскә күтәрде. – «Ходай сулышы!»

Тын торган зал, баштагы шаукымнан арынып, гөрләтеп кул чабарга тотынды. Киеренкелек мизгел эчендә юкка чыкты, зал өстеннән күңелле дулкын йөгерде. Зөлфәт шигырь укырга тотынды...

Хәзер дә уйлыйм, «Мин – шагыйрь!» – дип юкка гына әйтмәде бит ул. Аның шагыйрьлеген шик астына алучы да булмагандыр залда. Хәер... «Зөлфәт язудан туктады», «Зөлфәт элекке данына ышыкланып кына яши», «Зөлфәтне без инерция буенча гына шагыйрьләр рәтендә йөртәбез...» кебек сүзләрне ишетмәдекмени? Зөлфәт гомере буе иҗат итте, гомере буе аны турыдан-туры яки кинаяләп «актив булмауда» гаепләделәр. Әйе, аның китаплары сирәгрәк чыкты. «Язмышлар ярында» китабы белән «Утлы бозлар» арасы алты ел булса, чираттагы китабы унике елдан соң гына дөнья күрә. Әмма нинди китаплар бит алар! Зөлфәт китап арты китап чыгарырга омтылмагандыр да дип уйлыйм.

Әмирхан Еники Зөлфәтнең шигырьләрен «тәмле шигырьләр» дип атый. Тәмле әйбер күп булмый... Тик шунысы бар: Зөлфәтнең шигырьләрен, язмаларын бергә җыйсаң, шактый мул мирас калдырганлыгы бәхәссез.

Бүген шагыйрьнең җыентыкларын күздән кичерәм дә, никадәр рухи байлык, гаҗәеп шигырь үрнәкләре калдырып киткән икән ул безгә, дим. Зөлфәт шигъриятеннән мәхрүм булмаган килер буыннарга да сөенәм.

Ачыктан-ачык әйткәндә, аннан нык көнләштеләр. Шагыйрьлегеннән дә, янәшәсендә хатыны Фирая апа булудан да, бер дигән балалар үстерүеннән дә... Гаиләсе ныклы, димәк, тылы ныклы. Күп кенә каләм ияләре тыл юклыктан харап булдылар. Мөдәррис Әгъләмнең очрашкан саен әйтә торган сүзе: «Бүгенге көндә татарның иң зур шагыйре – Зөлфәт!» Бу сүзләр кемнәргәдер ошамагандыр. Әлбәттә, шулай. «Зөлфәт язудан туктады...» кебек сүзләр таратылып, аның шагыйрьлегенә шик төшерергә омтылыш барлыкка килгән икән, юкка түгел... Зөлфәт – шагыйрь генә түгел, гомумтатар шигъриятендә тирән эз калдырган, поэзиядә ачышлар ясаган, традицион булып калган хәлдә, яңа төр шигъри мәктәпкә нигез салган шагыйрь дип әйтәбез. Шуңа да инде, Наис Гамбәрнең «җиңел кулыннан» «зөлфәтлек» дигән аталыш та барлыкка килде: *«Акчасы ни, бакчасы ни, / Зөлфәтлекне югалтсак...»*

Зөлфәт... Зөлфәтлек...

Мәктәптә укыган елларында ук шагыйрь булып танылган ул.

Ерак 1964 елларга китик. Мөслим районының бер почмагындагы Урәзмәт авылы. Беренче сентябрь көне. Мәктәп умарта күчедәй гөжли: укытучы булып Казан дәүләт университетын тәмамлаган яшь шагыйрь Рәдиф Гатауллин килгән! Мәктәп директоры Нәһерлегаян ага Хөсәенов та (композитор, музыкант Азат Хөсәеновның этисе) шат: РОНО мөдирен тәки ризалаштырды бит – егетне үз мәктәбенә билгеләтүгә ирешге! Соңрак, бәлки, үкенеп тә куйгалагандыр... Рәдиф Гаташның укыту методикасы совет мәктәбенең методик таләпләренә бик үк туры да килеп бетми. Бигрәк тә төн уртасы җиткәч, шәкертләрен ияртеп, эштән арып йокыга талган авылны дәррәү уятып, шигырь әйтеп, урам тутырып шаулап йөрүләрне искә алсаң... Ул чор өчен баш Себер китәрлек нәрсә ич бу. Укучылары нинди әле, унынчы сыйныфтагылар. Егетләре, һәркайсы гүәрдин гәүдәле, алыпка тиңнәр! Хәлфә абыйлары аларны үз итеп «күсәк!» дип дәшә. Җитмәсә романтик холыклылар; кызлары – һәркайсы алиһәгә тиң... Мөслим кызлары алар башка, чибәрлек тә җитәрлек, акылдан да ким-хур түгел. Директорга жалу белән килүче ата-аналар да күренгәли. Моның ишене күргән кешеләрмени алар... Партия тәрбиясенә шулай төкер әле син.

Унынчыларга дәрескә кереп, бераз танышып алгач, бер арада җай чыгарып, Рәдиф Гаташ дәртләнеп шигырь укый. Татар, шәрык, дөнья поэзиясен су урынына эчкән шагыйрьнең авызыннан «энҗеләр сачелеп» кенә тора инде. Боларны мин, картлар әйтмешли, бик белеп язам, чөнки ул дәрестә шагыйрьгә мөкиббән китеп утыручыларның берсе – бертуган абыем булган бит. Яңа мөгаллим әдәбият турында гәп кора, һәр җөмләсен шигырь белән «ныгытып куя». Егетләрнең күңелләрендә ут өермәсе, кызларның күзләрендә, Марсель Гали әйтмешли, «тояк уйный». Яшь, чибәр егеттән күзләрен алмый утырган бер кызый, телгә килеп: «Беднең үдебеднең дә шагыйребед бар», – дип куя. Берәр Мәсеготь кызы булгандыр инде. Егетләр мәсьәләсендә иң тәҗрибәлеләре шул авыл кызлары.

Рәдиф Гаташ, сагаеп:

– Кем ул? – ди. Карашы сыйныф бүлмәсен капшап үтә.

– Дөлфәт, – дигән тавышлар ишетелә. Арада: «Исәр Мәләк» дип әйтүчеләре дә табыла. Моның да үз сере бар...

– Килмәде ул бүген... көтүдә.

Шагыйрьләрдән көтүче ясау яңалык түгел... Публий Овидий Назон... Хәсән Туфан...

Рәдиф Гаташ дәрескә керешә. Әмма, тәнәфескә чыккач, егет белән кызыксынуын дәвам итә.

Дөлфәт Маликов дигән шигырь язучы егет Яңа Сәет дигән авылдан икән.

Шагыйрь шәкерте белән очрашу, беренче тәэсирләр хакында Рәдиф Гаташ язганнар аша таныш без. Озак та үтми, күрше Бүләк авылында (Наис Гамбәрнең туган-үскән авылы) Рәдиф Гаташ кичә оештыра. Инде бу вакытта, Наис Гамбәр искәрткәнчә, мәктәптәге «һәр укучы бала, укытучы абыйсына охшарга тырышып, дөресрәге, аның тылсымына буйсынып, исәрләнә-исәрләнә, әсәрләнә-әсәрләнә шигырь яза. Мәктәп тоташ шигъри ялкын эчендә».

...Агач клуб. Тын беленерлек салкын. Шигъри кичә бара. Зөлфәт шигырь укый. Бөдрә чәч, зифа буй, баш югары чөелгән, уң кулы кош канатыдай җилпенеп-җилпенеп ала, әмма тавышы уйчан-моңсу: *«Елга буйларында талдыр. / Агызма – / Тик яшьлекне калдыр».*

Шигырь тәмамлануга, иске клуб сулкылдап куйгандай булды... Шигырь «җене» кагылган безнең авыл апа-агайлары шигырь тыңлыйлар. Алар нәкъ менә шушы минутта яңа шагыйрь тууын эчтән генә чамалап алганнардыр (халык сизгер ул!), әле яңарак кына әнисен югалткан егет «тик яшьлегемне калдыр» ди бит! Олыларча итеп, үзәккә үткәреп, үксетеп.

Бу – триумф иде. Сәхнә артына чыккач, Рәдиф Гаташ, шатлыгын яшереп тормастан, шәкертенең иңеннән кочып алды да яраткан сүзен шәрран ярып кычкырып җибәрде:

– Афәрин, күсәк!

Икенче елны ул ике «күсәген» – Дөлфәт белән Фәрит Гыйльмине ияртеп Казанны «яуларга» алып чыгып китә. Икенче елны аларга Наис Гамбәр кушыла...

*Аксакал да иде безнең хәлфә*
*Һәм егет тә – кызлар сөйде ул.*
*Сезнең өчен Рәдиф Гаташ булса,*
*Безнең өчен хәлфә иде ул –*
*Төнен әйбәт шигырь яза алса,*
*Хәлфә түгел, хәтфә иде ул!*
(«Юл өзеге»)

Казанда Яңа Сәетнең Дөлфәте шагыйрь Зөлфәткә әйләнә. Шагыйрь – туры сүз әйтү. Турысын әйтү – гадәтиләр эше түгел. Шагыйрь андыйларны үзе «гаҗәепләр» дип атады. Мөдәррис Әгъләмгә Зөлфәт болай эндәшә:

*...Исәр сантый. Сөйләр сүзеңнән дә*
*Бөрки сыман тере яктылык.*
*Хәзер ни дип әйтим инде:*
*Сантыйлыкмы? Әллә Антейлык?*
*...Бу татарны уйнатырга түгел,*
*Уйлатырга һаман шигырь әйт!*
*Аның барлык тәрәзләрен ачып,*
*Бар дөньясын җилләт, шигырьләт!*
(«Сантый»).

Тел, татар халкының язмышы Зөлфәтне беренче шигырьләреннән башлап, гомеренең ахырына кадәр озата бара. 1972 елда язылган «2072 елның язында явачак кояшлы яңгырга» шигырендә болай ди:

*Исән-саумы әткәм-әнкәм теле?*
*Тузан төшмәдеме чишмәсенә?*
*Урын бармы Тукай томнарына*
*Бөек чорның китап киштәсендә?*
*...Сукмадымы яшен туган моңның*
*Гасыр аша сузган күперләрен?*
*Өермәләр йолкып алмадымы*
*Безнең оныкларның хәтерләрен?*

Шул чорда Мөдәррис Әгъләм яза: *«Бездән соңгы буын кемчә сөйләр? / Яңгырармы анда безнең көйләр?..»* («Китә алмыйм»)

Шәп шагыйрьләр күп ул татарда. Ә Хәсән Туфан ни өчен Зөлфәт белән Мөдәррис Әгъләмне артык үз иткән? Сере нәрсәдә? Ул аларның күп кенә «шуклыкларына» да күз йомган бит. Туфан һәр каләм иясен хикмәтле бизмәненә салып үлчи: милләт гаме белән яшәү, иҗат итү, башкаларга юл күрсәтү (белдертү!), аларны арттан ияртә алу. Юкка гына Кадыйр Сибгатуллинга язган хатында олуг шагыйребез болай димәгәндер: «Синдә дә Зөлфәттәге, Әгъләмдәге (һәм Равилдә дә туа башлаган) гүзәл гамь, илең, халкың күңеле белән тоташкан әйбәт тынгысызлык бар, һаман үсә барган гүзәл иман бар, көнем өчен түгел, «Денем, Илем өчен!» дигән иман бар. Иманыңны ата шайтанга да бирмә, Кадыйр!» Хат 1971 елда язылган. Күренгәнчә, Туфан беренче итеп Зөлфәт исемен атый. Зөлфәт әле сабый гына, югыйсә... Монда һәр сүз, һәр тыныш аерым мәгънәгә ия. Әдәбиятка иманлы булып килү генә җитми, иманны гүзәл хәлдә саклый да белергә кирәк, башкаларга тапшыра торырга кирәк. Иң зур кыйммәт шул.

Татар халкының язмышы сызландырып яшәтә шагыйрьне. Ул аны данлый да, мактый да, кимчелекләрен дә аерып күрсәтә.

Җитмешенче елларга кайтыйк. Бердәм «бөек совет халкына» укмашкан, мираж идеяләр хакына теләсә нинди сәяси җинаятьләрне дә акларга әзер масса шагыйрьнең кисәтүле җан авазын ишетерлек хәлдә идеме ул чакта? Әдәбият мәйданында ат уйнатучыларның төп өлеше «бөек киләчәккә» кысыр өметләр

баглап элегияләр язып азапланганда, Зөлфәт – Намус, Вөҗдан өчен зур әхлакый көрәшкә чыккан бунтарь. *«...Мин буран туганыдыр – / Күкрәгемдә / Буран болытлары...»*

Шул дәвердән алга киттекме без? Алгамы, арткамы?.. Тарих хөкеменә ышану көчле, тарих гаделлекне торгызыр дип, көтеп яшибез. Бу көтү озакка китте инде. Чынбарлык башкача: *«Нигәдер бу кешеләрне тарих / Чалыш күрәк белән җилгәрә – / Ялган кала орлык булып ятып, / Ә дөреслек оча җилләргә».* («Хәерлегә булсын»)

Зөлфәтнең эпиграф итеп алынган «Чакырылмаган кунак – татардан да яманрак» дигән сүзләр астында иҗат ителгән шигыре хакында тулы трактат язарга булыр иде. Һәм бу әсәр хакында аз язылмады да. Шигырь астына 1965 ел датасы куелган. Бүгенге трагедия шунда: империячел сәясәт элеккедән дә яманрак рәвештә гамәлләр уйлап таба. Татар халкының язмышы тел язмышына тоташкан. Тел бар – халык бар, тел юк – халык юк. Халык юк икән – проблема да юк...

Шагыйрь сүз белән генә көрәшә ала, дибез. Сүздән дә көчле корал юк. Хакимнәр гомер бакый хак сүздән куркып, аны кычкырып әйтүчеләрнең телләрен тешләтү уе белән адарынып яшәгәннәр. Зөлфәт җәмгыятьтә көрәш рухы формалаштырырга омтыла. Бигрәк тә үзенең буынын, арттан килгән яшьрәк буынны көрәшчеләр итеп күрәсе килү теләге зур. Аның шигъри ачышлары шундый әсәрләрендә ныграк төсмерләнә дә. Зөлфәт – антитезалар остасы (Наис Гамбәр), Зөлфәт – экспрессионист – белдерүче, хакыйкатькә башлап төшенүче (Дания Заһидуллина), Зөлфәт – трагик шагыйрь (Илдар Юзеев), Зөлфәт – сюжетлы шигырьләр остасы (Наҗар Нәҗми). Мин ни өсти алам? Ул – тәнкыйди зәвыкны социаль гаделсезлекне фаш итүгә юнәлдергән шагыйрь. Һәм иҗат гомерендә моңа ирешә дә. Ә болай үзе бары тик: «Хан да түгел, мин – бары тик Зөлфәт», – ди.

Зөлфәт гомере буе сагынып яшәде. Мәхәббәтен сагынды ул, Уразмәт мәктәбендә укыганда яралган, яралы мәхәббәте – Гөлнәзирә апа аның, хәзергечә әйтсәк, шигъри музасы иде. Гөлнәзирә апа да Зөлфәт дигән атаклы шагыйрь барлыгын белеп, аның өчен горурланып гомер кичерде. Әмма яшьли вафат булды. «Бу югалтуны, – дип искә ала Наис Гамбәр, – Зөлфәт кенә түгел, шагыйрьнең хатыны Фирая ханым да бик авыр кичерде кебек...» Зөлфәтнең үзәген өзгәләгән тагын бер нәрсә – аның яшьлек эзләре калган Мәсеготь авылы да юкка чыкты. Озак еллар авылның коесы, сиртмәгә эленгән чиләк кенә сакланып торды...

Мәсеготь язмышы – туктаусыз бимаза. Юкка чыккан авылның халык язмышына әверелү ихтималын тоюу сагайта. Куркыныч төш сыман ул. Шушы шом «Үле авыл», «Ятим кое», «Ташландык кое», «Яшьлегемнең яшен яктысы», «Бәхил бул, сиреньле авыл» әсәрләрендә кабатлана.

Мәхәббәт нәрсә ул? Бу сорауга Зөлфәт болай җавап бирә: *«...Бөек хисләр хасил була икән / Яшәп түгел очып үткәндә... / Мәхәббәт ул / Бер кагылыш икән, / Канат кагылышы икән лә!»* («Кагылыш»).

Соңгы дәвердә Сөю турында иң көчле шигырь дип мин «Мәхәббәт» шигырен атар идем.

1976 елга кире кайтам. Имтиханнарны биреп, сессия тәмамлангач, авылга таба кузгалдым. Чаллыга кайтып төштем. Безгә иң якын юл шушы, Чаллыдан Мөслимгә автобус йөри. Төн уртасында «Метеор» пристаньга борынын төртте. Апаларда кунып чыгарга уйладым. Тик алар ГЭС бистәсеннән Яңа шәһәргә күченеп киттеләр, минем әле яңа фатирларында булганым юк, бара да белмим. Автобус тукталышында торган яшь пардан, апаларның адресын әйтеп, ничегрәк табарга, дип сорыйм. Автобуслар йөрми икән инде, шактый ерак җир барасы булып чыкты. Яшьләр исә мине үзләре илтеп куярга уйладылар. Сөйләшеп бара торгач беленде: егет тә, кыз да Мамадыш районыннан. Иплән кенә минем хакта да сорашалар. Үземнең Казан университетында, филология факультетында укыганымны әйттем.

– Шагыйрьләр шунда укый инде, әйеме? – дип сорады кыз.

– Анда укыганнары да бар...

Кыз шигырь укый башлады. Көтелмәгән хәл иде бу.

*– Юк, китмә. Кирәкми... мин сине*
*Аралап алырмын кышлардан,*
*Бу ап-ак гарасат нигәдер*
*Нәкъ безнең сөюгә охшаган...*

Яшьләрнең теленнән төшмәгән «Язмышлар ярында» китабыннан шул исемдәге шигырь бу. Мин дәвам иттем:

*...Тетрәнде керфегең, болыттан*
*Ак карлар ычкынган шикелле.*
*Ачылды керфекләр, бу көннәр*
*Бураннан ачылган шикелле.*

Без сүрән яктырткыч эленгән багана төбендә туктап калганбыз икән... Кыз гаҗәпсенеп миңа карады.

– Сез дә... бу шигырьне беләсез икән.

– Бу шигырьне егет кеше язган. Аны егетләр укырга тиеш, – дигән булдым, белдекле кыяфәттә. – Мин әле аның авторы белән дә таныш...

– Егетләр шигырь язарга оста... Ә мин шигырьне үземчә сөйлим. *«Ялвару төс түгел ирләргә / Толымың җылысы – мендәрдә» дигәнен, «Ялвару төс түгел кызларга, / Толымым җылысы – мендәрдә!»* – дип әйтәм. Мине белми бит ул... Зөлфәт, ачуланмас әле, – диде, шаян тавыш белән.

Без апалар яшәгән йортка килеп җиткәнче тәмам туганлашып беткән идек инде. Аерылышкан чакта егете, көлеп:

– Хәерле булсын, шундый шаукымлы кыз белән күзле-башлы булам инде. Икенче атнада туй, – диде. – Кунакка чакырабыз.

Шагыйрь булу да шаукымлы эш, шигырь ярату да шаукымлы эш булып чыкты.

Мин бу парны бәхетле булганнардыр дип ышанып яшим. Шигырьне бәхетсез мәхәббәт яздырса да, аны күтәреп алучылар арасында бәхетлеләр күп бит.

Казанга килсәм, Зөлфәт абый янына кермичә китми идем. Ул мин белгәндә – «Яшь ленинчы» газетасында, аннан озак еллар «Чаян» журналы редакциясендә эшләде. Берсендә, аның шактый шыксыз бүлмәдә, тәмам тузган утыргычта, кыршылып беткән өч аяклы өстәл артында, иске, тузган-кашаган җиһазлар арасында моңсу утыруына игътибар иттем. Мине күргәч, гадәтенчә, очынып, озын кулын күрешергә сузды:

– Һа, якташ, – дип, мине сораулар белән күмеп тә ташлады. – «Мәйдан» ничек? Чаллы ничек? Мөслимгә кайтканың бармы?

Мин сорауларга өзек-төтек җавап биргәч, дулап алдым:

– Хәзер баш редакторыгыз янына керәм, шагыйрь Зөлфәт мондый бүлмәдә, иске-москы арасында утырырга тиеш түгел. Оят!

Зөлфәт абыйның йөзе алсуланды. Авырткан урынына кагылдым, ахрысы. Урыныннан сикереп торды.

– Керә күрмә! Бер сүз дә тишмә! Үзләре күрергә тиеш алар...

– Моңарчы күрмәгәнне... – дип, ачуланып чыгып киттем.

Ике айлап вакыт үткәч, тагын Казанга килдем. Янә Зөлфәт абый янына йөгердем. Керсәм... Бүлмәне танымый торам. Яхшылап ремонт ясалган, яңа җиһазлар алынган, алар зәвык белән урнаштырылганнар. Түрдә, затлы кәнәфидә балкып Зөлфәт абый утыра.

Мине күрүгә көлеп, каршыга чыкты.

– Әйттем бит! Күрде бит Берәү... – диде ул мактанган кыяфәттә. – Белмиләр дип уйлама, беләләр мине!

Телдән калып, бүлмә буйлап күкрәк киереп атлаган Зөлфәт абыйга карап торам.

– Ничек, бик тиз... – дидем, ниһаять, аңга килеп. – Кемнең башына килде бу нәрсә?

Зөлфәт абый күңелле тавыш белән бармагын югары чөйде:

– Иң өстәгеләр күрде. Һа, кодаң президент булса, шулай була ул!

Бусын шаяртып әйтте инде. Зөлфәт абый әлеге үзгәреш турында сөйли башлады.

«Сөембикә» журналы редакциясенә, юбилее уңаеннан котларга дип, Президентыбыз Минтимер Шәрип улы Шәймиев килгән икән. Тиешле катка күтәрелгәч, сулга китәсе урынга, Президент уңга каерып, беренче ачык ишеккә килеп кергән. Анда, кәгазьләргә чумып, Зөлфәт утыра...

Күрешеп, бераз хәл белешкәч, Президент бүлмәгә күз ташлаган һәм нык итеп:

– Шагыйрь Зөлфәт мондый шартларда утырып эшләргә тиеш түгел, тиз арада төзәтегез! – дип фәрман биргән.

– Гап-гади итеп минем белән сөйләшеп торды Минтимер ага. Каушап калдым. Ни сөйләгәнемне дә белмәдем. Шулай да телгә килде: «Сез бит минем кода буласыз», – дидем. Көлде, аркадан какты.

Зөлфәт абыйның сөенече күкрәгенә сыймый иде.

Соңгы тапкыр аны 60 яшьлек юбилеенда күрдем. Юбилейда чыгыш ясап, аны тәбрик иттем. Кичәдән соң, тагын гәпләшеп алдык. Шат иде, күңеле күтәренке иде. Бераз вакыт үткәч, хәлләрен сорашу нияте белән өйләренә шылтыраттым.

Телефонны Фирая апа алды. Борчылган сыман.

– Ни булды, Фирая апа? – дип сорадым.

– Зөлфәт абыең авырып тора әле. Эч тирәсе авырта...

– Ашыгыч ярдәм чакырыгыз, Фирая апа.

– Чакырдык инде. Хәзер килеп җитәләр.

Тагын берничә көн үтте. Янә шылтыратам. Фирая апа белән сөйләшәбез. Зөлфәт абыйга операция ясаганнар.

– Зөлфәт абыйның хәле ничек соң? – дип сорау бирәм.

Шул арада Зөлфәт абыйның шактый көр тавышы ишетелә:

– Не дождётесь, дип әйт! Сәлам тапшыр. Казанга килгәч керсен! «Тулганаен» яраттым, шәп!

Сүз «Идел» журналында басылып чыккан «Тулганай» дигән повестем турында иде.

– Әйбәтләнә инде, торып йөри башлады, – ди Фирая апа.

Сөенеп, трубканы куйдым.

Тагын ике көннән аның вафатын ишетеп, аңсыз тордым...

Зөлфәт дигән бөек шагыйрь мәңгелек гомеренең алтмыш елын Җирдә яшәп китте... Кабере Яңа Бистәдә, иҗатташы Мөдәррис Әгъләм белән янәшә диярлек. Тукай да ерак түгел. Аларның рухлары очрашып, гамьле әңгәмәләр корып ала торганнардыр. Һәрхәлдә, безнең арада яшәгән чорларында, Зөлфәтнең Мөдәррис абый белән тугарылып сөйләшеп утыруларын күзәтеп, тыңлап утырырга ярата идем...

Зөлфәт китапларын еш укыйм. Бит артыннан бит ачыла. Укыган саен Рух уяна, җан Ил, Халык язмышына кушылып тетрәнә. Әйтерсең, шагыйрь мәңгелек хакыйкать тавының иң биек җиренә күтәрелгән дә укучысы белән сөйләшә.

*Рәхмәт, дөнья,*
*Язмышның син миңа*
*Тоташ шигырьлесен сайладың. –*
*Йөрәгемне былбыл чакты минем,*
*Һәм өздереп елан сайрады!..*

(«Ходай сулышы»)

Зөлфәтлекне саклыйсы иде җанда, килер буыннарга саклап каласы иде...

**Факил САФИН**

Зөлфәт

# ТОМЫРЫЛДЫМ ТИРӘН ҮТКЕЛГӘ МИН...

## Имансызлар

Туган телне ыштыр итүчеләр
Җир җимертеп бәйрәм иткәндә,
Газиз Сүзкәй,
урын кала сиңа
Тирәннәрдә бары, үткәндә...

Кер югандай
Сүзне юам тирләп,
Сабыйларны безнең уят, Сүз!
Синнән мәхрүм калган өчен генә
Монстр күк алар, оятсыз.

Бездән башка кем гаепле булсын
Башка төшкән мондый гарьлеккә?! –
Без су сибеп үстергәнгә күрә
Гөрләп үсте
рухи гарипләр.

Шәп омтылдык мәгәр бөтенлеккә!
Шул омтылыш безне җилкетте!
Туган халкын ыштыр иткәннәргә
Гарип йорты ачар көн җитте...

Арматура тимерләрен айкап.
Имансызлар бәйрәм гөрләтә,
Ваемсызлык һәм сансызлык өчен
Тарих бездән шулай түләтә.

Кулларында кастет уйнаганда,
Уйнаганда телдә «мат» кына,
И Туган тел! Коткар син аларны,
Чоңгыллардан чыгар яктыга!

Ал кан яна ап-ак күлмәкләрдә...
Исәндер бит, халкым, куәтең? –
Һичбер тапсыз һәм нахаксыз килеш
Җилфердә син җилдә,
Туган тел!..

## Тамыр көлләре

Бу төбәктә тайга шаулаганын
Кемнәр, ничек искә алырлар?
Ул шаулардан инде җилләр искән,
Тау-тау булып яна тамырлар.

Яна тамырларда алтын дастан,
Дастаннарда – кавем тарихы,
Тарихларда яна Җир өмете,
Өметләрдә нәрсә? –
Барысы!

Тамырларда мәхәббәтләр яна,
Мәхәббәттә яна җыр моңы,
Җыр моңында яна кеше дигән
Гали затның бөтен зурлыгы.

Яна тамыр! Тамыркайлар яна!
Күккә карап нәгърә орырлык –
Көлләр булып кала тамырлардан
Миң буынга җитәр
Бер хурлык.

Үзәк өзгеч бер хатирә булыр
Бу чорларның яман яңгыры...
...Язмышларга ургый-ургый дулый
Вәхшәт туе – Тамыр Яндыру.

Вакыт җилләрендә тарихларны
Карарлар да беркөн җилгәреп, –
Офыкларны каплар кара көлләр –
Хурлык көле – Тамыр көлләре...

***

Яшиселәр, әйдә, миң яшәсен!
Язмышыма килә эндәшәсем...
Күпме еллар яшәп үттем дә мин
Томырылдым тирән үткелгә мин, –
Синең белән килде сөйләшәсем...
Яшиселәр, әйдә, миң яшәсен!

Язмышыма килә эндәшәсем...
Түгелсен лә кайнар, ярсу яшем!
Инде, язмыш, кыйна бу җанымны,
Суксын яшен барлык булганымны! –
Керфегемдә инде кипмәс яшем,
Язмышыма килә эндәшәсем...

Күпме еллар яшәп үттем дә мин,
Сер йомгагын сүттем-сүттем дә мин –
Гомерлеккә сыкрап калды бәгырь...
Ничек инде? Син һәм... салкын кабер?!

Синдә булган икән дөнья гамем,
Күпме еллар яшәп үтсәм дә мин...

Томырылдым тирән үткелгә мин,
Тик... дөньяның чиксез читендә син...
Юк, кабынмас кабат яшьлек таңы,
Үтте дә бит китте гомер янып,
Күрдем дә мин бәхет сүтелгәнен –
Томырылдым тирән үткелгә мин!..

Синең белән килде сөйләшәсем,
«Таң ата... Күр!» – диеп эндәшәсем,
Сыйпап кайнар, калын толымыңны...
Кемнәр тояр тагын мондый моңны?
Әйтерсең, кош кошка эндәшәсе –
Синең белән килде сөйләшәсем...

Яшиселәр, әйдә, мең яшәсен,
Күкрәсен күк, уйнакласын яшен!
Очар йолдызлар күк-галәм ярып,
Кушҗан килде җиргә, китеп барды...
Изге икән Җирдә тик күз яше...
Яшиселәр, әйдә, мең яшәсен!

***

Хан да түгел, мин – бары тик Зөлфәт.
Кулымда да кайнар кылыч түгел.
Ә күңелне алгысыта яулар –
Ул нинди яу –
Җаным тыныч түгел.

Төгәл тарттырылган өзәңгеләр.
Ялтыр дага атлар – авызлыкта.
Тын җәяләр ярсып бөгелгәннәр.
Юешләнгән тояк таңгы чыктан.

Алда – мин яулыйсы Дорфа Бушлык,
Аннан ары – һич Шәфкатьсез Офык.
Янә ары китсәм – Өметсез Яр,
Иң соңында – Котылгысыз Ышык.

Ханнар, моңа ирешкәнгә кадәр,
Узар иде күпме җанны түшәп?
Мин ничекләр узыйм соң бу юлны? —
Мин хан түгел, мин – бары тик Зөлфәт.

# КЫЙБЛАГА КАЙТУ

## АЙДАР ХӘЛИМГӘ 75 ЯШЬ

Ни өчендер, бу әдипнең язганнарын, гомумән, аның үтә дә киң кырлы иҗатын күңелемә ихластан аваздаш һәм якынсыман дип кабул итәм. Сүз күренекле прозаик, шагыйрь, драматург һәм публицист булып танылган Айдар Хәлим иҗаты турында бара. Нинди жанрда язылуларына карамастан, аның әсәрләрендә сурәтләнгән вакыйгаларга катнашкан геройларның хәл-әхвәлләре, кичергән маҗаралары җанга якын хатирәләремне искә төшерә, күңелне сызландыра, шуларны яңартып, элеккеге, кайчандыр янәшәмдә йөреп тә, бүген инде истәлекләре генә калган яшьлек дусларым, иптәшләрем белән кавыштыргандай итә. Дөрес, безнең биографияләрдәге кайбер кызыклы һәм гыйбрәтле күренешләр, вакыйга-маҗаралар нәкъ шушы әсәрдә язылганча ук булмагандыр да – әмма чын әдәбият-сәнгатьнең яшертен сере-хикмәтләре ниндидер якынча охшашлыкка, янәшәлеккә нигезләнүен дә онытырга ярамый.

Татар халкының язылган һәм язылмаган, әмма күп гасырлар дәвамында сыналган әхлакый кануннарын булганынча сакларга тырышып яшәүчеләр һәм, киресенчә, аларны бар дип тә белмичә, байлыгы, хакимдәрлеге, тупаслыгы белән масаеп, хәтта үз наданлыгына сөенеп яшәүче адәм актыкларын да Айдар Хәлим әсәрләрендә байтак очратып була. Боларның һәркайсының үз йөзләрен, килеш-килбәтләрен төрле әдәби чаралар, ысуллар, сурәтләр аша укучыга җиткерү алымнарын карап чыгу үзе генә дә кызыклы булыр иде.

Инде байтак вакытлардан инанган карашым буенча, А.Хәлимнең иҗат стилендәге әһәмиятле үзенчәлек һәм билгеләренең берсе итеп аның әдәби деталь һәм миниатюр бизәкләр белән оста эш итү сәләтен күрсәтү кирәк. Чыннан да, бу аның новелла-хикәяләрендә һәм «Татар вакыты» дип аталган әсәрендә бик ачык расланды.

Озакка сузылган хәл-вакыйгаларны бәйнә-бәйнә шәрехләп язу бу әдипнең стиленә ятрак күренеш булып тоела. Бәлки, нәкъ менә шуңа күрәдер дә, аның масштаблылыкка омтылышы, инде болай да зурны, ниндидер ясалма чаралар кушып булса да, тагын да зуррак, тагын да бөегрәк итеп күрсәтергә омтылуы шәхсән үземне бераз гаҗәпләндерә төшә. Мондый «монументальлек чире» авторыбызда табигыйме, ул аны башка «бөек»ләрдән йоктырмаганмы? Ошбу чирнең шаукымы инде элегрәк «Татар вакыты» әсәренең жанр формасын билгеләгәндә үк сискәндереп алган иде. Әлеге гүзәл һәм җыйнак повестен автор, ни сәбәптәндер, укучыларга «кечкенә роман» дип тәкъдим итте. Соңгы елларда гаять киң масштаблы, эпопея рәвешендә уйланылган өч томлы «Хунвэйбин» һәм эпик документаль һәм публицистик катламнардан төзелгән «Татар солдаты» әсәрләренең дөньяга килүе авторның амбицияле омтылышларының кайсы юнәлештә икәнлеге турында ачык сөйли булса кирәк.

Гомумән алганда, А.Хәлим иҗаты үзенең масштабы белән гаять якты, чекерәеп янган йолдызлар белән бизәлгән күк гөмбәзен хәтерләтә. Нәрсә турында сөйли, нинди тормыш катламнарын ача-яба бу «монументаль гөмбәз»? Гади гәзит сурәтләмәсеннән, йөзләгән шигырьләр, поэмалар, хикәяләр, повестьлар, романнар, публицистик мәкаләләр аша «кем җырын җырлый» андагы геройлар

һәм катламнар? Әллә алар, даладагы акын кебек, күзе нәрсәгә төшсә, шуны җырлыймы, әллә ул җырларның уртак бер вакланмасы, түшәм-түбәсе бармы? Баксаң, Айдар Хәлим прозасы ул – XX гасырның икенче яртысында яшәгән һәм үз хокуклары өчен көрәшкән сугыш ятимнәре, ятимәләр, тол хатыннар турында фәлсәфи-нәфис әдәбият, җырлар тупланмасы, сага икән. Ул – энәсеннән җебенә кадәр, сугыштан беркайчан да аклана алмый торган зыян алган сабый, ана, әби-баба сагышы икән. Дистәләгән хикәя – бер бетмәс-төкәнмәс ятимлек сюжеты. Ул – гражданлык өлгерүе һәм тәрбия мәктәбе турында нәфис хикәят. Аның герое, маңгаена шешләр ала-ала, буш мораль, сентимент, иллюзияләрдән арына. Аның картлыгы да кабат кабатланган балачакны хәтерләтә («Татар вакыты» – Мотаһар, «Хунвэйбин» – Иркен ага). Моңа кадәр татар әдәбиятында сугыш ятимлегенең социаль-сәяси аспектларын бу кадәр озаклап тулы һәм җентекле итеп ачып салган язучы юк иде сыман. Сугыштан ата-анасыз, ач-ялангач кына түгел, китапсыз, хокуксыз калган татар баласы турында язучы тудырган нәфис әдәбият җир йөзенең теләсә нинди әдәбиятларында бу темага язылган әсәрләр белән уңышлы ярыша алырлык һәм сугышка каршы хәрәкәттә татар милләтенең йөз аклыгын якларлык рухи чыганакка әверелә («Трофей ашъяулык», «Ат казнасы», «Исемсез малай», «Берлинга хат» һ.б.) Дөнья әдәбиятында моның аналоглары да бардыр, бәлки. Ләкин бу бер-береңне кабатлау дигән сүз түгел. Чит илләрдәге ятимлек белән Татарстандагы ятимлек арасында охшашлыклар булган кебек, аерымлыклар да бардыр. Мин дөнья әдәбиятлары, шул исәптән унтугызынчы гасырда яшәп иҗат иткән бөек инглиз классигы Чарльз Диккенс буенча белгеч түгел. Шулай да бу язучы иҗатының үземә билгеле өлеше дә (әйтик, «Оливер Твист маҗаралары», «Николас Никльби», «Домби һәм аның улы» һ.б.) миңа Ч.Диккенс белән А.Хәлим иҗатлары арасында ниндидер охшашлык бар дип әйтергә мөмкинлек бирә. Алар икесе дә балачак җырчылары. Араларындагы төп аерма: Ч.Диккенс капиталистик-буржуаз җәмгыять урамга чыгарып ыргыткан сабыйлар – йортсыз-гаиләсез урам үсмерләре тормышын сурәтләсә, А.Хәлим социализм-коммунизм дигән әкият хакына ата-анасыз, аталары булып та, атасыз («Ат казнасы»), хәтта имансыз калган буыннар турында яза.

Кем белә, исеме – колагыма, әсәр үзе Айдар Хәлим иҗатын аңлавыма ятрак тоелган «Хунвэйбин» дигән гаять киң колачлы роман-эпопеясе, бәлки, алга таба бу авторны бөтенләй башка якларыннан таныτыр?.. Ялгышмасам, Мәхмүт Галәү тетралогиясеннән кала мондый олы әдәби «келәм-тукымаларны» бүтән тукучы булмады бугай.

А.Хәлим – нәни детальләр тарафдары дигән идек. Чыннан да, ул беренче карашка артык җитди тоелмаган тормыш ваклыкларын да энҗедәй балкып торырлык, тирән мәгънәле сәнгать һәм тормыш күренешенә әйләндерә белә.

А.Хәлим хикәяләренең повесть дип атарга мөмкин булганнарының байтагында төп геройлар – сабыйлар яисә сабыйлыктан яшүсмерлеккә чыгып килүчеләр. Тормышка сабый күзләре белән карау, күренешләрне яшүсмерләр хөкеме аша үлчәү, шуларның күңел бизмәннәренә салып, бәхет-хәсрәт, гаделлек-имансызлык, матурлык-сыйфатсызлык, миһербанлылык-юньсезлек кебек күренешләрне бәяләү, шуларны күрә-күрә, дөньяны-яшәешне аңларга, бу тигезсез һәм мәрхәмәтсез тормышта үз урыныңны табарга тырышу – менә Айдар Хәлим әсәрләрендә еш очрый торган мотивларның кайберләре...

Боларның барысы да язучыныкы, аның үзенеке икәнлеге әллә каян ялтырап күренеп тора. Әдип бу урында ялганлый да, укучысын адаштыра да алмый: чөнки боларның барысының да нигезендә, Клондайк җырчысы Джек Лондонныкы кебек, булган вакыйгалар – фәкать үзе күргән, үзе кичергән, алданган, җәберләнгән, рәнҗетелгән, үзе ышанган шатлык-хәсрәтләре, өметләре, омтылышлары, хыяллары ята.

«Кылганнар чәчкә атканда», «Теге малай», «Трофей ашъяулык», «Берлинга хат», «Китап», «Калеб яратылганда», «Әкчин», «Саный башлаганда», «Җырлар вакыт» хикәяләре, «Казыктагы тальян», «Өч аяклы ат» повестьлары – мондый әсәрләрне әдипнең иң югары казанышларыннан дияргә була торгандыр. Мондагы балаларның исемнәре дә бик матур: Зирәк, Бәгърем, Тансык, Кадерҗан, Канәгать, Балкыз, Кәбир һ.б. – исемнәр сайланышында аларга карата мөнәсәбәт тә, милли-мәдәни таләп тә, персонажның кайбер характер чалымнары да чагылгандай була. Мөгаен, мондый сайланышка нык төпченүне авторның детальгә мөнәсәбәтенең тотрыклы бер сыйфаты дип санарга кирәктер, чөнки олылар турында сүз барганда да шактый хикмәтле һәм сәер исемнәргә юлыгасың. Әлбәттә, халык арасында көн итүчеләрнең исемнәре дә кешечә: Өммегөлсем, Сәгыйдә, Сәгъдәт, Мөхәммәт, Гарифулла, Салихҗан һәм башка бик күп, бик матур татар исемнәре... Ә инде Гегель Әфләтунович, Псих (психолог сүзеннән кыскартылган) Сәлимгәрәевич кебек тузга язмаган исем ияләре лаексызга күтәрелгән, сәнәктән көрәк булган юньсез түрәләр арасында күбрәк очрый.

Бик күп әсәрләрендә икегә бүленеш күзәтелә: бер яктан гүзәллек, сафлык, миһербанлык ияләре балкыса, икенче яктан явызлык, әшәкелек, башкаларны санга сукмыйча, кирәксә, тегеләрнең башларына басып, өскә ыргылучылар пәйда була. Гомумән, бу иҗатның төп нигезен әнә шул Кеше гүзәллеге һәм аның үзенә хас матурлыгы шартларында яшәргә лаеклы булуы һәм тиешлеге тәшкил итә. Һәм моның символлар, шактый «вак» детальләр аша зур масштабта чагылуы һич тә гаҗәп түгел.

Элек тә, бүгенге шартларда да Явызлыкның еш кына өстен чыгуы, саф күңеллеләрнең, гадиләрнең бәхетсезлеккә тарулары әдипнең күңелен аеруча яралый. Әнә шундый ике гади саф күңел – татар карчыгы Гайния һәм сугыш чорында эвакуацияләнеп, шул татар авылына кайтып, шунда төпләнеп калган рус карчыгы Анна Афанасьевна бәхетсезлек кичерәләр. Сугыш вакытында Гайниянең ире, лагерьдагы ачлыктан тире һәм сөяккә калып, командирларының мәсхәрәләүләренә түзә алмыйча, качып авылга кайткан булган. Әлбәттә, дезертир монда озак тора алмаган: власть – НКВД кешеләре – авылдагы яманаты чыккан үләксә чокырында аны кулга алып, каядыр озатканнар, һәм Гали яңадан әйләнеп кайта алмаган, ә Гайниягә «дезертир хатыны» дигән тамга бик озакка ябышып калган. Сугыш чоры бәхетсезлекләрен тылдагыларның да бик күпләре кичергәндер, әлбәттә. Кешеләрнең мондый рәнҗетелүләрен хәтерләтә торган теге чокырны авылдашлары «Ыгдыбыгды чокыры» дип йөртә башлый. Мәгълүм аббревиатураны татарчалаштырып, шулай бозылып әйтелеше һич тә күңелне иркәләми кебек. Әмма... Әмма шушы тел бозылышы геройларны иҗтимагый чынбарлыкның, тормышның бозылышына алып килә, аларны «үләксә базына» куып кертә, шуның аша авторның иҗтимагый режим явызлыгына мөнәсәбәте белдерелә. Инде күп еллар узгач, нәкъ шушы чокырда Анна Афанасьевнаның бердәнбер куанычы һәм туйдыручысы булган кәҗәсенең бүре тарафыннан ботарлануы – шул мөнәсәбәтне көчәйтү вазифасының икенче уңышлы детале дип бәяләнә ала. Хикәяне чын хикәя итүче башка вак детальләр дә мулдан сибелгән: Гайниянең урыс телен чиктән тыш имгәтеп, Аннаның ике телне бергә болгатып сөйләшүләренә карамастан, гаҗәеп матур үзара аңлашулары, кәҗәнең Василиса кушаматлы булуы һәм үлеме алдыннан кычкырган соңгы авазының карчыкларга «ма-ма!» дип ишетелүе – болар барысы бергә аралаштырып бирелеп, юмор белән җитдинең бергә мәгънәле кушылуы, әдипнең новелла язу осталыгы һәм әнә шулай яңа, оригиналь формада төп фикерне әйтә белүе хакында да искәртә.

«Кыйбла» дигән хикәядә бер-берсен яратып, сөеп яшәгән Гарифулла белән Өммегөлсемнең тормышлары тулысынча укучы күз алдыннан узып китә. Бу тормышлар җиңел булмаган. Ил язмышы белән бергә яшәгәннәр, тарих

сөрешендәге вакыйгаларның авырлык-михнәтләрен дә ил, халык белән бергә татыганнар һәм кичергәннәр. Гадәттәгечә, җанга якын мондый сөйкемле кешеләрне әллә кайлардан эзләп тормый әдип – һәрбер татар авылында андыйларны очратып була торгандыр... Икесен дә замана михнәтләре гомерләре буена талкыган – аларга авылны күмәкләштерүгә кагылышлы хәрәкәтләрне дә татырга, динне мәсхәрәләү, мәчет манараларын кисеп төшерүләрне, сугыш фаҗигаләрен, соңрак СССР дигән империянең таркалуын да күрергә туры килгән. Хәер, мондый хәлләр бер алар башыннан гына узганмыни?! Әдип миллионнар язмышы турында сөйли түгелме соң? Әмма ул язганнарын чын әдәби табыш, чын хикәя итәрдәй ике нокта – ике деталь таба алган: беренчесе – геройларыбызның гомер буе икесенә дә тынгылык бирмәүче үз хәсрәтләре бар икәнлеген белдерә – Өммегөлсемгә, моннан илле ел элек, ире фронтта чакта, имчәк баласы белән Үзбәкстаннан туган авылына бөтенләйгә дип кайтырга чыккач, февраль суыгында, юлда, поездда гомере өзелгән сабыен Әкчин дигән станциянең каеннары төбендә җирләп калдырырга язган икән. Һәм автор шушыннан безне сюжетның икенче ноктасына юнәлтә: бу Тансык атлы сабыйның рухын шат итеп, мөселманча укыйсын укып, җәсәден кыйблага каратып урнаштырылуы лаземлеген төшендерә. Менә ни өчен Бөек Җиңү дип аталган гарьле-моңсу җиңүнең илле еллыгы көннәрендә картларыбызга улларының чит-ят тарафлардагы каберен, Ходай мөмкин итсә, эзләп табу һәм җәсәден яд итеп кайту хыялында яңадан сәфәргә чыгарга, җаннарын борчыган гамәлләрне кешечә хәл итү өчен тырышырга туры килә. Кыйбла сүзе дә үзенең олы мәгънәсендәге төшенчәсенә якынлаштырыла – «Синең кыйблаң бармы?», «Син кеше булып яшисеңме бу фани дөньяда?» дигән глобаль сорауларга җавап эзләүгә әверелә.

Ә шулай да шәхсән үземә А.Хәлимнең алдагы зур ачышлары геройларның балачакларыннан, тормышның олы, каршылыклы дәрьяларына күчеп барган мәлләрен сурәтләү җирлегендә башкарылыр төсле. Бәлки, балачакта күңелләренә иман нурлары сеңгән нәниләребезнең өметләре олылар дөньясында яңадан-яңа күркәм яклары белән ачылыр дигән фаразыбыз авторның соңгы әсәрләрендә расланып килә. Аның аксакаллары да еш кына сүзнең бик яхшы мәгънәсендәге «сакаллы сабый»лар булып чыга, ягъни геройларның күбесе, олыгайгач та, сабыйлыкның кайбер матур сыйфатларын югалтып бетермиләр. Гүя автор өчен кеше гомере – җанда гомер буе дәвам иткән балачак. Нәрсә белән бәйләнгән феномен бу? Монысын әле киләчәк тәнкыйтьчеләре ачарга тиеш булачак. Балаларның яраткан китапларына әверелгән шигъри «Биктырыш», «Кыярга төшкән малайлар», «Казанбаш», «Өч аяклы ат», «Тал баласы Талхаветдин» кебек шигъри һәм чәчмә әсәрләре алдагы фикеребезне раслар дип уйлыйбыз.

Кайсы гына яктан – ул гражданлык, социаль-иҗтимагый, сәяси яки эстетик аспект булмасын – карасаң да, бүгенге татар әдәбиятында Айдар Хәлимнән башка аеруча кыю, үзенчә уйлаучы, үтә дә хөр фикерле бүтән иҗатчыны очратуы кыен. Әдәбият тарихының олы юлында андыйлар да булгандыр, әлбәттә. Әлегә сүз бүгенге көн турында гына бара. Мондый могиканнарның соңгысы бездә, мөгаен, Мөхәммәт Мәһдиев булгандыр – әмма аның иҗат диапазоны күбрәк әдәбият-сәнгать һәм көнкүреш мәсьәләләре белән чикләнә иде сыман. Ә монысы үзфикерлелеккә, оригинальлеккә теләсә кайсы өлкәдә, шул исәптән милли рух, милли азатлык белән бәйләнешле аспектларда да дәгъва итәргә омтыла. Шул ук сюжет, жанр, композиция белән бәйләнешле мәсьәләләрне чишкәндә дә А.Хәлим оригиналь, мөстәкыйль фикерләү сәләтен һәм индивидуаль иҗат алымнарын сакларга тырыша.

Соңгы елларда әдипнең иҗаты бик үзенчәлекле яңа сыйфатлар белән баеды. Мондый үзгәрешләр «Хунвэйбин» (1997-2007) китабында ачык күренә. Чыннан да, «Хунвэйбин» роман-эпопеясына әдип бар таланты-сәләтен, дөньяга караш-күзәтүләрен барын бергә җыеп-туплап, бербөтен итеп бирергә тырышкан. Ул

үзенә күрә исеменең асыл мәгънәсен туган телебезгә төп-төгәл итеп күчерүе кыенрак булган әсәрне – А.И.Герценның мәшһүр «Былое и думы»сын хәтерләтә. Һәрхәлдә татар әдибенең шушы юнәлештәге дәгъвасы кечкенәдән түгел. Күләме генә дә шуны раслап тора сыман: әсәр саллы гына өч томга урнаштырылган алты кисәктән гыйбарәт, битләренең гомуми саны 1550гә җитә. Автор бу әсәренә үзенең ун еллык иҗат гомерен сарыф иткән.

Тик ни өчендер титаник колачлы бу әсәрнең үзенә тиешле яисә лаеклы бәясен бүгенгәчә алып җиткергәне юк әле. Болай гына, «әсәргә карата ниндидер битарафлык хөкем сөрә» дип кенә үтү аз да булыр. Бу – зур әсәрне аңлы рәвештә күрмәмешкә салышу яисә читләтеп узарга маташу кебек тоела безгә. Сәбәбе нәрсәдә икән соң? Авторның нык позицияләргә басып, бик кыю социаль-сәяси мәсьәләләр күтәрүендәме, сюжеты-композициясендәге хилафлыклардамы, әллә әсәргә безнең милләт балалары колагына ятрак яңгырашлы исем куелудамы? Нәрсәдер әдәбиятыбызның агай-энеләрен шикләндерә – бер-ике сүз белән генә җавап бирүе дә кыен.

Әсәргә «Хунвэйбин» дигән яман аты чыккан, әшәкелек, кабахәтлек, нәҗеслекнең барын бергә үз эченә җыйган атама исем итеп куелган. Эчтәлеге-идеясе белән әсәр нәкъ шушы явызлыкка каршы юнәлдерелгән дә. Аның буеннан-буена яхшы, изге күңелле, күп кыенлыклар кичереп тә, халкыбызның иң матур, гүзәл сыйфатларын гомере дәвамында җуймый-югалтмый үзендә саклап кала алган Иркен Сәлахи (Сало) образы үтә. Романның социаль-эстетик яңгырашы нәкъ менә шул хунвэйбинчылык дигән тискәре күренешкә каршы юнәлтелеп, төп идея сафлык белән явызлык арасындагы көрәшкә багышланган булгач, әсәрнең исеме дә безгә ике канатлы булырга тиеш кебек тоела. Мондый контрастны әдәбият-сәнгать әһелләре үз вакытында иҗатларында бик төгәл чагылдыра беләләр иде бит (мәсәлән, Аркадий Райкинның «Кешеләр һәм манекеннар» концерт циклы, Константин Симоновның «Тереләр һәм үлеләр» романы һ.б.). Болар янында А.Хәлим әсәренең исеме белән җисеменең үзара чагышмавы әллә каян сизелеп тора. Гадәттә, исем сайлауда үтә дә талымлы авторның әлеге кимчелеге безне дә гаҗәпләндерә.

Әсәрнең буеннан-буена вакыйгалар бер сызык буенча гына үстерелә. Нәселе, килеп чыгышы белән Татарстаннан булса да, уйгурлар (Кытай) илендә үскән татар кешесен язмыш җилләре, һәртөрле эзәрлекләүләр Америкага китереп чыгара, күп төрле кыенлыклар, авырлыкларны җиңеп, Иркен Сәлахи ага бу илдә кешечә тормыш корып җибәрә. Картаймыш көнендә, туган туфрагын искә төшереп, нәсел-нәсәбе җепләрен барлау нияте белән сәяхәткә кузгала – Татарстанга килеп чыга, мондагы хәлләрне үз күзләре белән күрә, чагыштыра, анализлый, күп кешеләр белән очраша. Романның иң зур өлешен әнә шул очрашулар тәшкил итә дә инде. Әдәбият белгече Муса Мөлеков бу мөнәсәбәттә әсәрнең Н.В.Гогольнең «Үле җаннар» («Мёртвые души») поэмасы белән аваздашлыгын күрсәтүе белән бик хаклы. Беренчесендә әсәрнең герое Чичиковның сәяхәтендәге ул юлыккан маҗаралар аша Россия помещиклары һәм башка катламнарының тулы бер дөньясы күрсәтелсә, икенчесендә шундый ук композиция алымы ярдәмендә татар халкының Россия шартларында яшәеше, кая таба баруы, тормышындагы үзгәрешләр һәм шуларга татар әдибенең мөнәсәбәте бирелә. Әсәрне укучы үзенең туган ягына, кадерле Татарстан Республикасына, аның гаделлек сөюче, намуслы, тырыш һәм кунакчыл кешеләренә мөсафир героебызның күзләре аша ихтирам белән карый. Иркен аганың игътибарлы мөнәсәбәтендә ул үзен, үз хәләтен, яшәешен, әйләнәсендәге тирәлеген дә таный һәм күрә ала. Бәлки, читтән караучыга күп нәрсәләр ачыграк һәм дөресрәк күренәдер. Моны кабул итә алган укучы тирәннәнрәк уйланырга, төпченергә, тирә-юньне һәм үз тормышын яңабаштан анализларга һәм үзалдына җитди сораулар куярга керешә икән – бу бик табигый

нәрсә – әсәр барыбызны да борчылдырыр, уйландырыр өчен язылган да. Чөнки тормышыбыз ал да гөл түгел бит. Милләтебезнең барыр юллары да шактый караңгы – әлегә еракта да якты маяклар, утлар күренми.

Проблемаларның күбесе әсәрдәге геройларның уйланулары, фикер йөртүләре, сөйләмнәре аша ачыла. Сүз уңаенда, нигездә вакыйгалылыкка корылган бүгенге татар прозасында нәкъ шушы сыйфатның җитенкерәмәвен дә искәртеп үтәбез. Айдар Хәлим тетралогиясендә исә катнашучыларның байтагы зыялылык сыйфатлары, фикерләүләре белән яки нәкъ шул сыйфатлардан мәхрүм булуы белән истә кала. Алар арасында авылдан авылга кул арбасы тартып, китап өләшеп йөрүче Рәгыйб, мөлаем Сихәт Сылу, илдәге һәр яңалыктан хәбәрдар, шофёр Алик, болгарчылык тарафдары Борһанетдин, керәшеннәр мөстәкыйльлеген фанатикларча яклаучы Җәкәү, шәхси тормышыннан уңмаган Стомат Сибгатуллович, кешелек сыйфатларын наркоманлыкка алыштырган Салют Сәлахи, тагын әллә кемнәр: ялган патриотлар, халыктан, тормыштан аерылып, олы түрә булып, үзләренчә фәлсәфә корып утыручылар, сәрхушләр, бушбугаз-демагоглар һ.б., һ.б.... Әсәр барышында без герой белән бергәләп республикабызның Казан, Чаллы, Әлмәт кебек зур шәһәрләрендә булабыз, көзге пычрак юлларда йөреп, Мамадыш, Баулы, Әгерҗе якларына килеп чыгабыз, җыелышларда, конференцияләрдә, конгрессларда, хәтта мәктәп залларында балалар белән очрашуларда утырабыз. Әнә шулай Иркен аганың юл маҗаралары, фикерләрен тасвирлаганда, авторга үзен борчыган, уйландырган бик күп сәяси, иҗтимагый, икътисади мәсьәләләр турында иркенләп сөйләшергә киң мөмкинлекләр ачыла. Авторны күп нәрсәләр борчый – ни өчен аның газиз халкы бүген шундый мескен хәлгә төшерелгән, нәрсә аны шундый хокуксыз, дәүләтсез һәм телсез иткән, тарихын, үткәнен оныттырган, күпләрне эчүчелек, хәтта наркоманлык юлына этәргән? Моңа кем гаепле? – Тарих тәгәрмәче аны шулай изгәнме, әллә татар кешесе моңа үзе гаеплеме?.. Бу изелгәнлек, мескенлек халәтеннән чыгу юллары бармы?.. Әллә без котылгысыз рәвештә милләтебезне, телебезне югалтуга таба барабызмы? Сорауларга җаваплар эзләгәндә, бик тә отышлы композицион алым табылган. Азатлык, хөр яшәүнең нинди икәнлеген, шуның тәмен белгән шәхес – Иркен ага әнә шул хокуксызлар хәлен күреп, башкалар белән чагыштырып йөргәндә туган контраст автор идеясен ак һәм кара фонында бик ачык итеп күрсәтергә мөмкинлек бирә. Әсәрнең сюжет һәм композиция җепләренә дисбе энҗеләредәй тезелгән күпсанлы очрашулар әсәрнең тормышчанлыгын тагын да арттыра төшә – чөнки язмыш тарафыннан чит-ят җирләргә олактырылган карт инсанның туган илен юксынып кайтуы һәм нәсел җепләрен барлап йөрүләре бик тә табигый.

Дөрес, күпсанлы күренешләр тезмәсендә әсәрнең сюжетына турыдан-туры кагылмаганнары да очрый... Бәлки, кабатлануларның кайберләрен кыскарту хисабына бу эпопеяны җыйнакландырырга да мөмкин булыр иде. Әмма әсәрне үзенең гомер китабы дип санаган автор белән бу турыда бәхәсләшүе кыенрак.

Әле күптән түгел генә Айдар Хәлим үзенең Америкага сәяхәте турында «Йөгереп кенә кайтыр җир түгел» дип исемләнгән юлъязмаларын һәм фашизмны җиңү көннәрендә рейхстаг түбәсенә беренче булып байрак кадаган милләттәшебез Гази Заһитов турындагы тарихи документаль романын бүләк итте. Аларның дөнья күрүе факты үзе генә дә әдипнең иҗат чишмәләренең тибеше тагын да көчәеп килүе турында сөйли.

Мөхтәрәм язучы үзенең гомер бәйрәмен әнә шундый зур иҗат уңышлары белән каршылый. Сәламәтлек һәм яңа бәхетләр телибез аңа.

**Рифат СВЕРИГИН**

# УРТАК ХАКЛЫК

## РАЗИЛ ВӘЛИЕВКӘ 70 ЯШЬ



Бүгенге иҗатчылар арасында әдәбиятның һәр төрен үз иткән бер язучы, шагыйрь, тәрҗемәче, публицист, җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе аерым урын алып тора. Ул да булса – Разил Вәлиев.

Язучы Разил Вәлиев күпләр өчен, беренче чиратта, шагыйрь буларак кадерле. Балалар күңелен исә ул күбрәк дөнья халыклары әкиятләренең тәрҗемәләре аша яулый. Ә прозаик Р.Вәлиев исә, нишләптер, игътибардан бераз читтәрәк калып килә. Югыйсә аның прозасы үз вакытында һәм соңрак та тәнкыйтьче һәм әдәбият галимнәре тарафыннан югары бәяләнде. Аның иҗаты турында саллы сүзләр әйткән Миркасыйм Госманов, Аяз Гыйләҗев, Әбрар Кәримуллин, Фәрваз Миңнуллин, Дания Заһидуллина һ.б. исемнәрен атап үтү дә ни тора! Шунысы куанычлы: 2013 елда язучының нәкъ менә чәчмә әсәрләрен тикшерүгә багышланган фәнни хезмәт – кандидатлык диссертациясе өлгерде. Аның авторы – Алфира Хәйруллина.

Бүгенге көндә Р.Вәлиевнең дөнья күргән прозасын өч повесть һәм бер роман тәшкил итә. Шунысы аяныч: язучының беренче чәчмә әсәре, «совет чынбарлыгын каралтып күрсәтүдә» гаепләнеп, ике дистә елдан артык укучысына тулы вариантта барып ирешми. «Эт кояшы» дип исемләнгән әлеге повесть 1968 елда язылган була.

Әсәр Ирекнең эчке монологыннан башлана һәм ирексездән укучыны шактый баш ватарга мәҗбүр итә. Ни өчен бу уйлар герой күңелендә туа? Ни булган соң? Рәхимсез, ерткыч кеше... Үзләрен Аллага тиңләгән даһилар... Иҗат кешесен юләргә санаучылар... Алга таба исә ретроспекция алымы ярдәмендә әсәрнең авторы вакыйгаларны барлый башлый. Укучы герой күңеленең яраланган булуын аңлый: «Кеше рәхимсез. Бик рәхимсез! Нигә кирәк булды бу су кызларын, урман егетләрен уч төбе кадәр мәйданга менгереп, мәгънәсез сикерүләр, бил бөгүләр, баш чөюләр, кул болгаулар, йөзгә, меңгә сыгылулар аша табигатьне кабатларга тырышып тамаша куеп азапланулар? Минем ярага тоз салыр өченме? Илаһи, тиңе булмаган бөек табигатьтән көлү, аны мәсхәрә итү бит бу». Игътибар итик, сәхнәгә менеп: «Мин – Шекспир!» – дип кычкырган сәер, юләр ир-ат бала чакта ук «сәер малай» буларак дан казана. Сәерлек исә гади генә аңлатыла: малай нечкә күңелле, кызганучан бала булып үсә. Шуның өстенә бала чактагы бер аяныч вакыйга аның күңелендә тирән эз калдыра. Каз бәбкәсе белән бәйле әлеге истәлек еллар узгач көтелмәгән рәвештә калкып чыга. Әсәрнең исеме үк эчтәлеккә бер ишарә рәвешендә яңгырый. Эт кояшы – алдаучан, ялган кояш. «Сәер малай» әлеге кояшны куып яши, ләкин аннан җиңел генә котыла алмый. Ирекнең күңелендә балачактан ике хатирә ачык уелып калган була. Аның берсе – уртак кояшны каплый торган болытлар: мич ягып, дөньяга төтен таратып, көнне болытлы иткән кешеләрне үз җылылары турында гына кайгыртып бөтен кешеләргә начарлык эшли дип саный ул. Икенче фәлсәфә исә каз бәбкәсе белән бәйле вакыйга. Нәкъ менә икенчесенә әсәр герое фәлсәфә чыгара алмый һәм шул хатирә аны борчып, һәрвакыт уйланырга мәҗбүр итә.

Кызгану хисе повестьның төп героен башкалардан аерып куя. Бер караганда, Ирек Әминәгә кызганып өйләнә сыман, гәрчә ул үзе моны мәхәббәт, ярату дип аңласа да. Ләкин башкалар Әминәне Ирек кебек кызганырга атлыгып тормый. Ягъни, Ирек гадәти булмаган гамәл кыла. Шул ук вакытта аның үзен дә кызганалар: декан, дусты Фәрит, әнисе... Кафедра мөдире дөрес, яхшы адымы белән тәбрикли. Гәрчә Ирек үзе игътибар үзәгендә булып, кызгану чыганагына әйләнергә теләмәсә дә. Ул гадәти студент булып яши бирер иде. Ә бер кызгану хисенең ни белән тәмамланганын күргән Ирек кабат шул ук юлны уза: югалтуга дучар ителә.

Әминәгә өйләнү биредә бала чактагы кызгану хисен тудырган сәбәпне акларга тырышу булып аңлашыла ала, чөнки каз бәбкәсен бәладән коткарып кала алмаган Ирек Әминәгә изгелек кылырга тели, өйләнергә ниятли. Игътибар итик: ата-анасы

аның бу адымын хупламый, бабасы да ата-баба йоласын бозуда гаепли. Ягъни, бер каршылык килеп чыга. Икенче каршылык – яшьләрнең «төрле дөнья» кешеләре булу. Ирек – гап-гади авыл малае. Ул авылда үскән, аның киңлеген сеңдергән, шуңа да күңеле шәһәр читлегенә ияләшә алмый интегә. Автор бу хакта ачыктан-ачык белдерә: «Ул театр ярата. Мин – чеп-чи авыл малае. Минем «Тәфтиләү», «Гөлҗамал»ларга җайлашкан колак Бетховен, Чайковский, Яруллиннарга ияләшә алмыйча иза чикте. Әминә, аларны аңлап, акылы белән яхшысын-яманын үлчәп тыңлый. Ә минем баш катнашмый. Бары йөрәк, күңел, җан... Музыка тыңлаганда, мин югалам, онытылам, адашам...». Ирекнең шигъри җанлы булуын да онытмыйк: «Шагыйрьләр – гомер буе сабый булып кала алган кешеләр. Тик акыллы сабый булып». Ул шигырьне могҗизага тиңли. Аның шигырьне аңлаучылар турындагы фикере кызыклы: шигырь – могҗиза, шигырьне бөтен тирәнлеге, нечкәлеге белән аңлаучылар – могҗизага ышанучы, терелүгә өмет итүче авыру кешеләр. Ирек могҗизага ышана... Әминә исә могҗизага ышанмый. Әминәгә өйләнү – бала чакта кызгану хисен кузгата алган вакыйгаларны яңадан кичерү аша үзеңне табу, ялгышны төзәтү. Ләкин Әминәне кызганып ул аны бәхетле итә алмый, үзе дә аяныч хәлгә кала.

Эчтәлектән күренгәнчә, Ирекне акылдан яздыру дәрәҗәсенә җиткергән сәбәпләр берничәү. Барысы да Әминә белән Фаяз арасында булган мөнәсәбәтләрне институт дәрәҗәсенә җиткереп оештырылган җыелыштан башлана: «Ул төнне мин йокламадым. Каз бәбкәсе белән булган фаҗигадән соң, мин менә тагын икенче тапкыр тормыш бөтерчегенә эләктем». Алга таба Әминәнең әнисе белән булган әңгәмәсе аша без Ирекнең юләрләр, акылдан язганнар турында күп уйланып йөргәнен беләбез. Күрше кызыннан килгән хат Әминәнең ачуын чыгара. Ирек исә шуннан соң тернәкләнә алмый: «Ул минем бөтен чынбарлыгымнан, рухи халәтемнән, өметләремнән, яшәешемнең мәгънәсеннән көлде. Кешене чокырдан тартып чыгардым, кешене коткардым, дип уйлап, тормыштан кызык табып, очып, янып яшәгәндә, кинәт бетеп, бушап калдым. Ул чокырга хәзер мин үзем төштем». Искә төшерик, каз бәбкәсе дә чишмә чокырында җан бирә. Иң аянычы – Ирек үзен гаепле санап хәтта җинаять кылдым дип саный. Тик үз-үзенә аклану таба алмый, чөнки гаебенең нәрсәдә икәнен белми. Бәлки, Әминәгә Фаяздан килгән хатны укымаган, аның алдавын аңламаган булса, Ирек акылдан да язмас иде. Ул кызганып йөргән Әминә аны алдый, самими, нечкә күңелле Ирекнең бәгырен яралый.

Шул ук вакытта Ирек фикерен исә төшерик: «Һәр җинаятьченең җинаятен аклый торган үз фәлсәфәсе була. Шуннан башка ул яши алмас, вөҗдан газабыннан үләр йә акылдан язар иде. Мин исә гаебемнең нәрсәдә икәнен дә белим, шуңа күрә аклану да таба алмыйм. Ләкин хәзергә үлмәдем дә, акылдан да язмадым әле». Димәк, Ирекнең акылдан язуы вөҗдан газабыннан килеп чыккан һәм ул – җинаятьче. Вөҗдан газабы исә бала чакта каз бәбкәләрен җиренә җиткереп карамау вазифасына барып тоташа. Әнә шул гаеп хисе Ирекнең күңелен битәрли. Ул каз бәбкәсе кебек яраланган Әминәне коткарырга тели, ләкин вөҗдан газабыннан котыла алмый. Ирек тулаем гаилә корып, җаваплылык тоеп яшәргә әзер түгел. Ахыр чиктә ул барысын да аңлый һәм ачынып, беренче чиратта, үзенең дә гаебен танып, «Әминәне нишләттегез», дип кычкыра. Тик соң була. Шунда ук Әминәнең Фаяз аркылы ачылып киткән «яңа йөзе» җинаятьчене үлемнән саклый. Ирек гаебен аклый. Ирек иреккә чыга, күңел иреге, җан тынычлыгына ирешә. Ышанасы килә, авыл һәм баласы аңа тормыш юлында таяныч булырлар.

Әсәр ахырында төп герой авылга юл тота. Алдарак булып узган бер вакыйга искә төшә. Күрше кызы аны озатып калганда, Ирек үзенең җиргә бәйләнгәнен, канатсыз икәнен ныграк сизгән, олы җирнең бәләкәй генә кешесе булуына тагын да ныграк инанган иде. Ягъни биредә авыл кеше җанын коткаручы, аңа ярдәм итәргә мөмкин булган бердәнбер чыганак буларак тәгаенләнә.

«Эт кояшы» повестен галимә Д.Заһидуллина фәлсәфи-психологик әсәр буларак билгели. Дөрестән дә, әсәрнең эчтәлеген берничә катламда чишәргә мөмкин. Бердән, ул турыдан-туры төп герой белән бәйле вакыйгалар булса, икенчедән – җәмгыятьтә тудырылган мохит. Повесть үзенчәлекле тел-стиль белән язылган, ул әзерлекле укучыны, җәмгыятьтәге күренешләрне аңлап бәяләргә әзер укучыны таләп итә.

Язучының 1978-1979 елларда язылган «Яшисе килә» повесте да әсәр героеның күңел газаплары белән сугарылган. Әсәр татар халкының каһарман улы Рифкать Миргазизов батырлыгына багышлана. Хәрби хезмәт вакытында граната шартлап каты яраланган Рифкать яшәү белән үлем арасында бәргәләнә. Дөньяда бары унтугыз ел гомер сөргән әлеге яшь күңел үткән юлын күзаллый. Аргта – балачак, мәктәп, кайгы-хәсрәтсез үткән яшьлек еллары. Рифкать ата-анасы, дуслары белән булган вакыйгаларны искә төшерү аркылы үз гамәлләренә бәя биреп бара. Аның үлем кочагына керәсе килми, чөнки ул авылга кайтырга вәгъдә иткән, аның әти-әнисен сөендерәсе, дуслар белән урам тутырып йөрисе, укырга керә һ.б. зур эшләр майтарасы килә. Әмма боларның барысы да чынга ашмас хыялга әверелә. Рифкать моны аңлый. Ул үлемнән дә курыкмый, гранатаны да үз кулында шартлатканы өчен үкенми, ләкин күңеле сызлана. Повестьта Харрас бабай сүзләре аркылы әсәрнең төп идеясе җиткерелә: сау-сәламәт кеше генә яшәү кадерен белми ул. Дөрестән дә, авыру халәттә, үлем алдында гына кеше яшәүнең кадерен ныграк аңлый башлый, бушка үткән гомерен, вакытын кызгана, үкенә. Әлеге әсәре аша язучы һәр кешенең гомере бер мизгел эчендә үзгәреп, һәлакәт алдында калырга мөмкинлеген искәртә. Кеше кылган гамәлләрен һаман үлчәп эшләргә, гомеренең кадерен белергә тиешлеген ассызыклый. Гадирәк юл белән барганда, әсәр патриотизм рухына, батырлыкка дан җырлый.

Р.Вәлиевнең «Иске сәгать дөрес йөри» (1981) повестеның герое Искәндәр – нечкә җанлы шәхес – ул музыка әсире. Авылдан калага укырга килеп, биредә гаилә корып җибәрә. Искәндәр үзен бөек максатлар өчен дөньяга килгән дип саный, даһи музыка язарга хыяллана. Ләкин бер мәлгә аның барлык яшәеше асты-өскә килә: хатыны һәм кызы аны ташлап китә. Гаиләсен үзенең хыялында туган музыканы иҗат итәргә комачаулаучы көч дип аңлаган Искәндәр кинәт кенә тормышының бар ямен җуя, ялгыз кала. Шул вакыт ул дусларыннан ярдәм өмет итсә дә, ялгыша. Аларның барысы да Искәндәрне Сөмбелдән башка күзалламый. Ул Сөмбелдән башка үзе дә үзе түгел кебек.

Шунысы кызык: «Эт кояшы» повестендагы кебек биредә дә төп герой һәм аның хатыны – ике төрле дөнья – авыл һәм шәһәр балалары. Сөмбел дөньяга акыл, якты күз белән карый. Искәндәр исә хыялларга чумып яшәүче зат. Сөмбел фикеренчә, кешеләр – Җирнең үги балалары. Шуңа да алар Җирнең кадерен белми, аның матурлыгын сакламый. Искәндәр исә аның бу карашы белән килешмәсә дә, ахыр чиктә үзен шәһәрдә үги бала булып хис итә башлый. Нәкъ менә шул үгисенү, үзеңне ялгыз тою аны ялгыз анасының язмышы турында уйландыра. Моңа кадәр фани дөнья мәшәкатьләреннән арынып, хыялланып яшәргә омтылган Искәндәргә исә, бер карасаң, бар юллар да ачылган иде. Әмма ялгыз калган күңел тынгылык тапмый.

Повесть дәвамында Искәндәр дуслары, танышлары, юлдашлары белән диалогка керә, аларның үзара сөйләшкәннәреннән нәтиҗә чыгарырга тырыша. Менә Альфред аңа дөньяның базар булуын төшендерә, бер читлеккә кергәнсең икән, шул шартларга ияләшергә чакыра. Фидан Искәндәрне тормышны катлауландыруда гаепли: «Тормыш син уйлаганча ук катлаулы түгел бит ул. Һәркем үзенең бәхете турында үзе кайгыртырга тиеш. Һәр кеше бәхетле булса, бар халык бәхетле була, дөнья түгәрәк була». Ахыр чиктә Искәндәр кызы Ләйсәннән килгән хатны укып үзе дә нәтиҗә чыгара: «Ул чынлап та яши белми, ахрысы. Кеше җылысына өмет итеп яшәмәскә, иң элек үз учагыңны тергезергә кирәк. Кемнең учагы зуррак, халык шуның янына җыелачак... Әгәр дә син кешеләр арасында яшисең икән, аларның гореф-гадәтләрен, йолаларын хөрмәт итәргә тиеш». Менә ни өчен иске сәгать кисәтү ясый аңа.

Тормышта үз урыннарын таба алмыйча газапланучылар да бер Искәндәр генә түгел икән. Поездда очраган юлдашлары төп геройга хакыйкатьне аңларга ярдәм итә һәм ул, ниһаять, «Якты юл» станциясенә якынлаша.

Р.Вәлиевнең «Мирас» романы 1983 елда дөнья күрә. Әсәрнең исеменә чыгарылган «мирас» сүзе, чыннан да, роман эчтәлегенә ачкыч ролен үти. Биредә «мирас» сүзе берничә мәгънәдә бирелә: ул бер үк вакытта матди һәм рухи дөнья табышы булып тора. Олы буынның гореф-гадәтләре, дөньяга карашлары, яшьләрнең бүгенгесе – болар барысы да иртәгә киләсе буынга мирас. Әнә шул мирас тапшыру күренеше романның

сюжет композициясе нигезендә Зыятдин, Тимерхан, Ихтыяр кебек геройлар үрнәгендә ачык чагылыш таба. Аларны туганлык мөнәсәбәтләре бәйләп торса да, һәрберсе үзенчәлекле үз заман шәхесе буларак ачыла. Күрәбез, Зыятдин совет чорын үз итми: авылдан читләшеп, атауда берүзе яшәп ята. Кияве Тимерхан, киресенчә, патриотик рухны алга сөреп, коммунизм төзү юлында йөргән кеше; Ихтыяр исә әнә шуларның барысын күреп үскән, ләкин боларга иярми, үз тормыш дөреслеген табарга тырыша. Шунысы кызык: әлеге геройларның эш-гамәлләре аша алар яшәгән чорга тәнкыйди караш бары тик тискәре якларны калкытып чыгару аша бармый. Автор һәр нәрсәдә уңай күренешләр эзли. Һәм таба. Моңа кадәр, 1960-1980 елларда язылган әсәрләрдә, күбесенчә, совет идеологиясен кискен рәвештә кире кагу, аны каралтып сурәтләү өстенлек итсә, язучы Р.Вәлиев башкача эш итә. Дөреслек исә кайчан да булса барыбер калкып чыга: бүгенге көндә җәмгыятебезгә совет чорында кулланылган уңышлы гамәлләр әйләнеп кайта тора...

Әсәрдә ярдәмче сюжет сызыклары да заман өчен актуаль мәсьәләләрне күтәреп чыгу белән кызыклы. Менә Ихтыяр – Зәлия арасындагы мөнәсәбәтләр. Биредә дуслык-туганлык-әшнәлеккә корылган заман сулышы, эгоистлык, ялган кебек күренешләр ап-ачык чагылыш таба. Карьера артыннан куган Зәлия, Нурисламнар, ахыр чиктә, күңеле саф булганнардан читләшә. Әнә шулай тормыш барысын да дөресли.

«Мирас» романында күтәрелгән зур мәсьәләләрнең тагын берсе – авыл, татар авылы юкка чыгу. Моңа шулай ук телне югалту, оныту проблемасы да килеп кушыла. Халкыбызның гасырлар дәвамында гореф-гадәтләрен, телен, миллилеген саклап килгән авыл, аңлашылганча – олы мирас. Кызганыч, әлеге мирасның бетеп баруы бүген дә (әсәр язылганга утыз елдан артык вакыт узса да!) дәвам итә һәм аяныч төсмер ала. Югыйсә мирасны саклау изге бурыч булып торса да. Билгеле, әсәрдә авыл күчереп утыртыла һәм шул рәвешле сакланып кала алу мөмкинлеге туа. Әмма авыл яшәсен өчен бу гына аз. Йортлары сакланса да, авылның рухи халәте юкка чыгу турында сүз бара монда. Яшьләрне исә хәзер дә шәһәр йота тора...

Р.Вәлиевнең романын аның повестьлары белән бер яссылыкта тикшерү дә кызыклы нәтиҗәләр бирә. Мисал өчен, төп геройларның барысы да – яшь ир-атлар. Аларның һәрберсе бер мизгелдә тормышта көтелмәгән каршылык белән очрашып, үз-үзен табарга, үткән елларына бәя бирергә тырыша: Иреккнең хатыны үлә, үзе акылдан яза; Искәндәрне хатыны ташлап чыгып китә, Рифкать граната шартлап үлем хәлендә больницага эләгә; Ихтыярның бабасы авыр хәлгә кала, Зәлия белән булган вакыйгалар... Аларның һәрберсе үз бәхетен табарга омтыла. Миркасыйм Госманов әлеге мәсьәләне кешеләрнең гармониягә, бәхеткә омтылулары дип гомумиләштереп билгели. Әсәрләрнең өметле рәвештә тәмамлануы да куандыра.

Язучы һәр әсәрендә, беренче чиратта, гомумкешелек өчен кадерле кыйммәтләр турында сүз йөртә һәм аларны шәхси бәхет, тормышта үз урыныңны табу, җәмгыятькә файдалы шәхес булып яшәү аркылы күрсәтә. Ягъни, аларга уртак хаклык, уртак хакыйкатьне төшендерү хас. Шулай ук язучы милли мәсьәләләрне дә читләтеп үтми. Авыллар бетү, телне оныту, матди байлыкка кызыгу... Боларга Җир, табигатьне саклау мәсьәләләре дә килеп кушыла: уңдырышлы басуларны су басу («Мирас»), нефтьле Идел сулары («Эт кояшы»). Шул рәвешле, каләм әһеле безне табигать белән кешелек арасындагы аерылгысыз мөнәсәбәтләр турында уйландыра.

Р.Вәлиев әсәрләренең үзенчәлекле ягы – аларны укыган саен яңадан-яңа фикерләр туа, вакыйгалар кат-кат уйландыра. Сизмәстән, үзең дә аларның кичерешләренә кереп чумасың, һәм бу – язучы прозасының сихри көче дип кенә бәяләнә ала.

**Ләйсән ГАЛИЕВА,**
*филология фәннәре кандидаты, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият белеме бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

**Редакциядән:**
*Каләмдәшебез бу айда үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*

# ТАРИХ ҺӘМ ЗАМАН



*Тарих фәннәре докторы Дамир әфәнде белән инде чирек гасырлап аралашабыз. Бу күренекле галим, шөкер, татар халкын һәм аның үткәнен өйрәнү белән генә чикләнмичә, халкыбызның киләчәге өчен дә җан атып яши, һәм шуның хакына шактый гына тәгаен эшләр дә эшләде әле. Мәсәлән, татар халкын 2002 елгы халык исәбен алуның зыянлы нәтиҗәсеннән коткарып калыр өчен иң нык тырышкан кеше нәкъ менә ул булды дип беләм. Шул җәһәттән кылган күп кенә игелекле гамәлләре арасында ике әңгәмәбез дә бар. Берсе («Без – татар халкы», «Идел», 2002, №3,4) – җанисәп алдыннан, икенчесе исә («Безне санадылар», «Казан утлары», 2005, №7) аңа йомгак ясалгач чыкты.*

***– Дамир туган! Дамир Исхаков атлы ошбу галим кайда туып, нинди туфракта үсте икән ул? Тарих җиле беренче кат кайчан, ничек килеп орынды икән аңарга?***

– Кызык сорау бу. 65 яшең тулып ятканда? ихтыярсыздан үзең дә уйлап куясың инде бу хакта...

Казаннан йөз чакрымдагы Шәмәрдән посёлогында туып-үстем мин. Катнаш татар-урыс бистәсе инде бу. Совет чорын ничек кенә сүксәк тә урыс мәктәпләре дә, татар мәктәпләре дә бар иде әле ул чакта. 1200 укучылы зур мәктәптә татарча укып чыктым мин. Бик шәп китапханә бар иде мәктәптә һәм посёлокта. Университетка укырга кергәндә, 1969 елны бу, имтиханнарны татар телендә бирергә дә ярый иде әле, бу миңа бик ярдәм итте. Мәктәптә Татарстан АССР тарихын да укыталар иде. Аннан, университетта укыганда, күренекле археологыбыз Альфред Халиков түгәрәгенә йөрдем мин. Һәм шул чакны Фәннәр академиясенең Тел, әдәбият, тарих институтына да кергәли башладым, чөнки Халиков анда да эшли иде. Әйе, ул чакта, ни дисәң дә, миллилекне саклауның ниндидер механизмнары бар иде әле. Кытайда хәзер дә шулай бит әнә.

***– Шаккатмалы хәл инде бу безнең өчен, Дамир. Кытайда милли депутатлар да бар икән бит: әйтик, уйгыр депутаты, казакъ депутаты, татар депутаты... 1998-2008 елларда Кытай татарларының дәүләт депутаты булган Әдибә Исхакова белән әңгәмәм «Казан утлары»ның 2013 елгы 7нче санында чыкты әнә, шул ук елны «Татар гаме» дигән китабыма да керде әле ул. Әдибә ханым сөйләгәннәрдән бер өзек тә укып күрсәтим инде үзеңә. «Менә безнең татар мәчетебезгә йөз елдан артып киткән. Нык искерде. Бу хакта халык фикерен үзәккә җиткергәч, халык җәмгыятенең милли эшләр комитетында моңа күңел бүлеп, яңача салдылар. Өремчедәге иң зур, иң әйбәт салынган мәчет хәзер – татар мәчете. Безнең татар авылыбыз бар. Пекиннан, милли эшләр комитетыннан килеп корып бирделәр бу Татар Чишмә авылын. Ничә министр гына килеп китте монда, үз күзләре белән күреп. Аерым мәктәп, больница салып бирделәр, күңел куеп. Юллар яхшы имәс иде, моны мин безнең Шенҗан-Уйгыр***

***автоном районының рәисе Абләт Әбдерәшиткә җиткергәч, авылның бөтен юлларын шундый шәп, матур итеп ясап чыктылар...»***

***Дамир туган, аңлатып бир әле, этнология ни дә, этнография ни? Тарихтан һәм бер-берсеннән кай яклары белән аерылып тора соң алар?***

– Этнология – тарихка мәдәният аша карау ул, хәзерге сәяси процессларны да этнос аша, ягъни этник күзлектән карап өйрәнү. Этнография исә традицион мәдәниятне өйрәнә.

***– Нигә нәкъ менә тарих юлыннан киткәнеңне әйтеп җиткермәдең әле, Дамир.***

– Бала чактан ук кызыксына башладым мин тарих белән. Норвегиянең этнологы һәм археологы Тур Хейердал китапларын уку да тәэсир итте моңа. Аннары инде шул археология түгәрәгенә йөри торгач, Альфред Хәсәновичка ияреп ике ел археологик экспедицияләргә дә йөрдем әле. Һәм диплом эшемне дә аның җитәкчелегендә яздым. Әмма эчтәлеге үзгәрде соңыннан. Археологиядән этнологиягә күчте, Нократ татарлары буенча булды ул.

***– Нигә үзгәрде инде?***

– Археологиягә бик күңел ятмады шул. Экспедицияләргә дә 3нче курстан этнологлар белән йөри башладым, әкренләп этнология ягына авыштым.

***– Хыянәт була түгелме соң бу? Халиков үзе ничек карады соң моңа?***

– Сүз әйтмәде. Институтта археология дә, этнография дә кергән секторга җитәкчелек итә иде ул.

***– Өйдә утырып кына өйрәнеп булмыйдыр инде халыкны, этнологның җиме дә йөргән аякка иярәдер?***

– Шулай, әйе. Бусы институтта эшләгәндә инде. Тамбовтан Омскига кадәрге арада биш йөздән артык авылга үз аягым белән бардым. Татар турында сөйләгәндә, мине беркем дә берничек тә алдый алмый шуңа күрә.

***– Ниләр керде инде колакка? Гомер онытылмаслык мәгълүмат та юкмы арада?***

– Менә монысын һичшиксез оныта алмаячакмын. Түмән өлкәсендә 5 аты, 10 сыеры булган ир-атны кулакка чыгаралар. Нишләтергә? Себер кешесен Себергә сөреп булмый бит инде. Архангельск өлкәсенә, Беломорканалны казырга җибәрәләр. Хатыны өч бәләкәй бала белән кала. Түзми, имчәк баласын алып ирен эзләп китә ул. Һәм күп газаплар кичереп булса да эзләп таба бит! Ике бәләкәчен исә күрше әбисендә калдырган була, әмма ул бераздан үлеп китә. Аннары бүтән күрше хатын күз-колак була боларга. Ләкин ни ашатсын соң ул аларга? Шунда бу ачтан үләсе балаларга... тычканнар ярдәмгә килә! Алар бик тә олы яу булып зур амбардагы ашлыкка ябырылалар. Бу яуны берничек тә җиңә алмагач, үтерелгән тычканнар өчен онлата түли башлыйлар. Шунда авыл балалары мәчегә әйләнә. Теге ике бала да җепкә асып тычкан койрыклары тапшыра башлыйлар һәм исән калалар! Күрше апалары он шулпасы пешереп ашата башлый аларга. Тагын ярты елдан исә әниләре дә кайтып җитә.

Институттан соң өч ел мәктәптә тарих укыттым – Саба районының Иске Икшермә авылында. Тарих түгәрәген дә алып бардым – ул вакытта бу шулай тиеш иде. Һәм укучы балалар белән авыл тарихын да яздык әле. Кешенең формалашуына йогынты ясый торган нәрсәләр бу. Үзем өчен исә иң мөһиме 1977-1980 елларда Мәскәүдә Этнография институтында аспирантурада укуым булды. Ул вакытта бу институтта 70 процент галимнәр яһүдләр иде. Алар бит инде чит телләрне дә шәп белгәннәр, экспедицияләргә чит илләргә дә чыгып йөргәннәр. Бик тә белемле галимнәр. Минем үземнең фәнни җитәкчем Соломон Ильич Брук булды, танылган этнодемограф бу.

Халыкны исәпкә алу белән шөгыльләнгән, 1970, 1979нчы еллардагы җанисәпләрне оештырган кешеләрнең берсе ягъни. Ул күп нәрсәләргә өйрәтте мине. Һәм мин СССРдагы милли проблемаларны аңлый башладым. Чөнки ул вакытта яһүдләр дә кысылган-изелгән халык иде бит. Мин аларның ничек бер-берсенә ярдәм итеп шушы сәясәткә каршы тора алуларын күрдем-белдем. Алар белән нык аралашып яшәдем инде. Арада дусларым да бар иде хәтта. Кайбер нәрсәләргә нәкъ менә яһүдләрдән өйрәндем. Һәм шунда укыганда без шул яһүд дуслар белән семинар да оештырдык әле. Караимнар белән башланып киткән иде ул, анда Кырым татарлары проблемасы да килеп чыкты. Бөтенсоюз География җәмгыятенең Мәскәү филиалы каршында үткәрелде бу семинар. Әмма Кырым татарлары турында сөйләшкәч, шунда ук КГБдан шелтә килде безнең институтка. Һәм институтның директор урынбасары Людмила Терентьева, рус кешесе, бик әйбәт апа иде, мине чакырып: «Дамир, бүтән бу эш белән шөгыльләнмә, синең өстән шундый шикаять килде ки, укып бетерә алмассың!» – диде.

***– Нидән гыйбарәт инде ул «шөгыльләнүләрең»?***

– Кандидатлык диссертациям татарларның демографиясе буенча иде. Халык санын исәпкә алу материалларын караганда, Кырым татарлары килеп чыга анда. Кәгазьләрдә рәсми рәвештә юк бу, «татарлар» дип кенә язалар иде ул вакытта аларны, ә менә документларда бар иделәр, шулар аша күп нәрсәдән хәбәрдар булдым. Алар хакында аспирантурада укыган чакта ук беркадәр белә идем үзе, чөнки Мари Республикасындагы биш авылга сөрелгән Кырым татарларының берсе Эдәм Әмәтов белән тулай торакта бер бүлмәдә тордым. Ул миңа күп нәрсәләр сөйләде. Сүз уңаеннан әйтим әле: Абхазиянең булачак Президенты Владислав Ардзинба белән дә бер вакыттарак укыдык.

Милли аңымны, татарлыгымны көчәйтү җәһәтеннән миңа Мәскәүдә укыганда күренекле галим Шамил ага Мөхәммәдъяров шәп кенә ярдәм итте. Аның белән нык аралаштык, чөнки ул диссертацияләр яклаган вакытта институтка килә иде. Ул бик шәп оппонент иде, һәм мин яклаганда шулай ук бер оппонентым ул булды. Мин аның өенә дә барып йөрдем. Миңа татарлар турындагы кайбер сирәк очрый торган китапларны да укытты әле. Чөнки алар ачык рәвештә юк иде. Совет чорында «Спецхран» дигән нәрсә бар иде китапханәләрдә. Материал кирәк булгач, гариза язып керәсең дә шунда укыйсың. Әмма, кул куеп кергәч, ниләр укыганың исәпкә алына инде. Мин сирәк китапларны укыштыргаладым шулай, һәм, Шамил Фатыйхович та биргәч, татар дөньясы турында өр-яңа карашларым формалашты. Шамил ага гомер буена Алтын Урданы, татар ханлыкларын беренче чиратка куйды.

***– Ә ул заманда Алтын Урданы өйрәнергә ярый идеме соң? Мәрхүм Миркасыйм ага Госманов әнә «Алтын Урда» урынына бу мәмләкәтнең «Җучи олысы» дигән элеккерәк исемен кулланган. «Шуңа күрә өлкә комитетында университет нәшриятының тематик планын раслау шома гына узып китте», – дигән иде ул миңа.***

– Юк инде, ярамый иде, Шамил Фатыйхович шуны күбрәк «татар ханлыклары» аркылы язарга тырыша иде. Татар ханлыклары иде аның беренче белгечлеге. Әмма Алтын Урданы өйрәнмичә, Казан ханлыгының ни икәнен аңлап булмый бит. Шуңа күрә ул шәп беләдер иде бу әйберләрне. Һәм шуннан соң җаен табып боларны СССР тарихына да керткәләде әле. Менә шул вакытта мин татар тарихына кагылышлы мәсьәләләрне башкачарак күрә башладым.

Аспирантураны 80нче елны бетереп, диссертацияне 81нең башында якладым мин. Инде ул вакытта ук СССРда милли проблемалар бу институтта барысы да күренә иде. Галимнәр шөгыльләнә иде болар белән. Хәтта ки шунысын да әйтә алам әле: минем белән аспирантурада укыган кешеләрнең шактые милли хәрәкәт

башына басты. Мәсәлән, шул абхаз Ардзинба. Этнология белән шөгыльләнү милли аңны бик нык үстерә ул. Чөнки шунда ук милләт белән очрашасың. Аннан соң мин Казанга кайтып төштем дә, 1981 елда бу, Татарстан Фәннәр академиясенең Тел, әдәбият, тарих институтында эшли башладым һәм шундук күренде: монда галимнәр арасында ниндидер бер кайнау процессы бара иде. Ягъни кешеләр ачылып сөйләшә башладылар, бигрәк тә яшьләр. Институтта ул вакытта яшь галимнәр советы бар иде. Күпмедер вакыттан мине шуның башына куйдылар да, шунда яшь галимнәрне туплап, без тарих турында сөйләшә башладык һәм безнең башка шундыйрак фикер килде: безнең тарих дөрес язылмаган, аны яңадан язарга кирәк! Һәм менә шушы 1981-1983 еллар тирәсендә төрле семинарларда без шул мәсьәләне тикшерә башлагач, безгә археолог Равил Фәхретдинов та килеп кушылды. Юкса 45 яшь тирәсе иде инде аңа. Ул вакытта бездә эшли иде, чөнки археологлар бүлеге шушы институтта иде, әмма ахырдан тарихчыларга китте. Шул вакытта безнең белән аралаша башлады. Ә инде 1985 елга ул яңа бер тарихны язу өчен проспект та эшләп бирә алды әле.

Менә бер хикмәт тә бар бит әле монда. Тарихчы шәхесе формалашу тарих аша бара. Ләкин заман, бүгенге көн дигән нәрсә дә бар бит әле. Тарихчыларның шактые, хәтта ки күпчелеге, шушы заманга кайта да үткәнне бүген соралганча тасвирлый. Заманга җайлаша ягъни.

***– 1944 елны заман татарга ВКП(б) карары аша Алтын Урданы онытырга, үзен бары болгар баласы дип кенә санарга куша, шулаймы?!***

– Әйе, нәкъ шулай. Кешеләр ничек җайлашалар бит. Мәсәлән, Сәлам Алишев, мәрхүм инде, Мирфатыйх Зәкиевләр әнә бик каты болгарчылыкны алга сөрәләр иде ул вакытта. 70-80нче елларда халык иҗаты мирасын җыю буенча бик зур эшләр эшләнгән иде. Шуның нәтиҗәсе булып күп томлы фольклор китабы да нәшер ителгән иде. Аннан тагын – «Идегәй» дастаны. Ул бит 1940 елны ук «Совет әдәбияты»нда басылган инде – Нәкый Исәнбәтнең кереш сүзе белән. Болардан исә безнең Болгар кысасында түгеллек килеп чыга иде. Шушы нәрсәләр безне, яшь галимнәрне, яңача карашларга этәрә башлады, нәкъ шул дәвердә Горбачёв та үзгәртеп коруын башлап җибәрде.

***– Халиков белән Фәхретдинов карашларындагы каршылык та шул Болгар аркасында бит инде.***

– Шуның аркасында, әйе. Төп сәбәп шул. Докторлыкны яклаган вакытта диссертациясенең Алтын Урдага кагылышлы өлешен кисеп калдырганнар. Ул исә моның белән килешмәгән. Һәм без шул агым белән бергә тарихта татар юнәлешендә ныклап шөгыльләнә башладык. Һәм аннан соң иҗтимагый хәрәкәткә дә кереп киттек.

Мине бер нәрсә уйга салды. Татарның милли хәрәкәте көчле булды дип әйтү бар. Башка халыклар белән чагыштырганда инде бу. Татар сан ягыннан зур бит. Аннан, Тел, әдәбият, тарих институтында алдынгы карашлы галимнәр булганга, милли аңның беркадәр базасы да эшләнде бит инде. 1990 елны үткәрелгән бер социологик тикшерү материаллары бар. Коммунистлар партиясен Татарстандагы татарларның 7 проценты хупласа, Татар иҗтимагый үзәген 11 процент хуплаган. Ул вакытта иҗтимагый үзәк төп милли орган иде, ягъни ул 11 процент милли хәрәкәтне хуплаган дияргә була. Ләкин барыбер калган 89 процент нигә милләтнең киләчәгенә битараф булган соң дигән сорау туа. Русларның алдынгырак карашлылары үз халкын сүгә әнә хәзер. Демократик рухлары юк, алга китәргә уйламыйлар, авторитар режимда яшиселәре килә дип. Безнең халыкның да күпчелек өлеше шундыйрак түгелме соң? Халык массалары аз-маз селкенеп алды да, 90нчы еллар башында ук бу нәрсә бетте чынлыкта.

***– Соң монда халык гаепле түгел бит инде, Дамир. Аны бит гасырлар буена кире иләктән иләгәннәр. Асыл орлыклар чүпкә чыгарыла барган, ягъни атылган***

***яки төрмәгә утыртылган, калганнарына исә берөзлексез максатчан идеологик су бөркеп торганнар. Шуңа карамастан халыкның бер өлеше уянган, тагын шактый өлеше уянуга якын иде әнә. Ләкин көчле чигенү башланды бит. Кайчан башланды соң ул? Инде бөтен эш тә эшләнгәч! Референдумда җиңү яуланды, Конституция кабул ителде, Россия белән Шартнамәгә кул куелды юкса. Халыкның күңеле шуңа сүрелде инде ул.***

– Мин бу фикер белән килешәм, ләкин яртылаш кына.

***– Нигә яртылаш кына?***

– Чөнки теге 11 процентка халыкның күңеле сүрелүләр керә алмый. Бу сан 1990 елны алынган. Чигенү түгел, күтәрелү башланганда. Ә чигенүгә килсәк, әйтик, латыш халкы мондый чигенүгә юл куяр идеме, йә? Шуннан килеп чыга бу, Рәфикъ: Балтыйк буе илләренең демократик юл белән китү теләге зуррак булган.

Татарстанны үстерүнең төрле юллары бар иде. Мин, мәсәлән, Татарстанны эчке яклап федеральләштерергә тәкъдим иттем. Ягъни Бельгия моделе буенча.

***– Халыклар, кавемнәр нигезендәме?***

– Әйе, кавемнәр нигезендә. Бу – сәясәтне алып баруның авыррак юлы, әмма килешү юлы белән барырга була иде барыбер. Дәүләт телләре статусын кертү өчен анда һәрбер төбәктә телнең әйләнешен тәэмин итәргә кирәк. Димәк, яңа законнар кабул итәргә кирәк була. Финляндиядә, әнә, шведлар яшәгән районнар бар, һәм бер шәһәрдә яки посёлокта алар 70 проценттан артык булса, анда инде швед теле алданрак йөри.

Тагын ни әйтим инде? Милли мәктәпләр һаман кими бара. Бу яктан безнең перспективалар бик юк кебек. Бәлки, безгә таррак даирәдә булса да эшләргә тырышырга кирәктер?

Без милли университетны булдыра алмадык бит инде. Ә чынлыкта ел саен 10-15 галим тәрбияләсәк тә җитәр иде. Әмма болар махсус тәрбияләнгән шәхесләр булырга тиеш. Мәсәлән, ни өчен Казандагы төрек-татар лицейларына 1 урынга 24-25 кеше керергә тели иде? Чөнки уку татарча да, инглизчә дә. Аннан сыйфат дигән нәрсә бар иде. Әгәр дә татар мәктәпләрендә дә сыйфат яхшы булса, аларга да керергә атлыгып торырлар иде. Мин, мәсәлән, 15нче татар гимназиясендә хәзер музей төзеп ятам. Анда 300гә якын бала укый. Шунда руслар да балаларын китерә башлаган. «Ни өчен алай?» – дип сорадым. Ата-аналар: «Монда тәртип яхшы!» – дип әйтәләр икән. Димәк, хәтта шәп тәртип кенә булса да, ата-ана баласын бирә икән бит! Шуңа күрә бүген без татар мәктәпләренең сыйфат ягын кайгыртырга тиешбез.

Шушы көннәрдә Казакъстан Президенты Назарбаевның интервьюсын тыңладым. Анда, Астанада, Назарбаев исемендәге университет эшли. Якын дустым Юлай Шамил улы хәзер шунда укытып ята. Инглиз телле университет бу. Казакъ теле дә бик шәп укытыла анда. Назарбаев 250 миллион доллар биргән бу университетны яшәтер өчен. Казакъстандагы тагын 50 урта мәктәптә балаларны шул университетта уку өчен әзерлиләр икән. Инглиз теле, рус теле, казакъ теле укытыла икән аларда. Әмма чынлыкта шушы мәктәп һәм университет аркылы казакъ элитасы әзерләнә бит.

Аннан, галимнәребез һичшиксез милләттәшләребезнең милли аңын уяту һәм үстерү белән дә шөгыльләнергә тиеш. Тагын менә шуны әйтергә телим: зыялыларыбыз, галимнәр, язучылар, журналистлар бергә җыелып сөйләшсәләр, бәлки, ниндидер бер сихәтле уртак фикергә килеп, шуны халыкка җиткерә алыр идек. Менә шуны оештыру – безнең алдагы бурычларыбызның берсе.

***– Дамир туган, мин сиңа, соңарып булса да, рәхмәт әйтим әле. Нәкъ менә «казан» өчен. «Идел» журналында эшләгәндә, безнең киләчәккә тәэсир итәргә мөмкин үтә җитди мәсьәләләргә төрлечәрәк караш ташларга мөмкин***

***зыялыларыбызның фикерләрен тыңлау кирәклеген тоеп йөри идем. Һәм бу хакта синең белән киңәшергә булдым. Һәм син, шөкер, шунда ук җавап та бирдең: аналитик үзәк оештырырга кирәк! Һәм бераздан исемлек тә төзеп китердең. 1995 елны булды бу.***

– Әйе, Рафаэль Хәкимов, фәлсәфәче Рашат Әмирхан, ислам дине белгече Рәфикъ Мөхәммәтшин кебек акыллы, оригиналь фикерле затлар керде анда. Җәмгысе ун кеше. Кайбер утырышларга башка саллы белгечләрне дә дәштек әле.

***– Баш мөхәррирebез Фәиз Зөлкарнәй бу аналитик үзәккә бик шәп исем дә кушты: «Акыл казаны». Утырышларны син алып бардың. Шөкер, югары кимәлдә үтте алар һәм текстлары журналда басылып та барды. Менә кайберләренең исемнәре: «Татарстанмы, татар станымы?», «Җәдитчелек һәм милли идеология», «Татарстан Япония була аламы?», «Татар тарихы татарча языла», «Миллилек һәм милек»... Резонансы нинди булды бу «казан»ның?***

– Бик көчле булды. Хәтта ки Тел, әдәбият, тарих институтыннан «тарих»ның мөстәкыйль институт булып «башка чыгуына» да беркадәр тәэсир итте әле ул.

***– Син теләгән яңа, зуррак «Акыл казаны» берөзлексез кайнап торсын иде! Тап-табигый әйбер бит инде бу: татар халкы бөтен яклап яши алырга, үсә алырга тиеш. Һәм шуннан әле куркып торучылар да бар бит – мондый тырышлыкны әллә нинди «подпольный» эшкә тиңләп.***

– Әмма чиновникларны да тәрбияләргә кирәк бит. Укытудан башлана бу. Әгәр дә безнең милли университет кебек уку йортыбыз булса, һәм булачак чиновниклар шул уку йорты аша үтсәләр... Милли даирәңдә кайнасаң, милли эшләр буенча мәгълүматлы шәхесләр укытсалар сине... Бу әйберләр юк бит. Кызганычка каршы, моны ике көндә генә эшләп булмый. Бераз вакыт кирәк моңа.

***– Аннары таләпне дә тоярга тиеш бит чиновниклар. Хәзер менә «Яңа Гасыр» телеканалыннан шалтырата башладылар – теге министрлыкка, бу министрлыкка, татарча җавап бирә аласызмы, дип. Бик дөрес эшлиләр.***

– Килешәм, бу бит бер-берсенә бәйле әйберләр. Инде демократик юнәлеш буенча киткәнбез икән, халык үзе дә активрак катнашса, ул вакытта чиновникларның да җаваплылыгы артыр иде. Әмма әлегәчә чын-чынлап демократия барып чыкмады һәм халык чынлыкта чиновникларга йогынты ясый алмый. Әмма бу, минемчә, мәңгелек күренеш түгел, дөнья үзгәргәч, Россия дә үзгәрер дип уйлыйм мин. Башкачарак тенденцияләр булыр.

***– Ә үзебезгә шушы хәлдә дә берөзлексез эшләргә кирәк. Шул вакытта милләтнең үсеше буенча уңышлар булырга мөмкин.***

*Әңгәмәдәш* **Рәфикъ ЮНЫС**

# АЧЫ ТӘҖРИБӘ АВАЗЫ: МӨХӘММӘТ МӘҺДИЕВ

Әдәбиятны, аның тарихын шактый тирән белеп тә, үзенең белемен ахыргача киңкатлам укучыга җиткерергә өлгермичә, арабыздан киткән һәм, бу хәл көтелмәгәнлектән, суга төшеп югалгандай тоелган каләм ияләре шактый. Араларында җанны аеруча сыкрандырганнары, фәнни-әдәби җәмәгатьчелеккә генә түгел, гади халыкка якыннары да бар. Бүгенгәчә искермәгән, эчтәлеге һәм бигрәк тә теле белән, хәзерге дәреслек авторларына үрнәккә куярлык уку әсбаплары калдырган; Казан дәүләт университетында озак еллар дәвамында XX гасыр башы әдәбиятын, татар фольклорын укыткан; бигрәк тә урта буын вәкилләренең рухи атасы саналырлык Мөхәммәт ага Мәһдиев – әнә шуларның берсе, үзәктәгесе.

Мөхәммәт аганың Тукай фәненә керткән өлеше турында, теманың төбенә төшеп, Т.Гыйләҗев, Г.Хәсәнова һәм башка авторлар да язды. Бигрәк тә галимнең кызы Гәүһәр ханым хезмәтләрендә М.Мәһдиевнең Тукайны ачудагы зур роле дәлилле, гомумиләштерелеп һәм комплекслы планда тулы да, дөрес тә яктыртылды дип уйлыйм. Мин шулай ук хөрмәтле укытучымның мәгълүмати бай, кызыклы нәтиҗәле, киң күзаллаулы мирасын бер читкә куеп китә алмыйм. Җитмәсә, бик хаклы рәвештә, «Жизнь и творчество Тукая в трудах Мухаммета Магдеева» исемле язмасында Гәүһәр ханым менә болай ди: «Г.Тукай тормышына һәм иҗатына кагылышлы хезмәтләр М.Мәһдиевнең фәнни-публицистик мирасында аерым урын тота. Эш аларның күпсанлы булуында гына да түгел. Мәһдиев үз чорында бу өлкәдә иң компетентлы кешеләрнең берсе иде. Кызганыч ки, галимнең үлеменнән соң, Тукай һәм аның иҗатын өйрәнүчеләр турында сүз барганда, кагыйдә буларак, Мәһдиев исемен әйтергә онытталар. Бәлки, әсәрләренең лаексыз онытылуына яисә аңлы рәвештә аталмавына күпчелегенең журнал һәм газета битләрендә генә чыгуы сәбәптер». *(Г.Тукай мирасы һәм милли-мәдәни бәйләнышлар // Г.Тукайның тууына 125 ел тулуга багышланган халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары. – Казан, 2011; тәрҗ. – Р.Р.).* Соңгы елларда кызыклы материаллар белән көннән-көн баетыла барган «Тукай» интернет-порталында да мин әлегә Мөхәммәт ага язган мәкаләләрне күрмәдем. Ышанам ки, алга таба портал алар белән дә тулыланыр.

Әйе, шагыйрь иҗатына мөнәсәбәтле дистәләрчә язма калдырган, аңа бәйле фикерләрне күзәтү характерындагы мәкаләләренә дә керткән, егерменче гасыр башы татар әдәбиятында һәм шул әдәбиятны ныклы нигез иткән бүгенге сүз сәнгатебездә зур Шагыйрьнең тирән эзләрен күрә алган Мөхәммәт ага чын мәгънәсендә тукайчы иде. Ул аның һәр әсәрен, йөрәге, хиссияте, аналитик акылы аша уздырып, студентларга җиткерде, эчтәлеген, язылу тарихын XX гасыр башының милли-иҗтимагый һәм әдәби-мәдәни тирәлегендәге хәлләр, күренешләр, шәхесләр белән бәйләде. М.Мәһдиев үзенең тукайчылыгын мәкаләләре аша да аңлатырга теләде булса кирәк. Әгәр галим-мөгаллимнең «Әдәбият тарихы чыганагы буларак унынчы еллар татар вакытлы матбугаты» хезмәтеннән чыгып фикер йөртсәк, инде аталган чорда ук татар матбугаты шагыйрьнең иҗат һәм тормыш юлы хакындагы материалларны барлау эшен оештырган булган. Димәк, Мөхәммәт ага әнә шул игелекле эшне дәвам итүнең мөһимлеген һәм кирәклеген аңлаган, аны фәнни эзләнүләренең дә бер юнәлеше итеп сайлаган.

М.Мәһдиев егерменче гасыр башындагы вакытлы матбугаттан Тукайга, аның язмышына, тирәлегенә, иҗатына бәйле һәр нәрсәне бөртекләп җыя, шагыйрьгә кагылышлы материаллар тарихын ача, аларның бүгенге көндә саклану-сакланмавы хакында фикерләр әйтә. Шуның белән, ул башка эзләнүчеләрнең дә эшен күпмедер җиңеләйтә. Галим Тукайның «Бәянелхак», «Вакыт», «Йолдыз» газеталары, «Шура»,

«Ялт-йолт», «Аң» журналлары белән мөнәсәбәтләрен, шагыйрьгә үз чорында халык мәхәббәтен чагылдыру эше белән дә шөгыльләнә.

М.Мәһдиев мирасында Тукай тормышы һәм иҗаты берничә яссылыкта яктыртыла. Беренчесе – шагыйрь-публицистның аерым әсәрләрен чагылдырган язмалар *(Мәһдиев М.С. Шагыйрьнең бер әсәре турында // Социалистик Татарстан. – 1986. – 23 март; Югалган бер шигырь эзеннән. Татарстан хәбәрләре. – 1992. – 25 апр.).* Икенчесе – татар вакытлы матбугатын, аның эчтәлеген, юнәлешләрен, әдәбият тарихын Тукай мирасына да таянып бәяләү, ачу *(«Әдәбият тарихы чыганагы буларак унынчы еллар татар вакытлы матбугаты»).* Өченчесе – Тукайның тирәлеге *(«Тукайның садәдил дусты» // Әдәбият һәм чынбарлык, 1987).* Дүртенчесе – шагыйрьнең әдәби бәйләнешләре *(Тукай и Толстой // Татарстан. – 1992. – №4).* Бишенчесе – Тукай иҗатының чыганаклары, социаль нигезләре *(Тукайниләр укыган? // Мәгърифәт. – 1995. – 25 апр.; Социальные корни таланта, 1990; Мәһдиев М. Шагыйрьнең бишеге // Әдәбият һәм чынбарлык, 1987).* Алтынчысы – Тукай тормышының, иҗатының тарихта яктыртылышы *(Габдулла Тукай. 1886-1913 / Фотоальбом. Текст Мухаммета Магдеева, 1986.)* һ.б. Кыскасы, күптән түгел генә төзелгән Тукай энциклопедиясенең һәр тармагында М.Мәһдиев язган хезмәтләр теге яки бу күләмдә чагылырга тиеш иде. Ул асылда шулайдыр да, чөнки галим Г.Тукай иҗатын яктыртуга әнә шулай киңпланлы якын килгән.

Мөхәммәт аганың дәресләрен тыңлаучылар белә: аның иң яратып сөйләгән өч авторы бар иде. Болар: Ф.Әмирхан, Г.Тукай һәм Ш.Камал. Әлбәттә, Г.Камал, С.Рәмиев, С.Сүнчәләй һәм башкалар да аның игътибар үзәгеннән читкә китмәде. Остазыбыз, теге яки бу чорның әдәбиятын характерлаганда, һәрберсе исеменә кагылып киткәли, аерым бер әдәби күренешләрнең ерактагы тамырларын барлый иде. Ә менә XX гасыр башы татар сүз сәнгатен галим Тукай һәм аның тирәлеге тудырган әдәбият рәвешендә ачты, дип гомумиләштерергә дә мөмкиндер. Ул бигрәк тә Ф.Әмирханның Тукайга карата кылган гамәлләренең, кешелекле ярдәмнәренең шагыйрь тормышында роле зур дип санады. Галим, Тукай тормышын мөнәсәбәтләр тарихы сыйфатында яктыртканда, аңа мәрхәмәтле Мотыйгыйлар гаиләсен дә, башкаларны да читләп узмады. Әйтик, алда телгә алынган «Тукайның садәдил дусты»нда М.Мәһдиев С.Сүнчәләй һәм Тукайның 1910-1911 еллардагы үзара кешелекле мөнәсәбәтләрен бик кызыклы чагылдыра.

Теге яки бу шагыйрьнең иҗатын коры тел белән, фәнни терминнар аша аңлатып чыгарга була. Күпләр шулай эшли дә. Үзе дә талантлы каләм иясе булган М.Мәһдиев исә, Тукай әсәрләренә анализ биргәндә, аларның язылу тарихын да, әсәр тууга сәбәп булган теге яки бу прототипларны һәм сәяси-иҗтимагый хәл-шартларны да ачты. Шул ук вакытта ул укучыга Тукайның үз образын да күзаллатты, чөнки туган-тумачалары белән очрашулары, яшәү рәвеше һәм урыны, шәхси мөнәсәбәтләре, әдәби бәхәсләре һәм якын яисә ераграк даирәсе турында да сөйләде.

Хәзер менә, мөгаллимнең китапларын күз алдымнан кичереп утырам да, уздырган дәресләренең язылачак хезмәтләренә апробация яисә инде чыкканнарына презентация рәвешен дә алган икән дип уйлыйм. Бер-икесен генә искә төшерик: «XX йөз башы татар әдәбиятында прототиплар. Аларны ачуның әһәмияте» фәнни хезмәтендә М.Мәһдиев Тукайның «Мәҗрух указ», «Улмы? Ул?..», «Катиле нәфескә», «Матбага белән уйнаган бер байга», «Эштән чыгарылган татар кызына», «Тешләре ямьсез матурга», «Мәхәббәт», «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш»ка нигез яисә ситуация биргән затлар турында сөйли. Ә бит ул дәресләрендә дә нәкъ менә шуларга кагылышлы истәлекләр белән уртаклаша, сүзен тарихи материаллар, документлар белән дәлилли иде. М.Мәһдиевнең Тукай исемле шагыйрь формалашуда туган төбәгенең ролен ачкан «Шагыйрьнең бишеге» (1976) язмасы Казан арты теленә, Казан арты кешеләренең, зыялыларының милли рухына Тукай бәясен чагылдыруы белән бик кыйммәтле. Без аннан шагыйрьнең Сүнчәләйгә язган хатында: «Милли әдәбиятымыз фәкать шулар телендә, шулар рухында булуын телим», – дигәнен беләбез.

Тукай юбилееның чираттагысына хәзерлек эшләре, гадәттә, алдагысы узуга ук башлана. М.Мәһдиевнең «Реализмга таба», «Әдәбият һәм чынбарлык» һәм башка кайбер хезмәтләре бик бай мәгълүматлы иде, әлеге мәгълүматлар Тукайга багышланган энциклопедиядә чагылып бетмәде дип уйлыйм, чөнки ул безнең тарафтан

шактый гомумиләштереп язылды, фикерләрнең чыганаклары гына, анда да чикләп күрсәтелде. Ә бит телгә алган китаплар инде сатуда юк, һәр кеше, бигрәк тә гади укучы, аларны укыр өчен, үзәкләштерелгән китапханәләргә йөри алмый. Хәтерем ялгышмаса, «Реализмга таба» хезмәте юка тышлык белән чыгарылган иде, искереп-тузып беткәнлектән һәм саклау вакыты чыкканлыктан, инде аны җирле китапханәләр хисабыннан төшергәннәрдер дә. Бу очракта мин наширләр колагына да, Мөхәммәт аганың кызы Гәүһәр ханымга да киңәш итеп әйтәм: әлеге хезмәтләрне, бергә туплапмы, аерым-аерыммы, яңадан басылуларын кайгыртасы иде. Аларның бигрәк тә төрле югарылыктагы уку йортлары өчен кирәкле булулары бәхәссез.

Мөхәммәт аганы гарәп шрифтында чыккан китапларны бүгенгегә күчергәндә хаталар җибәрелү бик нык борчыды. Ул шушы мәсьәләне кичекмәстән хәл итәргә кирәк дип сөйли иде. Әлеге проблема бит ахыргача хәзер дә чишелмәде. М.Мәһдиев телгә, сүзгә игътибар кирәклек турында даими кайгыртты. Остазыбыз дәресләрдә, вакытлы матбугатта басылган мәкаләләремне укымыйм, чөнки хаталары, редакторларның үзгәртүләре җанны тырный, дип сөйли иде. Ә бит аның күпчелек язмалары әлеге дә баягы газета-журнал битләрендә генә калды. Димәк, аларны җыентыкка туплап бастыра калганда, мөмкин кадәр игътибарлы булырга, әгәр хаталар табылса, төзәтергә кирәк. Үзем дә газеталардагы язмаларымны укымыйм. Бигрәк тә кыскартылып чыгарылганнарына күз дә ташламыйм. Аларның мин теләгәнчә булмавы, хаталары күплек, эчтәлектәге үзгәрешләр йөрәк өянәгенә китерер дип куркам. Ә бит бу сыйфат миндә Мөхәммәт абый сөйләгәнне ишеткәннән соң, мәкаләләремә игътибар белән күз ташлаганнан соң башланды. Язмаларым сирәк күренгән чорда да, инде мин аларны курку катыш кызыксынып кулга ала идем. Хата текстларның матбугатны басуы – бүгенге әдипләрнең барысын да хәсрәткә сала торган күренештер. Еллар уза, күрәбез ки, М.Мәһдиев язган хезмәтләр актуальлеген югалтмый. Инде һич югы классик мираска мөнәсәбәттә ул күтәргән проблеманы чишәсе иде бит… М.Мәһдиев «Әдәби сүз игътибар сорый» дигән язмасында да шул хакта әйтә һәм Г.Тукай, М.Гафури шигырьләрен һаман хата белән бастырып чыгарулары өчен борчылганлыгын сиздерә.

Мөхәммәт ага гомере буе Тукай эзләреннән йөрде, аның бәйләнешләрен барлады. Галим тырышлыгы, эзләнүләре белән, шагыйрь тормышын чагылдырган Гатиятулла Шәрәфиев, Ибраһим Биккулов, Зәйнәп Хәсәни истәлекләре фәнни әйләнешкә керде. М.Мәһдиев гомерен Тукай язган әсәрләрнең чыганакларын барлауга да күп сарыф итте. Мондый эш белән шөгыльләнүчеләр белә: соңыннан кем тапканлыгын фән игътибарга да алмаска мөмкин фактларны ачыклау өчен, кайчак берничә еллык матбугатны карап чыгарга, әллә никадәр халыкның әдәбиятын укырга туры килә.

М.Мәһдиев үз әсәрләренә материалны тормыштан алды, һичбервакыт уйлап чыгармады. Ул халыкның үзаңын формалаштырырга, үстерергә, күзаллауларын киңәйтергә алынган заман әдәбияты нәкъ шундый булырга тиеш дип саный иде. Әдип Тукайны да тормышка якынлыгы, гади халыкның яшәү рәвешен аңлавы, рухын тою өчен чиктән тыш яратты булса кирәк. Остазыбыз безнең буын каләм ияләрен дә кешегә кирәкле тормышчан иҗатка әйдәде. Үзенең хаклылыгын раслар өчен, Толстой, Тукай һәм башка каләм ияләренең әйткәннәрен мисалга китерә, цитацияли иде. Һәм гади укучы гына түгел, әдәби җәмәгатьчелек тә М.Мәһдиевнең нәфис әсәрләрен халык тормышын төбенә төшеп яктыртканга, ә фәнни хезмәтләрен хак һәм дәлилле сүз сөйләргә омтылганы өчен яратты. Без әле дә Мөхәммәт аганың Тукай кебек зур талантларны үстергән Казан артының камил сөйләшендә, моң-аһәңнәрендә язылган әсәрләренә ихтыяҗлыбыз.

Мөхәммәт ага үзенең тормышын, фәнни-әдәби даирәсен чагылдырган һәм шулай ук кыйммәтле документаль хезмәт булып тарихка керәчәк китабын «Ачы тәҗрибә» дип атады. Ул моның белән һәм әсәргә куелган цитата аша Тукай тормышының үзеннән соң килгән каләм әһелләре язмышында теге яки бу дәрәҗәдә кайтавазлары барлыгын да чагылдырырга теләгәндер. Галимнең һәр язганы, шул исәптән Тукай турында калдырган мәгънәви кыйммәтле, иҗтимагый-мәдәни кирәкле, фәнни эзлекле һәм фактик дәлилле мирасханәсе дә ачы тәҗрибә авазы кебек яңгырый.

**Рифә РАХМАН**

# ИГЪТИБАР ҖИТМИ!*

Соңгы елларда безнең вакытлы матбугатта да, китап нәшриятында да хикәяләр чыннан да сирәгрәк басыла. Редакцияләр хикәя азлыктан зарланалар. Чәчмә жанрда язучыларыбыз мөмкин кадәр зуррак күләмле әсәр язарга омтылалар: повесть, роман өстендә эшләүне артыграк күрәләр. Ләкин бу, минемчә, хикәянең жанр буларак искерүе, ягъни аның заман стиленә җавап бирә алмый башлавы турында сөйли торган хәл түгел әле. Чөнки безнең бүгенге чынбарлыкта хикәянең актуальлеген киметерлек бернинди социаль һәм иҗтимагый сәбәпләр юк. Киресенчә, һәр елы гына түгел, һәр көне диярлек тарихи яңалыклар алып килә торган безнең заманда хикәя – әдәбият арсеналындагы иң җитез, иң уңайлы коралларның берсе. Аны язу өчен дә, басып чыгару өчен дә, уку өчен дә күп вакыт кирәкми. Радио-телевидение аша тапшырырга яки турыдан-туры сәхнәгә чыгып укырга да бик кулай ул. Ә чын каләм остасы булган язучы бер-ике битлек кенә хикәядә дә кайбер романнар аша әйтә алмаган зур фикерләрне әйтә, дөньяны шаулатырлык проблемалар күтәрә ала. Моның классик үрнәкләрен без А.Чехов, О.Генри һәм башка күп кенә мәшһүр язучыларның иҗатларында күрәбез.

Совет язучылары, шул җөмләдән үзебезнең татар язучылары арасында да сокланырлык хикәяләр биргән авторлар азмыни? Татар әдәбиятында хикәя, гомумән, элек-электән бик хөрмәтле урын алып килә. Фатих Әмирхан, Газиз Гобәйдуллин, Шәриф Камал хикәяләре – әдәбият тарихыбызның иң гүзәл сәхифәләрен тәшкил итмиләрмени? Бүгенге әдәбиятыбызны Фатих Хөсни, Ибраһим Гази, Әмирхан Еники хикәяләреннән башка күз алдыгызга китереп карагыз! Гариф Галиев, мәрхүм Мин Шабай, Рафаил Төхфәтуллин, Газиз Мөхәммәтшин, Габдрахман Минский, Аяз Гыйләҗев хикәяләренә күз йомып карагыз! Һәм, гомумән, төп жанры ул булмаган башка бик күп язучылар һәм әдәбиятка яңа килүче яшьләр иҗат иткән хикәяләрне искә алыйк. Хикәяләрдән башка әдәбият дөньясын күз алдына китерәсе дә килми. Алардан башка әдәбият бакчабыз бөтенләй шәрәләнеп, ялангачланып калыр иде. Кыскасы, хикәя жанрының бүгенге көндә яшәргә һәм үсәргә хаклы булуы һәркем өчен ачык хакыйкать. Мәсьәләнең бу ягы турында бәхәс кузгатырга урын да юк.

Соңгы елларда хикәяләр (сүз, әлбәттә, чын мәгънәсендә бу атамага лаек булган әйбәт хикәя турында бара) азрак языла башлаган икән, моның сәбәбе, минемчә, әдәбиятчыларыбызның, шулай ук редакцияләребезнең бу жанрга карата игътибарны йомшартуларында. Аеруча әдәби тәнкыйть тарафыннан хикәягә игътибар җитми. Газета-журналларыбызда, китап нәшриятларыбызда хикәяләр азмы-күпме чыга тора. Яхшылары була аларның, начарлары була. Ләкин шуларның ни яхшысына, ни начарына карата матбугатта тәнкыйть сүзе әйтелми. Үзенең идея әһәмияте, сәнгать көче белән кайбер повесть яки романнарга торырлык хикәяләр була, дидек. Ә соң бездә аерым бер хикәягә әдәби анализ ясаган тәнкыйть мәкаләсе яки һич югында рецензия чыкканы бармы? Юктыр, булса, күренер иде. Узган елда бездә Ибраһим Газиның «Тургай картаямы икән?» дигән хикәясе күп кенә мәкаләләрдә телгә алынды. Чынлыкта, телгә алынуга гына түгел, бик зур мактауга, хәтта әдәби анализга лаеклы хикәя. Ләкин Ибраһимга 60 тулу уңае белән уздырылган юбилей чорына туры килмәсә, ул хикәя турында да шундый җылы сүзләр әйтелгән булыр иде микән? Элегрәк шул ук Ибраһим Газиның «Яшь ленинчы» газетасында «Ак сирень» дигән хикәясе чыккан иде.

* 6 гыйнвар – прозаик, драматург, публицист, җәмәгать эшлеклесе, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Мирсәй Әмирнең (1907-1980) тууына 110 ел.

Анысы да бик матур хикәя иде. Ләкин аны беркайда да телгә алучы булмады. Фатих Хөсни турында хикәя остасы дигән сүзне бик күп ишетәбез. Хаклы әйтелә. Ләкин аның кайсы хикәясенә, үзенә бер төгәлләнгән сәнгать әсәре итеп, бәя бирелгәне бар?

Хикәяләр белән беррәттән повесть һәм романнар да язучы автор иҗаты турында сүз бара икән, башлыча аның зур күләмле әсәрләре турында тулырак фикер әйтелә дә, хикәяләре турында гомуми характерда гына берничә юл язу белән чикләнелә. Ф.Хөсни турында да шулай була, Р.Төхфәтуллин турында да. Башкаларын әйткән дә юк.

Әдәбиятка яңа килүче яшьләр тарафыннан язылган хикәяләргә дә тәнкыйть игътибары җитми. Күптән түгел мин «Казан утлары» журналында Азат Ганиевның «Янәшә» исемле хикәясен укыдым. Ул миндә яхшы тәэсир калдырды. Бу яшь авторда хикәяче өчен иң кыйммәтле сыйфат булган кыскалык бар, нечкә күзәтүчәнлек һәм идеяне ачуга төгәл хезмәт итә торган тормыш детальләрен дөрес сайлый белү осталыгы бар. Аңа әле тел байлыгы җитми. Шулай да, образлар теле белән ул укучы күңеленә кирәкле настроениене бирә ала. Бу кыска гына хикәядән без бүгенге чынбарлык өчен хас яшь кеше образларын күрәбез. Алар барыннан да элек азат рухлы, интеллектуаль яктан бай дөньялы, һаман алга – белемгә омтылучы, яшьләргә хас булганча гаять үткен хисле, ялкынлы характерлы кешеләр. Аларда яшәү көче бөркелеп тора. Шунысы характерлы: хикәянең төп героинясы Зилә мәхәббәте уңышсызлыкка очрау хәсрәтеннән үзен-үзе үтерергә теләп, агу эчә. Ләкин тормыш, янәшәсендәге иптәшләре аңа үләргә бирмиләр. Зилә суга ташланып үлмәкче. Ләкин монда да тормыш җиңә. Янәшәсендә аның рухи халәтен аңлаган икенче кеше бар. Бер-берсенең йөрәген, уй-тойгыларын яхшы аңлаган кешеләр янәшә булганда, аларга берни дә куркыныч түгел. Уңышсызлыкка очраган мәхәббәт фаҗигасе дә җиңелә. Художник образы безнең әдәбият өчен яңа, дияр идем. Автор тарафыннан эчке дөньясын тоеп язылган, ышандыра торган образ. Ул үзенең янәшәсендәге Зиләне дөньяга яңача карарга өйрәтә. Сүз белән түгел, эше, хәрәкәтләре белән. Кыз үзенә күптән таныш булган урманны, рәссам караган ноктадан карап, бөтенләй бүтәнчә күрә башлый...

Кыскасы, мондагы саран образларга яшерелгән фикерләрне, идея эчтәлеген шәрехли башласаң, бик күп язарга мөмкин булыр иде. Билгеле, яшь автор үзе боларның барын да уйлап та бетермәгәндер. Ләкин ул художник сизгерлеге белән тормышның характерлы детальләрен дөрес тота алган. Алар җитмәгән урында, кирәк детальләрне үз фантазиясе белән тутырырга да курыкмаган. Сәнгать рөхсәт итә торган дәрәҗәдә шартлылыктан файдаланган. Нәтиҗәдә, әнә шундый үзенчәлекле, сәнгатьне тойган кешенең игътибарын җәлеп итәрлек хикәя килеп чыккан.

Билгеле, аны шедевр дип булмый. Яшь автор язган, әле җитлекмәгән урыннары да булган бу хикәягә бәлки озаклап тукталмаган да булыр идем. Кайбер иптәшләрнең аны бөтенләй игътибарсыз үткәрүләре белән килешәсем килми. Хәтта кайберәүләр аны башка җүнлерәк хикәя юклыктан аптырап кына басылган әйбер дип карыйлар икән. Алай гына да түгел, соңыннан беленде: бу хикәяне, идея әһәмияте юк дип, яшь язучының җыентыгыннан бөтенләй сызып та ташлаганнар икән. Бу хәл мине тагын да сагайта төшә. Хикәянең сыйфат дәрәҗәсен билгели торган критерийларыбыз төгәл микән? «Идея эчтәлеге», «сәнгать дөреслеге», «автор позициясе» кебек төшенчәләрне артык примитивлаштырып аңламыйбызмы икән? Бер яктан хикәягә кытлык дип тавыш күтәргәндә, икенче яктан «Янәшә» кебек хикәяләрне кәрҗингә озату – бу әдәби иҗатка карата хуҗаларча эш итә белмәү түгелме?

Сәнгать әсәрләренә бәя биргәндә, яхшыны яманнан аера белү бик җиңел түгел. Монда әдәби тәнкыйть ярдәме кирәк. Димәк, хикәя жанры бүген бездә беркадәр кыен хәл кичерә икән, моның җитди сәбәпләреннән берсе әдәби тәнкыйтебезнең аңа җитәрлек игътибар итмәвенә кайтып кала. Бу сәбәп, үз чиратында, редакцияләргә дә, хикәя язучыларның үзләренә дә кагыла. Хикәя турында, тәнкыйтьчеләрне төп трибунага бастырып, алар янына язучыларның үзләрен һәм укучылар активын да чакырып, матбугат битләрендә бик җитди сөйләшәсе бар безгә...

**Мирсәй ӘМИР**

*«Казан утлары», 1968 ел, №8*

*Конкурс игълан итәбез!*

# КЫСКАЛЫКТА ОСТАЛЫК

«Редакцияләр хикәя азлыктан зарланалар», «...хикәя әдәбият арсеналындагы иң җитез, иң уңайлы коралларның берсе», – классигыбыз Мирсәй Әмир 48 ел элек әнә шундый сүзләр әйтеп, тулы бер мәкаләсен тикмәгә генә нәкъ менә хикәя жанрына багышламаган инде. Хәзерге «Казан утлары»на хикәяләр, шөкер, килеп тора үзе, ләкин аларның сыйфатын яхшырту максатында иң шәп хикәяләргә ачык конкурс игълан итәбез, җәмәгать!

Хикәяләр 2017 елның азагына кадәр кабул ителә. Аларның саны чикләнми, ә менә күләмнәре чикләнә: стандарт бит (60ар тамгалы 30 юл) саны 15тән артмаска тиеш.

Җиңүчеләрне түбәндәге премияләр көтә:

**I урынга (бер премия) – 10 мең сум.**

**II урынга (ике премия) – 5әр мең сум.**

**III урынга (өч премия) – 3әр мең сум.**

---

# ХИКӘЯ ЯЗА АЛАСЫЗМЫ?

**Бу иҗади бәйгебез хәзер ел саен үткәрелә. Былтыргысының нәтиҗәләре киләсе санда басылачак. Биредә исә быелгысының «ачкыч»ларын, ягъни башламнарын бирәбез. Хикәячекләрнең саны чикләнми. Шәп булса, барысын да басарга тырышырбыз. Әмма аларның һәркайсы бер журнал битенә сыярлык булсын иде.**

**Бәйгедә балалар да, яшьләр дә, өлкәннәр дә катнаша ала.**

**Бер – беренче, өч икенче приз билгеләнде. Алар асыл китаплардан гыйбарәт булыр.**

***

Тук, тук-тук, тук – кинәт ишекне шулай итеп шакулары Гадиләне тетрәндерде. Ул «тук-тук»ларны морзе әлифбасына күчерсәң, нокта, сызык, нокта, ягъни «Р» хәрефе килеп чыга. Рүзәл ишекне гел шулай шакый торган иде бит. Соңгы тапкыр ул... унҗиде ел элек шакыган иде!.. Гадилә ишекне киереп ачып җибәрде.

***

Мәктәпне тәмамлап, өч ел үткәч, мәктәп тирәсен урап кайтмакчы булды Данис. Җәйге ишегалдында беркем дә юк иде. Кинәт бинаның почмак ягыннан мәктәп эте «Шаян» килеп чыкты. Аннан: «Кая киттең, «Шаянкаем?» – дип... партадашы Айсылу пәйда булды. Шул Айсылу да, түгел кебек тә иде ул...

***

Бигрәк сәер кеше инде мин. Гомерем буе бәхет артыннан йөгердем...

***

Әллә язмышым, әллә ялгышым, янәдән юлларымда Гамилне очраттым...

***

Күңелемне моңсу уйлар биләп алды. Алардан күпме генә арынырга теләсәм дә, булдыра алмадым...

***

Өстәл янында тәмләп чәй эчкән Шәмсенур әбине ачыргаланып кычкырган балачага тавышы сискәндереп җибәрде. Ул урыныннан торырга теләде, ләкин...

***

Палатада бөркү һава иде. Тәрәзәдән төшкән кояш нурлары Миләүшәнең битен сыйпады...

***

Җырлый-җырлый бәрәңге чүпләгәндә, Нәфисәнең күзе ниндидер кечкенә тимер кисәгенә төште. Аны ул саклык белән генә кулына алды. Бу – әнисенең югалган тәңкәсе иде...

***

Автобусның ишеге шапылдап ябылды. Юл читендә төшеп калган кыз, ул кузгалып китүгә, җиңел сулап куйды. Ахирәте машина белән каршы алырбыз дигән иде дә, нишләптер күренми әле. Ят төбәктә уңны-сулны аермаган кыз, телефонын эзләп, ашыга-кабалана сумкасын актарырга тотынды. Тик телефон табылмады...

***

– Безнең әткәйне син урладың! Син!

Ләйлә, бу сүзләрне ишеткәч, өстенә кайнар су коелгандай, бөрешеп, кечерәеп калды. Яшүсмер кызның йөрәге читлектәге нәни кошчыктай бәргәләнергә тотынды.

***

Баскыч белән бергә Ришат та түбәнгә очты. Җир белән күк бергә тибрәлгән мизгелдә малайның башыннан: «Беттем!» дигән уй сызылып үтәргә өлгерде.

***

Мөрсәлимә абыстай «Ясин»ны бертөрле көйгә салып укый. Беренчесен генә чыкмый инде ул бүген. Иртәдән үк чакырттылар аны. Ятим калганнан соң тәрбияләп үстергән абыстасын ахирәткә әзерләргә җыенуы. Тик әҗәл дигәнең карчыкны һаман җиңә алмый. Сәбәбе куәтле: ул оныгын көтә, аңа гына әйтәсе васыяте мөһимрәк шул!

***

Шурасу елгасыннан мөлдерәп торган өч чиләк балыкны дуслары белән тотып кереп, аны кыстый-кыстый үрдәк бәбкәләренә ашатканнан соң, Разим тыныч күңел белән шомыртлыкка китте. Бәбкәләрнең... нәфескә булышып, күбенәсен ул әле белми иде.

***

– Мин аны барыбер яшәтмим! – дип, Рафаэль, кайтуга иң беренче эш итеп, апасының әле кичә генә, бармакларын канатып, тырыша-тырыша теккән уенчык аюының башын кисеп ыргытты.

***

Кинәт күктә йолдыз атылды. Сәлим каушап калды һәм теләк теләргә өлгермәде. Шунда ул күккә карап торган кызны күреп алды һәм, янына килеп: «Әллә син дә өлгермәдеңме?» – дип сорады. «Өлгермәдем дә, өлгердем дә, – диде кыз. – Тагын бер атыл!» – дип теләдем мин. Шунда алар бергәләпкөлеп җибәрделәр һәм...

***

Сәрия һич йоклый алмыйча яндагы Истанбул паркына чыкты һәм, сагышка батып әрле-бирле йөри торгач, үзе дә көтмәгәндә әкрен генә җырлап җибәрде: «Кил, кил,

кил, кил, иркәм, кил инде...» Шунда, аның колагына һәм җанына рәхәтлек биреп, бүтән җыр ишетелде: «Көл, көл, көл, көл, иркәм, көл инде!» Җыр иясе янына килеп, ике җилкәсенә кулын да салгач, алар бергәләшеп көлеп җибәрделәр.

***

Бер-бер артлы унбиш квартирны үткәч, уналтынчысында Кыш бабай – Әүхәтне урта яшьләрдәге хатын һәм... тынлык каршы алды. Өстәлгә табын ризыклары һәм шампан шәрабе куелган иде. Аның аптыраулы карашыннан хатын кызарды һәм: «Зинһар, ялгыш уйлый күрмәгез!» – диде.

***

Төшендә ике юл чатында калган килеш уянып китте Идрис. Юл күрсәткеченең бер угына – «Романтика», икенчесенә исә «Банк» дип язылган иде. Торып, шул турыда уйланып йөргәндә, ишек шакыдылар.

***

Чакырсын иде мине Искәндәр Галиәхмәтович танцыга, чакырсын иде! Әллә кайларга, дөнья читенә чакырсын иде – китәр идем. Бер гаебе дә юк, иртәгәдән... Әллә бүгеннән үкме – мин аның укучысы түгел бит инде.

***

– Ә бит син ул көнне башка идең? – егет аптырап кызга текәлде.
– Нинди идем? Беркатлы, аңгыра идемме?
– Юк, ничектер башкача идең...
– Йә, йә, дәвам ит, – кыз аның саен үртәлде, үҗәтләнде.

***

Менә ничә көн инде «Одноклассники» сайтында ул аңа «дуслык»ка керә. Диләрә баштарак, аның кем икәнен төгәл белмәгәч, кире какты, соңыннан исә, чит кеше исеме астында әллә берәр танышы микән, дип тә уйлап куйды. Егет тә тиз генә җиңелә торганнардан түгел иде бугай, кат-кат керде. Инде бөтенләй кермәслек итеп ябып куярга гына торганда, егеттән хәбәр килеп төште.

***

Хәлимә, атнаның соңгы эш көнен төгәлләп, өенә кайтып җиткән иде инде. Подъездга керәм дигәндә генә, искәрмәстән, үзе яшәгән фатирның кухня тәрәзәсенә күзе төште – ник әле анда ут яна?! Эшкә киткәндә якты көн иде, кабызып-нитеп тормады... Соңгы биш елда япа-ялгызы яшәгән ханымның фатирында кем ул анда хуҗа булып йөри?!.

***

Агач ботагыннан куян күзенә тамган яңгыр тамчысы аркасында урманда мәхшәр купты.

***

Егет кызны мәңгегә яратырмын дип уйлады. Язның бер көнендә булган вакыйга чибәркәйне йөрәгеннән мәңгегә сызып ташларга мәҗбүр итте.

***

Кыз көндәлеген югалткач хафага төште. Анда үзе генә белгән сер бар иде.

# САРЫ ЙОРТКА ӘТӘЧ КИЛӘ

## ӘТӘЧ ЕЛЫ АЛДЫННАН

– Ә хәзер без синең теләсә нинди теләгеңне үтибез, – диде Кыш бабай, минем янда туктап, – әйт, җаның ни тели?

– Акчагамы, бушкамы? – дидем мин, кесәдәге кәгазьләрне йомарлап.

– Нинди акча?! Яңа елның могҗизалар кичәсе бүген безнең ресторанда! Әйт, ни телисең?

– Алайса, мин хан булам! – дидем дә киерелеп-җәелеп утырдым.

Шуннан, Кыш бабай өстәлләр янында утыручыларга таба борылып сөрән салды:

– Җәмәгать! Сезнең алда Бөекләрнең бөеге, зирәкләрнең зирәге, кодрәтле хан… исемең ничек әле?

– Вахит Әхмәди.

– Кодрәтле хан – Вахит утыра! Кунаклар баш иеп, хезмәтчеләр тез чүгеп, сәлам бирегез!

Барысы да кушылганча эшләнде. Гүзәл кызлар биеп кенә ризык ташыйлар. Өстәл тулы төрле төстәге шешәләр. Бер-ике тустаган күтәреп каплadым да тозлы балык кабып җибәрдем, исеме ничек әле, теге, япон балыгына кияүгә чыккан урыс балыгы… Селёдка… Әйе, фамилиясе – Иваси. Кабам, сөяге юк. Хан өчен чистартып бирәләр икән. Ә мин аны бармаклар белән тотып, кабыргаларын суырырга яратам. Иң тәмлесе шунда. Әмер биреп бөтенен китерттем дә өстәлдәге гәҗиткә сузып салып суырам гына башыннан койрыгына кадәр. Киттем өстәлдәге шешәләр, кабымлыклар буйлап. Җүнле ризык юк, кече телгә дә йокмый. Аяк тибеп, бәрәңге таптырдым. Кечкенә генә тәлинкәдән кыздырганын чүплим. Кем шулай ашый инде? Мин бит аның табага көеп ябышканын яратам. Иң тәмлесе шунда. Табасын да таптырдым. Пычак белән кырып, шул ук пычак белән авызга тутырам бәрәңгене. Кунаклар көлә, хатын-кызы чыраен сытып читкә борыла. Ачу чыкты, малай, сез кем, мин әйтәм, сез чүп минем алда, вакыты җиткәч белерсез әле минем кем икәнлегемне! Аннан соң боламыкка тотындым. Шулчак тагын искә төште: малай чакта әнинең бәрәңге төйгән тукмагын яларга ярата идем. Иң тәмлесе шунда. Акырып-җикереп, өстәл сугып, аяк тибеп тетмәсен тетәм тегеләрнең, тукмак таптырам. Кунаклар егыла-егыла көлә, хезмәтче кызлар еларга да, көләргә дә белмичә тыз-быз килә, Кар кызы да шүрләп кенә пырхылдап алгалый, ә Кыш бабай үз башына үзе суга-суга елый:

– Белгән булсам… белгән булсам… якын да килмәс идем… – ди.

Мин турысын сөйләшергә яратам. Кыш бабайның якасыннан тотып алдым. Син нәрсә, мин әйтәм, чүпрәк сакал, сүс мыек, мин бит тарихта калачак бөек, даһи Әхмәтхан Вахит…

– Вахитхан Әхмәди… – дип төзәтте күрше сәкедән берәү куркып кына.

– Барыбер хан!

Дер селкетәм, малай, Кыш бабайны. Тегенең кәптәчие кыңгырайды, сакал-мыеклары коела башлады. Ә минем сүз бер генә:

– Тукмак кайда?!

– Пеш…шек…чедә! Ты…гыл…гырры! – ди Кыш бабай асылынып төшкән мыеклары арасыннан.

– Сикереп торган идем, ак толымлы хур кызына күзем төште... Кар кызына… Әйе, кыр казына… Андыйларны болай гына ычкындыраммы соң мин! Китереп кыстым, куркудан ачылган авызыннан телен суырып ала яздым. Иң тәмлесе шунда.

– Бүген ханбикә итәм мин сине, – дим, ә хәзергә өстәлгә менеп «бүксә биюе» күрсәтерсең.

– Чаптым пешекчеләр янына. Тегеләр «Әтәч килә!» дип кычкырышып, тараканнар шикелле, кая качарга белмиләр. Таптым тукмакны. «Бүксә биюе» карап, балачакны искә төшереп, елый-елый тукмак ялап утырам, малай... Әллә кайдан тагын тап-таза өч пешекче килеп керде, нигәдер ак халатларын пәлтә өстеннән кигәннәр. Килеп керүләре булды, кулга энә дә кадап алдылар. Күтәреп алып чыгып барганнарын хәтерлим, калганы истә юк…

– Хан булганчы кем идең соң? – дип сорадылар күрше сәкедән.

– Язучы мин. Вахит Әхмәди.

– Нәрсә язасың?

– Бозык кеше язмалары…

– Тумыштан шулаймы, былтырдан гынамы?

– Мин мондый түгел идем… Атаклы булгач, вак-төяк шагыйрьләр белән шешәсенә атланып эчәргә туры килә. Ә үзең кем?

– Миңа күп сөйләргә ярамый, өянәгем кузгала...

– Ничек итеп? Ятып тәгәрисеңме, үрле-кырлы сикерәсеңме?

– Юк, сызгырам да күз кысам, сызгырам да күз кысам. Барлас Шәмсин мин, бәлки, телевизордан күргәнең бардыр…

– Телевизор карарга вакыт юк минем. Роман язам, гасыр романы…

– Шамил Шәлимовны беләсеңме?

– Белмим, аның белән сугышканым юк әле.

– Шул Шәлимов янына барган идем, тирләп-пешеп китап укып яталар икән. Шакып карыйм, ачмыйлар. Тибә башлагач, ачтылар. Китабының битләре тузгыган, иң кызык җиренә җиткәннәрие, ахры, бөтереп алдылар да, баскычтан тәгәрәттеләр. Очып чыктым урамга, миңгерәүләнеп. Очраган бер кешегә сызгырам да күз кысам, башым каты бәрелгән, ахры. Ике милиционер килә иде, аларга да сызгырып күз кыстым. Алып китәбез дигәннәр иде, беләгемне бөгеп күрсәттем. Озатып куйдылар, шушы бүлмәгә кадәр. Алар бит сыбызгы бирмәсәң сызгыра да белмиләр…

Уртадагы җәелеп-җыела торган урынга аксап-туксап тагын берәү кереп ятты:

– Йорт иясе, малай, ишектә...

– Аксакларга монда урын юк, – диде Әхмәди, – ахмакларга да җитми… Бәрәч! Хәниф Гарипов бит бу! Хәниф абый, якташ, ничек килеп эләктең монда?

Хәниф абыйсы кыскача сөйләде. Вахит теркәп барды, язып чыгарыр әле. Язмаса, Шәмсин сөйләр әле. Хәер, исән-сау моннан чыксам, үзем дә язам мин аны.

**Рәниф ШӘРИПОВ**

**Редакциядән.** *2010-2012 елларда «Печән базары» дигән сатирик әсәрләр конкурсы үткәргән идек. «Конкурс тәмам, әмма «Печән базары» ябылмый, рубрика булып кала», дигән сүзебезне онытмыйча, шушы «әтәч»ен җибәргән Рәнифкә – рәхмәт! Базарыбыз сездән әсәрләр көтә, кадерле авторлар һәм укучылар!*

### САДРИ МАКСУДИГА – ҺӘЙКӘЛ

Казанның Чистай һәм Әпсәләмов урамнары чатындагы Истанбул паркында төрек-татар дәүләт һәм иҗтимагый-сәяси эшлеклесе, академик, философ, заманында Төркиядә Ататөрекнең киңәшчесе булган Садри Максудига һәйкәл (авторы – сынчы Асия Миңнуллина) ачылды. Аны ачу тантанасында ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов, Төркия Республикасы Премьер-министры Бинали Йылдырым, ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев һәм башка рәсми затлар катнашты.

### ЭШКУАРЛАР ҖЫЕНЫ

Казанда Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты канаты астында Татарстанның эшлекле хезмәттәшләре җыены уздырылды. Анда эшкуарлар икътисади багланышларны ныгыту, милләтебезгә бергәләп хезмәт итү турында сөйләштеләр. Җыенда Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов катнашты һәм чыгыш ясады.

### «МИНТИМЕР ШӘЙМИЕВ» КИТАБЫН ТӘКЪДИМ ИТҮ

Казан Кремленең вәкиллекле корпусында Мәскәүдәге «Молодая гвардия» нәшриятының «Жизнь замечательных людей» сериясеннән дөнья күргән, «Минтимер Шәймиев» дип аталган китапны тәкъдим итү булды. Шушындый ук чара Мәскәүдә, Татарстан вәкиллеге йортында узган иде инде. Тантананы Татарстан Республикасы Президенты аппараты җитәкчесе Әсгать Сәфәров ачты һәм алып барды. Дәүләт эшлеклеләре, сәясәтчеләр, әдәбият-сәнгать әһелләре, журналистлар, галимнәр алдында әлеге проектның идея авторы Валентин Юркин, китапның авторы Нурсөя Шәйдуллина (авторларның икенчесе Игорь Цыбульский, авырып китү сәбәпле, бу чарада катнаша алмады) чыгыш ясады. Тантанада Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты директоры Рафаил Хәкимов, галим Индус Таһиров, Казан шәһәре хакиме урынбасары булып эшләгән Людмила Андреева, Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының баш режиссёры Фәрит Бикчәнтәев, «Казанские ведомости» газетасының баш мөхәррире Венера Якупова хатирә-истәлекләре, уй-фикерләре белән уртаклашты. Алар китапка югары бәя бирде, аның укырга кызыклы, мавыктыргыч, бай мәгълүматлы булуын әйтте.

Чарада Татарстан Республикасының Беренче Президенты, ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев үзе дә катнашты, сорауларга җавап бирде.

### ТАТАР ТЕАТРЫНА – 110 ЕЛ

Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында татар театрының 110 еллыгы билгеләп үтелде. Ике көн барган бу бәйрәмдә спектакльләрдән өзекләр, театр артистлары катнашында концерт күрсәтелде. Театр әһелләрен ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев котлады.

### ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕНЕҢ ТУКАЙ КЛУБЫНДА

Татарстанның халык шагыйре, Россиянең М.Горький, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты Сибгат Хәкимнең тууына 105 ел тулу уңаеннан «Юксыну» дип аталган әдәби-музыкаль кичә узды. Анда ТР Дәүләт Советының Мәдәният, мәгариф, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиев, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов, Татарстанның халык шагыйрьләре Ренат Харис, Рәдиф Гаташ, шагыйрь Наил Касыймов, Татарстанның халык артисты, шагыйрьнең авылдашы Луара Шакирҗан чыгыш ясады. Кичәдә Татарстанның халык артистлары Рафаэль Сәхәбиев, Римма Ибраһимова, Резеда Галимова, Георгий Ибушев, халыкара конкурслар лауреаты Энҗе Шәймурзина С.Хәким сүзләренә язылган җырларны башкарды. Кичәне К.Тинчурин театры артистлары Резедә Сәләхова һәм Артём Пискунов алып барды.

***

Татар әдәбияты классигы Габдрахман Әпсәләмовның тууына 105 ел тулу уңаеннан искә алу кичәсе үткәрелде. Анда әдип турында истәлек-хатирәләр яңартылды, тарихи фоторәсемнәр тәкъдим ителде. Кичәдә Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов, галим, әдәби тәнкыйтьче Әлфәт Закирҗанов, Г.Әпсәләмовның оныгы, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы Альбина Әпсәләмова, республикабызның сәнгать осталары катнашты.

***

Мәскәүдә яшәп иҗат итүче язучы Рауль Мир-Хәйдәровка 75 яшь тулу уңаеннан әдәби-музыкаль кичә үткәрелде. ТР Дәүләт Советының Мәдәният, мәгариф, фән һәм милли

мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиев ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиевнең һәм үзенең котлавын ирештерде. Бәйрәмдәрны ТР мәдәният министры урынбасары Эльвира Камалова, Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе урынбасары Илдар Миргалимов, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов, Татарстанның халык шагыйрьләре Ренат Харис, Равил Фәйзуллин, язучы-прозаик Ринат Мөхәммәдиев тә котлады. Кичәне язучы-прозаик Камил Кәримов алып барды.

## ФӘННИ-ГАМӘЛИ КОНФЕРЕНЦИЯ

Уфада, Башкорт дәүләт университетында, Татарстанның халык шагыйре, ТР Дәүләт Советының Мәдәният, мәгариф, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиевкә 70 яшь тулу уңаеннан «Татар филологиясенең көнүзәк проблемалары» дигән темага Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе булып узды. Анда Башкорт дәүләт университеты ректоры Николай Морозкин, республика парламенты җитәкчесе урынбасары Йомабикә Ильясова, Башкортстан Фәннәр академиясе президенты Әлфис Гаязов, Башкорт дәүләт университетының татар филологиясе һәм мәдәнияте кафедрасы галиме, «Рамазан» төрки агарту үзәге рәисе Марат Шәрипов чыгыш ясады. Алар Разил Вәлиевнең иҗатына һәм иҗтимагый-сәяси эшчәнлегенә югары бәя бирде. Конференциядә Казаннан Разил Вәлиев үзе, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Илфак Ибраһимов (шагыйрь Мөхәммәт Мирза), Казан, Чаллы галимнәре катнашты һәм чыгыш ясады. Кунаклар Башкортстан Республикасы Милли музеенда, Милли китапханәсендә булдылар. Китапханәдә «Разил Вәлиевнең тормыш юлы һәм иҗаты» дигән күргәзмә белән таныштылар.

## ӘДӘБИ ПРЕМИЯЛӘР ТАПШЫРЫЛДЫ

Спас районы Көек авылы мәдәният йортында үткәрелгән тантанада Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Рәмис Аймәт Абдулла Алиш премиясенең быелгы лауреатын игълан итте. Ул – Татарстанның халык артисты, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы Хәлим Җәләй. Каләмдәшебез бу олуг бүләккә 2015 елда Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан «Әкиятләр» китабы өчен лаек булды. Тантанада Казаннан кайткан кунаклар – А.Алиш премиясе лауреатлары Әнәс Хәсәнов, Фәйрүзә Мөслимова, Вакыйф Нуриев, Хәбир Ибраһим (Ахир), язучы Индус Сирматов, Алишның туганы Гөлшат Сөнкишева, Татарстан Язучылар берлегенең матбугат үзәге җитәкчесе Нәгыйм Шаһи чыгыш ясады.

***

Актаныш Мәдәният йортында Гамил Афзал премиясен тапшыру тантанасы булды. Быел әлеге күркәм бүләккә «Юморкалар» китабы («Ихлас» нәшрияты) һәм юмор-сатира өлкәсендәге хезмәтләре өчен язучы-юморист Ләбиб Лерон лаек булды. Премияне Актаныш муниципаль районы башлыгы Фаил Камаев белән Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов тапшырды.

## БӘЙГЕ

Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында «Яңа татар пьесасы – 2016» конкурсына йомгак ясалды. Беренче премиягә Илгиз Зәйниевнең (Җамалетдин) «Борһан йорты», икенче премиягә Айгөл Әхмәтгалиеваның (Фәтхи) «Сагынган чакларымда», өченче премиягә Зөлфәт Хәкимнең (Илхан Казанлы) «Тәрәзәдә һаман ут яна» пьесалары лаек булды. Бәйгенең «Татар театрының 110 еллыгына багышланган пьеса» номинациясендә – Илгиз Зәйниевнең (Мәгарәчеләр) «Җәүдәт белән Зөбәрҗәт», «Стилистик эзләнү өчен» номинациясендә – Рәмис Латыйповның (Шурасу) «Кит!.. Китмә!», «Балалар өчен пьеса» номинациясендә Нәфисә Исмәгыйлеваның (Агач) «Тамчылар» пьесалары җиңү яулады. Ркаил Зәйдулла (Субаш) «Нәгыймә» пьесасы белән ТР Мәдәният министрлыгының махсус бүләгенә лаек булды. Артур Шәйдуллинның (Марсель Абзалов) «Кайтыр юлга чыккан идем», Айсылу Хафизованың (Кол Шәрифә) «Прима», Нәфисә Исмәгыйлеваның (Сын) «Эх, җаныем» әсәрләре жюриның махсус бүләкләренә ия булды.

## КОТЛЫЙБЫЗ!

ТР Президенты «Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт премияләрен бирү турында»гы Указга кул куйды. Олуг бүләккә лаек булучылар арасында «Борынгы заманнардан татарлар тарихы»ның җиде томлык басмасын әзерләүдә катнашкан каләмдәшләребез Искәндәр Гыйләҗев һәм Булат Хәмидуллин да бар. Әлеге премиягә Гаяз Исхакыйның унбиш томлыгын әзерләп бастырган Зөфәр Рәмиев, Лена Гайнанова, Фатыйма Ибраһимова (вафатыннан соң), Зөфәр Мөхәммәтшин да ия булды.

***

Россия Язучылар берлеге һәм «Бийский вестник» журналы Татарстанның халык шагыйре Ренат Харисны (Ренат Мәгъсүм улы Харисов) Россия халыклары әдәбиятын үстерүгә керткән зур өлеше өчен Василий Шукшин медале белән бүләкләде.

2016 елның 24 декабрендә 80нче яшендә Казанда шагыйрь һәм тәрҗемәче, 1969 елдан СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Г.Державин исемендәге әдәби премия лауреаты **Беляев Николай Николаевич** вафат булды.

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Слово главного редактора И. ИБРАГИМОВА.*
*«Проза и поэзия»: Р.БАТУЛЛА. « Первый Президент»;*
*Роман-новелла М.ГАЛИЕВА «Да пусть живёт!», рассказ Х.ИСМАГИЛОВА;*
*стихи Р.ВАЛИЕВА, ЗУЛЬФАТА, А.ХАЛИМА, Р.КУРБАНА, Р.МУХАМЕТШИНА.*
*«100-я страница»: Г.МУРАТ. «От первого парня на селе до Первого Президента».*
*«Новые имена»: стихи Л.ГАБДРАХМАНОВОЙ.*
*«Наши юбиляры»: статьи – Ф.САФИНА, посвящённая 70-летию со дня рождения ЗУЛЬФАТА; Р.СВЕРИГИНА, посвящённая 75-летию А.ХАЛИМА; Л.ГАЛИЕВОЙ, посвящённая 70-летию Р.ВАЛИЕВА.*
*Интервью Р.ЮНУСА с доктором исторических наук Д.ИСХАКОВЫМ.*
*«Тукай и татарская литература»: рубрику ведёт Р.РАХМАН.*
*«Встречая юбилей»: М.АМИР. «Не хватает внимания!»*
*«Сенной базар»: юмористический рассказ Р.ШАРИПОВА.*
*Из фотоархива журнала.*
*Дневник общественно-культурной жизни.*
*На наших обложках: Казань. Кремль. Фото Рамиля Галиева;*
*«Зимняя тропинка». Картина Рема Сайфульмулюкова.*

# IN THIS ISSUE:

*I.IBRAHIMOV, Chief Editor's word.*
*«Prose and poetry»: R.BATULLA «The First President».*
*Romance-novel by M.GALIEV «Let him live!», story by H.ISMAGILOVA.*
*Poems by R.VALIEV, ZULFAT, A.HALIM, R.KURBAN, R.MUHAMETSHIN.*
*«100 th Page»: G.MURAT . «From the first guy of the village to the First President».*
*«New names»: poems by L.GABDRAHMANOVA.*
*«Our anniversaries»: articles by F.SAFIN dedicated to the 70th anniversary of ZULFAT;*
*R.SVERIGIN dedicated to the 75th anniversary of A.HALIM;*
*L.GALIEVA dedicated to the 70th anniversary of R.VALIEV.*
*Interview by R.YUNUS with the Doctor of Historical Sciences D.ISHAKOV.*
*«Tukai and Tatar literature»: section is led by R.RAHMAN.*
*«Meeting the anniversary»: M.AMIR. «The lack of attention!».*
*«Hay market»: humorous story by R.SHARIPOV.*
*From the photo archives of the magazine.*
*Diary of the social-cultural life.*
*On our covers: Kazan. Kremlin. Photo by Ramil Galiev;*
*«The winter path». Picture of Rem Saifulmulukov.*

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* Казан. Кремль. *Рамил Галиев фотосы.*

*Тышлыкның дүртенче битендә:* «Кышкы сукмак».
*Рем Сәйфелмөлеков картинасы.*